# Казан утлары

4

АПРЕЛЬ

1969

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

4

АПРЕЛЬ
1969

## БУ САНДА:

Ф. А. ТАБЕЕВ. Даһи Ленинча яшәргә һәм көрәшергә . . . . . . . . . . . . 3

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

В. В. МАЯКОВСКИЙ. М. Садри тәрҗемәсе. . . . 12
А. МӨСЛИМОВ. Ленин — студент. . . . . . . . 13
А. БАТЫРОВ. Өч каен янындагы өй. . . . . . . 23
Т. ФӘТТАХ. Күңелгә якын кала. Шигырь. . . . . 25
Алтын таң. Ойрот халык легендасы. . . . . 26
Л. СӘЙФУЛЛИНА. Ленин турында мужиклар хикәяте. . . . . . . . . . . . . . . . . . 32

ПОВЕСТЬ, ПОЭМА, ШИГЫРЬЛӘР

Ә. МАЛИКОВ. Чигүле кульяулык. Поэма. . . . 37
Ф. ХӨСНИ. Гыйльменисә. Повесть. . . . . . . 44
Ш. МАННУР. Диңгез дәфтәреннән. Шигырьләр циклы. . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Ф. ШӘФИГУЛЛИН. Мәңгелек ут; Төнге күктән; Кызык хәл; Диңгез; Эш коткара. Шигырьләр. 104
И. ТУКТАР. Әйтемнәр. . . . . . . . . . . . . 106

ПУБЛИЦИСТИКА

Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Без һәрвакыт Ленин белән. . . 108

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Л. САФАРОВ. Кулларын кучерә килеп; Ник читләргә кылыч күтәрик без; Музей; Килә бераү; Шундыймын шул; Егермене узгач; Бозлар китә, кызлар китә. Шигырьләр. . . . . . . . . 120

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Г. ГАЛИЕВ. Ак басу. Очерк. . . . . . . . . . 123

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Н. ИСӘНБӘТ. Тукайның әлегәчә игълан ителмәгән бер шигыре. . . . . . . . . . . . . . 128
Н. ЛАИСОВ. Тукай лирикасында элегик мотивлар. 133

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


Р. МОСТАФИН. Үз жырың, үз көең булсын. . . . 141
Р. ШӘМСЕТДИНОВА. Ялкын кебекләр. . . . . 156


ЯҢА КИТАПЛАР


К. МОСТАФИНА. Шиһабетдин Мәрҗани. . . . . 167
Р. ГАЛӘВИН. Сары яфраклар коела. . . . . . . 167


ӘДӘБИ МИРАСЫБЫЗДАН


Ә. НӘҖИП. Хикмәт энҗеләре. . . . . . . . . 169


УКУЧЫЛАР СОРАВЫ БУЕНЧА


Ф. ВӘЛИЕВ. Мәһабәт биналар һәм алардагы ямь. 174


БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ


З. ГОМӘРОВА. Исем бирделәр; Куян артыннан; Бер һәм биш; Битлек. . . . . . . . . . . 181


ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ


Ф. ЯРУЛЛИН. Гыйльминур карчык курортта. Хикәя. 183
Р. ИСАЕВ. Күрше киңәше. Янчык югалгач. Хикәя. . 187
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. . . . . . . 189


Редакциягә кергән
кульязмалар
кире кайтарылмый


Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*



Баш редактор Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Гариз Мөхәммәтшин, Рафикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.



Производствога бирелде 14/II-1969 ел. Басарга кул куелды 3/IV-1969 ел. ПФ 09007.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 85146 экз.
Заказ В-84. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1969 ел.

**Ф. А. Табеев,**

партия өлкә комитетының
беренче секретаре

# ДАҺИ ЛЕНИНЧА ЯШӘРГӘ ҺӘМ КӨРӘШЕРГӘ

Тагын бер елдан, 1970 елның 22 апрелендә, Коммунистлар партиясе, совет халкы, җир шарының барлык хезмәт ияләре Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулуны билгеләп үтәчәкләр. Хәзерге заман тарихы өчен бу — тиңдәшсез олы һәм күркәм бәйрәм. Ленинның бөек идеяләре һәм ул башкарган эшләр үлемсез булган шикелле, даһи Ильичның исеме дә чын мәгънәсендә мәңгелек һәм җиңүчән, чөнки, Владимир Маяковский бик төгәл һәм образлы итеп әйткәнчә, «Ленин хәзер дә барлык терелләрдән дә тererәк».

Совет дәүләтенең барлык казанышлары даһи Ленинның үлемсез исеме белән аерылгысыз бәйле. Без үзебезнең зур хокукларыбыз — хезмәткә, ял итүгә һәм белем алуга хокукыбыз өчен бөек Ильичка, ул төзегән һәм көрәшләрдә чыныктырган Коммунистлар партиясенә, дөньяда беренче итеп нигезен ул салган Совет дәүләтенә бурычлыбыз. Тормышыбызда иң ачык һәм гүзәл максат — коммунизм төзү максаты белән яшәвебез өчен, шул максатка ышанычлы адымнар белән бару бәхетенә ирешүебез өчен без аңа, сөекле Ильичка, һәм барлык җиңүләребезне оештыручы Коммунистлар партиясенә бурычлы.

«Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулуга хәзерлек» турында КПСС Үзәк Комитеты карарында В. И. Ленинның дөнья-күләм әһәмияткә ия тарихи хезмәтләре эзлекле һәм бик тулы күрсәтелгән. Владимир Ильич — Маркс һәм Энгельс тәгълиматын бөек дәвам иттерүче, пролетар революциянең һәм җәмгыятьне социаль үзгәртеп коруның даһи теоретигы. Аның хезмәтләрендә марксизмның барлык состав өлешләре — философия, политик экономия, фәнни коммунизм тәгълиматы тагын да баетылды һәм конкретлаштырылды. Ленинизм — яңа тарихи эпоханың, империализм һәм пролетар революцияләр, кешелек дөньясының капитализмнан социализмга күчү һәм коммунистик җәмгыять төзү эпохасының марксизмы ул.

Ленин тарихка пролетар революциянең бөек юлбашчысы булып, яңа типтагы партияне — большевиклар партиясен төзүче һәм аның җитәкчесе булып керде. Ленин дөньяда беренче социалистик дәүләтне — эшчеләр һәм крестьяннар дәүләтен төзүче һәм аның җитәкчесе булды.

Ленин илебездә социализм төзү планын эшләде. Владимир Ильич фәннең һәм техниканың соңгы сүзе буенча төзелгән эре промышлен-

ностьны үстерүне социализмның бердәнбер материаль нигезе дип карады. Ленин атаклы кооператив планын эшләде. Бу планны тормышка ашыру крестьяннарның гасырлар буе килгән артталыгын бетерүгә, авылда нык экономик база булдыруга, авыл хуҗалыгында гаять тирән социалистик үзгәртеп корулар эшләргә мөмкинлек бирде. Ленин социализм төзүне культура революциясе ясауга, демократияне үстерүгә аерылгысыз бәйләде. Ленинның даһилыгы милли мәсьәләне теоретик һәм практик хәл итте.

Советлар Союзында социализм тулысынча һәм тәмам җиңде. Илебездәге барлык милләтләр һәм халыклар партиянең ленинчыл политикасы аларга яшәү көче бирүен тойдылар. Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының төзелүе һәм аның чәчәк атуы — КПСС политикасының нәтиҗәлелеген раслый торган күп санлы мисалларның берсе.

Татарстан хезмәт ияләре өчен 1970 ел икеләтә юбилей елы — чөнки шул елның июнь аенда республикабыз төзелүгә ярты гасыр була. Татарстан АССРны төзү турындагы Декретка бөек якташыбыз Владимир Ильичның кул куйган булуы безнең күңелләргә иксез-чиксез горурлык тойгысы өсти. Хәзерге Татарстан бик нык алга киткән промышленность һәм авыл хуҗалыгы булган, тоташтан укый-яза белүчеләр яши торган, фән һәм техника прогрессы югары дәрәҗәгә җиткән республика ул. Без, дүрт елга республикасы кешеләре — Совет Татарстаны коммунистлары, барлык хезмәт ияләре — даһи Ленинның революцион чыныгу алуы Казанда, университет студенты чагында булу белән хаклы горурланабыз. Ул патша самодержавиесенә каршы аяусыз көрәш юлын бездә башлады. В. И. Ленин соңрак та безнең якларда революцион хәрәкәт барышын һәм үсешен игътибар белән күзәтте. Ул Татарстан автономиясен формалаштыруның күп мәсьәләләрен турыдан-туры үзе хәл итте. Шуңа күрә Татарстан АССР Советларының I Учредительный съезды 1920 елның сентябрендә сөекле юлбашчыга беренче котлау сүзен җибәрде.

Безнең партия, безнең халкыбыз Ленин васыятьләрен уңышлы тормышка ашыра. Совет власте елларында илдә куәтле индустрия булдырылды, авыл хуҗалыгыбыз гаять алга китте. Советлар Союзы үз үрнәге белән иң алдынгы һәм прогрессив иҗтимагый строй булган социализмның өстенлекләрен һәм мөмкинлекләрен бөтен дөнья алдында ышандырырлык итеп күрсәтә. КПССның XXIII съезды Директиваларында, мәсәлән, илебездә промышленность производствосы күләмен биш ел эчендә 47—50 процентка үстерү күздә тотылды. Шуннан соң планга кертелгән үзгәрешләр нигезендә продукция җитештерүне 53 процентка арттыру билгеләнде. Бу промышленность продукциясен ел саен уртача чама белән 8,9 процентка арттыру дигән сүз. Бишьеллыкның өч елы дәвамында промышленность производствосының күләме Директиваларда каралган 26—27 процент урынына, 29 процентган артыгракка үсте дә инде.

Халык хуҗалыгында эшләр елдан-ел яхшыра бара. Бишьеллыкның өч елында милли доход 23 процентка артты. Болар бөтенесе илебездә экономика үсешенең яңа үрләргә күтәрелүен ачык дәлилли.

Капиталь төзелештә дә алга китеш бәхәссез. Хәзер республикабызда төзелешкә һәр елны 600 миллион сум акча тотылуны гына әйтү дә җитә. Бу — моннан ун ел элек булган расходлардан ике тапкыр диярлек күбрәк.

Авыл хуҗалыгы эшчәннәренең дә җиңүләре һәркемне куандырырлык. Узган елны колхоз-совхоз басуларының фидакарьләре Ватаныбыз амбарларына 92 миллион пот ашлык салдылар. Татарстанның бөтен тарихында мондый зур җиңүгә ирешелгәне юк иде әле. Үтелгән юлга күз салсак, без республикабызның дәүләткә ел саен 40—45 миллион

пот ашлык тапшырып барганлыгын күрәбез. Соңгы 6—8 ел чамасы вакыт эчендә, партиябезнең зирәк политикасы нәтиҗәсендә, авыл хуҗалыгы хезмәт ияләренең фидакарь хезмәте бу күрсәткечне ике тапкырга арттырды. Республика колхозлары һәм совхозлары былтыр бөртекле культураларның иң югары уңышын үстерделәр. Татарстан буенча һәр гектардан уртача 15,5 центнер, шул исәптән уҗым бодаеннан — 17,4 центнер, сабан бодаеннан — 16,7 центнер, борчактан — 19,3 центнер, карабодайдан — 11,7 центнер уңыш җыеп алынды. Бәрәңгенең һәм шикәр чөгендеренең дә уңышы яхшы булды. Бу культураларны дәүләткә сату планы уңышлы үтәлде.

Республиканың терлекчеләре дә бик күркәм нәтиҗәләр яуладылар. Продукцияне җитештерү сизелерлек артты. Дәүләткә ит, сөт, йомырка һәм йон сату планнары уңышлы үтәлде.

Экономикадагы җитди уңышлар һәм милли доходның артуы нәтиҗәсендә, хезмәт ияләренең материаль хәле ныгый, көнкүреш дәрәҗәсе күтәрелә һәм культурасы үсә. Авыл хуҗалыгы работниклары хезмәтенә түләүдә зур үзгәрешләр булды. Хәзер барлык колхозлар һәм совхозлар хезмәткә гарантияләнгән түләүгә күчәләр. Бер колхозчының айлык эш хакы 1967 елда уртача 52 сум булды яки 1965 елгы белән чагыштырганда 1,4 тапкырга артты. 1968 елда исә бу сумма тагы да күбрәк.

Мондый үсешкә һәм күтәрелешкә хуҗалыкка яңача җитәкчелек итү нәтиҗәсендә, производствоны планлаштыру һәм стимуллаштыруда яңа система куллану белән, партия оешмаларының, советларның, профсоюз һәм комсомол оешмаларының актив һәм максатка юнәлешле эше белән, республикабыздагы барлык хезмәт ияләренең инициативалы һәм фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә ирешелде.

В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу көнен каршыларга хәзерләнү чорында идеология эшен, масса-политик эшне тагын да күтәрү, В. И. Ленинның идея мирасын пропагандалауны көчәйтү юнәлешендә аеруча зур тырышлык белән эшләргә тиешбез. Ленинның бөек һәм изге васыятьләрен гамәлгә ашыру өчен партиябез һәм совет халкы алып бара торган көрәшне һәрьяклап күрсәтү политик эшнең төп эчтәлеген билгеләргә тиеш. Тормышны революцион үзгәртеп кору процессында марксизм-ленинизмның әһәмиятен, бөек фикер иясе, революционер, Коммунистлар партиясе һәм кешелек тарихында беренче социалистик дәүләтне төзүче, халыкара коммунистик һәм эшчеләр хәрәкәтенең юлбашчысы буларак, Ленинның тарихи ролен тирәнтен күрсәтергә кирәк.

Хезмәт ияләренә марксистик-ленинчыл белемнәр бирү аларны идея ягыннан тәрбияләүдә беренче дәрәҗәдә әһәмиятле урын тота. Агымдагы уку елында партия укуларының төрле буыннарында 190 мең кеше, шул исәптән 132 мең коммунист, ягъни бөтен өлкә партия оешмасының 50 проценты марксизм-ленинизм теориясен өйрәнә. Шул кадәресен дә әйтергә кирәк, соңгы елларда занятиеләрнең эчтәлеге, оештырылуы һәм методлары камилләштерелә, аларның идея дәрәҗәсе күтәрелә.

Тормыш тәҗрибәсеннән ачык аңлашылганча, без ирешелгәннәр белән генә канәгатьләнә алмыйбыз. Политик пропагандага карата таләпләр өзлексез арта. Чынбарлык, көндәлек тормыш практикасы бу өлкәдә дә яңадан-яңа бурычлар куя. В. И. Ленин өйрәткәнчә, миллионнарның аңында социалистик идеология берниндн тоткарлыксыз, үзеннән-үзе, шома гына түгел, бәлки буржуаз идеологиягә каршы, социализмга дошман булган карашларга, теорияләргә, идеяләргә каршы көрәштә ныгып урнаша. Бу исә идея тәрбиясенең барлык ысулларын һәр коммуниста һәм совет кешесендә идея ягыннан ышанганлык, совет патриотизмы һәм пролетар интернационализм хисләрен ныгытуга, идея

ягыннан какшамаслыкны һәм буржуаз йогынтының теләсә нинди формаларына каршы тора белүне ныгытуга юнәлдерелергә тиеш диген сүз.

Безнең өчен иң әһәмиятлесе — укуның идея дәрәҗәсен һәм нәтиҗәлелеген күтәрү. Ленин мирасын абстракт өйрәнү һәм пропагандалау түгел, бәлки аны партиянең һәм совет халкының агымдагы бурычларына аерылгысыз бәйли белү таләп ителә.

Ленин мирасын пропагандалауның нәтиҗәлелеге идеология работникларын теоретик әзерләүгә, аларның пропагандистлык һәм лекторлык осталыгына бик нык бәйләнгән. Партия оешмалары аларны идеология эшенең ленинчыл принциплары белән һәрвакыт коралландырырга бурычлылар.

Ленин юбилеена эшлекле әзерлек барышында матбугатка, радиотапшыруларга һәм телевидениегә мактаулы һәм бик җаваплы роль туры килә. Алар бу юнәлештә мәгълүм дәрәҗәдә эш башкардылар һәм башкаралар да инде.

Татарстан китап нәшрияты алдындагы бурычлар да бик җаваплы. Агымдагы елда В. И. Ленин әсәрләренең берничә томын, ленинизмның проблемалы мәсьәләләре буенча китапларны, Ленинга багышланган матур әдәбият әсәрләрен татар телендә күпләп чыгарасы бар.

Республикабыз яшьләре Ленин юбилеен каршылауга зур дәрт һәм ашкыну белән әзерләнәләр. В. И. Ленин васыятьләрен үтәп, комсомол партия җитәкчелегендә өлкән буын юлыннан бара, революцион традицияләрне дәвам иттерә, җәмгыятебезнең материаль һәм рухи байлыкларын ишәйтү эшенә үзеннән лаеклы өлеш кертә. Комсомол, ярты гасырлык героик юл узып, яшьләр өчен җәмгыять тормышының, политик чыныгуның, коммунистик тәрбиянең бик яхшы мәктәбенә әверелде.

Партия оешмалары, ВЛКСМ өлкә комитеты һәм комсомолның җирле комитетлары комсомолларны, барлык яшьләрне ленинизмга тугрылык рухында, партиябезнең бөек идеаллары өчен фидакарь көрәш рухында тәрбияләүгә аеруча игътибар бирергә тиешләр. Өлкән буын вәкилләренең яшьләр белән очрашуларын үткәрү, Ленин исеменә бәйләнешле урыннарга экскурсияләр һәм походлар оештыру, Ленин һәйкәлләрен һәм туганнар каберлекләрен кадерләп саклау, үз оешмаңның тарихын өйрәнү, совет халкының героик тарихына багышланган китаплар һәм фильмнар буенча укучылар конференцияләре үткәрү кебек иҗади эшләр Ленин юбилеен лаеклы каршылау буенча үткәрелә торган чаралар комплексына иң беренче урын алып керә алалар. Яшь кешеләрдә Ленинча яшәргә һәм көрәшергә әзер тору, шундый сәләт тәрбияләү — комсомолның зур һәм катлаулы бурычы.

Даһи юлбашчыбызның тууына 100 ел тулуга әзерлек уңае белән фән, югары һәм махсус урта мәктәп халык мәгарифе работниклары алдына аеруча җаваплы бурычлар куела.

Совет мәктәбенең төп идея нигезләрен В. И. Ленин салды. Комсомолның өченче съездында ул сөйләгән атаклы речь, коммунистик тәрбиянең асылы, мәктәпнең социаль функцияләре, укучыларга белем һәм тәрбия бирү методлары, яшьләр оешмаларының роле һәм урыны турындагы проблемалар кебек мөһим проблемаларның идея-теоретик нигезе буларак, совет педагогикасының алтын фондына керде.

Совет мәктәбенең алдагы чорга эш программасы укытучыларның Бөтенсоюз съездына КПСС Үзәк Комитеты, СССР Верховный Советы Президиумы һәм СССР Министрлар Советы котлавында, КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре Л. И. Брежневның шул съездда сөйләгән речендә бик ачык билгеләнде. Бу программа мәктәпнең тормышка аяк басучы һәр кешегә иҗтимагый һәм фәнни-техник прогрессның хәзерге таләпләренә туры килерлек һәм тулы кыйммәтле гомуми белем бирүен, үсеп килүче яшь буында дөньяга коммунистик караш формалаштыруын, укучыларны коллективизм, Ватанга мәхәббәт һәм

социалистик интернационализм рухында тәрбияләвен, яшьләрне җәмгыять файдасына хезмәткә әзерләвен, яшьләрдә буржуаз идеологиянең теләсә нинди күренешләренә кискен каршы тора алучанлык рухы тәрбияләвен күздә тота.

Олы юбилейларга әзерлек көннәрендә нефть чыгаручы белән игенченең уңганлыгына, станоклар төзүче белән галимнең тырышлыгына әдәбият һәм сәнгать осталарының илһамы да килеп кушыла. Художниклар, композиторлар, артистлар, язучылар дәүләтебезнең һәм республикабызның тарихындагы иң якты, иң күркәм даталарга иҗат бүләкләре әзерлиләр. Әдәбият һәм сәнгать эшлекләре идеология фронтының алгы сызыгында тора. Алар, үзләрен бик хаклы рәвештә партиянең алдынгы сугышчылары һәм якын ярдәмчеләре дип санап, бөтен көчләрен коммунистик төзелешкә бирәләр. Хәзерге кискен сыйнфый көрәш шартларында иҗат ителә торган әсәрләрнең идея-художество дәрәҗәсе югарырак булсын өчен, аларда совет халкының героик батырлыкларының бөеклеген тагын да киңрәк һәм ачыграк күрсәтү өчен, аларның совет кешеләрен коммунизм идеалларына чиксез бирелгәнлек рухында тәрбияли торган булулары өчен барлык иҗат работникларының җаваплылыгын тагын да күтәрү таләп ителә.

Әдәбият һәм сәнгать эшлекләренең әсәрләрендә социалистик интернационализм, халыклар дуслыгы һәм туганлыгы идеяләре, социализм һәм коммунизм эпохасында халыклар тормышына торган саен тирәнрәк үтеп керә барган Ленин, революция, Коммунистлар партиясе идеяләре тагын да тәэсирлерәк яңгырарга тиеш.

Язучылар җитди социаль темаларны яктыртырга бурычлылар. «Ленин — кеше ул», «Ленин — революционер», «Ленин һәм Россиянең җәберләнгән халыклары», «Ленин — галим», «Ленин — Совет властен оештыручы» кебек яңа темалар безнең әдипләребезнең яңача каләм тибрәтүен көтә.

Бөек Ильич юбилеена әзерлек алып барганда, әдәбият һәм сәнгать осталары төп көчне хезмәт кешесенең тулы канлы калку образын тудыруга аеруча юнәлдерергә тиешләр. Шушыны һич тә хәтердән чыгармаска кирәк: хезмәт процессында кеше үзенең камилләшүен, рухи үсешен дәвам итә. Аның хезмәткә мөнәсәбәте үзгәрә, хезмәтнең социаль мәгънәсе бүтән төс ала, кешенең аңы үсә. Димәк, хезмәт кешесе хакында шаблон буенча язарга ярамый һәм мөмкин түгел.

Әдәбият-сәнгать эшлекләренең иҗади активлыгын тагын да күтәрү максаты белән республиканың Культура министрлыгы, профсоюзларның Татарстан өлкә советы һәм иҗади Союзлар иң яхшы драма әсәрләренә, иң яхшы җырларга конкурслар игълан иттеләр. Иң яхшы спектакльләр күрсәтүгә, патриотик җырлар һәм вокаль цикллар башкаруга конкурс-смотрлар, тематик концерт программалары әзерләргә, Ленинга багышланган фестивальләр үткәрергә, сынлы сәнгать күргәзмәләре оештырырга кирәк.

В. И. Ленин юбилее уңае белән республикабыз хезмәт ияләре клублардан, культура-агарту учреждениеләренең барысыннан да кызыклы һәм тирән эчтәлекле яңа эшләр көтә. Димәк, моңа культура фронтының барлык работниклары да культура-агарту эшенең барча формалары дәрәҗәсен күтәрергә бурычлылар.

Безнең өчен, совет кешеләре өчен, ирешелгән нәтиҗәләр инде башкарылган эшләр үлчәве генә түгел. Алар, бер үк вакытта — алдагы яңа үрләр дә. Шулар биеклегеннән торып без киләчәккә карыйбыз, үзебезнең бурычларыбызны һәм яңа перспективаларны билгелибез.

Республикабызның хуҗалык ягыннан үсү перспективалары тагын да зур. Партиябез Үзәк Комитеты һәм хөкүмәтебез җитештерү көчләрен

үстерү, минераль-чимал ресурсларыннан хуҗаларча файдалануны киңәйтү һәм һәр яклап яхшырту өчен халкыбызга нәтиҗәле ярдәм күрсәтәләр.

Татарстанның 1970 елда 100 миллион тонна нефть чыгарачагын әйтү генә дә җитә. Шул уңай белән, 1913 елда патша Россиясенең 9,2 миллион тонна нефть чыгарганлыгын хәтергә төшерү урынсыз булмас! Бөек Ватан сугышы алдыннан Советлар Союзында 31,1 миллион тонна нефть чыгарыла иде. Сугыштан соң, җимерелгән хуҗалыкны торгызу чорында, совет халкы 60 миллион тонна нефть чыгару турында хыялланды. Хәзер исә Татарстан үзе 100 миллион тонна чамасы «кара алтын» чыгара. Безнең генә нефть индустриябез масштабы да менә нинди!

Электроэнергетика үсешен алып карасак та шулай. Татарстан АССР территориясендә энергетика гигантлары корыла. 1970 елда электр станцияләренең егәрлеге 3,1 миллион киловатт булачак, ә 1975 елда ул 5,5 миллион киловаттка җитә.

Химия промышленностеның бездә тоткан урыны аеруча зурая. Европада һәм дөньяда иң зурларның берсе буларак Түбән Кама нефтехимия комбинатын коруга хөкүмәтебез бик күп акча бирде. Экономиканың башка тармаклары үсешенең дә шундый ук перспективалары ачылды.

КПСС Үзәк Комитеты карарында әйтелгәнчә, В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуны билгеләп үтүнең иң төп чарасы — игътибарны хуҗалык һәм культура төзелеше өлкәсендә совет халкы алдында торган гаять зур планнарны тормышка ашыру эшенә юнәлтү булырга тиеш.

Татарстан хезмәт ияләре, илебезнең барлык халкы белән бергә, бу карарны зур канәгатьләнү белән каршыладылар. Фабрикаларда һәм заводларда, колхозларда һәм совхозларда, транспорт һәм төзү оешмаларында бишьеллык заданиеләрен срогыннан элек үтәү, бөек датаны лаеклы каршылау өчен социалистик ярыш киң җәелдерелде. Республикабыз эшчеләре, крестьяннары, интеллигенциясе, социалистик йөкләмәләр алганда, 1968, 1969, 1970 елларны **Ленин юбилеена багышланган хезмәт вахтасы еллары** дип игълан иттеләр.

Агымдагы елның башында С. П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы, «Лениногорскнефть» промыселлар идарәсе, С. М. Киров исемендәге Казан синтетик каучук заводы, «Камгэсэнергострой» төзү идарәсе һәм Буа районының «Память Ленина» колхозы членнары республикабызның барлык хезмәт ияләренә, ленинчыл удар вахтага басарга чакырып, мөрәҗәгать белән чыктылар. Аларның ялкынлы чакыруы һәркайда кайнар яклау тапты.

Хәзер, Ленин юбилеен лаеклы каршылау өчен массовый социалистик ярыш киң җәелдерелгән иң актив чорда, безнең хуҗалык эшебез практикасына конкрет нәтиҗәләр ясау, ирешелгән уңышларны беркетү, игътибарны әлегә хәл ителмәгән яңа проблемаларга һәм яңа кыенлыкларны җиңүгә туплау аеруча әһәмиятле.

Бишьеллык планны срогыннан элек үтәү өчен көрәштә производствоны һәм хезмәтне фәнни оештыру хәлиткеч роль уйный. Бу өлкәдә инде байтак эш башкарылды. Күп кенә предприятиеләр хезмәтне фәнни оештыру чаралары үткәрү нигезендә җитештерүнең нәтиҗәлелеген шактый күтәрүгә ирештеләр. Ләкин без алга карарга, яңа офыкларны күрергә тиешбез. Без хезмәтне фәнни оештыру чараларын, практиканың иң яңа казанышларын тагын да киңрәк һәм квалификациялерәк куллана алабыз һәм кулланырга тиешбез, шуның исәбенә хезмәт җитештерүчәнлеген туктаусыз күтәреп була һәм күтәрергә тиешбез.

Химия промышленносте сафына яңа кертелә торган куәтләрне үзләштерү бездә канәгатьләнерлек түгел әле. Тәҗрибә күрсәткәнчә, экономик рычагларны хәрәкәткә китерү — реформаның башлангычы гына, иң мөһиме, производстводагы һәр кешенең психологиясен үзгәр-

тергә кирәк. Шуннан башка без теге яки бу завод-фабрикада реформа бирергә тиешле нәтиҗәгә ирешә алмабыз. В. И. Ленин өйрәткәнчә, мәсьәлә шулай тора: аңлы эшче үз заводында үзен хуҗа итеп кенә түгел, бәлки илнең вәкиле дип хис итсен, ул үзендә җаваплылык тойсын.

Бишьеллык планны срогыннан элек үтәүне тәэмин итү өчен, предприятиеләрнең җитәкчеләре производствоны реконструкцияләү, механикалаштыру эшләрен киң күләмле һәм максатлы итеп алып барырга, продукциянең сыйфатын яхшырту чараларын тормышка ашырырга тиешләр.

Төзү эшләрен җитди яхшырту таләп ителә. Бишьеллык ахырына кадәр бу өлкәдә гаять зур күләмле эш башкарасы бар. Түбән Кама промышленность районы төзүчеләре якындагы арада үтәлә торган эшләрне күп тапкыр тизләтергә, күп кенә яңа объектлар төзүне башларга бурычлылар. «Татэнергострой» тресты шин заводы төзүгә дә керешә.

«Татнефтестрой» комбинаты коллективы республика нефтьчеләренә 1970 елда нефть чыгаруны 100 миллион тоннага җиткерергә мөмкинлек бирерлек объектларны файдалануга кертергә тиеш.

Промышленностьның химия, азык-төлек, ит-сөт продуктлары җитештерү тармакларын үстерүгә, машина төзелеше объектларын коруга, төзү оешмаларының һәм төзү материаллары промышленностеның производство базасын үстерүгә элеккечә үк аеруча игътибар биреләчәк. В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан университетының яңа биналарын салу зур төзелешкә әверелде. Анда күп катлы уку биналары, тулай торак комплексы, университет профессорлары һәм укытучылары өчен торак йорт салыначак.

Авылда капиталь төзелешне киң җәелдерү кичектергесез башкарырга тиешле бурыч булып тора. Шуларны хәл итү белән бер үк вакытта, киләчәкне дә ачык күрергә, күп еллар үткәч тә игътибарны җәлеп итәрлек нәфис архитектуралы авыллар булдырырга кирәк. Ул ландшафтка уңай бәйләнешле булсын, авыл хуҗалыгы производствосын тагын да үстерү, халыкка хезмәт күрсәтү дәрәҗәсен күтәрү мөмкинлекләрен исәпкә алып төзелсен. Чөнки авыллардагы тораклар әле хәзергә тиешле проект-план документлары буенча төзелмиләр. Кайчакларда торак йортларны, культура-көнкүреш биналарын һәм производство объектларын төзегәндә, элементар санитария-гигиена, технология һәм архитектура-план кагыйдәләре гомумән бозыла. Бүгенге төзелеш өлкәсендәге төп бурычыбыз шул безнең: яңа производство куәтләрен, торак, культура-көнкүреш һәм авыл хуҗалыгы объектларын социалистик йөкләмәләрдә билгеләнгән срокларда һәм минималь чыгымнар белән бик яхшы сыйфатлы итеп файдалануга тапшырырга кирәк.

Югарыда әйтелгәнчә, республиканың авыл хезмәт ияләре быелтыр, гомумән алганда, әйбәт эшләделәр. Партиябез Үзәк Комитеты безнең үз эшебез нәтиҗәләрен тәнкыйть күзлегеннән карап бәяләргә өйрәтә. Ә бу нәтиҗәләр республикабыз авыл хуҗалыгының кайбер өлкәләрендә әлегә югары түгел. Бер үк уңай шартларда эш итеп тә, кайбер хуҗалыклар игенчелекне кызу темплар белән үстерү өчен, җитештерү нәтиҗәлелеген күтәрү өчен зур резервлардан йомшак файдаланалар.

Игенчелектә һәм терлекчелектә зур һәм катлаулы бурычларны уңышлы хәл итү интереслары безнең партия, совет һәм авыл хуҗалыгы органнарыбызның массаларны оештыру һәм тәрбияләү эшләрен өзлексез камилләштерүен, барлык категория кадрларның осталыгын күтәрү турында туктаусыз кайгыртуын таләп итә.

Моннан бер ел элек ВЦСПС Президиумы В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу хөрмәтенә производство культурасы буенча Бөтенсоюз җәмәгать смотры игълан итте. Профсоюз оешмалары смотрда катна-

шуга. В. И. Ленинның 100 еллыгын лаеклы каршылау өчен әзерлеккә һәр совет кешесен тартуны, әлбәттә, мактаулы бурыч итеп санаячаклар.

Данлы юбилейга әзерлек барышында оештыру эшенең формалары һәм методлары даими камилләштерелергә тиеш. Партиянең шәһәр һәм район комитетларының, башлангыч партия оешмаларының сугышчанлыкларын күтәрүгә, аларның теге яки бу карарда кабул ителгән хуҗалык һәм идеологик чаралар комплексын оператив рәвештә тормышка ашыра белүләренә ирешергә кирәк. Партия һәм дәүләт җитәкчеләренең барлык буыннары да Ленин стилен тайпылышсыз үзләштерүе — эштә уңышка ирешүнең төп шарты булып тора.

Партия тормышының Владимир Ильич нигезләгән һәм безгә мирас иткән принциплары буенча эш итеп, партиябез гаять зур уңышларга иреште. Җитәкчелектә ленинчыл осталык коммунизм өчен көрәштә бөек җиңүләргә ирешүдә партиянең куәтле коралы булды һәм һәрвакытта да шулай булып кала.

Ленин стилен үзләштерү — ул, барыннан да элек, революцион теорияне һәм практиканы органик рәвештә берләштерү, политик, экономик, идеологик һәм оештыру бурычларын фәнни позицияләрдән чыгып хәл итү дигән сүз. Теория белән практиканың аерылгысыз бәйләнеше теориянең һәм партия политикасының бердәмлегендә, политик һәм хуҗалык, шулай ук идеологик һәм оештыру эшләренә җитәкчелекнең бердәмлегендә чагыла. Димәк, партия комитетлары, хуҗалык органнарының вазифасын үтәү белән һич мавыкмыйча, үзләренә хас методлар кулланып, хуҗалык һәм культура төзелешенең мөһим мәсьәләләрен хәл итү белән даими шөгыльләнергә тиешләр.

Ленинның: хәзер нәкъ менә практик нәтиҗәлелек, нәкъ менә эшлеклелек төп һәм чираттагы лозунг булып тора, дигән сүзләре безнең көннәрдә аеруча әһәмияткә ия. Ленинның бу сүзләре КПССның XXIII съезды карарларында гәүдәләнделәр һәм һәр коммунистка, ул кайда һәм кем булып эшләмәсен, партиянең нинди генә кушкан эшен үтәмәсен, мөһим таләп булып калалар.

Партия һәм дәүләт эшләрендә эшлеклелек абстракт төшенчә түгел. Партиячә эшчәнлек дигән төшенчә буш, кирәксез утырышлар ыгызыгысы белән сыеша алмый. Ул эшне төгәл оештыруны, кадрларны дөрес сайлап алуны һәм эшкә дөрес куюны, үтәлешне тикшерүне һәм контрольгә алуны таләп итә. Ә контроль исә кимчелекләрне ачыклауга гына кайтып калса, көчләрне оста урнаштыру, эшне тагын да яхшыртуга киң активны мобилизацияләү истән чыгарылса, аны нормаль дип санап булмый.

Ленинчыл эшлеклелекнең төп сыйфатларыннан берсе итеп һәртөрле чараның идея һәм практик бурычын, аның максатка ярашлылыгын алдан күрә һәм билгели белүне санау дөрес булыр иде.

Тәнкыйть һәм үзара тәнкыйть — партия җитәкчелегендә һәм һәртөрле практик эштә ленинчыл стильнең мөһим таләбе. Ул һәрвакытта да эшне камилләштерү чарасы, КПССны идея һәм оешу ягыннан ныгытуның, һәр коммунистта үз оешмасының һәм тулаем алганда бөтен партиянең эше өчен җаваплылыгын күтәрүнең состав өлеше булды. Һәм шулай булып кала. КПССның XXIII съезды эшлекле, принципиаль тәнкыйтьне һәм үзара тәнкыйтьне җәелдерү һәм аның өчен тиешле шартлар тудыру кирәклеген, тәнкыйтьне кысучыларны каты җавапка тарту зарурлыгын күрсәтте. Шуңа күрә дә, безнең Ленин юбилеена әзерлеккә бәйле бөтен эшебез дә югары таләпчәнлек һәм дисциплиналылык, эшлекле тәнкыйть һәм үзара тәнкыйть рухы белән сугарылган булырга тиеш.

Мәскәү шәһәр партия оешмасының XIX конференциясендә иптәш Л. И. Брежнев, партия обывательләрчә тәнкыйтьне түгел, ә партияле, принципиаль тәнкыйтьне яклый, дигән фикерне әйтте. Тәнкыйтьнең кыйммәте кискен әйтә белү белән түгел, ә дөрес әйтү белән, һәм әйткәннең исбатланган булуы белән, куелган мәсьәләнең әһәмияте һәм файдасы белән билгеләнә. Партия барлык коммунистларның да тәнкыйть коралыннан дөрес, ленинча файдалanулары белән һәрвакытта да тирәнтен кызыксынды һәм кызыксына, Ленин үз вакытында әйткәнчә, тәнкыйть иптәшләрчә, туры булырга тиеш, аңа дипломатия һәм вак исәп-хисаплар чит нәрсә. Кешеләргә ленинча сизгерлек һәм игътибарлылык, тыйнаклык, үзеңә һәм башкаларга карата югары таләпчәнлек безнең барыбыз өчен дә һәм һәрвакытка да якты үрнәк булып калырга тиеш.

Ленинның 100 еллык юбилеена әзерлек безгә зур һәм җаваплы бурычлар йөкли. КПСС Үзәк Комитеты эшчеләрне, колхозчыларны, интеллигенцияне бу истәлекле датаны КПСС Программасында, партиянең XXIII съезды карарларында һәм Октябрьның 50 еллыгын бәйрәм итү уңае белән кабул ителгән документларда билгеләнгән коммунистик төзелеш планнарын тормышка ашыру өчен көрәштә яңа җиңүләргә ирешергә чакыра.

Шик юк ки, коммунистлар, Татарстанның барлык хезмәт ияләре һәм иҗат интеллигенциясе бу бурычларны хәл итүгә лаеклы өлеш кертерләр, бөек юлбашчыбыз һәм остазыбыз Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулуны намуслы эштә ирешкән яңа һәм зур уңышлар белән каршыларлар.




## *ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ*

*Төрле илләрдән, төрле телләрдән*

### Вл. Маяковский

...Университет —
данлыклы ул Казанда,
Бөек гражданинын
бүген дә
Бик яратып,
сөеп саклыйлар анда —
Адым саен,
һәр даим, һәр күңелдә.
Шушы йортта,
лекцияләр залында
Фикерләре йөргән
бик еракларда,
Зур көрәш,
Кызыл Октябрь хакында
Уйлаган ул
менә бу баскычларда.
Карашым
тынып калган залда:
һәрбер йөзнең
унысы минем алда
Нәкъ аның гадәтенчә кыса күзен,
Хәтерләтә
аның яңагын, йөзен.
Орынырга
үлем
кыймас аңарга,
Киләчәк сметасында
ул эш итә!
Колак сала яшьләр
үлем турындагы
строфаларга,
йөрәкләре —
үлемсезлек ишетә.
Кечаге көн фәкыйрь,
түбән һәм черек,
Иске-москысы
күп калган дөньяда.
Классның күкрәген
җиңмәс карт-искелек,
Класс йөрәге —
Коммунизм утында —
яңада!

А. Мөслимов

# ЛЕНИН—СТУДЕНТ



Казан.

1887 ел.

Чиркәүләр һәм мәчетләр, байлар, алпавытлар салган зиннәтле йортлар һәм ярлы-ябагайлар яши торган алачыклар. Күккә энә булып кадалган озын кирпеч моржалардан кара төтен бөркелә.

Шәһәр уртасында колонналы зур бер бина бар. Бу — университет. Шул заманның укымышлы кешеләре аны фән сарае дип йөрткәннәр. Ләкин бу бик үк дөрес түгел. Университет, үзенең ачылу көненнән башлап, патша хөкүмәтенең колонизация политикасына хезмәт итү өчен яраклаштырылган. Университеттагы беренче ачылу көненнән үк урнаштырылган тәртипләр дә моны ачык чагылдыра: мундир һәм шпага биредә, геометрия дәреслегенә караганда да, студент өчен мәҗбүри әйберләр. Бүтәнчә булуы да мөмкин түгел, чөнки университетның беренче ректоры генерал Желтухин була, аны гусар полковнигы Мусин-Пушкин алыштыра, ә аннан соң кызына студент Лев Толстой гашыйк булган генерал Молоствов билгеләнә. Бу хәрби чиновниклар кул астындагы гражданский кешеләр дә, кайбер чын фән вәкилләреннән тыш, үзләренең дорфалыклары, наданлыклары белән аерылып торганнар. Аларның бердәнбер омтылышы патшаның ышанычын акларга тырышу булган.


Ә патшалар Казан университетыннан канәгать булганнар. Ничек инде канәгать булмасыннар: мәсәлән, кара-горуһ Магницкий ректорга язган инструкцияләренең берсендә: «Политик хокук укытучылары Маккиавели[1] һәм Гоббс[2] тәгълиматларын начар яктан күрсәтергә мәҗбүрләр. Алар тормыштагы бөтен башлангычның Муса, Давыт, Сөләйман пәйгамбәрләрдән, аларның сәхәбәләреннән яки, иң яхшысы, безнең иң югары хөкемдарыбыздан башланганын күрсәтергә һәм үз дәресләренең дөрес булуын шул күзлектән карап мөһерләргә тиешләр»,— дигән.

Ярты гасырдан артык университеттагы тәртипләр шулай дәвам иткән. Ул вакыттагы мәгариф министры: «Безнең Казандагы студент-

---

[1] Маккиавелли — феодализмның таркалу чорында Италиядә буржуазия идеологларының берсе, философ (1469—1527).

[2] Гоббс — инглиз философы-материалисты (1588—1679).



XIX гасырда Казан университеты күренеше.

лар менә дигән егетләр, политика белән шөгыльләнмиләр, эчү белән типтерүне генә беләләр»,— дип, юкка гына язмаган.

Шулай да студентлар дөньядан ваз кичеп яшәмәгәннәр. Алар арасында Каракозовлар[1], Осипановлар[2] барлыкка килгән. Студентлар әледән-әле, патша хөкүмәтенә ризасызлык белдереп, чыгышлар ясаганнар. 1871, 1882 һәм 1886 еллардагы Казан студентлары арасындагы буталышлар патша хөкүмәтен шактый куркуга төшергәннәр. Мәгариф министры М. Д. Делянов хәзер инде: «Казан студентларында Пугачев каны уйный»,— дип язарга мәҗбүр булган.

1887 ел бик тынгысыз башлана. 3 мартта (19 февральдә), крестьяннарны «азат итү»нең еллыгын бәйрәм иткәндә, университетта дәресләр булмый. Университет побы чиркәүдә Александр II патшага мәдхия укый. Ләкин чиркәү буш диярлек була. Бу вакытта студентлар, патша өчен гыйбадәт кылырга теләмичә, алдынгы карашлары белән үзен күрсәткән врач Потехин каберен зиярат кылырга китәләр.

Каберлектән кайтканда, студентлар уку-укыту округы попечителе яши торган йорт алдында мәет янында гына башкарыла торган тәбарәк әйтәләр. Урамнан үтеп йөрүчеләр моңа бик гаҗәпләнә: ничек инде исән кешегә тәбарәк әйтү мөмкин?..

Ульяновлар Казанга килгән елны университет студентлары менә шундый рух белән яшиләр.

Володя Ульянов исә Казанга, гимназиядән соң, белем алуын дәвам иттерү максаты белән килә. Володя белән бергә Ульяновларның бөтен семьясы Казанга күчә.

Володя ни өчен Казан университетын сайлый соң?

Аның өчен башкаладагы университет ябык. Чөнки ул — патшага һөҗүм иткән Александрның энесе. Икенчедән, бу вакытта инде Казан университетының революцион традицияләре бар.

---

[1] Каракозов Д. М.— рус революционеры-террористы (1840—1866). 1866 елның 4 апрелендә Петербургта Александр II гә ата, ләкин тидерә алмый. Җәзалап үтерелә.

[2] Осипанов — Александр Ульянов белән патшага һөҗүм әзерләүгә катнашкан. 1887 елда җәзалап үтерелгән.

Казанга килгәч тә, Ульяновлар семьясы [illegible] Ростовалар йортында торалар. Берникадәр вакыттан соң Ново-Комиссариат урамына күчәләр. Хәзер дә Комлев урамында бу йорт бар. Бу урамнан үткәндә, Володя Ульянов турында кем генә уйланмый икән: нәкъ шул ук тротуарлардан атлаганда, ул революцион көрәш планнарын башында йөрткәндер!

Ул елларда Владимир Ильич юриспруденцияне өйрәнүне үзенә максат итеп куя. Үзенең туганнары белән сөйләшкәндә ул:


— Хәзер вакыты шундый. Хокук һәм политик экономияне өйрәнергә кирәк. Әгәр дә бүтәнрәк вакыт булса, бәлки, мин башка фәннәрне сайлаган булыр идем,— ди.

Әмма университетка кабул итүне сорап язган беренче гаризасына Владимир Ильич каршы җавап ала. Үзенең табигате буенча икеләнүчән ректор Н. А. Кремлев Владимир Ульянов гаризасын укыгач, туптуры: «Гариза белән бергә гимназия дирекциясеннән характеристиканы да бирергә кирәк иде»,— ди.


Озак та үтми, университетка Сембер гимназиясе директоры Ф. Н. Керенский һәм педагогия советы членнары кул куйган характеристика килеп җитә. Ниһаять, шуннан соң, 13 (25) августта, Владимир Ильичны юридик факультетка кабул итәләр һәм аңа университетка керү-чыгу өчен 197 номерлы билет бирелә.

Элек Россия ВУЗларында һәр студент үзе теләгән лекция курсларын тыңларга алдан ук язылырга тиеш була. Владимир Ильич хокук фәнен профессор Н. П. Загоскиннан тыңларга тели. Бу профессор борынгы заман тарихын, гомумән үз фәнен яхшы укытуы белән аерылып торган. Аның лекциясе вакытында аудитория һәрвакыт студентлар белән тулы булган.

Владимир Ульянов рим хокукы буенча да лекцияләр тыңларга теләгән. Бу фәнне Б. Ф. Дормидонтов алып барган. Ә аның лекцияләре,



Ново-Комиссариат (Комлев) урамында Ульяновлар торган йорт.



Университетта В. И. Ульянов лекцияләр тыңлаган бүлмә. Хәзер анда В. И. Ульянов-Ленин музей-бүлмәсе.

киресенчә, бик коры, ялыктыргыч булган. Аның дәресләренә студентлар йөрергә яратмаганнар.

Владимир Ильич, шулай ук инглиз телен өйрәнергә, барлык студентлар өчен мәҗбүри булган дин дәресләренә йөрергә тиеш булган.

Менә беренче лекция. Барлык студентларның күңелләре күтәренке. Ләкин университеттагы надан чиновникларның юк-бар бәйләнчек кисәтүләре ачуны китерә. Беренче көнне үк Владимир Ильич мондый бәйләнчек кисәтүнең шаһите була. Инспектор Потапов тәнәфес вакытында коридорда бер студентны туктата да:

— Сезнең тышкы күренешегез государь император кушуы буенча чыгарылган министр кагыйдәләренә туры килми,— ди.— Шулай булгач, сез хөкемдар боерыгын үтәми булып чыгасыз...

Эш шунда гына була: беренче курс студенты, яшүсмер егет, сюртугының төймәләрен барысын да төймәләп кенә бетермәгән икән. Ә Потапов, студентның калтыранган кулларына карап, ләззәт алгандай тыңкыш аваз белән сүзен дәвам итә:

— Моны хәтерегездән чыгармагыз — соңгы кисәтү...

Тиздән Владимир Ильичка мондый кыргый мөнәсәбәт белән үзенә дә очрашырга туры килә. Аны университет канцеляриясенә чакыралар һәм шундый йөкләмәгә кул куярга кушалар:

«Землячество һәм шуның кебек җәмгыятьләрдә, гәрчә аларга хәтта закон тарафыннан юл куелган булса да, иң якын торган начальникларның рөхсәтеннән башка член булып тормаска һәм катнашмаска сүз бирәм».

Университетта укый башлауның беренче көннәреннән үк Владимир Ильич студентларның ихтирамын казана. Студентлар аның җәзалап үтерелгән Александр Ульянов энесе икәнлеген беләләр, бик укымышлы, дәртле, марксистик әдәбиятны яхшы белүе өчен хөрмәт итәләр. Бу турыда студентлар гына түгел, университет җитәкчеләре дә, жандармерия дә яхшы белә. Владимир Ильич артыннан махсус күзәтү оештырылган була. Шуларга карамастан, ул Сембер землячествосына керә, аның советына депутат итеп сайлана. Моны белеп торалар. Казан уку-укыту округы попечителе югарыга болай дип хәбәр җибәрә:

«Күрелгән чараларга карамастан, Сембер землячествосы үзенең эшен, дәвам итү генә түгел, соңгы вакытларда күзгә күренерлек көчәйтте дә».

тябрь аенда Лазарь Богараз житәкчелек иткән түгәрәккә член булып керә. Ульянов Владимир монда да игътибарны үзенә җәлеп итә. Шул ук түгәрәкнең члены булган Н. Алексеев соңыннан болай дип яза:

«Студентларның урамдагы буталышлары алдыннан берничә көн элек Комлев йортында бик якын иптәшләр белән чәй янында бәхәсләр булып алды. Шунда Владимир Ильич тыйнак һәм ышандыргыч итеп Маркс тәгълиматы турында сөйләде һәм Бахның «Дөньяда бар бер патша, ул патша рәхимсез — аның исеме ачлык» исемле халык арасында танылган брошюрасыннан өзекләр укыды».

Ул вакытта Владимир Ильич күп укый, хәтта тәнәфес вакытында да газетадан аерылмый, дөнья хәлләре белән даими танышып бара. Володя түгәрәк эшләренә катнашу белән генә чикләнми, ул эшчеләр белән дә бәйләнешкә керә, аларның тормышын өйрәнә, алар арасында Маркс идеяләрен пропагандалый. Аның белән бергә укыган И. В. Португалов: «Ульянов нигә лекцияләрдә күренми?» — дигән сорауга: «Владимир Ильич хәзер бик еш Алафузов фабрикасы эшчеләре янына йөри,— дип җавап бирәләр иде»,— дип яза.

Ново-Комиссариат урамындагы квартираларына Владимир Ильич кичләрен соңгарып кайта. Өйдә һәрнәрсә күңелгә якын. Һәр бүлмәдә, һәр әйбердә әнисенең кайгыртучан кулы сизелеп тора. Аның акыллы күзләре һәрвакыт ягымлы.Ниләр генә кичермәгән ул! Шулай да язмыштан һич зарланмас, тормыш авырлыгы хакында сөйләнмәс. Мария Александровна балаларының омтылышы белән яши, ул — балаларының иптәше, дусты һәм киңәшчесе.

Владимир Ильич кичләрен семьяда ял итә, сеңелләре белән фикерләрен уртаклаша. Һәр иртән университетка — уку һәм көрәш буенча дуслары янына бара.

Еш кына яшерен түгәрәк утырышларына йөри. Тиздән ул член булып торган түгәрәк үзенең әһәмияте ягыннан үзәк түгәрәкләрнең берсенә әверелә. Полиция департаментының шул елларда язган бер донесениесендә болай диелгән:

«Казанда гаять зарарлы юнәлештәге түгәрәк оешты. Җәзалап үтерелгән Александр Ульяновның энесе — Казан университеты студенты Владимир Ульянов бу түгәрәккә катнаша. Бу түгәрәк хөкүмәткә каршы юнәлештәге Петербург түгәрәкләре белән бәйләнеш тота».

Бишенче (яңа белән унсигезенче) ноябрьда университетта уку йортының ачылу көненә багышланган традицион бәйрәм үткәрелә. Землячестволарның студентлар советы бу рәсми бәйрәмгә катнашмаска карар кабул итә. Ул көнне студентлар революцион җырлар җырлыйлар, митингларга җыелалар, төркем-төркем булып, шау-гөр килеп урамнарда йөриләр.

Кичен Дворяннар җыелышы йортында бал үткәрелә. Ләкин балга да халык килми. Попечитель белән инспектор өйдә утыруны артыграк күрәләр, ә алар яшь торган йортларның ишекләрен городовойлар саклый. Ләкин әле болар — яшенле яңгыр алдыннан исеп үткән җил генә. Давыллы күк күкрәү соңрак башлана.

Ноябрь ахырында патша хөкүмәте Мәскәү университеты студентларына карата репрессия үткәрә. Бу турыда хәбәр Казанга да килеп житә.

1 (13) декабрьда университеттагы һәм ветеринария институтындагы землячестволарның депутатлары Түбән Федоровский (хәзерге Федосеевский) урамындагы Воротников йортында яшерен киңәшмәгә җыелалар. Бу киңәшмәгә Владимир Ильич та килә. Киңәшмә репрессиягә каршы протест сходкасы үткәрү турында карар кабул итә. Шунда ук


«Сходкага!» СССРның халык художнигы Н. Жуков картинасыннан.

петиция һәм прокламация текстлары кабул ителә. Бу текстларны язуда Владимир Ильич турыдан-туры катнаша.

Сходканы үткәрү 4(16) декабрьга билгеләнә. Владимир Ильич киңәшмә карарларын тормышка ашыру эшенә җиң сызганып керешә. Инспектор Потапов язган характеристикада бу турыда ачык әйтелә:

«Ульянов Владимир... сходкадан ике көн үк элек ниндидер ярамаган эшкә әзерлек алып баруда шикләнергә сәбәпче булды: күп вакытын тәмәке тарту бүлмәсендә үткәрде, бик еш өенә кайтып-килеп йөрде, бүтәннәр соравы буенча, үзе белән нәрсәләрдер алып килде, нәрсә турындадыр башкалар белән пышылдашты...»

Сходкадан бер көн элек властьлар кайбер аудиторияләрне ябалар, тентүләр үткәрәләр, кайберәүләрне кулга алалар. Ләкин инде студентларның чыгышын берни дә туктата алмый.

4 декабрь көне гадәттәгечә тыныч кына башлана. Бары тик төш вакытында, сәгать 12 дә генә:

— Сходкага! — дигән чакыру яңгырый. Бу команда ишетелү белән, студентлар аудиторияләрдән коридорга атылып чыгалар һәм Актлар залына ябырылалар. Җитез хәрәкәтле, дулкынланган Владимир Ильич — студентларның беренче сафында. Актлар залының ишекләре бикле. Студентлар, әйләнеп, залга юридик факультет ягыннан (хәзер В. И. Ленин музей-бүлмәсе яныннан) омтылалар. Инспектор коридорда, кулларын җәеп, студентларны туктатырга маташа. Аны бер читкә этеп җибәрәләр. Владимир Ильич биек имән ишекләр янына беренче булып йөгереп килә. Ишекләр моннан да бикле. Җыйнаулашып этәләр, ишекләр ачылып китә. Студентлар залга тула, кайсы урындыкларга, кайсы тәрәзә төпләренә утырыша. Шундук сходканың комитеты (президиум) сайлана һәм чыгып сөйләүләр башланып китә. Владимир Ильич та ялкынлы речь белән чыга. Н. Алексеев истәлекләрендә язылганча, ул «патша хөкүмәтенең халыкны изүе, хаксызлык, яшәп килә торган режимга каршы университет студентларының протестын оештыру кирәклеге» турында сөйли.

Менә залга инспектор һәм аның ярдәмчесе атлыгып керә:

— Әфәнделәр, закон исеменнән таралышырга чакырам,— дип кычкыра Потапов, боеручан тавыш белән.

Аңа каршы:

— Алдыңнан артың!.. Эзең булмасын! — дигән авазлар яңгырый.

Инспектор үзенең таләбен тагын кабатлый. Ләкин һичкем таралышу турында уйлап та карамый. Бу вакыт ветеринария институты студентлары да килеп җитә. Сходка кызганнан-кыза бара.

Юридик факультетның беренче курс студенты К. Алексеев трибуна янына килә, кизәнеп Потаповның яңагына суга. Инспектор студентның кулыннан тота да:

— Моның өчен җавап бирерсез,— дип ысылдый. Тч алу турында кисәтү студентларга утка май сипкәндәй тәэсир итә. Инспектор ярдәмчесе үзенә таба очкан урындыктан читкә тайпылып чак кына котыла. Икесе дә көч-хәл белән чыгып ычкыналар.

Потапов ректор бүлмәсенә чаба. Кремлев хәзер үзе, икеләнеп кенә, Актлар залына юнәлә.

— Галиҗәнап... Анда мәхшәр... Безне кыйнадылар... Бармагыз анда,— ди Потапов, көч-хәл белән тын ала-ала.

Менә сәхнәдә ректорның агарынган йөзе күренә. Залдагы шау-шуны басарга тырышып, ректор бар көченә:

— Мин сезне таралырга чакырам,— дип кычкыра.— Әгәр тыңламыйсыз икән, гаскәр һәм полиция чакырачакмын...

Бу вакытта инде Казан шәһәр полиция идарәсе ишек алдында Ревель пехота полкы батальоны сугышчан әзерлек хәлендә тора.

Ә биредә, залда, шау-шу дәвам итә. Ректор кафедрага күтәрелә.

— Тынычлык сорыйм,— дип кычкыра ул.

Шунда студентларның берсе:

— Безнең петицияне тыңлавыгызны һәм кабул итүегезне сорыйбыз,— дип, Кремлевка мөрәҗәгать итә.

— Студентларның ни теләгәнен мин беләм,— ди ректор аңа каршы.— Сез сходкалар хокукы, кассалар, китапханәләр, кухмистерский кебек нәрсәләр сорыйсыз.

— Юк, безнең петициядә бүтән нәрсәләр дә бар,— ди студент, тантаналы төстә.— Менә карагыз!

Һәм ул ректорга петицияне суза. Кремлев калтыранган куллары белән аны ала һәм зур игътибар белән укый:

**«Гомумән рус тормышындагы һәм, аерым алганда, студентлар яши торган шартларның түбәнлеге, шулай ук бу шартларга җәмгыятьнең игътибарын тарту, хөкүмәткә түбәндәге таләпләребезне белдерү теләге безне бирегә җыйды. Без университетларга карата якын арада һичшиксез булырга тиешле реформаларга түбәндәгеләр кертелергә тиеш дигән карарга килдек:**

**а) Россиядәге барлык университетлар өчен устав бер үк булырга тиеш.**

**в) Университетлар белән үзбаш рәвештә профессорлар коллегиясе җитәкчелек итәргә тиеш.**

**с) Студентларның шәхси тормышына университет берничек тә контроль ясамаска тиеш.**

**d) Студентларның үз эшләрен тикшерү өчен аларга сходкалар хокукы, коллектив петицияләр тапшыру хокукы бирелергә тиеш.**

**е) Үз китапханәләрен, уку залларын, ярдәмләшү кассаларын, кухмистерскийлар булдыру хокукы булырга һәм алар белән сайланып куелган студентлар идарә итәргә тиеш.**

**f) Карарларын профессорлар коллегиясе кире кага алмаслык ачык студентлар суды булырга тиеш.**

**q) Студентлар үзләре сайлаган иптәшләре карары буенча стипендияләрне һәм пособиеләрне бүлү хокукы алырга тиеш.**

**II. Уку йортларына керү өчен киртә булып торган барлык нәрсәләр (мәсәлән, зур түләү, форма һ. б. ш.) бетерелергә тиеш.**

**III. Дөреслек шуны таләп итә: барлык университетлардан студентлар арасындагы буталышлар өчен чыгарылган барлык иптәшләр яңадан кабул ителергә тиеш.**

узган айның егерменче числоларында безнең иптәшләребез — Мәскәү студентлары өстеннән кылынган ерткычлыклар, хәтта рәсми рәвештә яшереп яткырыла торган үтерешләр өчен җаваплы кешеләр хөкемгә тартылырга тиеш.

Казан студентлары»

Ректор, бу таләпләрне укыгач, баскан урынында катып кала — аның кулында политик документ!.. Кремлев озак вакыт гадәти хәленә кайта алмый тора. Ниһаять, тынычлангач, ул яшьләрнең үз-үзен тотуы, закон һәм тәртип турында бик озын итеп речь сөйләргә керешә.

Университеттан чыгарылган студентлар турында сорап, аның речен бүлдерәләр. Ректор җавап бирә алмый, ык-мык килә.

— Ни өчен чыгарганны югары начальство да белми диген, ә?! — дип кычкыра студентларның берсе.

Аннары сходкада «Барлык Казан студентларына» дигән мөрәҗәгать кабул ителә.

«Иптәшләр!

Яңа университет уставы[1] безнең өскә авыр йөк булып төште,— диелгән бу мөрәҗәгатьтә.— Сезне, кадерле «alma mater» шәкертләрен, алдынгы карашлы, зыялы яшь буын вәкилләрен ул шымчы инспекция хакимлегенә тапшырды, ул профессорлар коллегиясенең хокукларын кысты һәм бөтенләй юкка чыгарды, ул ярлы кеше балаларына университетка керү мөмкинлекләрен чикләде, ул аларга лекцияләр тыңлаган өчен түләүне арттырды, стипендияләр алу шартларын катлауландырды һ. б. Әмма болар барысы да түгел әле: 1887 елның 18 июнендә халык мәгарифе министрлыгы чыгарган циркулярда сезнең энеләрегезгә хәтта гимназия белеме алу мөмкинлеге бетерелгән. Ниһаять, шушы елның 23, 24, 25 ноябрендә Мәскәүдә булып үткән вакыйгалар вакытында иптәшләребезнең каны коелганда (2 студент үтерелгән), алар башы өстендә нагайкалар сызгырган чакларда[2], барлык рус зыялы яшьләре хурлыклы төстә мыскыл ителде. Казан студентлары! Университетларыбызның хурлыклы төстә аяк астына салып тапталган хокукларын яклап күтәрелик, киң җәелгән реакциягә үзебезнең протестыбызны белдерик! Без Казан студентларына ышанабыз һәм аларны университет диварлары эчендә ачык протест белән чыгарга чакырабыз».

Туксан тугыз студент кул куйган петицияне ректор кире кага. Моңа протест йөзеннән студентлар, билетларын бер-бер артлы өстәлгә ташлап, университеттан чыгып китәләр.

Владимир Ильич өенә кайта да ректор исеменә түбәндәге гаризаны яза:

«Университет тормышындагы хәзерге шартларда университетта белем алуны мөмкин түгел дип санап, император университеты студентлары исемлегеннән мине сызу турында тиешле боерык бирүегезне Сез галиҗәнаптән түбәнчелек белән үтенәм»...

Салкын төн. Агачлар бәскә күмелгән. Жандармнар бөтен шәһәр буйлап эзләнәләр, тентиләр, кулга алалар. Кулга алынганнарны Кремль төрмәсенә озаталар. Бер төн эчендә генә дә йөздән артык кеше кулга алына.

---

[1] 1884 елда чыгарылган реакцион устав турында сүз бара.

[2] Студентлар концерты вакытында, юридик факультетның III курс студенты Синявский, «Барлык студентлар исеменнән» дип, Мәскәү университеты инспекторының бик каты итеп яңагына суга. Кулга алынган Синявскийне яклап ике меңләп студент университет ишек алдына сходкага җыела. Аларга каршы солдатлар, полицейскийлар, казаклар көче кулланыла. Сходка 24, 25 ноябрь көннәрендә дә дәвам итә. Бәрелешләр вакытында үтерелүчеләр дә була, бик күп студентлар яралана, йөзгә якын кеше кулга алына.

Ново-Комиссариат урамындагы бер катлы өй ишегенн дә төн уртасында шакырга керешәләр. Өй эчендә ут алалар, өй алдында хатын-кыз тавышы ишетелә:

— Кем бар анда?

— Телеграмма бар,— ди пристав.

Ишек ачылып китә, полицейскийлар, городовойлар өйгә кереп тула. Тентиләр, тентү турында протоколга кул куйдыралар һәм Владимир Ильичны кулга алу турында белдерәләр.

Тар экипаж эчендә пристав Владимир Ильичка «акыл өйрәтергә» керешә:

— Нәрсәгә дип сез бунт күтәрәсез, егет,— ди.— Алдыгызда стена!

— Стенасын стена, әмма черек — төртсәң җимерелергә тора,— дип җавап кайтара Владимир Ильич. Пристав куркып читкә тайпыла һәм тына.

Владимир Ильичны төрмәгә алып килеп, администрациягә тапшыралар.

Бу вакытта инде губернатор, жандарм идарәсе студентлардан үч алу чараларын әзерлиләр. Инспектор Потапов, мыскыллануының үчен кайтарырга теләп, 39 студентны университеттан чыгара. Аларның берсе — Владимир Ильич Ульянов. Сходкада катнашучыларның исемлегендә һәр фамилия турысында тәре билгеләре куелган: бер, ике яки өч тәре — «гаебе» никадәр зуррак, тәре шулкадәр күбрәк. Ульянов фамилиясе турысында өч тәре билгесе тора.

Эчке эшләр министрлыгы губернаторга университеттан чыгарылган студентларның барысын да шәһәрдән куарга боера. Губернатор исә Петербургтан телеграмма килгәч тә эшкә керешә. Кирәк була-нитә калса дип, гаскәр чакыртыла. Кайбер студентлар «гаепләрен таныйлар», үкенүләрен белдереп гариза язалар, андыйларны университеттан чыгармыйлар. Әлбәттә, Владимир Ильич — андыйлар арасында түгел. Шуңа күрә аңа — җәзаның катысы. Ульянов сөрелгәннәр арасында да «иң куркынычлыларның берсе» итеп карала.

Казаннан сөрелү көне килеп җитә. Сөрелүчеләрнең күбесе җиңел киемнән. Полицейскийлар аптырап кулларын җәяләр:

— Аларны ничек алып китәсең? Бөтенләй ялангач диярлек бит...

Студентлар бу турыда белеп алып, йорт борынча кереп, җылы киемнәр, азык-төлек җыялар.

Воскресенский (хәзерге Ленин урамы) урамындагы полиция участогы бинасы янына йөзләрчә студентлар, яшьләр җыела. Алар сөрелгәннәрне «ура!» кычкырып, революцион җырлар җырлап озаталар, чаналарга азык-төлек, киемнәр салалар. Бу көнне бөтен шәһәргә: «Сау бул, Казан, сау бул, университет!» дип исемләнгән листовкалар тарала.

Менә ул листовканың тулы тексты:

**«Сау бул, Казан!.. Сау бул, университет!.. Университетка, аның тормышына ышаныч һәм мәхәббәт белән килгән көнебез кайчан гына иде. Без бирегә, фән сараенда, кыерсытылган Ватаныбыз бәхете һәм иминлеге өчен көрәшчеләр булып тормышка керә алырлык аң-белем табарга өметләнгән идек! Без бу белемне зур дәрт белән эзләдек!.. Ләкин без бирегә нәрсә очраттык?.. Безне 4 декабрь сходкасында кайбер профессор әфәнделәр ярсып яклаган «фән өчен фән», алар әйткәнчә, студентларны кадерле ватаныбызның изелүенә һәм җәберләвенә тыныч күңел белән салкын гына карарга өйрәтә торган фән каршы алды... Шуның белән бергә безне инспекциянең һәм аның шымчылар өеренең, аларның нирчённәренең мораль яктан тарката торган йогынтысы биләп алды... Без куркыныч һәм өшеткеч хәлдә калдык... Без укытучыларыбыз артыннан иярмәдек. Безнең яшь каныбыз, безнең яшь**

нөрәгебез бүтән юл эзләргә мәҗбүр итте... Без иптәшләребез арасында үзара бер-беребезгә ярдәм итәчәгебезгә, үзара аңгәмәләшеп, укып, намуслы, какшамас карашларыбызны үстерергә дәртле омтылышларыбызны канәгатьләндерәчәгебезгә нык лы ышанып, землячествога оештык... Ләкин безгә моңа да мөмкинлек бирмәделәр!.. Чыгару белән янап, землячестволар оештыруны тыйдылар!.. Яңа уставның изүе көннән көн катылана барды... Университеттан куулар башланды. Бу изүгә каршы без университеттагы акт вакытында тыныч һәм тотнаклы рәвештә протест белән җавап бирдек, аннан тыш, яңа университет уставының изүенә каршы көрәшебездә ярдәмгә чакырып, барлык профессорларга язма рәвештә мөрәҗәгать иттек. Бернинди җавап булмады! Ниһаять, ярлы эшчеләргә, хезмәт кешесе балаларына, ярлы крестьян, мещан һ. б. балаларына гимназияләргә, шуның белән университетларга керү мөмкинлеген чикләгән мәгълүм циркулярлар дөньяга чыкты. Боларның барысы да безне бик нык нәфрәтләндерде... Мәскәүдә ноябрьдә булып үткән вакыйгалар, безнең иптәшләребездән, Мәскәү университеты студентларыннан, оятсыз рәвештә канлы үч алу фактлары безне бик нык хурландырды... Без протест белдерергә тиеш булдык, һәм безнең протест актив форма булып — сходка булып оешты. Протест белдерүебез өчен безне университеттан чыгардылар һәм Казаннан куалар!!!

Без Казаннан эшебезнең хаклыгына тирән ышаныч белән китәбез!.. Безне яратучыларның барысының да кулын кысабыз!!!

Казан җәмәгатьчелегенең күп әгъзалары күрсәткән матди ярдәм һәм теләктәшлек өчен чын күңелдән рәхмәт!!!»

7 (19) декабрь. Аяз, салкын көн. Артсыз, киң үрәчәле чана җигелгән ат төнлә белән яуган кар өстеннән салмак кына юырта. Чанада — пальто якаларын күтәргән Владимир Ильич Ульянов. Ул сөрелү урынына — Кокушкино авылына бара.

Владимир Ильич Казан университеты диварлары эчендә 113 көн була. Бу вакыт дәвамында бер генә зачет та, бер генә имтихан да тапшырырга туры килми аңа. Ләкин ул биредә зуррак нәрсә ала — революцион көрәш юлына аяк баса һәм бу көрәш аның бөтен гомер юлының якты маягы булып кала.

# ӨЧ КАЕН ЯНЫНДАГЫ ӨЙ



Үз күзебез белән күрмәгән булсак, без моны әкият дип санар идек...

Казандагы ул җәйге көн кетелмәгәнчә салкын һәм болытлы булды. Кешеләр анда-монда посалар, зонтикларын тотып чаттан-чатка йөгерәләр. Күз күреңдәгечә түбәнтен йөзгән болытлардан шәһәр өстенә яңгыр коела. Хәтта шәһәрнең үзәгендә дә кеше берән-сәрән генә күренә.


Һәм кинәт, тыныч урамнарның берсенә килеп чыгуга, без өч карт каен янындагы иске өй буенда тып-тын гына торган чиратны күреп алдык. Монда ерак татар авылларыннан килгән колхозчы хатын-кызлар да һәм чәчләре чаларган интеллигент та, «болон» кигән студентлар һәм ераклардан килгән яшь туристлар да, кайсыдыр авыл мәктәбеннән килгән кыюсыз пионерлар һәм эшчеләр дә бар.

...Ак күлмәк кигән, пионер галстугы таккан кара күзле малае белән янәшә тора ул — күпне күргән карт эшче. Кулын улының җилкәсенә куйган. Бу өйгә таба алар шулай атладылар.

Күктән исә һаман яңгыр сибелә. Каенның салынып төшкән алкаларыннан тамчылар тама. Тәбәнәк тәрәзәсе бакча ягына караган бәләкәй бүлмә ишеге төбендә экскурсовод яшь Владимир Ульяновның Казан университетында укыган вакытлары, өч каен янындагы шушы өйдә торган чаклары турында сөйли.

Өч каенның да үз тарихы бар. Ульяновлар семьясы бу өйгә килеп урнашканда Володя тәрәзә буенда карт каен үсеп утырган бәләкәй бүлмәне сайлый. Вакыт үтү белән бу каен бөтенләй корып бетә. Әмма күп тә үтми, шушы тәрәзә буенда ак каусәле нәфис кенә өч агач үсеп чыга.

Бүлмәне әлеге эшче бик игътибар белән, күңеленә мәңгегә сеңдерергә теләгән-



Казанда В. И. Ульянов-Ленин музей-йорты.

лар куелган киштәгә дә, тәрәзә буенда утырган ак каеннарга да текәлеп карап торды ул. Шушы тәрәзәдән студент Ульянов Россиянең киләчәгенә караган һәм шул киләчәккә баруның бердәнбер юлын — социалистик революция юлын күргән.

Өй эче тын. һәркем сүзсез. Мондый минутларда экскурсовод тавышы кирәк түгел. һәркем уйлана. Кешеләр үзләренең йөрәкләрен һәм күңелләрен ачып салалар. Аларның хисләре олы хисләр, изге хисләр.

«Бөек юлбашчының тормышы белән танышкач, мин, Петров Владислав, аның гадилегенә гаҗәпкә калдым. Күңелемдә минем сүнмәс ут кабынды, һәм ул утны мин гомерем буена саклармын».

«Ильичның бөтен тормышы һәм эшчәнлеге безнең өчен, Ленин эшен дәвам иттерүчеләр өчен, тормыш мәктәбе булып тора.

Ленин мәктәбе — дөнья мәктәбе,
Шаулы Енисей — Ленин мәктәбе,
Ленин мәктәбе — туган илебез,
Бар зәңгәрлеге белән күктәге.

Петропавел шәһәренең тугызынчы класс укучылары. Казагыстан».

«Болгариядән килгән комсомол-туристлар группасы пролетар революция юлбашчысының Казандагы өендә булды. Ленин эше — безнең яшьләребез йөрәгендә. Ленин байрагы астында, СССР белән бергә, без бөтен көчебезне коммунизм төзүгә бирербез».
Унбиш кеше кул куйган.

«Ленинның һәм аның семьясының тормышына сокландым мин. Йөрәккә барысы да якын. Ленинның уйлары Совет Ватанының миллионнарча кешеләренең хезмәте белән тормышка ашырыла.

**З. ХӘЙРУЛЛИНА.**
Чиләбедән килгән студентка».

«Бу йорт безнең йөрәкләребезгә мәңгегә кереп урнашкан кешене хатергә төшереп тора. Минем улым Владимир Ильич өйрәткәнчә яшәр дип вәгъдә бирәм. Шушында, бөтен кешеләр алдында, бөек коммунизм эше хакына көчемне кызганмам дип эшче сүземне бирәм.

**В. М. ЛОГУНОВ, улым белән.**
Красноярскидан килгән эшче».

Калын китаптагы соңгы язма әле кибеп тә җитмәгән. Тигезле-тигезсез хәрефләр дәфтәр бите буйлап йөгерә. Күңелендәгеп шушында язып калдырган кеше улы белән әкрен генә баскычтан төшеп бара.

Соңгы елларда бу өйнең бусагасын атлап Ленин янына кергән һәм гади генә өстәл өстендә ачылып яткан Ильич китабына карап уйга калып торган ике миллион кешенең берсе иде әлеге эшче. Бу бүлмәдә элек булып киткән кешеләр кебек үк, ул да олы хисләр кичерә. Киңәшеп, уйлашып, кешеләр монда үз тормышларын Ленин тормышына чагыштырып карыйлар...

Инде яңгыр туктаган. Тәрәзә буендагы өч каенның яфракларыннан соңгы тамчылар тама. Яфраклар яшеллеге арасыннан Казан заводларының трубалары, төзелеш краннары, яңа кварталлар, Идел диңгезенең зәңгәр көзгесе күренә. Болары да аның Ленин васыять итеп калдырган үрентеләрдән үсеп чыккан...

Революциягә кадәрге 113 еллык гомерендә Казан университетында татар студентлары күп булмаган. Бүгенге көн статистикасына күз салсак, анда: Совет властеның 50 еллык дәверендә бу университетта 5.670 татар кешесе белем алган, шуларның күбесе күренекле совет галимнәре булып, промышленностьны оештыручылар, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре булып чыккан.

Китаптан аерылып торган арада, картаеп барган каен кәүсәләренә һәм калкынып килүче үсентеләргә карап, беренче семестр студенты Володя Ульянов боларны да күргән...

**А. БАТЫРОВ**

## Тимер Фәттах

*Үзбәк шагыйре*

# Күңелгә якын кала

Рус җиренең яшел бу каласын
Якын итте минем күңелем.
Кеше монда зур киңлекләр гизә,
Һәм сафлыкка яши күмелеп.

Күп карадым монда яшьләрнең мин
Һәм картларның якты йөзенә.
Елмаялар алар матур итеп,
Күңелләрне тартып үзенә.

Бульварларны кат-кат әйләндем мин,
Идел буйлап кат-кат атладым.
Даны белән иске бу каланың
Яңа җырын сөеп ятладым.

Кайчагында хәтта Ташкентта дип
Хис иткәндәй булдым үземне:
Бөтен нәрсә нурлы булып күренә,
Һәм яуларын ала күземнең.

Ничек инде горур хис кичермә:
Бу ташны бит Ильич таптаган!
Гүя аның кайнар эзен күрәм —
Кыю яшьлек шуннан атлаган.

Ишеткән ул шушы зур киңлектә
Бурлакларның кырыс шыңшуын.
Шул җырларны йөрәгенә салган,
Җырлаган ул шуңа кушылып.

Егет күргән: шушы зарны тыңлап
Тал-тирәкләр хәтта тетрәгән.
Җыр Иделгә җәйгән киң канатын,
Җыр күкләрдә яшьнәп күкрәгән.

Хәзер исә җырның бу якларда
Мин бүтәнен бүген ишетәм.
Ул җыр чыга ачык тәрәзләрдән,
Ул җыр керә бәреп ишектән.

Бу җырларда — күз иңләмәс киңлек,
Бу җырларда — яшәү шатлыгы.
Шул җыр булып керә йөрәгеңә
Бу якларның якты сафлыгы.

Шулай тоела: гүя Ильич үзе
Шул җырларны килгән тыңларга,
Ул чактагы Ильич тавышы да
Кушыла гүя дәртле моңнарга.

Ант итәм мин: иркен бу якларны
Гомерлеккә якын итәрмен.
Ленин баскан изге бу туфракка
Башкаемны иеп үтәрмен.

ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәсе

# АЛТЫН ТАҢ

*Ойрот халык легендасы*

Алтайда, кардай ак болытлар артында,
Таш-таулы, хуш исле ямь-яшел үзәндә,
Яп-якты йолдызлы зәңгәр күк астында,
Яшәгән икән, ди, сунарчы бер бәндә,
Аңчы дип йөрткәннәр. Ул ярлы торган, ди,
Карт кына сыеры, бер аты булган, ди,
Өстендә киеме тетелгән, тузган, ди.
Ойротның гадәте, әлбәттә, аучылык —
Мылтыгы туйдырган мәргәнне — Аңчыны.
Ул сукмак салмаган җирләр, ди, калмаган,
Күзәтеп карурман һәм таулар арасын.
Ул төрле җәнлекләр һәм кошлар аулаган,
Ашаткан хатынын, ике яшь баласын.
Гаилә кайгысы әле ул бер генә,
Аңчының башка зар-кайгысы күп менә:
Аучының табышы булганда уңайлы,
Сыйларга тиеш ул комсызны — гуҗ байны,
Мәҗбүр ул сүзенә баш иеп күнәргә,
Аңарга бурычын арттырып түләргә.
Зайсанга[1] бирсен ул шунда ук ясагын,
Шаманга[2] илтсен зур бүләген ул тагын.
Бер тапкыр кыш көне никадәр юл йөреп,
Еларлык көрсенеп өенә кайта ул,
Сап-салкын урманда газаплар кичереп,
Барлыгы тик алты тиенне ата ул.
«Аларны алмашып булмасмы икмәккә?»
Борчыла сунарчы бусага төбендә.
«Ай, сукыр булсамчы?» — шакката хикмәткә,—
Тордын-бай кулакны күргә өендә.
Бай аңа үгездәй төбәде күзләрен:
«Я, Аңчы, әйт әле, куансын колагым,
Табышың бик мулмы? Яшермә үзләрен,
Нинди шәп җәнлекләр китердең син тагын?»
Юк, тупас дәшми бай, кычкырмый ул аңа,
Тавышы бик йомшак, ягымлы кылана,
Карашы сагыздай ябышкак: «Мал кайда?»
«Нәкъ бер ай йөрдем мин урманлы Алтайда,
Нәкъ бер ай чытырман эчләрен таптадым,
Тик алты тиеннән башканы атмадым».

---

[1] Зайсан — старшина, башлык.
[2] Шаман — багучы, өшкерүче.

«Аз булган, аз булган, ай-ай-ай,—
Диде аңарга Тордын-бай,—
Ләкин мин ашыгам китәргә,
Вакыт юк озаклап көтәргә,
Күп аучы бурычын бирмәде,
Күзәтәм тирмәдән тирмәне.
Бир миңа шул алты тирене,
Бурычың аз гына кимеде...» —
Дип кагып кыйммәтле, ефәктәй шәп тунын,
Сузды күн янчыкка Тордын-бай уң кулын.
Бирмичә хәле юк, нишләсен соң Аңчы?
«Алтысы да монда... зинһар,— ди,— мә, алчы...»
«Әй, эти, тирене ник бирдең син аңар?» —
Тилмереп, яшь коеп сорады балалар.
«Ник бирдең? Ни өчен? — дисезме,— үсегез,
Шул вакыт барысын аңларсыз үзегез».

Ике ай йөрергә юл тотты тауларга,
Үзгәрмәс микән, дип, ярлының язмышы.
Ачырак котырды каршы җил аңарга,
Юл тагын уңмады, булмады табышы.
Бәхетең булмаса, булмый ул ничек тә,
Бары тик бер җәнлек — тик бер кеш атты ул,
Өенә ярым буш янчыгын күтәреп,
Кайгыга сабышып, сызланып кайтты ул.

Борчулар тынгылык бирмиләр аучыга.
Атыннан сикереп: «Ни эшлим?» дигәндә,
Кайдандыр чыкты да ябышты Аңчыга
Ясакчы шул Кокшин-Тихмәче, җен-бәндә:
«Зайсанга соңгарып түләми беркем дә!
Я, Аңчы, әйт әле, ишетсен колагым,
Табышың бик мулмы? Яшермә берсен дә!
Нинди шәп җәнлекләр китердең син тагын?»
«Өшәндем мин, каттым, бер генә кеш аттым!» —
Диде ул, ачасы килмичә авызын,
Ә Кокшин-Тихмәче, иренен сыпырды,
Ук кебек юнәлде сүзләре явызның:
«Тик бер кеш аткансың... Шөкер, сау кайткансың,
Кайда ул? Ясагың хакына ялтырат!»
Алтындай йонлы кеш ычкынды Аңчыдан,—
Ал! — диде зайсанга, тилмереп, калтырап.

Зайсанны ачулы озатып калалар,
Тирмәдә икәүләп сөйләшеп алалар:
«Ничек көн итәргә? Ничек соң түзәргә?
Чара юк, хатыным, без мәҗбүр үләргә!
Без үлсәк, ничек соң көн күрер балалар?»
Ә хатын иренә сарылып шул чакта:
«Без әле үлмәбез, яшәрбез, ди, бергә...
Сабыйлар саргаеп үлсәләр почмакта,
Син алар белән күм мине дә каберга.
Юк, үлмәс балалар, догасын син алсаң,—
Шаманга үтенеп аларны коткарсаң».
Шунда ук күршедән аракы таба ул,
Балалар хакына шаманга чаба ул.

Аракы чөмереп, эт кебек иснәнеп:
«Кычкырма! — диде кам,— ни булды, нишләдең?
Балалар үләргә ятамы? Икәүме?
Бик төгәл йөртәм мин гыйбадәт исәбен:
Ул ике балаңа ике бит дога да,
Корбан да ике кат тиешле ходага!»
«Балалар терелсен! — яшь чыкты аучыдан,—
Кызганмыйм булганны, ал, алла хакына!»
Шаманга атлады карт сыер Аңчыдан,
Ычкынды юлдашы — бердәнбер аты да.
Балалар үлделәр. Кәүсәдәй яфраксыз,
Аңчылар калдылар баласыз-чагасыз.
Бәхетсез ир кеше кайгыга уралды:
«Сөт биргән сыерым, син кая югалдың?
Тауларда, ауларда армаган күк-атым,
Кайда син, ярдәмчем, житез пар канатым?
Мәхәббәт тудырган балалар, сез кайда?
Сезгә дип, өчләтә көч белән Алтайда
Без янып эшләргә тырыштык, булмады,
Хәлебез калмады...
Бәндәләр алдады.
Аллалар алдады...»

Комсызга, явызга кем кайчан чик куяр,
Хурлыклар, газаплар гел дәвам итәрме?
Караңгы упкындай дөм кара төн аша
Якгылык балкыган чаклар бер житәрме?
Кургашын болыттай бик авыр уйлары,
Аңчының башына тупланып, сызлата,
Байларның ныклыгы, гел талап яшәве
Аучының нәфрәтен, ачуын кузгата!
Ач бүре шикелле коточкыч Тордын-бай
Бурычың күп диеп, желекне киптерә;
«Хатының минеке, ди, бурыч бирмәсән».
Ә зайсан салымын тагын да үстерә.
Беркөнне сунарчы хатыны янында
Янып һәм сызланып: «Телим, ди, белергә:
Әллә, ди, даими законнар чыкканмы,
Байларга ярлыны ботарлап йөрергә?
Бер чыгып әйләнеп йөрсәм мин һәркайда,
Алтмышлап милләттән сорашып Алтайда,
Үз күзем белән мин барысын карармын,
Сорауга мәкерсез жаваплар табармын.
Зайсанны тетрәтеп алдына бастырган
Көчләрнең барлыгын-юклыгын күрермен,
Байларның бер тиен акчасыз йөргәнен,
Күгәргән ипигә тилмереп үлгәнен
Күрәчәк чакларым житәсен белермен.
Шаманны фаш итеп ахмакка калдырган,
Дөньяга акыллы бер зур көч табылган
Көнгәчә кайтмамын, бик авыр чакта да,
Без бәхет эзләгән кадерле якларга».
Хатыны белән ул ягымлы хушлашып,
Юнәлде зур юлга, ачуы бик ташып.

Күзәтеп йөрде ул тауларда, һәркайда,
Күп юллар урады чиксез зур Алтайда,

Җир өстен җиде кат әйләнде, кичте ул,
Кайгылар шулпасын яшь коеп эчте ул.
Зайсанны биетеп тимердәй кулында
Тотарлык батырны күрмәде юлында.
Белмәде, барса да ул әллә кайларга,
Азаплы ач тормыш кыләсен байларга.
Очрата алмады хикмәтле кешене,
Шаманны ахмакка калдырыр ишене...
Чүплекләр өстендә казынып туенды,
Зинданда ял итте — ябылып куелды.
Аягы атламас булды күп йөрүдән.
Теле дә сөйләми, күп сорау бирүдән.
Дөньяны аркылы һәм буйга гизде ул,
Яшәүдән өметен бөтенләй өзде ул.
Төшәм бит дигәндә упкынга — кабергә,
Тырмашып менде ул иң биек бер үргә.

«Күзләре томанга капланган кешегә,
Һәрвакыт изелгән, тапталган кешегә,
Бишектән ярлы дип, аталган кешегә,
Бәхетне күрмәгән, тапмаган кешегә,—
Миңа, дим, булырмы якты көн бирүче
Көчле бер баһадир — ярдәмгә килүче,
Булырмы шундый көч — шәфкатен салырлык,
Бу кара үлемнән коткарып калырлык?» —
Шулай дип, кычкырды ул өзелеп-моңланып,
Ачудан пошынып, ярсынып, сызланып.
Аучыбыз ничектер егылып китмәде,
Кайтаваз тауларда тынып та бетмәде,
Алынды шикелле дөньяның терәге:
Зур таулар селкенде, бөтен җир тетрәде.
Бервакыт Алтайның өстендә ялтырап,
Аңчыбыз кычкырган урынга, аптырап,—
Иң биек бер тауның башына омтылып,
Гөрселдәп, нур сибеп күренде ак болыт.
Көнчыгыш ягыннан таң ата башлады,
Ал кояш ялкынлы карашын ташлады,
Көмештәй нур чәчеп әнә шул чагында
Ялтырап балкыды ай кояш янында.
Аңчыбыз бер мәлдә туп-туры караса,
Алдында баһадир һәм халык — тамаша!
Сүзеннән җир тетри, нур сибә яктысы,
Ул икән иң көчле, яхшының яхшысы!
Кашлары — тауларның тезмәсе шикелле,
Күзләре — ялкынлы, ә йөзе — сөйкемле!
Дөньяга ул җирне яктыртып күренде,
Байрагы янына бар халык үрелде.
Ал кояш нурлары — аның уң кулында,
Көмеш ай нурлары — кулының сулында.
Байларга каршы ул — куәтле, гайрәтле,
Эшчегә, ярлыга — искиткеч шәфкатьле.
Ул дәште, сүзләре, ут-яшен уйнатып,
Таралды урманнар, тау, сулар буйлатып:
Син кайсы яклардан килдең соң ил гизеп,
Мендең бу биеккә азаплар кичереп?

«Мин ярлы,— диде ул,— тетрәп бу хикмәткә,
Ярлылар имгәнә азаплы хезмәттә,
Сабыйлык чагыннан тырышып эшләп тә
Акчам юк иңбашын ябарлык чүпрәккә,
Йөрим гел ялангач,
Хәлем юк азыгым булмагач,—
Тамагым һаман ач.
Күпме һәм ни генә тапсам да тырышып,
Табышны талый бай һәм зайсан, орышып,
Шулчакны үземә беразы калганда,
Йөземә ут чәчел кул суза шаман да.
Бәлки, син бирерсең шәфкатьле кулыңны,
Ярлыны үлемнән син тартып алырсың?
Бәлки, син сызарсың халыкка юлыңны,
Бәлки, син, кансыз юл, яңа юл салырсың?»

«Бел, Аңчы: зайсаннар, котырган хакимлек
Юк булды, күкрәүдәй җимергеч көчемнән,
Ярлылар котылды ерткычлар тешеннән,
Байларның аяусыз, кабахәт эшеннән.
Шаманнар алдавы фаш булды һәркайда,
Бәхеткә илтүче юлыгыз — каршыда;
Терлекләр һәм урман җәнлеге, кошлары,
Сезнеке, туганнар, барсы да, барсы да!
Бертуган шикелле тупланып, берләшеп,
Батырлык күрсәтеп, гөрләшеп, серләшеп,
Төзегез искиткеч матурны, яңаны,
Азатлык кояшы бизәсен даланы!»
Ялкынлы йөз белән хисләнеп һәм янып,
Баһадир шулай дип, сөйләде рухланып.
Бар халык янына җыелып, тупланып,
Сүзләрен раслады шаулашып, шатланып.

«Әйт әле, баһадир, кайларда Ватаның?
Яраткан баласы син кайсы ананың?
Бабаң кем? Атаң кем? Үстең кем кулында?
Баһадир тумастыр ташландык урында!
Күчкәндер сиңа да аларның утлары,
Мәңгегә яшәсен синдәге рухлары!
Исемең әйт безгә, аны без нык ятлап,
Яшәтик буыннан-буынга кабатлап!
Ойротлар син сызган юллардан атларлар,
Батырлар син куйган тәртипне сакларлар!» —
Диде ул, сокланып сүзенә, эшенә,
Аңчының шатлыгы сыймады эченә.
Баһадир янына сырышып тагын да,
Кешеләр әйттеләр аңар шул чагында:
«Чыкмады ул безгә җиде җир астыннан,
Инмәде болытлар эченнән, һавадан,
Халыкның тиңсез зур кодрәтле улы ул,
Көрәшкә ярсыды ул безнең арадан.
Җиңде ул дошманны туздырып, таратып,
Ленин! — ди һәр кеше, аны бик яратып».
Яз көнен китергән Кояшны тәбриклап
Очкандай Ватанның шат сайрар кошлары,
Ленинга омтылды, Ленинны котлады,
Хөр хезмәт, туганлык, тынычлык дуслары!

Төгәнмәс көч керде изелгән Анчыга,
Кояшның нурлары сибелде аучыга.
Яктырды чырае — төс керде йөзенә.
Яңа яшь баһадир булды ул үзе дә!

Газаплы коллыкта тудык без,
Караңгы дөньяда тордык без,
Канлы яшь агызып гомергә,
Без дучар ителдек үлемгә.
Бу хәлдән безне син коткардың,
Яктыга безне син чыгардың,
Безгә син китердең азатлык,
Син бирдең мәңгелек зур шатлык!
Дан сиңа, дан сиңа, юлбашчы!
Дан бөтен дөньяның кояшы —
Ленин!
Яктыртып кешенең йөзләрен,
Көч бирә акыллы сүзләрең,
Яшисең һәр кеше телендә,
Һәркемнең йөрәге түрендә —
Ленин!
Дан жыры янгырый һәркайда,
Кошлар да жырлыйлар Алтайда,
Олылап баш ия үләннәр,
Елгалар агалар жырлашып,
Борынгы урманнар шаулыйлар.
Чыга һәр күңелдән жыр ташып:
Шатлыкны дөньяга таратып,
Жырлыйбыз сине бик яратып,
Даһи Ленин!

**МӨХӘММӘТ САДРИ** тәрҗемәсе

**Лидия Сәйфуллина**

# ЛЕНИН ТУРЫНДА МУЖИКЛАР ХИКӘЯТЕ

*Быел апрель аенда күренекле совет язучысы, чыгышы белән безнең якташыбыз Лидия Сәйфуллинаның тууына 80 ел тулды.*

*Л. Сәйфуллина әдәбиятка «Павлушканың карьерасы» исемле беренче хикәясе белән 20 еллар башында килә. 1922 елда яңа оешкан «Себер утлары» журналында «Дүрт бүлек» исемле повесте һәм «Тәртип бозучылар» дигән хикәясе басыла. Л. Сәйфуллина шушы хикәясе, соңрак иҗат иткән «Черемә», «Виринея» исемле повестьлары белән профессиональ язучы булып таныла һәм аның бу әсәрләре көнбатыш Европа телләрендә дә басылып чыга. Болардан тыш, Л. Сәйфуллинаның «Җырчы», «Александр Македонский», «Үз җирендә», «Кеше» дигән һәм башка әсәрләре бар.*

*Зур әдәби хезмәте өчен Лидия Сәйфуллина берничә тапкыр орден һәм медальләр белән бүләкләнә.*

*Журналыбызның бу санында укучыларга язучының В. И. Ленин турындагы очерк-хикәясен тәкъдим итәбез.*



Башкаладан һәм олы шәһәрләрдән еракта торган зур гына бер өяз. Җире белән ул кайбер чит ил дәүләте чаклы бар. Монда алтын прискалары, иген игә торган кара туфраклы яхшы җирләр, аракы һәм туң май заводлары, атаклы Оренбург шәле бәйли торган йомшак мамыклы кәҗә һәм сарык көтүләре булган.

Халкы — бирәдә күптән яшәүче казаклар һәм төрле җирдән: Тамбов, Пенза, Саратов, Харьков, Екатеринослав, Воронеж, Полтава, Таврида губерналарыннан күчеп килгән, төрле йола, гореф-гадәтле кешеләр. Моннан башка, Сакмар елгасы буена һәм эчкәрерәк, далага таба, мордва, башкорт һәм кыргыз авыллары таралашып утырган.

Болар төрлесе төрле каннан яралган, һәркайсы үзенчә тормыш итүче һәм үз динен тотучы халык: православныйлар, иске дин тотучылар, мөселманнар, субботниклар, евангелистлар һәм хөкүмәт диненнән качкан башка бик күп секталар.

Меңләгән гектар җире булган бай крестьяннар һәм үзләренә йорт та кора алмаучы җирсез «фатирчылар». Станица һәм авылларда сирәк-мирәк кенә вак-төяк интеллигенция: унлап врач, укытучы, агроном һәм китапханәче очрый. Бөтен Рәсәй дәүләтенең тормышы турындагы хәбәрләрне һәм газеталарны Оренбургтан алалар. Ул хәбәрләр телеграф баганалы олы юл буена урнашкан станицаларга, алтын прискаларына һәм өяз калаларына гына тиз килеп җитә. Өяз шәһәре агачтан салынган. Аның яшәү дәвере — бер зур янгын чыгып янганнан соң, яңадан төзелеп, икенче тапкыр янгынга кадәр. Йортлар тәбәнәк. Тик арада чиркәү манаралары һәм мең тугыз йөз ундүртенче елда тынып калган аракы заводы морҗасы гына калкып тора. Газета һәм дөнья хәбәрләре чимал шәһәренең

торгынлыгы эчендә йотылып кала. Өязнең эчкәре җирләрендәге авыллар өяз каласыннан һәм Оренбургка бара торган тимер юлдан йөзәр чакрым читтә утыралар. Бу авыл һәм хуторлардан Оренбург белән тимер юл станцияләренә дала-кыр, чокыр-чакыр, тау-урманнар аша җәяүле һәм атлы юллар гына илтә.

Һәр авыл, һәр хуторның үз дине, үз йола-гадәтләре бар. Авыр салымнардан котылып, бөтен Рәсәй тормышы белән генә түгел, губерна тормышы белән дә кызыксынмыйлар. Патша һәм министрлар турында берничнди хикәят тә, риваять та сөйләмиләр, гаскәр хезмәтеннән кайткан солдатлар андый хикәятләрне бик тиз онытарлар, үз тирәләрендәге түрәләр: земский начальниклар, становой, урядниклар турында гына сөйлиләр. Рус-герман сугышы башлануы һәм Февраль революциясе бирәдәге халык өчен бөтенләй көтелмәгән, уйга да килмәгән бер хәл була.

Земство лекторлар һәм агитаторлар җибәрә. Ләкин алар буранлы кышларда барлык авыл, хутор, кышлакларны, җәй көне кызу эш өстендә барлык кыр, басу, болыннарны, күченеп йөрүче кыргыз авылларын йөреп бетерә алмыйлар.

Кыю, чая кешеләр тарафыннан өяз каласына таба салынган туры юллар мең тугыз йөз уңдүртенче елдан соң шактый такырайса да, хәрби башлыклар һәм революцион җитәкчеләрнең өяз каласыннан ишетеп кайткан исемнәре бу аулак урыннарда бик тиз онытыла. Безнең өяз авылында Керенский белән Родзянконы бутаучы кешеләр дә булды. Ә хатын-кыз һәм үсмер бала-чага андый исемнәр белән бөтенләй кызыксынмыйлар иде.

Әмма давыллы уңсигезенче ел кышында большевиклар турындагы «шомлы хәбәр» тәбәнәк агач йортлы өяз каласын да, бөтен өязне дә уятты. Бу хәбәр белән бергә Ленин дигән исем килеп ирешә.

Бу исем, килеп, телеграф баганалы олы юлдан гына узып китмәде, хутор һәм кышлакларга үтеп керде, ыруы, байлыгы, уйакылы белән төрле-төрле булган өяз кешеләренең берсен дә битараф калдырмады.

Рәсәйгә генә түгел, бөтен дөньяга исеме таралган әллә кайдагы бу кеше турында төрле халыклы аулак өяздә хикәятләр туа башлады. Бай казак станицаларында, күп җирле иске диниләр өстенлек иткән авылларда, община җирендә баеп, үзләренә әрым кыр-басулар алган сектантлар арасында бу хикәятләр көчле дошман гына уйлап чыгара алырлык нәфрәт белән сугарылганнар. Алар Ленинны үз файдасын күздә тотучы дип кенә яманлап калмыйлар, Библия буенча, адәм кавеменә ят икенче бер дөньядан килгән җан иясе дип, аның турында легендалар уйлап чыгаралар. Мин кайбер иске диние кешеләрнең һәм сектантларның, Ленинга алты йөз алтмыш алты санын — антихрист санын тагып, битебите белән Библия сүзләрен кычкырып әйткәнен дә ишеттем.

Секта башлыгы, кара сакаллы бер мужик, безнең элекке волость идарәсендә җыенда Ленин имзасы белән чыккан декретларның теле турында төкерекләрен чәчә-чәчә сөйләде. Указлардагы кыскартылган сүзләрне әйтүче кешеләрне, «моннан да аңлаешсыз, сәер, саңгырау телле халыкны беркайчан да күрмәссең!» — дип, Исаия пәйгамбәр исеменнән куркытырга тырышты. Әлеге кыскартылган сүзләрне Ленин сүзләре дип атады.

Камыт тегүче икенче бер сектант исә өяз каласындагы митингта, тырпаеп торган чәч чәчле башын боргалый-боргалый, кулларын болгап, Библия сүзләрен китереп Ленинны яклады. Ленин, «байларның майлы калҗаларын» тартып алып, Библия кушканча эш итә, «дөньяда үзләре генә яшәгән кебек, башкаларга урын калдырмыйча, бер йортка икенче йорт, бер басуга икенче басу өстәүчеләр яхшылык көтмәсеннәр»,— диде. Аның өчен Ленин Исаия пәйгамбәр әйткән гадел, изге бер үч кайтаручы кеше икән.

Иске дин тота торган Карагай поселогында какча тәнле, җирән чәчле Болдин дигән берәү дә, Библиядән чыгып эш итүче башкалар шикелле, Ленинны фанатикларча кабул итте. Партиягә язылып, җилкәсенә винтовка асты, кобурасыз гына наган тагып йөри башлады. Һәр җыен саен ул, наганын селкә-селкә, Ленин кылган политиканың дөреслеген раслый торган сүзләр китерә иде. Шушы чыгышлар, Библия һәм Ленин турындагы бәхәсләрнең барысы бергә кушылып, өяздә Ленин турында буталчык хикәятләр туды. Төрле-төрле караштә, Ленинга төрле мөнәсәбәттә булсалар да, алар һәммәсе пафос белән, тасвирлы итеп сөйләнелә иде. Берәү дә салкын канлы булып кала алмый иде. Җирсез «фатирчылар», аз җирле кешеләр, батраклар, рус, мордва, башкорт ярлылары Ленин турында хәтта дастаннар тудырдылар. Ленинның әле кабер өсте дә ябылмаган

бер вакытта ашыгып, дулкынланып язган бу мәкаләмдә мин күп нәрсәләрне хәтерләп бетерә алмыйм. Бик күп исемнәр килеп ирешеп тә югалып калган һәм кинәт бер зур исем генә телдә яшәп калган караңгы бер өяздә язам мин. Бу исем, телдән төшмичә, гаҗәеп бай мужик илһамы белән җанландырып үстерелде. Шул хикәятләрдән хәтеремдә төгәл һәм ачык булып калган берсе бар.

Калага барганда бер хуторда ишеттем мин аны. Мең тугыз йөз унсигезенче елның давыллы кышында Никита Минушев дигән кеше, яңа хәбәрләр ишетергә дип, йөз кырык чакрымдагы ерак калага барырга чыкты. Үзе белән мине дә алды. Әче салкын җил һәм җәяүле буран кузгалганлыктан, без караңгы төшкәнче үк бер хуторга төн кунарга туктарга булдык. Минушевларның бер кергән танышларында шыгырдап торган агач караватта, өстәл катындагы агач эскәмияләрдә, саргаеп беткән самовар тирәсендә безнең ише байтак юлчы бар иде. Болар да хуҗаның танышлары булып, бураннан курыкмыйча, калага яңа хәбәрләр ишетергә баручылар иде. Кич җитеп караңгы төшкәнче бер-берсенә сынап карашып утырдылар. Гадәттәгечә чит кешеләр очрашканда сөйләнә торган сүзләр: икмәк бәяләре турында, товар булмау хакында һәм бик сакланып кына яңа тәртипләр турында сөйләштеләр. Кечкенә генә өйгә тулган халыкның сулышыннан түшәмдәге бишле лампа инде сүнә башлаганда, хатыннар сүзгә керештеләр. Яулыгы астыннан чал чәч бөртекләре тузгып чыккан, саргаеп ябыккан какча йөзле, кара күзле бер хатын йокламаганнарга Ленин турында, Ленин белән патшаның ничек халыкны бүлешүләре турында әкият сөйли башлады.

«Көннәрдән бер көнне Микулай патша янына иң зур генералы килгән, ди. Микулайга әйткән, ди бу: «Патша галиҗәнаплары, менә шундый-шундый хәл, ниндидер бер илдә бөтен гыйлем суын эчкән бик белемле бер кеше килеп чыккан, ди. Чины-дәрәҗәсе дә, пашпорты да юк, исеме Ленин икән, ди. Шул кеше әйтә икән, ди: Микулай патша иленә барып, бер сүземне әйтү белән бөтен солдатларын үз ягыма алам, ә барлык генераллар, түрәләр һәм офицер җәнапларын һәм Микулай патшаның үзен көл итеп күккә очырам, мин шундый бер сүз беләм, дип әйткән», ди. Бу сүзләрне ишеткәч, Микулай патшаның коты алынган, шул чак тыпырдап, кулларын бутап, кычкырып җибәргән, ди. «Чины-дәрәҗәсе билгеле булмаган, пашпортсыз, Ленин дигән ул кешегә хәзер үк язып җибәрегез, андый сүзе белән минем илгә килмәсен, мине, генералларымны, түрәләремне, офицер җәнапларын көл итмәсен, ул кешегә ярты дәүләтемне бирермен!» — дигән, ди. Шуннан соң патша янына, ах-ух килеп, тиз-тиз генә укымышлы кешеләр җыелганнар да, каурый каләмнәрен очлап, Ленин дигән кешегә язганнар, ди: «Менә шулай-шулай, син, Ленин, ул сүзең белән Микулай патшага килмә, сугышсыз-талашсыз гына Микулайның ярты дәүләтен үзеңә ал»,— дигәннәр, ди. Күпмедер вакыт үткәч, әлеге Ленин дигән, чины-дәрәҗәсе билгесез, пашпортсыз кешедән язма җавап килгән. Микулай патшага әйткән, ди: «Шулай-шулай, Микулай патшаның ярты дәүләтен алырга ризамын. Тик бүлешү шартымны әйтеп язамын. Губерналап, өязләп тә, волостьлап та бүлмибез. Ничек бүлешүгә риза икәнлегемне әйтеп язам да шуның белән сүз бетте. Син, Микулай патша, бөтен ак сөякләреңне: генералларыңны, түрәләреңне, офицер җәнапларыңны бөтен чиннары, погоннары, тәреләре белән, затлы нәселле хатыннары, ак сөякле балалары белән үзеңә ал. Бөтен байлыклары, хәтфә-ефәк киемнәре, алтын-көмеш савытлары, хатын, бала-чагалары белән бергә алпавыт-байгураларны да ал. Сәүдәгәрләреңне дә товарлары, бик күп акчалары белән үзеңә калдыр, банктан алар бөтен акчаларын алсыннар. Бөтен машиналары, маллары һәм акчалары белән завод хуҗаларын да ал. Ә миңа барлык кара сөякне: юк-бар мөлкәтләре белән мужикларны, солдатларны, фабрика халкын бир. Үрчемгә терлек-туар калдыр да иген игәргә басулар һәм болыннар калдыр», дигән, ди. Хатны алып укыгач, Микулай патша шатлыгыннан кулларын чаба-чаба биеп киткән һәм генераллары, офицерлары һәм түрәләренә болай дип әмер биргән: «Барсына да риза икәнлегемне ул Ленинга хәзер үк языгыз. Шулкадәр байлыктан, сәүдәгәрләр малыннан, алпавыт җирләреннән баш тартып, бернинди мөлкәтсез кара халыкны алгач, ул нинди гыйлем кеше, тылсымлы сүз белә торган кеше булсын, ди. Ул байлык белән без үзебезгә башка кара халыкны яллярбыз, шулар арасыннан солдат җыярбыз да тагы рәхәттә, тынычлыкта яшәрбез»,— ди. Шуннан соң патша янына, ах-ух итеп, тиз-тиз генә тагы бик күп укымышлы кешеләр җыелганнар һәм, каурый каләмнәрен очлап,

әлеге Ленинга патшаның ризалыгын әйтеп язганнар. Ә патшаның көлүе турында ләммим бер сүз ычкындырмаганнар. Ленин, акылына килеп, әлеге тылсымлы сүзе белән боларны харап итмәсен дип курыкканнар. Күпмедер вакыттан соң, озакламый, Ленин шыпырт кына үзенең солдатлары, мужиклар һәм фабрика халкы янына килә. Ә патша үзенең ак сөякләре белән арырак киткән була. Мужиклар, солдатлар һәм фабрика халкы, карасалар, шунда күрәләр: болар янына гади бер крестьян кешесе килгән дә: «Исәнмесез, иптәшләр»,— ди. Күз күреме кадәр җирдәге бөтен халык белән күрешеп чыккач, кычкырып әйтә: «Без хәзер бер-беребезгә иптәшләр, мин сезнең белән бер тиң булам. Тик сез минем сүзне тыңлагыз, мин бөтен гыйлем суын эчкән кеше, мин үз иптәшләремне яманлыкка өйрәтмәм»,— ди. Солдатлар шундук солдатча җавап кайтаралар: «Так точно, иптәш Ленин, тыңлыйбыз»,— диләр. Фабрика халкы — укымышлы, һөнәрле шәһәр халкы да — аңа каршы килми. Ә мужиклар, алдатты бу дип, шаулаша-борчыла башлыйлар: «Ни өчен шулкадәр акча белән байлыкны кулдан ычкындырдың! Шуны безгә бүлеп бирсәң, хуҗалыгыбызны рәткә китерер идек»,— диләр. Шул вакыт Ленин көлеп, башын чайкап, боларга җавап кайтара: «Тавышланмагыз, ачуланмагыз, җирне, мал-туарны үзегезгә алыгыз да иген игегез, терлек үрчетегез, калганын карарбыз. Ул байлыкны сезгә бүлә башласаң җитмәс иде, чөнки сез әллә ничә мең, ә ак сөякләр берничә йөз генә. Ә барлык ак сөякне җир йөзеннән юк итүгә килгәндә, мин ул сүзне әле тулысынча белеп бетермим. Бераз өйрәнеп җиткермәгәнмен. Әмма миндә бөтен җирдәге бөтен кара халык аңлый торган башка бер сүз бар. Шуны әйтсәм, бер ак сөяк тә беркайдан бер солдат та, хезмәтче дә таба алмас. Барысы да алардан баш тартып, минем кул астыма күчәчәкләр. Аксөякләр, эшләмичә ашап ятучылар гына булганлыктан, дөньяда озак яши алмаячаклар»,— ди. Шуннан, күпмедер вакыттан соң, нәкъ ул әйткәнчә булып чыга. Атлы бер йомышчы Ленинга Микулай патшадан хат китерә. Хатында Микулай патша язган ди: «Менә шулай-шулай, Ленин, син мине бик алдагансың. Үзеңә бөтен кара халыкны алгансың да миңа эшләп мал табучыларны түгел, эшләмичә ашап ятучыларны гына калдыргансың. Минем генералларым, офицер җәнапларым, солдатлары булмагач, абзардагы ат кебек, ашап-эчеп, симереп кенә яталар. Алпавыт хәзрәтләре бөтен азыкларын ашап, сандыкларындагы киемнәрен туздырып бетереп киләләр, бөтен ес-башлары ертылып, пычракка буялып беткән. Сәүдәгәрләрем дә бөләләр, мужик булмагач, аларның товарларын алучы юк. Завод хуҗалары бөтен машиналарын ватып, җимереп бетергәннәр. Алар китапча белсәләр дә, куллары эшкә ятмый, винт бора белми. Ә чит илдәге кара халык безгә эшкә ялланмый, синең кул астыңа килә, синең тылсымлы сүзеңә иярә. Башка бернинди чара калмаганлыктан, бөтен кара халыкны үзебезгә кайтарып алу өчен, минем генералларым, офицер җәнапларым сиңа каршы сугышка чыгалар»,— ди. Менә шуннан инде аксөякләр белән кара сөякләр арасында сугыш кузгала. Тик аксөякләр бик озак каршы тора алмаячаклар, ул генераллар, офицер җәнаплары солдатка боерырга, гаскәрләрен тегеләй-болай йөртергә генә өйрәнгәннәр бит, үзләре сугыша белмиләр, буыннары сыек, озак яши алмаячаклар...»

Лампаның уты сүнде. Мужиклар гырылдап йоклыйлар. Йокы аралаш бер хатын саташып сөйләнеп куйды. Ә ябык карт хатын идәндә туны өстенә утырган да, дога укыган кебек бирелеп, әкият сүзләрен тезә бирә.

Аның әкиятендә тагы өстәмәләре һәм чигенешләре дә бар иде, аларын хәтерләмим инде. Сүзләре дә төгәл исемдә калмаган, әмма ниндирәк сүзләр иңәнлеген, эчтәлеген, ритмын-көен хәтерлим, бүгенгедәй колак төбемдә яңгырап тора. Шуңа күрә, бозудан курыкмыйча, әкиятне сөйләп бирә алам. Хикәятләргә, әкиятләргә ярлы бер өяздә бу — Ленин исемле кеше турындагы беренче легенда. Минем өчен мужик халкының күңеле белән Ленинга ышанганлыгына бер дәлил ул. Күңеленә җанлы образ булып кергән, үзе ышанган кешеләр турында гына шулай сөйли авыл халкы. Шуңа күрә бу кайгылы көннәрдә аның гади әкиятендәге көлке сүзләрне китерүдән дә курыкмыйм. Шушы әкиятләр белән Ленин мужикның күңел түренә керде. Мин тагы олаучы бер башкорт сөйләгән әкиятне дә китерер идем, тик хәтерләп бетермим. Моның өчен аның сүз тезмәләрен, эчтәлегендәге детальләрне һәм сөйләү ритмын искә төшерергә кирәк. Хәзергә мин аларны хәтерли алмыйм. Башкортларны хәйләкәр һәм усал руслардан яклаган кызыл түрә Ленин турында сөйләгән иде

ул. Өяздә яшәгән халыкның тел һәм ди-аерымлыгы озак еллар буена талаш-ызгышларга һәм хәтта канлы сугышларга сәбәп булган. Надан да, усал да, каты да булганнар. Күптән килгән бу ызгыш әле бетеп җитмәгән. Халыкка аң-белем килеп, үзеңнекеннән башка дингә, үзеңнекеннән башка телгә хөрмәт туганнан соң гына бетәчәк ул. Бу өяздәге рус крестьяннарының күпчелеге өчен башкорт кешесе әле хәзер дә җирәнгеч, түбән бер җан иясе. Алар дуңгыз белән бер савыттан эчсә эчәр, әмма сәламәт башкорттан җирәнеп, савытын читкә этеп куяр. Ә Ленинга русы да, башкорты да ышаналар.

Мин анда Октябрьның җиңүе өчен көрәшнең никадәр каты булганлыгы аңлашылсын дип, өяз турында тулырак сөйләргә тырышкан идем. Кайбер авыл һәм поселоклар аклардан кызыллар кулына алтышар-җидешәр тапкыр күчкәләде. Байтак хуторлар юк ителде. Станицалар янып бөлде, яхшы уңдырышлы җирләр иген чәчелмичә тапталып бетте. Ярым җимерек өяз каласы үлеп бара. Бу җәйне мин шул калада һәм өязнең авылларында булдым. Шәһәрнең үзендәге мәйданнарга һәм тротуарларга үлән үсеп беткән. Йортларның өчтән бере җимерелгән. Мәктәпләр җимерек. Шәһәрнең аларга ремонт ясарлык хәле юк. Сәүдә эше җанланмаган. Бер кооператив кибете генә очраклы товарлар белән сату итә. Башкорт кышлакларының күбесенең көле генә калган. Бу өяздә рәхимсез сугышның табан эзе ярылып ята. Укытучылар ач-ялангач. Авыллардагы мәктәпләр ябылып беткән. Идел буендагы шикелле үк һәм шул елда ук өязне, сугыштан башка, ачлык та кырып киткән. Төрле төркемнәр һәм карашлар бәрелешкән өяздәге бу тын агач шәһәр атлы казаклар тарафыннан ике ай камалып яшәгән. Шәһәрне акларга калдырганда кала халкы кызылармеецларга чолганыштан чыгып армиянең төп көчләренә кушылырга ярдәм иткән. Октябрьның бөтен утын-давылын үз өстенә алган бу өяз Ленинга какшамас ышанычын саклаган. Легендалар белән ул аның күңеленә сеңеп калган, ул ышанычны авыр сугышлар да җимерә алмаган. Алар Ленин турында үз туганын сорашкан кебек, Мәскәүдә булган һәр кеше Ленинның көндәлек тормышын бик җиңел белергә тиеш кебек итеп сорашалар:

— Я, нихәлдә яши ул анда! Кайда яши!

— Икмәк займы турында нәрсә ди!

— Ленинның хәле ничек хәзер! Сәла[illegible], имеш. Аңа теләсә нинди [illegible] ашарга рөхсәт итәләрме, юкмы! Ниләр сөйли! Авыл хакында нәрсә ди!

— Аның җәмәгатен күрмәдегезме!

— Менә Ленинга әйтәсе иде. Ичмасам ул, дөресен дөрескә аерып бирер иде,— диләр.

Бу сорауларны гади бер кызыксынудан да бирергә мөмкин. Мин авылда байтак яшәдем. Крестьяннарның хәйлә белән сорашуларын бик яхшы беләм. Ничек «үз» итеп сорашуларын да беләм. Андый тонны мужиктан бик еш ишетмисең. Аның күңел сандыгы тиз генә ачылмый — йозак салган. Ул аны бик сирәк ача, зур ышанычын бик сирәк чыгара. Ә Ленин өчен ул күңел сандыгын ачты. Хәтта бай крестьяннарның нәфрәтендә дә Ленинның үз сүзендә нык торучы, ярлыларны хәлле итәр өчен тырышучы бер кеше булуына фанатик ышану бар иде. Крестьян аңынча, үз дигәнендә нык тору һәм хуҗалыкчыл булу бик зур сыйфат ул. Авыл халкы үзенең ышанган кешеләрен генә шундый итеп күрә. Бер бай мужик, коммунистлар белән җирле властьны сүгеп сөйләгәндә, көтмәгәндә әйтә куйды:

— Менә волость саен берәр Ленин булса икән!.. Юкса бездә — нибары бер культпросвет. Аннан ни мәгънә! — диде.

Төрле губерна халыкларыннан җыелган бу өяз бөтен крестьян Рәсәенең кечкенә бер чагылышы булып тоела миңа. Аның Ленин турындагы хикәятләре бу исемнең бөтен Рәсәй тормышы катламнарына үтеп кергәнлеген күрсәтә. Ленин турында яңа хикәятләр дә туа тора. Күптән түгел Мәскәүдә булган карт бер крестьян хатыны, без авылда Мәскәүнең нинди икәнен дә, аның театрлары барлыгын да белми идек, дип, авылча гади сөйләп съезддагы бөтен кешенең күңелен кузгаткан. Хәзер инде ул Мәскәүне күргән, дәүләт мәсьәләләрен хәл иткән һәм Ленинга авылның «бәхилләшеп үбүен» тапшырган. Авылга кайткач ул Ленин турында яңа хикәятләр сөйләр. Һәм аның ул хикәятләре, бормалы-сырмалы вак юлларны узып, киң таш юлларга чыгып таралыр. Тарихчылар теләндә дә легенда булып яңгыраячак кешенең тормышы, чын белән әкият аралашкан бу хикәятләр аркылы, туасы буыннарның күз алдына чын булып, ачык булып килеп басар...

«Ленин турында хикәяләр һәм очерклар» дигән җыентыктан.
Мәскәү. «Матур әдәбият» нәшрияты. 1967 ел.

## Әдип Маликов

# ЧИГҮЛЕ КУЛЪЯУЛЫК

ПОЭМА

*Колшәрип авылында яшәүче Җиһангир абзый белән Эмма-Әминә апаның тормышы поэмага нигез итеп алынды.*

**КЕРЕШ**

Ялынды Әминә:
— Алып бар, Җиһангир,
Калам бит абыйны күрми дә...
Россия килене,
ГДР кияве —
Кунакка килделәр Берлинга.

Бер-берен табышкан
Дөньяга килделәр.
Хәтерли Җиһангир барысын да...
Тарихка күмелгән
Әсирлек еллары
Йөгерә шикелле каршына.

Күкләре Берлинның
Бүленгән урталай,
Метролар өзелгән кырт итеп.
Баралар таксида,
Куышып төн белән,
Күргәнне күңелгә беркетеп.

Сүз куша Әминә
Шоферга немецча,
Аңлата тиешле адресын.
Илле ел эчендә
Күп сулар акты бит,
Танырмы бердәнбер абыйсын?

* * *

Бакчада — сары йорт.
Веранда ишеген
Ачты да бер шәүлә, югалды.
Халатын кигәч ул
Күренде яңадан,
Рәтләде күн тышлы диванны.

— Гутен нахт! [1]
— Гутен нахт!
Һәр эшнең үз вакыты —
Немец ул үзгәртми гадәтен...
Кичкенә булмада,
Баш терәп диванга
Көттеләр иртәнге сәгатьне.

Түгәрәк өстәлдә —
Әминә хатлары,
Аталган абыйсы исеменә...
Сәяхәт микән бу
Сихерле үткәнгә,
Әллә соң гаҗәеп төш кенә?

Уйлады Җиһангир
Башыннан кичкәнне,
Бушлыкка юнәлтеп карашын...
Уздыңмы сызгырып
Атта да, җәяү дә
Гомернең җитмеш ел арасын?

**БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК**

1

Җиһангир абзыйның
Тормышы гыйбрәтле,
Булгандыр гөнаһлы чагы да;
Әвәлге заманда,
Уйнатып бай атын,
Чапкан ул Ырынбур ягына.

---

[1] Гутен нахт — тыныч йокы.

Ырынбур шәлләре —
Кызларның хыялы,
Иркәли мамыгы иңнәрне...
Чапкан ул бай өчен,
Көн дими, төн дими,
Кыскартып иң озын юлларны.

Дусларга кыз урлап
Дан тоткан өяздә,
Булса да титулы ярлыдан,
Бирмәгән Рәхим бай
Малаен солдатка,
«Хезмәт ит, Җиһангир, бар»,—
дигән.

Болында — җыр-бию,
Моңая тальяннар...
Уйласаң үкереп еларлык.
Җиһангир кулында
Сабан-туй бүләге —
Каюлап чигелгән кульяулык.

Бәхил бул, Көлшәрип,
Урманың, суларың...
Казарма барын да киртәли.
Башка бер дәүләттән
Кыз урлап кайтыры
Төшенә кермәде микәнни?!

Белгәндер Җиһангир
Окопта ятасын
Күгәргән сохари кимереп.
Немецны каршылап
Туплардан атасын,
Мөгаен, йөргәндер сизенеп.

Бозлана кендегең
Җылытып кар өстен,
Нәүбәтең җиткәнчә һөҗүмгә.
Калалар солдатлар
Сугылган көлтә күк,
Йөзләре охшаган уҗымга.

Барасы юлларың
Озынмы, кыскамы,—
Кайдадыр куела бер нокта.
...Яралы Җиһангир
Лазарет моргында [1]
Сискәнеп уяна тынлыкка.

Ак патша өчен син
Ант иткән үләргә,
Кәгазьгә куелган тамгаң да.
...Үлеп тә караган —
Оҗмахка кермәгән,
Юк икән тигезлек анда да.

[1] Морг — мәетләрне вакытлыча куя торган урын.

Көлшәрип урманын
Гел күрә төшендә.
Бар анда юкагач суйганы,
Чабата үргәне...
Яшереп баеннан
Төлкегә тозаклар куйганы.

Төлкенең төлкесе
Рәхим бай үзе дә,
Батыра җилкәңә тырнагын.
Күпсенә кешедән
Күлләрнең балыгын,
Күпсенә күктәге торнаны.

2

«Көтегез, гүзәлләр —
Ходайның кушканы.
Кайтмасак, сезгә яр табылыр...»
Кердеме, ичмасам,
Төшеңә, Җиһангир,
Әсирлек хурлыгын алырың?

Абзарлар бик озын,
Араннар буш тора,
Атларны алганнар сугышка...
Миче юк икән бит.
Борчылма, Җиһангир,
Җылыныр меңләгән сулыштан.

Санаулы барсы да:
Адымың, минутың...
Ашаган китә тик сакалга.
Хакы бар әсирнең
Типкедә яшәргә,
Хакы юк үз-үзен сакларга.

Тартырсың җигелеп
Немецлар арбасын,
Табарлар я башка әмален.
Тезәләр тәркемгә.
— Мөслимнәр [1], өч адым!
Ни өчен? әйтмиләр сәбәбен.

Яшертен шом йөри:
Куалар Төреккә,
Тамгалап коллыкка сатарга.
Солдатлар кирәк, ди
Камчылы Солтанга —
Каф тавы [2] ягына атарга.

— Мөслимнәр, өч адым!
Кузгалмый беркем дә.
Сүз ала чалмалы козгын да.

[1] Мөслим — мөселман.
[2] Каф тавы — Кавказ таулары күздә тотыла.

Юмалый карт имам:
— Калсагыз бу илдә,
Сез — кулга бер кашык тоз
гына...

Өндиме атарга
Россия ягына
Мөхәммәт өммәте хакына?
Бу фани дөньядан
Ваз кичү яхшырак,
Хыянәт иткәнче халкыңа!

3

Ялчылык итә ул
Гадәте буенча
Череган бер немец баена.
Төшенә Җиһангир,
Башына бер төшкәч,
Мондагы тормышның җаена.

Икмәге кәгазьдәй,
Күренә үтәли,
Бер телем йокмый да тамакка.
Бер казан аш кирәк
Ачлыктан йөдәшеп,
Каешы бушаган солдатка.

Өй тулы нәнкәләр.
Эммасы бик сылу...
«Җитми лә бездәге кызларга».
Яшь немка көн саен,
Яшереп түшенә,
Ак ипи чыгара абзарга.

Ятимә кыз икән,
Иркәлек күрмәгән,
Йөргән ул бер байдан бер байга.
Күзләрен тутырып
Карый да елмая:
Моңайма, янәсе, моңайма

Тутыккан краннан
Су ага чылтырап...
Чылтырый чишмә күк, ялганчы.
Чишмәдән кайтучы
Кызларны туктатып,
Суларын эчәргә туйганчы...

Җимертеп эшли ул,
Әйтмәсен «хуҗа»сы
Урыслар хәрәсән икән дип.
Эммасы бик сылу...
«Ярату» дигәндә —
Тәрҗемә кирәкми икән бит.

Чигүле кульяулык —
Туган як төсе ул,
Кан табы җәелгән алланып.

Чигүен карый да
Соклана Эммасы...
Ирене тулышкан балланып.

Шуклыкка, Җиһангир,
Тәһарәт кирәкми,
Китмәсен эшләрең тирәнгә.
Сизенә калсалар —
Җуярсың башыңны,
Бу сиңа Колшәрип түгел лә.

4

Патшаны туздырып
Очырган Россия.
Бәрелә ялкыны монда да.
«Рот-фронт! Рот-фронт!»
Сизенә Җиһангир:
Европа үзгә болгана.

Качалар әсирләр.
Уяу бул, Җиһангир,
Кучәрдән ычкына дөньясы...
Үлсәң дә илдә үл!
Туган як юлына
Озата яшереп Эммасы.

Бормалы сукмаклар
Эммага бик таныш...
Ай нуры коела җемелдәп.
Нур сибеп шушы ай
Чияле тауларга
Үткәндер Колшәрип күгеннән.

Борылмый кыз бала,
Гел бара, гел бара...
Сарыла Җиһангир иңенә.
Чит дәүләт җиреннән
Кыз алып кайтсаң син
Ни җавап бирерсең илеңә?!

Сиңа бит көн булмас
Кардәштән, дус-иштән,
Кертмәсләр телгә дә исемеңне.
Котыра иблисләр:
«Адаштыр син аны...»
— Ул мәче баласы дисеңме?

Юк, бирмәм бер кемгә,—
Бер полк солдатлар
Күз кысып мылтыктан тәбәсен.
Үләрмен, ичмасам,
Сөюем хак диеп,
Дөньяда бер генә үләсе.

Кардоннар үтелә
Атта да, җәяү дә...
Эммасы әйләнә телсезгә.

Чыктым дип кияүгә
Мәлкәтсез бер татар-юньсезгә.

Бай диеп беләдер...
Чыннан да бай булыр,
Туздырсак Рәхим бай оясын.
Җитте ич заманы
Ярлылар ягына
Борырга гаделлек кояшын.

Уйлана Җиһангир.
Уйлый ул кычкырып,
Аңлата барсын да Эммага.
Баш кага тегесе —
Сөенә немкасы,
Хыялга бирелеп елмая.

Немецлар таялар,
Борылмый Эммасы...
Каршылый Россия җирләре.
Аудара аяктан,
Көйдерә йөрәкне
Сугышның көйдергеч җилләре.

Россия җирләре...
Поездлар туктаган.
— Еракмы, Җиһангир, Бәгелмә?
Ничә көн кайтасын
Белми бит үзе дә,
Көн саен бер җавап: «Тегендә».

— Пропуск?! Документ!
Йолдызлы, мыеклы
Солдатлар текәлә күзләргә.
— Ычкындым пленнан,
Рәхим бай белән мин
Кайтамын исәпне өзәргә.

— Бу кемең, маткаңме?
— Знаешь, абзыкай,
Күчмәсен иягең бер якка!
Россия җире бит,
Ник куркып торырга,
Күрсәтә Җиһангир дулап та.

Уйлый ул эченнән:
«Эләктең, асыл кош,
Тормаслар озаклап сөйләшеп»...
Эммасы кызганыч.
Белмәгән ят илдә
Бик әче була шул күз яше.

Комендант постында
Никахлап йөрмиләр,
«Парлы» дип, документ язмыйлар.
Сөйгәнен Җиһангир
Бер үбә онтылып...
Елмая мылтыклы абзыйлар.

Сөюе чын булса...
Өйрәнсен умачка, катыкка.
Бар икән гөнаһым
Колшәрип каршында —
Кан белән юармын окопта.

Чигелгән кульяулык —
Туган як билгесе,
Күчә ул Эмманың кулына.
Өстендә бик йока...
Ятимә бу кызны
Төреп ал, Россия, туныңа.

— Булачак киләшем,
Теле юк, мескеннең...
— Йөрерсең кияүләп соңыннан!
Бер кисәк табарлар
Рәхим бай ишеге...
Мылтык ал!
Тот җайлап!
Корылган!

5

Йөгәнсез хисеңә
Ияр дә кит, имеш...
Ояңнан чыгарга кем кушкан?
Ярый ла Җиһангир —
Бердәнбер өметең
Исән-сау кайталса сугыштан.

Чигүле кульяулык —
Җиһангир төсе ул,
Бер сынык ак ипи төрелгән...
Таяныр кешең юк,
Үзең дә куләгәң...
Син люмпен-пролетар бүгеннән.

Кайда соң Бәгелмә,
Җиһангир җирләре?
Бар, диде, урманым, күлләрем.
(Хыялын әйткәндер...
Яшергән, әлбәттә,
Юклыгын алмашка күлмәге.)

Вокзалдан-вокзалга...
Эш таба үзенә —
Чистарта вокзаллар иденен.
Тукталып кайчакта,
Атналар буена
Көтә ул поездлар килгәнен.

Шул менә Россия!
Иге юк, чиге юк...
Юк синдә кайгысы кемнең дә.
Белгәне — Җиһангир:
Өмете, борчуы...
Яши ул йөрәкнең түрендә.

«Бәгелмә» диелгән.
Тәрәзсез вагоннан
Төшә кыз ялгызы берешеп.
Итәге бик кыска,
Тезеннән югары...
Калалар аңардан көлешеп.

Вокзалга керә да
Кискәли яулыгын,
Озайта кулмәген чамалап.
Булачак киленне
Ниндирәк язмышлар
Тора икән юлларда сагалап?!

6

Бәгелмә базары.
Сатылар-алалар
Яшереп итен дә, маен да.
Мыж килә жуликлар.
Кычкыртып алдыйлар,
Карамый аеңа-ваеңа.

Шикләнә Эммадан
Яулыклы апалар,
Түгәрәк сакаллы абзыйлар.
Аңлата ым белән,
Белә тик бер сүзне:
«Җиһангир»... Ахыры аңлыйлар.

— Бай, диме,—
Урманга,
Тауларга күрсәтә...
Бай кызы булгандыр, мөгаен.
— Тиф белән яткандыр,
Кискәннәр толымын;
Күрсәтмә андыйны, ходаем.

— «Җиһангир» диде бит,
Башкасын оныткан,
Исемен саклаган хәтердә.
Мәхәббәт сарысы
Чыккандыр йөзенә,
Белми бит, бичара, әйтергә.

— Берәүнең газизе,
Кадерле баласы,
Йөрәктән төшкәне өзелеп...
Җан керә Эммага,
Җыелган халыкның
Хәстәрле карашын сизенеп.

— Җиһангир бар бездә.
— Бездә бит икәү дә...
Кил, утыр, менә бу арбага.
Илтәләр Кәшергә.
Каеннар сап-сары...
Моңаеп беренче кар ява.

7

Чигелгән кулъяулык —
Җиһангир бүләге,
Күчә ул куллардан-кулларга.
Таулары чигелгән,
Елгасы, күлләре...
Өйләре тералгән урманга.

Танымый берәү дә...
«Җиһангир» дигәне —
Карт солдат, борынгы инвалид.
Йөзендә үкенеч:
«Әй, кызым, яшь узган,
Килгәнсең дөньяга соңгарып».

Мәтрүшкә аңкытып
Мунчасын ягалар.
Әйрәне бик тәмле тансыкка.
Йокларга салалар
Эмманы татарча
Кабарган түшәккә, ястыкка.

Бирәләр яулык та,
Кыйшайган түфләнең
Куялар үкчәсен каеннан.
Урманга, суга бай
Кем булыр бу якта,
Булмасмы Миңлебай ягыннан?!

Йөртәләр Эмманы
Авылдан-авылга...
Файда юк кайгырып, җылап та.
Сихерле таулары,
Зәп-зәңгәр урманы...
Колшәрип күренә еректан.

* * *

Хат язган Җиһангир:
«Киленне рәнҗетми
Каршылый күрегез, туганнар.
Кайтырмын әйләнеп
Дошманны җимергәч,
Яшелгә киенгәч урманнар».

Чигүле кулъяулык —
Җиһангир пароле,
Ураган чит дәүләт җиреннән.
Түгелгән аңарга
Россия таңнары,
Халыкның хыялы чигелгән.

## 1

Җиһангир карт инде.
Үткән ул җәяүләп
Ничәмә дәүләтләр арасын.
Йөргән ул иртәп
Туган як моңнарын,
Иртәп йөргән күк баласын.

Кыйбласы татарның
Гаделлек ягында,—
Чал тарих үзенчә сөйләсен...
Халыклар гомергә
Омтылган хөрлеккә,
Саклаган туганлык йоласын.

Җылыткан Эмманы
Шул изге тойгылар,
Мөлаем карашы халкымның.
Күңелең саф икән —
Кадерле кеше син,
Кирәкми зәбәрҗәт-алтының.

Җиһангир кайтуга
Эминә киленнең
Татарча ачылган телләре...
Балалар үстергән
Имезеп күкрәген,
Күргән ул башкалар күргәнне.

Гөнаһсыз сабыйлар...
Син шулар аша бит
Тоясың яшәүнең бар ямен.
Күзләре зәп-зәңгәр...
Күчкәндер аларга
Колшәриф күгенең зәңгәре.

Чияле тавы бар
Йөгереп уйнарга,
Тәгәрәп уйнарга — болыны.
...Төс алды үзенә
Эминә киленнең
Тасмалап үрелгән толымы.

Күчәнә замана
Бер чордан бер чорга,
Юлларда сынгалый күчәр дә...
— Җир-сулар мул булсын,—
Димләде Җиһангир
Дусларын колхозга күчәргә.

Урагын урдылар,
Өйрәнде Эминә
Байларга көлтәне өздереп.
Уйламыйм дисәң дә
Туган ил — канында,
Юксыну куя шул сиздереп.

Чигүле кулъяулык...
Офыгы, таңы бар,
Чигелгән күп төрле төсләрдән.
Рәссамнар шикелле,
Өретеп хыялга,
Эминә болытлар өстәгән.

Мамыктай болытлар...
Мавыгып кайчакта,
Китәсез иярәп җилләргә.
Болытлар, болытлар,
Чикләрне белмичә,
Күчегез илләрдән илләргә.

Коелсын мул булып
Шифалы тамчылар,
Һәммәбез бер кояш баласы.
Көн арты көн уза.
Һәр иртә үзенчә,
Искегә охшамый яңасы.

Күршедә — зур мактап.
Өйрәтте Эминә
Немецча сөйләргә, укырга.
Телеңнән төшкән сүз —
Күңелгә күчкән сүз,
Ничә күз ымсынып утыра!

## 2

Җиһангир карт инде.
Чүкече, балтасы
Гомергә кулыннан төшмәгән.
Чүкеп тә, юнып та
Рәтләгән дөньяны —
Иләнә ул муллык өстәгән.

Кердеме, ичмасам,
Төшеңә Җиһангир,
Утларда янасың яңадан?
Эленке яралар
Җөйләнеп бетмәгән,
Кан тама эленке ярадан...

Керәләр фашистлар
Тынлыкны җимереп,
Киләләр җимереп хыялны.
Куя ул балтасын,
Җыена походка
Җиһангир — Дойчланд [1] кияве.

[1] Дойчланд — Германия.

Кайгыда Әминә.
Шулмени туган ил —
Халыклар иреген таптаучы?
Мин ана ялварам:
Ябыгыз, кешеләр,
Сугышның хурлыклы капкасын!

* * *

Яратты Әминә
Бормалы Зәй буен,
Йөрделәр карлыган җыярга.
(Юк иде ул чакта
Шәһәри Әлмәтләр,
Яшәде бары тик хыялда.)

Күңелгә хуш килгән
Җырлары өчен ул
Бурычлы Колшәрип халкына.
Үз итте бу якның
Урманын, суларын,
Җан өзгеч балалар хакына.

Хәстәрле улларын —
Бәхетен озата...
Йөрәге төшә күк өзелеп.
Хәвефле моң белән,
Колшәрип күгеннән
Торналар очалар тезелеп.

* * *

Син, ярман кияве,
Улларың иярттеп,
Китәсең сакларга илеңне.
Озата аларны,
Яралы кош сыман,
Озата Россия килене.

Әминә кулыннан
Коела әйберләр,
Йөри ул абына-сөртенә.
Каһәрле үзенең
Шул илдән булуын,
Чачләре агара бер төндә.

Чигүле кульяулык —
Бер түгел, өч икән,
Кузгалды өч солдат бүгеннән.
...Түгелгән аларга
Колшәрип таңнары,
Туган җир туфрагы төрелгән.

3

Кузгалды Россия,
Нәфрәте, ярсуы
Ашылды бер чиктән бер чиккә.

...Көч бирде аңарга
Җиһангир сүзләре:
«Бирешмә, Әминә, ничек тә».

Эшләде җигелеп,
Ир заты калмагач,
Бәйләде ярасын эш белән.
Бер көнне аңарга
Дәштеләр «немка» дип,
Ишетте шул сүзне күршедән.

Халыкның ачуы
Чамадан артылган.
Юк инде чарасы башкача.
«Башын өз, ходаем,
Шул мәртәт Гитлерның»...
Ялвара Әминә татарча.

Язмасын алырга
Нәфрәтен халыкның,
Бергә күр ни газап күрсәң дә.
Кечкенә шатлыктан,
Иң олы кайгыдан
Куймасын читләтеп күршең дә.

4

Кичергән Җиһангир
Җиңүләр шатлыгын...
Улларын сугышта калдырган.
Әйләнә төлсезгә
Әминә яңадан,
Сүзләрен оныта кайгыдан.

Китсенме җыенып
Шул килгән юлыннан
Уллары каберен эзләргә?!
Оныклар бар әле,
Оныклар үскәндә
Булмый ич сөйләшми түзәргә.

* * *

Сер бирми Җиһангир:
— Яшибез патшача,
Кулда көч, кесәдә акча бар.
Үткәрдек алтын туй...
Чит дәүләт кызына
Өйләнә бары тик патшалар.

Россия килене,
ГДР кияве —
Барганнар парлашып Берлинга.
Сулары ширбәтле,
Үз суың татлырак,—
Беләсең еракка йөрми дә.

1968

## Фатих Хөсни

# ГЫЙЛЬМЕНИСА

ПОВЕСТЬ

## I

Сугыш арты өзек еллар иде. Колхозлар хуҗалыкларын көч-хәл белән генә тарталар, ләкин тарталар, шул ук вакытта шәһәрне дә туйдырып торалар. Аннары тагы, яшерен-батырын түгел, күршеләрдәге туганнарына да өлеш чыгаралар иде. Шуның да өстенә тагын, колхозларда вәкил өстенә вәкил утыра торган чак, колхоз председателенең гел тыкырдатып-ашыктырып торучы вәкил белән, гел кулын сузып, «җитмәгән җирен ялгап җибәрүне» сорап торучы гади колхозчы арасында, нишләргә белмичә, өзгәләнгән чаклары иде.

Мин үзем ул елларда өлкә газеталарының берсендә әдәби сотрудник булып эшли идем. Колхозлар һәр төрле вәкилләргә бер дә аптырамаган бер вакытта, алары янына тагын, газеталардан булсын, радиокомитеттан булсын «үз хәбәрчеләре», «үз корреспондентлары», берсеннән-берсе уздырырга тырышып, эшләгән кешеләрнең аяклары арасында әледән-әле буталып йөргәндә, кунак өстенә кунак дигәндәй, «Якты көн» исемле колхозга без фәкыйрегез килеп төште. Көне яктысын якты да, әмма колхозның экономик хәле бик үк шәптән түгел иде. Тик хәзергә мин ул турыда түгел, мин сөйләргә җыйнала торган хәл бөтенләй башка: ял түгел, бәйрәм түгел, гап-гади көннәрнең берендә, кулыннан эш килердәй кешеләрнең бөтенесе диярлек кырда, фермада, каралтыкура юнәтү эшендә мәш килеп йөргәндә, әйтәм бит, тавык артыннан чыккан күкәй кебек, түп-түгәрәк, гап-гади бер көнне салам түбәле искерәк кенә бер өй түбәсендә — бөтен авылына бер өйдә — кыекка нытытылган кызыл флаг җилфердәп тора иде. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, бу хәл мине бер үк вакытта бик кызыксындырды да, аптыратып та калдырды: нилектән икән бу? Их, әгәр теге «уңай хәлләр» төяп кайтырга дип тыгып килгән блокнотка дөньяда юк берәр тамаша тотып кайтсам?

Колхоз идарәсе кешеләреннән — килешсә, килешмәсә — иң элек шул турыда сорашырмын дип керсәм, мин сүз башлаганчы, монда үзеннән-үзе сүз шул турыда кузгалып китте.

— Бу Гыйльменисаттәйгә хат артыннан хат, телеграмма арты телеграмма ташып бушый алмыйм бүген,— дип зарланган да, мактанган да кебегрәк итеп әйтеп куйды хатлар, газеталар белән күбенгән сумкасын муенына асып кергән колхоз почтальоны. Сумкасыннан колхоз идарәсенә дигән газета-журналларны бушатты да сүзен янә дәвам итте,— җитмәсә тагы, ике җирдән берьюлы акча да килеп төште,

ярыйсы гына сумма болай, кая куярга белмичә аптырар, нишләргә инде миңа ул Гыйльменисаттәй белән?

Почтальон кызның сумкасы кебек, үзенең дә авызы жырык булып чыкты, күренеп тора, юл уңаеннан аның мондагылар белән бераз шаярып сөйлисе килә иде бугай. Ләкин председатель Мөрсәлимов бик житди иде бүген — башка көннәрә өчен җавап бирә алмыйм.

— Аптырама, бөтенесе заслуженно Гыйльмениса түти өчен. Килеп торсын акчасы, янчыгы табылыр,— диде ул кырт кына.

Әлбәттә, председательнеке дөрес, акчасы булса — урыны табылыр. Почтальон кыз, озак бәхәскә кереп тормыйча, чыгып китте. Мин эшнең нәрсәдә икәнлеген беркадәр чамаладым. Ниндидер бер Гыйльмениса атлы карчык турында барды сүз. Әйтүләренә караганда, аңарга житмеш яшь тулган, имеш, хат-телеграммалар әбине шул житмеш яше белән котлап ява булса кирәк. Председатель Мөрсәлимовның сүзләреннән мин тагын шуны да абайлап калдым: үз вакытында ярыйсы гына эш күрсәткән кеше булса кирәк ул Гыйльмениса карчык дигәннәре.

Инде чират миңа да житте бугай, дип, авызымны ачарга гына торганда, бер як читтә, үзенең кәгазьләр һәм папкалар белән тулган шкафлары алдында, әлегә хәтле сүзгә-өнгә катышмый утыручы баш счетовод (аны «бухгалтер» дип тә йөриләр, ә ул үзенә күбрәк ошаганга күрә үзен «баш счетовод» дип йөртә), әллә ни зур мәгънә бирүдән түгел, шулай да уяулык күрсәтүнең бер вакытта да зыян түгеллеген искә алып булса кирәк, аптыраганнан кузгаткан бер тон белән:

— Акчасы-телеграммасы аның чорт с ним, токымы шулай Нух диңгезе булгач, йөзә бирсен, эчен төртеп тишмәс,— дип, элек председательне куәтләгән булды һәм шундук, житди политик мәсьәлә чишкән кебек, үтә житди тавыш белән ялгап китте,— менә сез шуны әйтегез, кайсыдыр бер дурагы, шимбәне үтмичә, жомганы көтмичә, дигәндәй, аның өй түбәсенә кызыл флаг менгезеп кадаган. Значится, политически төс бирмәкче Гыйльмениса карчыкның житмеш еллыгына. Ә бу соң сыямы икән берәр төрле капкага? Соңыннан, энәдән дөя ясап чыгаргансыз, дип сүзе булмасмы икән, дип әйтүем.

Председатель бу юлы, хәтта озак сузып торырга теләге юклыгын сиздерергә тырышып, берьюлы өзеп салды:

— Сыяр. Гыйльменисаттәй кебек борыны белән боз тишеп гомер иткән, Гыйльменисаттәй кебек уллар-кызлар үстергән кешене, әгәр хәлемнән килсә, музейга куяр идем әле мин. Ә теге аның өе түбәсенә флаг менгезеп кадатучы «дурак»ның кем икәнлеген беләсең бик килә икән, бел: аны мин әйттем, комсорг Җавит эшләде.

Мөрсәлимов исте-осте юк чагында кинәт миңа борылды, аның чак кына кысылыбрак торган соры күзләрендә көч һәм халык арасында озак еллар эшләүдән жыелган хәтәр хәйләкәрлек янып тора иде:

— Менә корреспондент иптәш әйтеп бирер тагын без белмәгәннәрне,— дип башлады ул, сүзләрен юри әкренәйтеп,— яшь-яшь көенә ике ирдән калып — берьюлы ике ирдән калганнар турында сүз бармый, берьюлы өч ирдән калганнары да бар аның безнең авылда — элек бер оядан өч бала белән калып, аларны үстереп кеше иткәч, аннары икенче оядан тагын өчне итәгенә төяп тол калган, и шул атасыз ятимнәрне бер ялгызы, кешегә орчык эрләп, әвен сугып, үзе киенмичә киендереп, тамагын, өстен-башын карап, укытып, канат-каурый куеп дөньяга очырган, и шуның да өстенә колхоз чыкканнан бирле колхозында кая куйсалар — шунда эшләп килгән, и шуның да өстенә яше житмешкә житкәнче шушы мәшәкатьле дөньяда без яшьләр белән бер аяктан диярлек атлап килгән Гыйльменисаттәйнең өй түбәсенә, аның бәйрәмен котлап кызыл флаг менгезеп кадау, йә, әйтегез, кайсы контрның тегермәненә су кою булыр икән? Дөрес, безнең колхозда моннан башка да эшләр бар, без аларны онытмыйбыз, иллә-мәгәр кешеләрне онытырга да хакы-

быз юктыр дип уйлыйм мин. Дөрес уйламыйм икән, әнә корреспондент иптәш утыра. Казанның үзеннән чыккан кеше, әйтсен, тәзәтсен, тиешле таба икән, «Якты көн» колхозының председателе Мөрсәлимов дөрес эшләми, дип газетасында язып чыгарсын, сүзем юк.

Мин аның мондый ихлас күңелдән һәм чын-чынлап кешене яклап әйткән сүзеннән тәмам әсәрләнеп, авыз эчемнән ниндидер мәгънәсез ымлыклар ясаудан узмыйча утыргач, председатель тагын да канатланып китеп, соңгы тәкъдимен үк ясады:

— Көндез сез үз ирегегездә, иптәш корреспондент. Йөрегез, күрегез, телисез икән, кешеләр белән сөйләшегез. Кичкә урыныгыз — безнең мәҗлеснең түрендә. Чакыру шушы: бергәләп, безнең хөрмәткә лаеклы колхозчыбыз Гыйльмениса түти Рахманованың җитмеш яшьлек юбилеен бәйрәм итәрбез. Кызыксына калсагыз, соңыннан аның гомер юлы, биографиясе белән дә танышырсыз. Бик тә гыйбрәтле аның биографиясе.

Бу кадәр кистереп әйтүгә каршы килә аламмы соң? Кунак — хуҗаның ишәге, дигәндәй, бу очракта ишәк булудан да яхшысы булмас, дидем эчемнән. Ләкин, ишәк булу белән бергә, мин әле бит кеше дә идем. Кичен булачак мәҗлесне көтеп, күләгәле чоланда баш астыма ястык, ястык астына блокнотымны салып, йокы симертергә ашыкмадым. Үз күзләрем белән авылны, колхоз хуҗалыкларын караштыргалап йөрергә, туры килсә, җайлап кына кешеләр белән дә сөйләшкәләргә дип, урамга чыгып киттем. Авыл, шома хикәяләрдә язылганча, коеп куйган түгел, сугыш арты еллары авылы икәнлеге бөтен җиреннән күренеп тора иде. Әмма шулар арасында салам түбәле бер өй — бары тик бер генә өй башында җәйге җилдә зур ут күбәләге кебек җилфердәп торган кызыл флаг, бер үк вакытта, гаҗәп тә, серле дә булып, әледән-әле минем күз алдыма калкып килеп чыга торды.

## II

Клублары, әлбәттә, зур түгел иде, ул чакларда күп авылларда шулай булганы кебек, монда да иске мәчеттән бозып әтмәләгән тәбәнәк кенә бер бина, аның каравы стеналарына плакат һәм лозунгларны бер дә җәлләмәгәннәр. Бер караганда, ник кирәк булды икән монда сәхнәгә кызыл җәйгән президиум өстәле сузып кую? Ник кирәк трибуна? Ник кирәк башы китек графинга су тутырып кую? Күй зал дигәненә буйдан буйга сузып өстәл. Берсе җитмәсә, икенчесен китереп ялга. Кунагың күбрәк булырлык икән, икенчесе янына өченчесен, дүртенчесен тез. Тигезле-тигезсезрәк чыгуы мөмкин, була бирсен. Өстәлнең ике башында ике самоварың гөҗләп утырсын. Чыңлап торсын чынаяклар. Кайберәүләрнең, әйтик, чәй белән генә сусыны басылмый икән, андыйларны да кырын какма, елына күрә җылы шулпа, дигәндәй, мыек чылатырлык кына «тегесе» дә йөгереп торсын. Ә президиум нишли? дип аптырап калучылар булса, баш-күз әйләнгәнче аларга да турысын әйтеп калыйк: туктагыз әле, егетләр, атна башында, шимбә азагында халык туплап шаулаша торган гадәти җыелыш түгел бит бу. Әгәр беләсегез килсә, бу — бәйрәм, кеше бәйрәме һәм күтәр син әнә шул бәйрәм итүчене «гарше-көрсигә». Анысына ук буең җитми икән, күтәр һич югы бөтен кешенең күз алдына — сәхнәгә. Бер үзе бер президиум булып утыра бирсен. Бер үзе бер президиум булып утыруны килештермәсә, янына үзе белән бергә гомер иткән — җәфаны, шатлыкны бергә кичергән кордашын менгезеп утырт. Күңелсез булмасын өчен юбилярның бер үзенә бер самовар гөҗләтеп куй. Әгәр кордашы белән икәү икән — икесенә бер самовар. Татарны чәй белән куркыта алмассың, эчә алган чаклы эчсеннәр. (Әгәр инде бөтенесе дә

түгәрәк булсын дисәң, кагылсалар-кагылмасалар — алар эше, самовар артына — ышыккарак ящереп, «тегесен» дә куй.) Ә үзең, авылның нинди генә алыштыргысыз тоткасы булма, әйтәсе сүзеңне моннан, кеше арасыннан торып әйт — юбиляр сиңа хезмәт күрсәтүче түгел бүген, син аңарга хезмәт күрсәтүче! Ә бирәсе бүләгең булса, анысы өчен купмый булмас инде, шау-шусыз гына менгезеп бир, зинһар, кирәкле сүзен дә әйт. Ә чәйне рәхәтләнеп коя бирсеннәр, моңа хәтле чәй эчеп бераүнең дә Каспийга агып киткәне юк.

Дөресен әйтим, юбиляр Гыйльмениса түтинең салам түбәле өй башына кызыл флаг менгезеп кадарга башлары житкән бу авылда үтәчәк юбилей кичәсен дә, чама белән, шулайрак булыр дип күз алдыма китергән идем мин. Юк, алай булмады. Китте стандарт. Китте китаптан яки газеттан күчереп алган цитаталар. Китте тешкә тия торган мактау сүзләре. Юбилярыбыз Гыйльмениса түти — яхшы ук бөрешеп калган, иңбашлары төшкән, күз төпләрен жыерчыклар баскан, тешләре рәтсезлектән иреннәре эчкә батып кергән, шунлыктан булса кирәк, сөйләшмәскә, сүз әйтмәскә тырышыбрак утыручы тыйнак кына бер әби булып чыкты. Ләкин күзләре — нур ук чәчмәсә дә, әле тоныкланырга-сүнәргә өлгермәгән һәм әле тиз генә бирешергә җыйналмый да торган үткен, беркадәр хәйләкәррәк, бу шау-шуга бик ук ышанып та җитмәүче, сизгер, җылы карашлы һәм бик-бик күпне күргән күзләре карчыкның әле бөтенләй үк тузмаганлыгын, яшәү дәрте көчлелеген, болай олылаудан яхшы ук нык сөенгәнлеген, шул ук вакытта бу шаушудан, бу купшы сүзләрдән, бу бүләкләрдән башы әйләнеп, аптырабрак та калганлыгын раслап тора иде. Мин тагы шуны да сизеп алдым: бу шау-шу уңае белән балаларын һәм балаларының балаларын күрүдән Гыйльмениса түти әйтеп бетергесез куанган, хәтта бу вакытывакыты белән мәзәк хәлләргә дә барып житә иде: әйтик, аның эшчәнлеген билгеләп, фәлән-фәлән оешмадан, районның фәлән учреждениесеннән махсус жибәрелгән оратор, кызып-кызып, Гыйльменисаттәйнең узганын, хәзергесен, балалар тәрбияләп үстерүдәге тырышлыкларын санап адрес укый, ә Гыйльмениса түти, бу сүзләргә бөтенләй игътибар да итмичә, Казаннан кайткан кызы Фасиләсенең кулын үз кулларына алып, кунак кулларының аклыгына, йомшаклыгына исе киткәндәй, сыпыргалап утыра. Шулай булмыйча соң, беренче ире Гаптелбаридан туып калган кызы икән ич, ике яшь ярымлык кына булып калган әтисеннән. Кеше балалары өстеннән төшкән искене рәтләп киереп үстергән анисе, ә хәзер әнә нинди ханым-солтаным булып утыра кызыл япкан президиум өстәле артында. Алланың биргәненә шөкер, кияве зур урында эшли, ә шулай да кайнанасының бәйрәменә жибәргән, әле нинди бүләкләр белән... Шул турыда уйлый Гыйльмениса.

Сораштыра торгач тагын шуны да белдем. Гыйльмениса түтинең алты кызыннан өчесе үзләре килгән, калган өчесе, төрле сәбәпләр белән үзләре килә алмаганлыктан, бүләген-бүктәрен күтәртеп, житкән кызларын, буй үстереп килүче малайларын жибәргәннәр, бу соңгылары өчен беркатлы карчык аеруча куангандай күренә иде. Баламның баласы — балдан татлы анасы, дип көйли-көйли, берсе артыннан икенчесен алдына алып сөяргә дә сөяргә иде дә бит, икенче буын тармаклары булып киткән һәм үзләрен инде бик үскәнгә санаган яшьләр соң синең кытыршы куллы әбиең алдына кереп утыралармы.

Кичтән клубта булган ыгы-зыгыдан болай да башы әйләнеп кайткан Гыйльмениса түтинең моңа хәтле ялгызы гына яшәгән кечкенә өендә иртәгесен олылы-кечеле берьюлы жиде-сигез кеше кайнаша башлагач, шуның янына тагын күршеләре дә, керә-чыга йөреп, кайсы хәл белә, кайсысы чит-ят жирдән кайткан кунаклар белән кызыксынып, шау-гөр килергә тотынгач, бөтенләй зиһене таралган. Әле чәй куеп жибәрмәкче булып, самовар колагына барып ябыша, әле урта бер

җирдә самоварын онытып калдырып, кергән күршеләренә юбилей бүләкләрен күрсәтергә тотына иде.

Шул ыгы-зыгы арасына — бик кирәкле кишер яфрагы — мин дә килеп кердем. Нишләмәк кирәк, ачып кергән ишектән шундук борылып чыгып китү дә мөмкин түгел иде. Шулай да мин Гыйльмениса түтинең юбилей ыгы-зыгысыннан, кунак-төшемнән һәм өстәвенә тагын, әлеге теге Фасиләсе нәртеп кайткан, күп сөйли-сораша торган бәйләнчек оныгыннан нык кына арганлыгын шундук сизеп алдым. Дөресен әйткәндә, минем сүз дә аз булмас, һәрхәлдә, аяк өсли генә сөйләшә торган түгел иде. Колхоз председателе Мөрсәлимов әйткән тәкъдим истә нык саклана, бер-ике көн кайдан килеп — кая китмәгән, мин Гыйльмениса түтинең, кунаклардан арынып, бераз тынычланып калуын көтәргә булдым. Һәм оттырмадым. Карчыкның куанычы куенына сыймый, теге көнне килгән бүләкләр өстенә тагын, идарә карары нигезендә, аның ишек алдына фермадан бүләк тана да килеп кергән иде.

Берничә көннән ул мине бөтенләй яңа кунак итеп (теге көнне ыгы-зыгы аркасында рәтләп күзенә дә чалынмаган булсам кирәк!), самовар җырлатып, чәй табынына шәһәрдән кайткан затлы күчтәнәчләрен куеп, барлык башыннан кичкәннәрен сөйләп бирде. Әлбәттә, авылдашларыннан, белгән-күргән исән кордашларыннан да сорашкаладым. Минем бурыч хәзер шуларны, түкми-чәчми, укучыларга җиткерү. Чынлап та, гыйбрәтле Гыйльмениса иде бу.

## III

Безнең бу егерменче йөзне башлаганда, Гыйльмениса егермедән ашкан кыз була, бик аһ итәрлек чибәрләрдән саналмаса да, үз тиңнәре арасында матур кызларның берсе исәпләнеп йөри, буе-сыны коеп куйган кебек, чәч тәңкәләрен чыңлатып, вак-вак атлап чишмәгә суга киткәндә, бүрәнә өсләрендә тезелеп утырган карт наяннар, инде әллә кайчан өйләнгән булганлыктан, кызга бик төбәп карарга яхшысынмасалар да, берсенә-берсе сиздермичә, эчләреннән генә, «җитте бит кыз да Әлмөхәммәт абзыйда, насыйбы кем икән дә, кайсы бәхетлесенең куенына кереп эрер икән!» дип вәсвәсәләнеп калалар иде. Килешле буй-сын янына тагын каш-күз дә килгән, озын керфекләре китапларда язылганча, кара күзләрен саклап ук басып тормасалар да, шулай да үз урыннарын беләләр, уйнап-сикергәләп кыланырга өйрәнмәгәннәр. Әйе, кыз бик тыйнак күренә тыйнаклыкка да, шулай да яшьлек яшьлек инде. Җитмәсә җиле дә тыйнак түгел авыл җирендә. Кайчакта шулай, болында печән җыйганда булсын, тау буендагы кичке уен вакытларында искәрмәстән генә исеп, кызның башындагы яулык читен ачып ташлый, шунда аның пөхтә итеп үрелгән һәм чәчне тартып, басып торсын өчен тагылган көмеш чулпылы калын толымнары күренеп кала... Алай гына булса бер хәер иде, кайчагында түгәрәк ак муенының бәләкәй генә бер «уч төбе» дә ачылып китә. Ходавәндә, шул минутларда син инде күрми күргән авыл егетләренә, «аһ!» дип, шашынып, бер кычкырып җибәрүдән тыелып калу өчен күркәм сабырлыклар бир!

Озын сүзнең кыскасы, кыз нәкъ үз ботагында, кояшның күзе астында пешеп җиткән алма, акылы-фигыле дә макталып телдән төшми, эшкә дә уңган, әйтүләренә караганда, абыстайдан укып кына булса да «китапны су урынына эчә», шуның янына тагын — бусын бәлки көнчелектән дә әйтә булганнардыр инде — егетләр хатын килештереп язарлык каләм дә кыштырдата белә, имеш.

Сездә дә шундый бер сорау туа торгандыр, минем үземдә дә беренче карашка андый сорау бик туды: шундый кызарып пешкән алма булгач, җитмәсә тагын авылда бер Әлмөхәммәт бай кызы да икән, нишләп соң ул егерме ике, егерме өч яшькә хәтле гел үз ботагында —

әтисе өендә утыра? Нишләп аңарга, өйләнергә теләп, яучы җибәрмиләр? Яки соңгы исәп — кара исәп: нишләп аны берәр карчыгадай чая егет, каз бәбкәсен тибеп алып киткән тилгән кебек, көпә-көндез «тибеп» алып китми? Ул елларда безнең татарда андый эшләрдән качу булмаган бит! Тора-бара аңлашылыр, туктагыз, сез мине бүлдермичә, белгәнемне-ишеткәнемне әкрен генә тезәргә ирек бирегез.

Моның, әлбәттә, сәбәпләре күп булгандыр, хәтта безгә мәгълүм булганы да берничә. Беренчедән, Гыйльмениса, баш очында ничаклы гына чая карчыгалар үтәли-сүтәли кисешеп очканны сизмәсен, каз бәбкәсе кебек түгел, каз бәбкәсе кебек «пи-пи», каз бәбкәсе кебек юаш кыз булмый. Ул үз дәрәҗәсен белә, кирәк-кирәкмәс урында ихахайлап чапмый, теләгән-теләмәгән кешене кулына якын китерми, кичке уеннарга сирәк чыга, чыкса да, вакытында һәм берәүдән дә озаттырмыйча, үз өенә кайтыр юлны үзе табып, тизрәк кайтып китү ягын карый.

Икенче сәбәп: үз ишләре арасында иң чибәрләрдән берсе буларак, юкка-барга борылып карамау да бар, муенны-башны бик текә тота. Бу текәлек вакыты-вакыты белән тәкәбберлеккә үк үсеп җитә. Һәрхәлдә, син аңарга, күктән йолдыз ук чүпләп бирә алмасаң да, җирдәге йолдызларның яктырakларын тотып китер. Гыйльмениса да кеше ич, башка чибәрләргә хас борын күтәрү нишләп анда гына булмыйча калсын, ди?

Өченче сәбәп — һәм бусы бичара кызны иң аптыратканы — Гыйльменисаның авылда бер Әлмөхәммәт бай кызы булуында. Ах, кайдан гына килеп чыга икән бу байлык та фәкыйрьлек һәм шулар нәтиҗәсендә килеп туа торган тигезле-тигезсезлек! Нинди генә бәхетсезлекләргә сәбәп булмаган да бу, күпме генә гашыйкларны кан-яшь түгәргә мәҗбүр итмәгән. Без генә, безнең яшьләр генә моны хәзер белмәгәнгә салышабыз. Әлбәттә, дөньялар, гореф-гадәтләр бүтән хәзер. Ләкин шулай да — хәтта хәзерге көндә дә — берәү дә үзенең карап үстергән кызын әтисе акчасына ялтырап йөри торган, үзенең кулыннан нинди дә булса эш килмәгән «шома» пижон кулына ансат кына тоттырып җибәрмәс. Ә ул чагында, байлык һәм фәкыйрьлек кешеләрне урталай аерып торучы койма хезмәтен үтәгән ул заманда, үзен авылның өстен катламына калкып чыккан бердәнбер «Әтәч Фәхри» итеп исәпләүче, тәкәбберлеккә алай тәкәббер булмаса да, үзен бүтәннәрдән берничә башка югары тотучы Әлмөхәммәт кибетченең хәленә кереп карагыз инде сез. Үзенең күз алмасы кебек карап үстергән бердәнбер Гыйльменисасын капка каккан һәрбер яучы-камчат бүреккә тоттырып җибәрә аламы соң ул?

Шулай да, никадәр генә авылда бер бай булма, кызың исә никадәр генә «сусыз кашык белән суырып йотарлык» булмасын, яшьлек законы үзенекен итә икән: шушы ук авылның Хафиз атлы бер егете, әйтергә кирәк, бик алай асыл кошлардан булмаса да, ярый торган ике аяклы, ике куллы, әмма җырлый яки бии башласа авылда берәүне дә алга чыгармаучы, шул һөнәрләре өстенә тирә-күрше авылларда сабан туе саен батыр калып, Хафиз көрәшче дигән даны чыккан, шуннан башка тагы картаеп хәлсезләнә башлаган бер әнисе, салам түбәле бер өе, берничә торык каралтысы һәм бер арык сыеры, дүрт-биш сарыгыннан бүтән терлек-туары булмаган бер егет белән әлеге безнең Гыйльмениса-«пешкән алма» арасында күзгә күренми торган ефәк җепләр — мәхәббәт җепләре үрелә башлый. Әлбәттә, башта бик яшертен рәвештә, сакланып, кеше теленә керүдән үтә куркып кына. Монда безнең Гыйльмениса туташыбызга әлеге шул сабак абыстаена йөргәндә ничек кирәк алай, кубесенчә үз тырышлыгы белән эләгеп калган «каләм кыштырдату» һөнәре дә, әлбәттә, ярдәмгә килә. Карагыз әле сез яшьлек, мәхәббәт дигән нәрсәне. Кеше күзенә күренмәс, ә ташны ярыр.

Ташны гынамы соң! Авыл өстендә бер тулган ай булып та моңа хәтле үрелеп бераүнең дә буе житмәгән Гыйльмениса «тиң тапмас»ны әйт әле син. Иөрде-йөрде дә зәңгәр күкнең ялгыз чулпаны булып, кәне житкәч, аргы оч күпер төбендәге шул салам түбәле Хафиз өенә төшеп кунакламасынмы! Хәйләсен әйт әле син, бары тик гашыйк кешеләр генә мондый беркатлы була ала торгандыр: кибеткә тозга дип кергән Хөбби карчыкка — әлеге шул керәшче Хафизның аны-моны абайламас карчык әнисенә — тоз төргән кәгазь почмагына ике-өч авыз сүз «тырнап» жибәрә безнең Гыйльменисабыз: «Хафиз, бүген кич сезнең буй әрәмәлеккә тана эзли төшәм». Язган язуы бары шул, ләкин күнелендәге планы — кыек атып туры китерү: тәмәке төрер кәгазьгә аптырап йөргән Хафиз тоздан бушаган бу кәгазьгә, әлбәттә, ташланачак һәм, ихтимал, әлеге сүзләрне күреп алуы да мөмкин. Бусын күрмәсә, иртәгә тагын икенчесен — ак муенлы чуар тананы «югалтып», аны эзли төшәргә кирәк булыр. Вакыты житкән, дәрте кузгалган, ничек тә эзләп табар!

Моңа хәтле дә булгандыр, әйтмәгез «булмагандыр» дип, тоз кәгазенә язылган булмаса, күңелләренә, күзләренә язылганны эндәшмитынмый гына «укып» йөргәннәрдер — яшьләрнекен белмәссең. Ә бу тоз кәгазе почмагына язылган сүзләр үз нәүбәтләрендә шулай ук үз эшләрен эшләделәр. Шул кичне, авыл өсте кызгылт шәфәкъ һәм яшькелт йолдызлар белән тулган шул дымык кичне, керәшче Хафиз белән Әлмөхәммәт бай кызы Гыйльмениса кичнең кич буе әрәмәлектә ак башлы тана эзләп йөрделәр, ә ул, юньсез хайван, бактың исә, әллә кайчан Әлмөхәммәт байның абзарында башка терлек-туар арасында жай гына күшәп ята, имеш.

Ни генә димәгез, башын күктә йөртә торган горур кызның күктән жиргә төшүенә сәбәп була ул кич. Бактың исә, жирдә чагыштырмаслык рәхәт икән, жирдә курка-курка гына булса да жан сөйгән кешең белән бергә атлап йөрергә мөмкин икән. Ә ул жан сөйгән кешең шунда, ялгыш кына тиеп киткәндәй итеп, кулын синең биленә орындырса, анысы инде бөтенләй дөнья жәннәте икән!

Әлбәттә, болай соңлап «тана эзләп» йөрүләр эзсез генә узмадылар. Буй житкән кызның һәр адымын жентекләп күзәтә торган өйдә аның кичнең кич буе югалып торуы шактый зур жанжалга сәбәп булды. Ләкин, ничек кенә булмасын, бусы әле монын өй эчендә генә булып калган хәл. Соңга таба, булганы, уйлап чыгарылганы бөтенесе бергә кушылып, халык теленә үк менде, ә бу кеше сүзләре Әлмөхәммәт байны чәнчелсә бер тамчы каны чыкмас хәлгә китерде. Әйтергә ансат, ишетергә авыр: имештер, рәтле кунаклар колгасы булмаган Чуртан Сабир малае Хафиз авылда бер Әлмөхәммәт байның ефәккә төрелгән кызына борын сузсын. Әллә кайлардан, әллә нинди затлы жирләрдән, юлга тузан төшермичә, яучылар йөреп торганда, житмәсә.

Олылар киреләнә барып, кызны дүрт стена арасына кыса төшкән саен, яшьләрнең хәйләкәрлеге, тапкырлыгы шулай ук арта барды. Кайда инде ул тоз төргән кәгазь почмагына сәлам хат «тырнап» жибәрүләр — алары аның гөнаһсыз яшь чакның беркатлы шуклыклары гына булган икән. Кире беткән Әлмөхәммәт Сабирныкыларны һәм аларның барлык агай-энеләрен кибеткә кабул итмәс, аларга әҗәткә булсын, хәләл акчаларын тотып килсеннәр, кибеттән әйбер жибәрмәс булды — йөрмәсеннәр коры ком тутырган башлары белән Әлмөхәммәт кибетченең абруйлы исемен төшереп. Әйе, Сабирныкылар ягына кибет тирәсенә хәтта көндез дә килергә ярамый, ә Сабир малае керәшче Хафиз үзе, төнен, кеше аягы басылгач, Әлмөхәммәт байның өсте чәнечкеле тимер чыбыклар белән беркетелгән биек коймалары аша үтеп, Гыйльмениса йоклый торган яңа өй тәрәзәсенә килгәли иде. Дөрес, Гыйльмениса мәхәббәттән шашынган Хафизны артыкка жибәр-

ми, башка кызлардан ишетелгәнчә, яки җырларда җырланганча, тәрәзәдән тартып алырга һәм куенына салырга ашыкмый, Гыйльменисаның ул яктан тотырыгы җитә, ләкин, шул ук вакытта, Гыйльмениса хәзер, теге вакыттагы кебек, билгә егет кулы ялгыш тиеп киткәннән генә эреп калу дәрәҗәсеннән узган, Гыйльмениса хәзер шундый батырлык күрсәтеп тәрәзә төбенә үк килеп җиткән Хафизын, һич югы, тәрәзә аша гына сузылып булса да, бер үпмичә һич җибәрә алмый иде. Ә бусы — әлеге шул ачык тәрәзә аша курка-курка гына бит очыннан гына булса да бер үбешеп алу — бусы моның бөтенләй тамаша нәрсә икән: бер үк вакытта йокыны качыра һәм аннары татлы төшләр дөньясына очырып алып китә торган бер әкият икән!

Ике хәл бу татлы әкиятне бозды да куйды. Шул ике хәл булмаса, кем белгән бу фани дөньянықын, бу ике гашыйк тәрәзә аша үбешү белән генә калмаган булырлар иде. Беренчедән, әллә яше җитеп, әллә Әлмөхәммәт куштанның акча төртүе аркасында, шул көзне Хафизны, наборга кертеп, тиз генә солдатка озатып куйдылар. Солдат дигәне дә якын-тирәдә, бара-кайта йөри торган җирдә түгел. Якынрак, әйтик, Казандамы, Лаештамы икәнен белсә, ихтимал, ничек тә җаен туры китереп, барып күреп кайтуга да бер өмет сакланыр иде. Ә аның Хафизын, буе-сыны килгән дип, тотканнар да җәһәннәм астына, Каф тавы артына, Кара дингезгә, әйтмешләренә караганда, биш-алты елсыз әйләнеп кайтмый торган җиргә олактырганнар. Анысы да әле, бәхете булып, сугыш-фәлән кузгалмый торса. Ә сугыш чыга калса, алла сакласын, беренче булып кем диңгез төбендәге зур авызлы кит балыкларына азык булып китәр? Шул буе-сыны белән, әлбәттә, Хафиз инде. Әйтерсең лә, сугыш буйны-сынны тикшереп тора да, су астындагы «зур авызлы кит балыклары» барыннан да элек Гыйльменисаның Хафизын гына көтеп яталар.

Нишләмәк кирәк, сөйгәненне сагыну ничек булырга тиешлеге бер китапта да язылмаган, Гыйльменисаның сагынуы менә шулай тилетилемсәрәк булып башланды. Ул кич яткан саен белгән-ишеткән догаларын барысын да берәр кат укып чыкканнан соң, кинәт үз теленә күчеп, чын-ихластан: «Ия ходай, Хафизымны — күз нурымны зур авызлы кит балыкларына ризык итә күрмә!» дип, авыз эченнән пышылдап куя, тик шуннан соң гына бераз тынычлангандай булып, йоклап китә торган иде.

Бәлки кеше сүзе дә, керми дисәң дә, колакка кереп калгандыр, бер мәлне аңарга, әлеге шул төнлә йокларга ятканнан соң (көндез алай уйланырга вакыт тими, дөнья мәшәкате: өен җыясы, суын китерәсе, терлеген карыйсы, кыр эшенә йөгерәсе бар — кырыкмаса кырык эш, кырык беренчесе чират көтеп тора!), әлеге теге белгән-ишеткән догаларны укып бетергәч, Хафизын — күз нурын китлар авызыннан да саклап алып калгач, һич искәрмәстән башына кинәт мондый бер тәшвишле уй төште: болай да егерме өчне тутырып килә торган ул кызга, әгәр Хафизы анда биш-алты ел торып кайтса, егерме сигез, егерме тугыз тирәләре була түгелме соң? Ничек килеп чыга соң инде бу? Бик карт кыз булып утырып кала түгелме соң? Ярый ла, Хафизы, киткән вакытта биргән вәгъдәләрен онытмыйча, әйләнеп кайтса!

Кайдан башка килеп керде соң әле бу шайтан коткысы! Вәгъдәсендә тормыймы соң аның Хафизы? Торачак, алла боерса, торачак. Дөресен әйткәндә, хатлары сирәгрәк килә килүен, мәгәр бит аның бу ягын уйларга кирәк: Хафиз үз ирегендәге кеше түгел, солдат хезмәтендәге кеше, вакыты бардырмы, юктырмы? Аннары тагы хатны да турыдантуры Гыйльменисага атап, аларның өенә яза алмый, яраткан кызына хат язган өчен әнисеннән әллә ни уңайсызланмаса да, кеше теленнән куркып, Гыйльмениса аңарга әнисе адресына да җибәрмәскә кушты.

Җибәрсә, әлеге шул Түбән оч Хафаза апасы аша иде! Ярый ла, ул Хафаза апасының адресын почта йөртүчеләр бутамаган булсалар...

Кыскасы, башка бик күп борчулы уйлар янына бу борчу да килеп кушылды. Арада иң куркыныч булып «29 яшь!» кара маяктай алда басып тора иде. Болай да теле авызына сыймас көнче-күбәләкләр егерме өч яшьне, карт кыз булып утырып калуның башы, дип, турыдан ук йөзенә бәреп әйтмәсәләр дә, читләтеп-читләтеп исенә төшерә торганда, утыз бусагасындагы «29» Гыйльменисаны — күктә йөреп өйрәнгән горур башны — бик-бик уйландыра иде...

Шул ук вакытта олылар да кул кушырып тик кенә утырмаганнар икән. Бер базар көнне Әлмөхәммәт кибетче аеруча күтәренке кәеф белән кайтты. Сәүдәсе дә уңган булса кирәк, ләкин төп сәбәп ул гына булмаган, кызын ярәшергә кешесен табып кайткан, имеш. Эшне озынга сузарга бирмичә, шундук чарасына да керештеләр. Ике як та хәрәкәткә килде: яучы, колак сөенчесе, сандык маллары әзерләү, туйга әзерлек һәм башкалар, һәм башкалар... Кызыгы бигрәк тә шунда: иң әһәмиятлесен Гыйльмениса «һәм башкалардан» соң гына белде: аның кияве булып куенына керәсе һәм гомерлек ир булачак кешесе Чардаклы мулласының ничә еллар буе Мәчкәрә мәдрәсәсендә пишкадәм булып җилән чабуы туздырудан узмаган, авыл теле белән әйткәндә, ни аллага, ни муллага өлеш чыгара алмаслык бөкре бер мәхдүм икән.

Ни сабыр, кулы сынса җиңеннән чыгармас кеше Гыйльмениса, моны ишетеп, хәтта аның да сабырлыгы шартлап сынды. Зур авызлы кит балыкларыннан курку кинәт арткы планга калды, Хафизы өчен бер төн төнозын елап чыкты да аны да әлеге шул Каф тавы артындагы диңгезендә калдырып торырга булды — насыйбы түгел икән, башны ташка орып булмый, әмма үзенең бернинди хорафатка да буйсынмас эчке горурлыгын җиңә алмады — аңарга бик тиз һәм бернинди киңәшсез-табышсыз, тәкәббер этисенең планын җимерү, дөньясыннан, диңгезгә китеп олаккан беренче мәхәббәтеннән, үзенең егерме өч яшькә хәтле карт кыз булып утырып торуыннан үч алу кирәк иде. Дөньяны вак-вак кына атлап үтүче һәм кирәкле сүзне дә әйтмичә, эчендә йотып калдырырга сәләтле бер кыз күренә иде, ә эчендә — купса давыл булып тузгый торган характер утырган икән. Әти-әнисенә ризалык биреп тә, каршы килеп тә бер сүз дә әйтмәде (ә тегеләр моны үзләренчә ризалык галәмәте дип юрадылар), бер кеше белән киңәш-табыш итеп тормады, сандык әйберләренә кул тидереп, өйдәгеләрне шиккә төшермәде. Бер көнне шулай, кичтән чишмәгә суга киткән җиреннән, чиләк-көянтәсен тал төбенә куеп калдырды да, кайчандыр үзләрендә батрак булып эшләгән, болай үзенең әллә ни дан җире булмаса да, җае туры килгәндә томырылып карап куюлары белән Гыйльменисаның исендә калган Галимбәк Барыеның бер якка кыйшайган ярлы өенә барды да керде. Өйдә Барыйның үзеннән бүтән берәү дә юк, ә Гыйльменисаның хәле тел яшереп торырлык дәрәҗәдә түгел иде, гомердә күрелмәгән хәл, ачулы иде бу минутта Гыйльмениса, чая иде һәм, бер үк вакытта, күзендә яшь иде. Исәнме-саумы дип тә тормады, дуамал кызулык белән берьюлы әйтте дә салды:

— Мин сиңа ябышып чыгарга дип килдем, Барый. Аласыңмы мине?

— Тукта әле, чү... Менә монда сәкегә килеп утыр,— дип мыгырданды, берьюлы тәмам аптырап калган Барый. Аның бөтенләй зиһене чуалды, нәрсә әйтергә дә, бу эшне нәрсәгә юрарга да белми иде бичара Барый.

— Утырып кына торырга дип килмәдем,— диде Гыйльмениса сүзне шундук үзеп,— чиләк-көянтәләремне су буенда калдырып киллем, мине хәзер эзли чыгачаклар. Мине хатынлыкка алырга риза икәнсең, сузма вакытны, әйдә, су буйлатып, җәяүләп кенә Челәнле күл авылына

барып никах укытыйк. Никах өчен туләргә миндә бар. Курыкма, Әлмөхәммәт бай кызы мин.

— Әлмөхәммәт бай кызы булганга әйтәм дә, Гыйльмениса... Мине бит беләсең, баш өстемдә күк, аяк астымда җир генә.

— Шулары булып торсын, югалмабыз. Бергә эшләрбез, туры килә икән, бергә ач торырбыз. Тик син мине киредән ул якка кума. Җепләрне өзеп килдем мин ул як белән...

Дөньяны вак-вак кына атлап үткән кыз иде Гыйльмениса, бай кызы дигән яңгыраулы исеме бар иде, затлы кием-салымы бар иде, ә шулар өстенә, шуларның барысы өстенә тагын, кеше белеп житкермәгән давыллы характеры да булган икән. Булган бөтен байлыгын калдырды да авылның иң фәкыйрь егетенә, бернинди шарт куймыйча, беркемнән рөхсәт сорамыйча, тотты да кияүгә чыкты.

Ни белән бетәр моның азагы? Ни белән генә бетмәсен, Гыйльменисаның күңелендә хәзер тик бер генә акыл: үзе егылган еламас!

## IV

Ләкин тормыш дигәнең бик үҗәт хайван бит ул, аның йоны уңаеннан гына сыпырып торсаң да, ул әле сиңа, син бөтенләй көтмәгәндә, арты белән әйләнеп, куш аяклап бер тибеп куя. Ә Гыйльменисаны күрә башладык, ул яшьләй үк тормышны йон уңаеннан гына сыпырып торырга теләмәде. «Үзе егылган еламас», дип бик кистереп әйтсә дә, елаган чаклары булгалады Гыйльменисаның. Хәтта шундый минутлары булды, күңеле елый, ә күзеннән яшь чыкмый иде. Әлбәттә, Галимбәк Барыеның кыйшык өеннән, Камәр атлы бөкре сеңелесеннән бүтән байлыгы булмаганны белеп чыкты ул — мәсьәлә анда түгел. Мәсьәлә шунда: башта бөтен авыл ничектер сәерсенеп, дөньяда булмаган бер эш итеп карады моңа. Үзен авыл тоткасы дип йөргән Әлмөхәммәт байның кызы, бердәнбер кызы, күз алмасы кебек үстергәннәре, авылның иң өтелгән чирләшкәсенә — Галимбәк хәерченең кешедә батраклыкта йөреп башы чыкмаган Барыена ябышып чыксын, имеш. Кызның ата-аналары бу эшне кабул итмәделәр дә итмәделәр, ләкин шул ук вакытта, нинди байлык һәм абруй иясе булмасыннар, кулдан тәгәрәп киткән йомгакны кире тартып алырга да соң иде инде: укыласы никах укылган, кыз белән егетнең ризалыгы бар, эш законлаштырылган. Бәддога кылырга, карганырга, бусагадан атлатып кертмәскә, әйберләрен бирмәскә мөмкин, әмма кулдан тәгәрәп киткән «йомгак»ны, очын бөтенләй чуалтып та, чуалтмыйча да, киредән кулга тартып алырга мөмкин түгел иде. Авыл кешеләренең, күрше-күләннең сәерсенеп каравы, әти-әниләренең кеше артыннан ишеттергән каһәрләре Гыйльменисаны какшатмады түгел, киресенчә, бу кыйшайган өйгә тагын да ныграк беркетә төште: «Әле мин менә сезгә күрсәтермен, әгәр берберебезне ошатышсак, торырга тиешбез Барый белән! Барый кемнән ким? Бүтәннәр кебек үк ике аяклы, ике куллы кеше. Торырга тиешбез Барый белән».

Никахлашып тора башлауның икенче көненнән үк моңа хәтле эш рәте белмәгән Камәрне, әкренләп-җайлап, тәмле тел белән өй эшенә өйрәтә башлады Гыйльмениса. Үзе шулай ук сызганып эшкә кереште. Гомердә кул тимәгән, ярылып-кырылып беткән мичне, ярыкларын элек кызыл балчык белән сылап, аннары изелгән ак таш суы белән менә дигән итеп агартты. Идән-сәкене сап-сары итеп юып чыгарды. Барыен, кием-салымын ничек әлләксә шулай атып бәрүдән биздереп, бүреген бүрекчә, киемен киемчә элеп куярга өйрәтте. Өйдә пыскытып тәмәке тартып утырулар бетте. Элекке гадәт буенча, эч пошканнан кичләрен җыелып, Барыйның чабата ясаганын карап, авыл яңалыклары, гайбәтләр белән бүлешеп утыручылар да кими төште, соңга таба бөтенләй

бетте. Өйдә урнашкан тәртип, чисталык һәм Гыйльменисаның беркемгә дә каты бәрелмичә, шул ук вакытта сызганып эшләп йөрүе, инде аны да күрмәмешкә салышып утыручы үгез тиреле кешеләргә, читләтеп-читләтеп кенә булса да, аларның үз өйләре дә барлыкны исләренә төшерү житте — кеше дигәнең никадәр генә каткан сөяк булмасын, әгәр аның янында дөньяга яңа жан өрүче икенче бер тырыш, эшлекле, кешелекле кеше үзен сиздереп, орынып яши башласа, эремичә кала алмый икән. Бу эрү иң элек Барыйның сеңелесе Камәрдән башланды. Камәр сизелерлек жыйнакланды, башын-күзен юып, чәчен тарап, элек тә беркем белән дә рәтләп сөйләшми торган кыргыйлыгын ташлап, туганым-жиңгие белән рәхәтләнеп сөйләшеп йөри торган булып китте. Хәтта бер көнне жиңгәсе аның кече якта кулына көзге кыйпылчыгы тотып, янган шырпы белән кашын-күзен төзәтеп торуына кадәр күреп алды. Ләкин бичараның алыштырыр күлмәге юк, кулын чак кына күтәрде исә култык астындагы күлмәк ертыгыннан тәне күренеп кала иде. Хәер, бу яктан Гыйльменисаның үзенең дә әллә ни мактанырлыгы юк, ябышып чыгышлый, шул су буена киеп төшкән бер кат күлмәге белән йөри, туган йортына кайтып, әйберләрен алып килергә омтылып куйган минутлары булса да, каты бәгырьле әтисенең каядыр киткән чагын көтеп, хәзергә ни бар — шуңа канәгать булып торырга мәжбүр иде. Өс-башның бик каралуы житсә, анда да рәтен таба: төнгә каршы Барыена өйдән чыгып торырга кушып, кече як тәрәзәсенә искеләр бөркәп, шул кече якта үзенекен дә, каенсеңелесе Камәрнекен дә салдырып, тиз генә юып элеп куя.

Шулай да Гыйльмениса, кем артыннан булса да сүз кушып, бай өйдә калган күлмәк-күнчекләрен, сандык әйберләрен соратып алуны яхшысынмады. Ят кеше алдында сер бирү була дип карады, шулай ук әти-әнисен дә яман яктан күрсәтәсе килмәде, вакыты житкәч үзләре төшенерләр, әти-таш йөрәкнең башы житмәсә, әни күңеле чыдамас, ничек тә бер рәтен табар, дип көтте. Һәм ул уйлаганча булып чыкты да. Ябышып чыгу дигән нәрсә элек-электән бар, тик менә кемгә чыккан? Шунысы бигрәк азаплый иде ана күңелен. Шулай да ахыр бер йомшар чиге килеп житкән булса кирәк, көннәрдән бер көнне Гыйльменисаның әнисе Шәмсениса түтидән «яшертен илче» итеп жибәрелгән күрше хатыны, Әлмөхәммәт үзе сәүдә эше белән базар киткән кичне чамалап, кызының бер төен әйберләрен — күлмәк-алъяпкычларын, жәймә-одеалларын, хәтта — ничә әйтсәң дә аңа күңеле! — иреннән яшереп жыйган байлыклары исәбенә, кызын үтә бәхетле һәм матур итәсе килеп алып куйган затлы энжеле калфагына хәтле китереп китте. Туган өйне рөхсәтсез-нисез ташлаудан, әти-әнисенең каргышын алудан да читенрәк булды бу төенне алып калу Гыйльмениса өчен! Болай, ичмасам, суынып килә иде инде, суынмаса да, бәгыре алай ук өзелми иде. Һәм кинәт... артта, авылның икенче очында бүленеп калган байлык-дөнья рәхәтенең бер почмагы аның артыннан үзе куып житкәндәй булды. Гыйльмениса, нәрсәнең нәрсәгә икәнен дә рәтләп төшенеп тормастан, бары тик әнисенең бу төен эчендә яшеренеп килгән шәфкатьле күңелен тоюдан, һич түзеп тора алмыйча, яртылаш таралган төен өстенә йөз түбән капланып, озаклап елады. Барый һәм аның аптыраган сеңелесе икесе бер якта, ни дип сүз кушарга да белмичә, катып калдылар, Гыйльменисаның елап туктаганын, борыннарын тарта-тарта, көтеп тордылар. Гыйльмениса кинәт төен өстеннән башын күтәрде, ул елап туктаган иде инде, күзләре кызыллыкка кызыл, ләкин яшьле түгел иде.

— Менә бусын сүтеп иртәгә үк Камәргә күлмәк итеп тегәм,— диде ул, арадан иң затлы бер күлмәген селкеп,— кыз кеше, кеше арасына чыкканда кияр күлмәге юк. Ә менә бу тотыла төшкәненнән алмаштилмәш өйдә кия торганны рәтләрбез.

Ул әле әйтәсе сүзен әйтеп бетермәгән һәм хәзер ни дип әйтергә дә белмичә аптырабрак калган: чөнки төендә Барыена бүләк итәрдәй бер генә әйбер дә юк иде.

— Әллә сиңа түбәтәй урынына менә бу энжеле калфакны кидереп йөртергәме икән? Әлмөхәммәт байның кияве була торып: дөньяда юк шундый затлы такыя да киеп йөрмәгәч,— дигән булды, ни әйтергә белмәгәннән шаярткандай итеп. Һәм калфакны шундук кире алып урынына куйды, шул секундта ук ул инде шаяртудан узган иде,— курыкма, урын табарбыз без аңа. Акча китерә торган зат әйбер ул.

Ул кичне алар утлыгы җимерелгән, ләкин Гыйльмениса бу йортка килен булып төшкәннән бирле әледән-әле су буенда ком белән ышкып агартыла-агартыла чак кына рәткә кергән самовардан, чынаякларга кашык очы белән генә кәҗә сөте тамызып, гадәттә эчелә торган чәйне эчтеләр, гадәттә сөйләшенә торган сүзләр сөйләшенде, тик Камәр генә, юктан гына да очынып китә торган тәэсирчән Камәр генә, ихтимал, җиңгәсенең күлмәк тегеп бирәм дигән сүзләреннән очынып булса кирәк, тора торгач, «иске күлмәк киеп йөргәнгә генә бөкре дип үртиләр мине, яңаны кисәм, алла боерса, мин бөтенләй бөкре күренми торганмындыр әле!» дип куйды. Гыйльменисаның да, Барыйның да күзләренә яшь килде, чәй эчеп туктаганчы бүтәнчә сүз яңартучы булмады. Ләкин шулай да, сөйләшмәсәләр дә, телләренә купшы сүзләр килмәсә дә, бу кичне, бу табын яныннан торганда алар өчесе дә күңелләре белән иксез-чиксез яхшырганнар, дөньяда алардан да бәхетле кеше юктыр, дөньяда булса да, боларның Ташлы Ярында андый кеше юк һәм булмаска да тиеш кебек тоела иде. Һәм менә шушы бәхетле кичне Гыйльмениса беренче тапкыр сүрүе-тышы катып беткән иске түшәккә кар кебек ак җәймә җәйде, мендәрләренә яңа тышлыклар кидерде. Хатынының шундый актан-чистадан урын җәйгәнен бер читтән оялган сыманрак карап торган Барый, урын җәелеп беткәч, балалар кебек, кинәт бер киреләнеп куйды.

— Кирәкми, Гыйльмениса, ятмыйм мин бу урынга. Ятсам да йоклый алмам. Эт корсагына сары май килешмәс.

Гыйльмениса, чын эшкә килгәндә уен-көлкене һич күтәрә алмый торган житди табигатьле Гыйльмениса, Барыйның бу сүзләренә хәтта җавап та биреп тормады, вакыты житүе белән аны төртеп аударгандай яткырды.

Иртәгесен Барый иртүк күз ачып, Гыйльменисасы уянганчы эндәшми-тынмыйча, көйле бала кебек, яткан җиреннән көлемсерәп, уйланып ятты. Ниһаять, түземлеге җитмәде.

— Яңа урын-җир килештеме, озаграк йокладың син бүген,— дигән булып сөйләнә-сөйләнә, хатынын уятты да шул ук очтан янадан сөйләнә китте: — Ә миңа, Гыйльмениса, син теләсә нәрсә әйт, килеште бу яңа урын. Бик матур бер төш күрдем. Имештер, кырдан тузан туздырып ат көтүе кайта. Ат иң изге хайван ул, Гыйльмениса, белмәсәң бел. Ир төшенә ат кердеме — тикмәгә генә түгел инде. Син әле аның азагын тыңлап бетер, хикмәте азагында аның. Шул көтүдән бер тай, әкәмәт, ялы кыркылган, койрыгы киселгән менә дигән яшь бер тай чабып безнең капкадан килеп кермәсенме! Куып чыгарыр хәл юк малны, әкәмәт. Син теләсәң нәрсә әйт, Гыйльмениса жаным, гел болай коелып төшкән булмаячак безнең тормыш, менә шушы алама Барый әйткән ие, диярсең. Алдагы елда бездә җир бүләшү булырга тиеш, шуңарга тиклем син, ходай кушып, миңа үзем кебек бәләкәй генә тагын бер Барый да табып бирсәң, җир бүләшкәндә ике имана булып керәчәкбез дигән сүз бит. Менә бит ул бәхетнең башы кайда? Бер имана белән дүрт кеше туйдырып кара да син, ике иманаң белән сөйләшеп кара...

— Нигә кирәк бер Барый өстенә икенче Барый? — дигән булып, шаяртып иренең төшен җупләргә ашыкты Гыйльмениса,— Барый булмаса, безгә Әхәт тә ярый. Минем әни ягыннан апай тиешлебез Шәмсеҗиһан тутинең улы да Әхәт. Әле нинди генә Әхәт, сыйрагыннан тотып күлгә ташлый этисе, бата, тончыга, шундук тагы, калкавыч кебек, калкып килеп чыга.

Барый төшендә күргән ак тояклы яшь тай аларның җил капкасыннан әле кайчан атылып керер, керерме-юкмы, әмма ир кешенең яхшы төше күңелле бер эшкә сәбәп булды. Кызына «яшертен илче» аша әйберләрен җибәртүдән соң атна уздымы икән, кичләрдән бер кичне, авылга эңгер кунгач, боларга искәрмәстән генә Шәмсениса үзе килеп керде. Кырыс кына исәнләште, әйтер сүзен тапмагандай, ишек төбендә беравык сүзсез таптанып торды — бу хәлендә ул өйнең кечкенәлегенә, түшәменең тәбәнәк булуына хәйран калган кешегәрәк охшый иде.

— Түргә уз, әни,— дип ыргылып урыныннан кузгалды Гыйльмениса. Сәке йөзлегенә киез китереп салды, әнисенең беләгенә барып ябышты.

— Узып тормыйм,— диде әнисе, кыска гына итеп,— менә монда үзенә генә әйтәсе сүземне әйтәм дә...

Ул кызы Гыйльменисаны кече якка таба тартты, анда икәве генә калдык дип ышанганнан соң, артык һич көттермичә, кызының элек бер янагына, аннары икенчесенә, бик авырттырырга тырышмыйча гына, чапылдатып китереп сукты.

— Әйткән антым бар ие, үтәмәсәм бәхетең ким булыр дип куркам.

Һәм шундук, кызын кочагына кысып, үксеп җылап җибәрде. Аннары киткән чакта Гыйльменисаның учына бәләкәй генә төен салды — нәрсә икәнлеген әйтеп торуны кирәк тапмады, ә төендә ананың картыннан яшереп җыя килгән акчасы төйнәлгән иде.

Акчадан күп мәртәбәләр артыгы, чагыштыргысыз артыгы: чыгышлый Шәмсениса, күп төчеләнеп тормыйча, әмма күңелендә булганны әйтмичә дә китә алмагандай:

— Хуш, кияү. Болай ут капкандай йөрүемне гаепкә алма, вакытым шулай,— дип, йомшак кына исәнләшеп, китеп барды.

Әйе, җылы авызы белән шулай диде, «Хуш, кияү!» диде. Бу — кайчандыр аларда батрак булып эшләгән чандыр Барый өчен әйтеп бетергесез олылау булса, аның Гыйльменисасы өчен тагын да зуррак: бу — ананың ризалыгы һәм аның Барыен «киявем!» дип кабул итүе иде.

Әмма, тулаем алганда, Барыйның ак җәймә җәеп яткач кергән татлы төше алар юраганча ук килеп чыкмады. Гыйльмениса Барый белән тора башлавының икенче елында, нәкъ әлеге шул җир өләшәсе елны, ире түземсезләнеп көткән ир бала түгел, кыз бала тапты. Димәк, хыял гамәлгә ашмады, алар дүрт кешегә бер иманалары белән калачаклар. Әлбәттә, Барый моны эченнән кичермичә булмагандыр, әмма моны иң нык кичерүче Гыйльмениса үзе булды. Бичара, күзгә күренеп, берьюлы суырылып калды, ниндидер гаепле эш эшләгән кебек, Барыеның күзенә туры карарга кыймыйча йөри башлады. Үз нәүбәтендә Барый хатынының бу эчке кичерешләрен шулай ук сизә, ул ничек тә Гыйльменисасын тынычландырырга тырыша, горып-торып баланы үз кулына ала да аяк бармакларын, кул бармакларын саный башлый.

— Бөтенесе үз урынында, менә син әкәмәт,— дип куя, үзе балага әйләнгәндәй куанып,— бөтенесе сиңа охшаган, әнисе. Күзләрен кара әле син аның, күзләрен... бу тиклем дә сиңа охшап туар икән.

— Бишектәге бишкә тәрләнә, диләр. Әле ошау-ошамау турында сүз әйтергә иртәрәк,— Гыйльмениса теләр-теләмәс кенә шулай дип әйтеп куя һәм, баланы ире кулыннан тартып диярлек алып, кабык бишеккә илтеп сала,— иңләштермә кулга, гел аны кочаклап утырырга туры килмәс, дөньябыз бик үк түгәрәкләнмәгән.

Сизелеп тора: Гыйльменисаның бу төрпә сүзләрендә ачыктан-ачык әйтелмәгән, шул ук вакытта әллә ни еракка да яшерелмәгән үпкә бар. Барыйга түгел бу үпкә, сабыйга шулай ук түгел — әле кайчан гына йөрәгеннән өзелеп төшкән үз валчыгына ничек үпкәләмәк кирәк... Барыннан да элек, үзенә аның бу үпкәсе; бит аклый алмады Барые көткәнен! Ир бала булмады, кыз булып туды — нишләтәсең аны. Аннары курка-курка гына булса да язмышына да үпкәләп куя, ләкин бусына да ул чаклы түгел, бирәү дә көчләп такмады бит аны бу чирләшкә Барыйга. Үзе чыкты, өлешеңә чыккан көмешең шул икән, монда кемгә булса да үпкәләргә урын бармыни? Ләкин эчке ярсулы Гыйльменисса шулай да тынычлана алмый: нииндидер зур гаделсезлек яшеренгән бу дөньяда! Бирәүләрнең бай, икенчеләрнең ярлы булуында түгел — анысы аның ходай язганы буенча. Хәзергә менә әйтеп кенә бирә алмыйм: аннан башка да гаделсезлек бар. Уйлана торгач бу гаделсезлекнең дә очы кайда яшеренеп ятканын тапкан кебек булды: кара әле, нишләп соң хатын-кызга имана җире бирмиләр икән? Хатын-кыз да ике аяклы, ике куллы кеше ләбаса! Аның да тамагы бар. Нишләп соң алай? Кайдан чыккан рәхимсез закон бу?

Шул ук вакытта Барый да тормыш турында уйланмый түгел иде. Кешегә чабата ясап кына тишекне тутырып булмаячак, юк, булмаячак. Бер көнне ул Гыйльменисасының ак һәм тыгыз имчәгеннән баласын туйдырып утырганны һәм сабыйның, мул күкрәк сөтен кирәгенчә йотып өлгерә алмыйча авыз кырыйларыннан ташытып, тәмләп чупылдатуын читтәнрәк һәм сиздермичә генә сокланып карап торды да:

— Кара әле, Гыйльмениса, әгәр мин сезне ун-унбиш көнгә калдырып китсәм, сез чыдарсыз да чыдарсыз, синең юанычың әнә кулыңда, үзем чыдый алырмынмы икән? — дип сәер генә итеп сүз башлады. Һәм шундук Казан — Мамадыш юлында, юлга таш түшәү эшендә бераз акча эшләргә мөмкин дип сөйләгәннәрен, күрше Ярмәкбаш авылының ике егете унбиш көнгә, ашау-эчүдән кала, унар сум акча төшереп кайтканлыкларын дәртләнү белән сөйләп китте. Барый чынлап та бу эшкә бик купшынган, әйтерсең, төшәчәк акча инде аның кесәсендә үк, шул ук вакытта күз карашларының хатынына һәм баласына томырылган хәтәр елтыравында яшерен бер курку, тәвәккәлсезлек чагыла: ничек уздырыр ул көннәрен әнә шул ике җан иясеннән башка? Уздыра алырмы?

— Шушы эсседәме? Утырыр идең яндырган кояш астында юлда таш түшәп? — Әллә шаяртып әйтте Гыйльмениса бу сүзләрне, әллә болай да саулыкка бик туймаган Барыен җәлләүдән ялгыш ычкындырды. Ничек кенә әйтелмәсен, аның бу сүзләре Барыйга ничектер көлгән сыманрак, һәрхәлдә, ышанып җитмичәрәк карау кебек ишетелде. Һәм бу аның бөтен икеләнүләрен берьюлы чәлпәрәмә китерде. Барыйның әле Гыйльменисага өйләнгәннән бирле бер эшне дә болай кызу тотканы, мондый тәвәккәллек күрсәткәне юк иде. Гомумән, ул ялкауrак селкенә торган кеше иде, бәлки фәкыйрьлеге дә өлешчә шуннан килгәндер. Эшкә уңган, пөхтә куллы һәм кешеләргә гел яхшылык кына теләүче Гыйльмениса белән янәшә һәм тату яшәү аңардагы ул яман гадәтне куып чыгаргандай булды — ул тәвәккәлләнә төште, аңарда дөньяның кайсыдыр моңарчы күрелмәгән бер почмагын тизрәк күрәсе килү теләге кузгалды.

Иртәгесен ул, котомкасына вак-төякләрен салып һәм капчык өстенә бер кием запас яңа чабата тыгып, юлга чыкты.

Бер көне бер ел булып тоелган чаклары булды Барыйга. Чынлап та, бик-бик ярата икән ул Гыйльменисасын. Анасын яратканга, күрәсең, баласын да шулай өзелеп яратадыр. Аннары тагы хатынының уйный-көлә кисәткәне дә дөрескә чыкты — көннәр бик эссе, таш-тузан арасында көнозын кояш астында эшләүдән башның миләре кипкәндәй

була иде. Әмма барысына караганда да яманрагы сагыну иде. Чак кына буш вакыты булдымы, яки төнге йокыга ятып, күзен йомарга өлгердеме, әлеге шул тыгыз ак күкрәген бәләкәченең авызына каптырган хәлдә, ә тегесе авыз читләреннән сөтен ташытып чәпелдәтә-чәпелдәтә, гел Гыйльменисасы белән сабые каршысына килеп баса иде. Шулай да ал димәде, ял димәде, унбиш көнгә дип чыгып киткән кеше нәкъ ике ай эшләп, азмы-күпме акча төшереп, хатынына һәм сеңелесенә бүләк яулыклар, исле сабыннар алып, кайтырга чыкты. Һәм кайткач, үзара шаярыша-шаярыша, тагын шуны ачыкладылар: шул ике айда Барый Гыйльменисасына — өенә нәкъ унике хат яздырткан һәм шул унике хатның уникесе дә бер төрле үк сүзләр белән башланып, бер үк сүзләр белән очлана булып чыкты: «күз алмам да бәгырем, якында чакта белмәгәнмен кадерең...» һәм башка шуның кебек сандугач телләре. Өстәлсә, соңыннан берничә коры сүз белән саран гына итеп нинди дә булса баштан кичкән бер факт кына өстәлгән булып чыга. Аңлаша торгач шунысы ачылды: Барый үзе яза белмәгәнлектән, хатларны кышлык акча эшләргә дип килгән бер шәкерттән, шактый зур хак биреп, яздыра торган булган. Дөресрәге, шулай эшлим дип тынычлык табып яшәгән. Бактың исә, теге хәйләкәр таз моны утырткан: бер буш вакытында хатларның барысын да стандарт сүзләр, стандарт сайраулар белән язып тутыра да икән, шуңа өстәсә тик юклы-барлы фактларны гына өсти. Ә бәясен Барыйдан тулысынча каерып, бичараны әкрен генә төп башына утырта бара, имеш. Бу көлке дә, чак кына аянычлы да хәлне ачыклагач, Барыйның теге хәйләкәр шәкерткә ачуы бик чыкса да, инде эш узган: шәкерт анда — кырыкилле чакрымдагы Мамадыш юлында калган, ә сагынып хат яздырткан Гыйльменисасы Барыйның җылы куенында иде. Бу кызыклы ачык авызлык һәм, аннан да бигрәк, ике ай бер-берсеннән аерылып тору аларның араларын тагын да җылыта төшкәндәй итте.

Шул ук вакытта бу ике ай аерым торып эшләп кайткан барлы-юклы акча ир белән хатын арасында чак кына сүзгә дә сәбәп булды. Чәйдән-шикәрдән башка берни дә алмыйча сандык төбенә салып куйган акчага Барый Гыйльменисасына кышка бишмәт җиткермәкче була, дөресен әйткәндә, ул әле һаман малай көткәндә кыз тапканы өчен Гыйльменисасы борчылып йөридер кебек сизә, шунлыктан, әлеге шул тегеләчәк яңа бишмәт белән ничек тә хатынының күңелен тапмакчы була иде. Ә Гыйльменисаның исә бишмәт дигәнне ишетәсе дә килми, ул кеше рәтеннән ничек тә хуҗалык ягын рәтләмәкче, башка бер сүзне дә ишетергә теләмичә, үз тәкъдимен куәтли: кәҗәне сатып, аның акчасына әлеге шул сандык төбендә ята торган акчаны да кушып, ул да җитмәсә, әнисе алып килгән бәләкәй төендәге көмеш тәнкәләрне дә өстәп, көзгә ничек кенә булса да бер башмак тана алып булмасмы? Моны болай яклавының үзенә генә билгеле булган бер сәбәбе дә бар: ире өйдә юк чагында, Гыйльменисаның этисе тәкәббер Әлмөхәммәт, кызына карата чак кына күңеле йомшарыпмы, әллә аларның фатихасын алмыйча, ярәшкән егеттән качып, авылның иң йолкыш егете Барыйга ябышып чыгуы өчен мыскылларга теләпме, кеше артыннан: «теге хәерчесе өйдә юк чагында, әнә минем акбаш тананы алып китсен. Баласына сөте булыр, бозаулары уртак — түлке белеп алсыннар: садакага түгел, асрамага гына биреп торуым, анысы да нарасый баланы җәлләп» дип әйттергән иде. Бу сүзне ишетеп, Гыйльмениса, әлбәттә, бик хурланды, ләкин эченә сеңдерде. Каршы килеп, эти-әниләренә сүз җиткермәде, иркәләнергә теләп, иренә дә күз яше күрсәтмәде. Гомумән, ул дөньяның уен түгеллеген инде белә башлаган, иркәләнергә яратмый, хәер, иркәләп-иркәләнеп торырга аларның вакытлары да юк иде. Әмма көзгә башмак тана алып җибәрергә дигән сүзендә Гыйльмениса ирен тәки җинде. Белмәгән кеше белеп торсын: хәзер

инде алар ишек алдына да сыер малы аяк басты — игелеге белән генә була күрсен. Әмма ишек алды дигәненең бер дә рәте юк, түбәсе күк белән ябылган ихатасыз шыр ындыр табагы иде. Кәҗәне ябып куярга яраган читән әрбәлек сыер малы өчен, әлбәттә, ярамады. Шуны искә алып, аннан да бигрәк, хатыны Гыйльменисаның таналы булудан соң туган куанычы белән дәртләнеп, элек тә «Ялкау Барый» дип мыскыллап йөртелә торган Барый, күз күрмәгән, колак ишетмәгән тырышлык күрсәтеп, кечкенә арба белән урманнан чыбык-чабык ташыды, танасы өчен иркен генә абзар кораштырды, ишек алдын ихаталап тотып алды. Менә бит кая үрләп бара эшләр! Әле шуның янына тагын күнеле дә бөтенләй үк өметсез түгел. Дөрес, быелгы җир өләшү вакытында ул инде үзенең шул бер иманасы белән калачак. Алдагы җир өләшү тагын унике елдан. Аңа хәтле Гыйльменисасы — рәхмәт төшкере — ничек тә берәр ир бала табып куймасмы?

## V

Ләкин Барыйның ул өметләре дә барып чыкмады. Шул бергә торган һәм, бер-берсенә кырын сүз дә әйтмичә, бик сөешеп торган бишел эчендә Гыйльмениса бер-бер артлы диярлек өч кыз бала тапты. Моның өчен, йорт башы буларак, Барый да, әлбәттә, тыныч калмагандыр, ләкин моның өчен иң нык борчылганы, моны әллә нәрсәләргә юрап, шомланып беткәне иң элек Гыйльмениса үзе булды. Һәр корсакка узганы саен ул, «йа ходам, бусын ир бала итә күр, мин синең итагатьле колың лабаса! Ник син минем аһ-зарымны, ихлас күңелләрем белән ялваруларымны искә алмыйсың?» дип, көферлеккә төшүдән курка-курка булса да, инанган алласы белән әрепләшеп китә, хәтта юклы-барлы мөлкәтеннән, Барыена сиздермичә генә, нәзер-садакалар өләшеп, ырымчы карчыкларга йөреп, алдан үзенчә чарасын да күргәндәй була иде. Әмма нишләмәк кирәк — үзең теләгәнне кул белән генә тартып ала торган эш түгел шул! — гамәлдә исә гел шул бер бәрәкәт: кыз артыннан кыз туа да тора, туа да тора иде. «Әллә бик итагатьле колы түгелме мин аның? Әллә əти-әниләрнең сүзенә каршы килеп, ярәшеп әйтелгән сүзне таптап, икенче кешегә чыгуым өчен ул мине шулай җәзалыймы?» дигән уйлар да килгәли иде вакыт-вакыт. Ләкин Гыйльменисаның буйсынмас эчке характеры шундук каршы да күтәрелеп чыга. «Дөньяны яраткан, кешеләрнең кылган эшләрен, дөресне, дөрес түгелне югартын күреп, яклап торырлык бөек зат икән, нишләп соң ул күрәләтә минем — үзенең ярдәмсез колының — теләгенә ачыктан-ачык каршы килә? Яшьләй башы нужадан чыкмаган, фәкыйрьлектән тәмам тәкатьсез калган шул Барый бичарамның ялгыз бер иманасы белән алты кашыклы семьяны ничек туйдырмак кирәк? Алай барсына да кодрәтле хаким булгач, син үзең уйлап кара, ходай җаным!» дип, курка-курка гына булса да, кайдадыр — югарыдамы, түбәндәме, ундамы-сулдамы— анысы мәгълүм булмаган, ләкин, ихлас күнелле хатынның керсез инануы буенча, аның бу интегүләрен күреп-ишетеп торырга тиешле югарыгы бер зат белән шулай бәхәскә дә кергәли иде...

Газап өстенә газап, шулай эчтән өзгәләнгән көннәрнең берсендә аңарга әллә кайдагы, Каф тавы артындагы дәрьяларда-диңгезләрдә, менә ничә еллар инде, хатсыз-хәбәрсез югалып калган элекке Хафизыннан, бик яшертен рәвештә генә, кайчандыр, әле бай кызы булып чуклы тәңкәләр тагып йөргәндә, Гыйльмениса белән та-кыямәт дус булырга — сер саклашырга дип сүз бирешкән «ахирәт дусы» Әсхапҗамал аркылы хат килеп төште. Хат, әлбәттә, әллә ниләр вәгъдә итә торган түгел — хәер, вәгъдәләргә инде соң да иде. Ләкин эшнең ничек булганы белән исәпләшмәстән, хәтта ул турыда кызыксынып та тормастан, Хафиз үзенең бу хатында Гыйльменисаның ашыгып кияүгә чыгуы өчен

тау хәтле үпкә белдергән иде. Моңа хәтле хатсыз-хәбәрсез торуының гаебе дә әлеге шул күктән куркучы һәм, ихтимал, мохтаҗ вакытларында әҗәткә чәй-шикәрен биреп торучы авыл тоткасы Әлмөхәммәт бай-дан да шүрләүче карчык анасында тәенләнеп яткан, имеш. Дингә ышанучан карчык, никахлы кешеләр арасына коткы салудан куркып, улы Хафиздан Гыйльмениса исеменә аталып язылган хатларны утка яндыра килгән. Шуның да өстенә тагын Хафиз, әллә үзенең еракта инде бик күпне белә торган шәп кеше булып җитешкәнлеген сиздерергә тырышып, ялган горурлыкка бирелүдән, әллә флотта узган шул дүрт-биш ел төшендә башыннан кичкән «муштра» йогынтысы астында, кайбер адәм аңламаслык, һәрхәлдә, Гыйльменисаның колагына якын да килмәслек сүзләр дә кыстыргалап язган иде. Тагын да әчкәредәрәк кузгалганы, кешегә, хәтта «ахирәте» Әсхапҗамалга да сиздерми үз-дырганы ничек булгандыр, күз алдында ярылып ятканы шул булды: «узасы узган, тузаны тузган эшләрне яңартып ятырга ничу,.. аннан башка да күңелем дөнья гаме белән тулган!» диде дә, Хафизның хатын шундук, «ахирәте»нең күз алдында ук, вак-вак кисәкләргә тураклап, күңел түгел, кул да җыя алмаслык итеп, җилгә очырды. Күрәшче Хафиз һәм Әлмөхәммәт бай кызы Гыйльмениса арасында кайчандыр матур гына уйнап алган мәхәббәт романтикасы шуның белән вәссәләм... дип исәпләргә дә мөмкин булган булыр иде, әгәр соңыннан, бик соңыннан, ун-унбиш еллардан соң, көтмәгән хәлләр килеп чыкмаса! Мәкерле дә, хәтәр дә соң син, дөнья!

Ә Гыйльмениса өчен дөньяның иң хәтәр чаклары узганда да әллә ни сизелмәде — ул тәвәккәл иде, үз дигәнен эшләде. Әлбәттә, уен булып чыкмады, хәзер дә уен түгел. Барлык нужасы өстенә шунысы тагын җанны кыйный: этисе, әнисенә караганда, күп каты булып чыкты. Әле шушы көнгә хәтле кызының Барыйга ябышып чыгуын чын-чынлап гафу итә алганы юк. Очраганда бер-ике авыз сүз белән исәнләшә дә китеп бара. Гыйльменисаның хәле ничек? Ничек яшиләр? Нарасыйлар ничек үсә? Ул турыда хәтта кызыксынып та карамый. Бу яктан бик тырнал-гач, бер кичне Гыйльмениса, «танабыз кайтмады, тана эзләп йөргән җиремнән» дигән сылтау табып, ә чынлыкта этисе белән бер сөйләшеп-үпкәләшеп алу нияте белән, тәвәккәлләп барып кергән иде. Икенде-ахшам намазына әзерләнеп, таһәрәт алып йөргән җиреннән Әлмөхәммәт кызына сәер генә итеп бер карап алды да хатыны Шәмсенисага:

— Казан ас, табын әзерлә, барып, теге йолкышын да алып кил, бер уңайдан азрак утырып китәрләр, тана пычагыма да китмәс, — дип курт кына боерык бирде дә үзе шундук намазына кереште. Гыйльмениса моны, бердән, этисенең йомшара башлау билгесе дип кабул итсә дә, Барыена карата бу тәкәббер картның әле һаман да болай һавалы торуы аны тагын сискәндереп җибәрде. Кыз чагындагы истәлекләрне яңарткан бу йорт бусагасыннан ул, яхшы ук борынын салындырып, кире атлады. Әлбәттә, аңыкы да бераз тупасрак килеп чыкты — ничә әйтсәң дә шул Әлмөхәммәт кызы ич бусы да. Ләкин ничек чыкса да, үкенми, шулай әкренләп чиркәнчек ала-ала ияләшерләр әле. Теге чакта, аларның планнарын берьюлы өзеп ташлап, хәтерен калдырган булса кирәк шул. Хәер, бер-бер артлы туган өч иманасыз-җирсез кызың аяк арасында буталып йөргәндә, үкенергә инде соң да иде. Алдагысы аны шулай ук куркытмый, ни булса — шул булыр, Гыйльмениса өчен дөньяның иң хәтәр чагы менә бүген иде.

Гадәттә, Гыйльменисасы белән төрле планнар корырга, әле өйнен тәрәзәләрен кадаклап читкә китәргә, әле яңадан байга ялланып батрак булып керергә, әле, һич югы, ат печүчеләргә ияреп китеп, аларның һөнәренә өйрәнергә дә аннары, бер җаена төшенеп алгач, хәтта ат белән генә дә чикләнеп калмыйча, шул үткен пәке белән ике аяклы затларны да печкәләп йөрергәме икән, дип, уенын-чынын кыстырып сөйләшергә

ярата иде Барый. Кыскасы, ничек кенә булмасын, тәкъдир дигәнендә нәрсә генә язылмасын, өскә ишелеп барган бу иске өйдә алты җан иясе бер имана җиргә ябышып ятарга мөмкин булмаячагын ул яхшы сизә, тыштан шаяртып сөйләгән булса да, эчендә ут үрли, кеше ышанмастай юкны-барны сөйләп җибәрүләре дә ничек тә Гыйльменисасын юату, аңа боегырга ирек бирмәү өчен була торган иде. Шул рәвешчә, тел белән тегермән тарта килгән Барый көннәрдән бер көнне — әйтерсең, кемдер аны шуңа котыртты — бөтенләй беркем белән дә сөйләшмәс булды. Ашарга ни дә булса әзерләсәләр, килеп утыра, ашый, аннанмоннан гына амин тоткан булып, ләкин юкны бар итеп әзерләгән Гыйльменисасына һич сүз катмыйча, хәтта күз кырыен да төшермичә, янадан ян сәке буена китеп чабатасына утыра иде. Үзгәлек тик шунда: әллә нидә бер кызларын — әле берсен, әле икенчесен, әле өченчесен — кулына алып, аларга да һич сүз кушмыйча, гадәттәгечә, балаларының инде мең мәртәбә саналган аяк бармакларын, кул бармакларын, берәм-берәм санарга керешә, минутлар буенча күзләренә текәлеп карап тора, аннары әйтсә тик өй эчен тутырып берничә сүз әйтә:

— Бу кадәр үзеңә охшатып, матур итеп тудырырсың икән, Гыйльмениса. Сина хет матур булсаң да, килешкән: Әлмөхәммәт бай кызы. Ә болар кемнәр? Болар бит иске мүк арасындагы тычкан балалары гына... таптап, сытып китмәсәләр ярый үзләрен бер дә бер көнне...

Я бөтенләй телсез калып сәгатьләр буенча бер сүз дә кушмыйча утыра бирә иде. Барыйның балалар турында болай өметсез сөйләнүләрен дә бер дә яратмый иде Гыйльмениса. Ә бер көнне шул «телсез» Барый, һич көтмәгәндә, ясый торган чабатасын калыплы килеш почмакка тотып атып бәрде дә дәррәү аяк-өс калкып һәм бик катгый рәвештә:

— Киттем, Гыйльмениса,— дип, өзеп-кистереп сүз башлады,— синең атаңа, Әлмөхәммәт байга барам. Теге вакытта да эшләгәнемне тутырып бирмәде, аны да таптырам, янә дә килеп, менә бу балалар тычкан балалары түгел, аның баласының балалары. Килсен, күрсен. Бусаганы атлап кергәне юк, ничә ел бергә торып. Әллә фәкыйрьлегебез йогар дип куркамы?

Авызы тулы кара кан булса да кеше алдында төкермәскә өйрәнгән Гыйльмениса өчен бу соңгысы бөтенесенә караганда да куркынычрак булды: ул этисе алдында баш июдән курыкмый, ул югында үзенең туган йортына сирәк булса да баргалап-кайткалап та йөри, әнисе белән аның мөнәсәбәте, бик үк ялтырап тормаса да, ярыйсы, этисе күрмәгәндә генә әнисе «менә бусы үзеңнең бәләкәй чагыңнан калган, оланнарыңның я берсенә, я икенчесенә рәтләп кидер» дип, вак-төяк чүпрәкчапракларын да биреп җибәргәли, юл өсте туры килгәндә, үзе дә сугылып, балаларны ни белән булса да куандырып, сылап-сыйпап киткәли иде. Боларына горурлыгы комачауламаган Гыйльмениса Барыйның теге сүзләрен ишетеп, чыдый алмады, бергә тора башлаганнан бирле беренче мәртәбә тавыш кубарып, китте тезеп, китте тезеп:

— Шул көнгә калдыңмыни инде, бичара? Үзе сүз кушмаган кешенең бусагасына дүрт аякланып, мүкәләп барыр көнгә? Мина ата тиешле кеше ул, аны мин синнән яхшырак беләм. Сырты белән торыр-торыр да йөзе белән әйләнмичә булдыра алмас, бер әйләнер. Шул чагында адәм теле белән барысы турында да сөйләшербез.

Хәер, Барый бик кызган иде бу минутта, яхшы сүз белән генә тотып торыр хәлдә түгел иде, Гыйльменисаның юатырга тырышуларын берьюлы күреп, бөтен тавышына һәм бөтен ачигысын салып, акырып җибәрде.

— Кем әйтте сиңа мүкәләп барам, дип? Теге вакытта биреп житкермәгән хакымны даулап барам. И бер очтан шунда синең хакыңны да даулыйм! Егерме өч яшенә хәтле шул йортта эшләп, нәрсә биреп жи-

бәрде ул сиңа? Я, әйт, нәрсә киеп килдең син миңа? Әлмөхәммәт бай кызы була торып? Бер кат ыштаннан килдең.

Сүз бу хәтле ачыктан-ачык киткәч, Гыйльмениса иренә ачулана алмый, хәтта сүз дә әйтә алмый, әйтер сүзе булса да әйтә алмый: шундый йомшак, бала табигатьле, тумыштан ук китек күңелле, хәтта беркадәр йомыкыйрак та булып яралган кеше дә шушы чиккә җитеп гаҗизләнгән икән, аңа каршы сүз әйтеп, аны кирәкмәскә осскытып торуның ни мәгънәсе бар? Шул ук вакытта Гыйльмениса бу йортта бергәләп узган тормышында беренче кабат сизде: теге вакытта ата-анасына күзгалган сукыр ачу аркасында чынлап та бик йомшак, зәгыйфь кешене сайлаган икән ул тормыш иптәше итеп. Балалары тәпили алганы тәпиләп, тәпигә китмәгәне шуышып — аның тирәсенә җыелганнар, кайсы итәгенә ябышып, кайсы кулга сорап, шыңшый башлаганнар иде. Җирсудан мәхрүм ителгән бу кыз балалар тудыру яңадан беркат күңелен өшетеп алды Гыйльменисаның — ахыр чиктә, Барыйның болай гаҗизләнеп калуының нигезендә аның да гаебе бар ла. Әллә шуны сизенүдән, әллә, тавышны зурайтып, балаларны куркытырга теләмәүдән, Гыйльмениса җайлап кына, хәтта сүзне уенга борырга теләгәндәй итеп әйтте:

— Син ул сүзләрне чынлап әйтмәгәнсеңдер, Барый? Булгандыр шундый җенең чыккан вакытың, ычкындыргансыңдыр ялгыш. Булмастай эшне сөйләүдән кемгә файда.

Бу юлы инде Барый да кычкырмыйча гына, ләкин шул ук вакытта уйнап сөйләмәгәнлеген аермачык сиздереп әйтеп куйды:

— Чынлап әйттем мин ул сүзне, Гыйльмениса. Барачакмын. Аласымны якасыннан каерып алачакмын. Инде алай түгел икән, үпкәләш булмасын беребезгә дә, өенә ут төртәчәкмен.

Әлбәттә, җен чыкканда кузгалып китә торган бу бер кабыну гына булып калды. Моңа хәтле кешенең чебешенә дә кул якмаган, гомумән, кешегә яман сүз дә әйтә белми торган, ә Гыйльмениса белән бергә яши башлаганнан бирле, хатынының сабырлыгыннан, киң холыклы булуыннан бөтенләй эреп киткән бәләкәй гәүдәле чандыр Барыйдан мондый куркыныч адымны көтеп тә булмас иде. Ә кем белгән? Кайбер хәлләрдә нәкъ әнә шул көтеп булмый торган эшләрне эшләп ташлыйлар да бит! Бер хәл дә тумыштан кешенең маңгаена язылып куелмаган. Килеп туа шундый хәл-әхвәлләр, дөнья кешене кирәгеннән артык үчекли башлый, кешедә — нинди генә сабыр һәм авыр холыклы кеше булмасын — әкренләп ачу җыела, үпкә җыела, сары су булып үт җыела һәм кеше — моңа хәтле гомердә андый кабыну күрсәтмәгән кеше — кинәт бомба булып шартлап куя.

Семьясы зураеп та күгенең зураюын күрмәгән һәм балалары өчен, бигрәк тә Гыйльменисасының әчтән сыза баруын күреп, йөрәге әрнегән Барыйда соңгы вакытларда әнә шундый көтелмәгән кабынулар әледән-әле күренгәли башлады. Шундыйлардан берсе, мәсәлән, көннәрдән бер көнне ул һич сәбәпсезгә сеңелесе Камәргә бәйләнергә тотынды.

— Син, кызый, җиңгәң үз күлмәгеннән бозып тегеп биргән бу күлмәктән кайчан чыгарсың икән? Чыгарга уйлыйсыңмы, юкмы? — дип башлап китте ул, башта бик алай кызмыйча гына. Камәре каршы килеп сүз әйтмәсә, бәлки, шуның белән беткән дә булыр иде, һәр яктан кимсетелгән кеше бит, бу сүзләр Камәргә дә авыр кагылды булса кирәк.

— Бөтенләй күлмәксез йөрергә кушуың түгелдер бит бу, абый? — диде Камәр, чак кына тавышын күтәрә төшеп.— Инде мине башук күпсенә башлавыгыз икән, китәрмен... Кайда булса да минем дә чабата олтаны хәтле генә туфрагым бардыр. Мин алай, кайбер кешеләр кебек, байларныкы азрак таммасмы, дип кешедән калганны көтеп тормыйм.

Ай, шушы соңгы сүзләрен әйтмәгән булса! Бик авырткан җиренә тиде шул бу сүзләр Барыйның. Һәм ул һични белештермичә, һичбер нәрсә белән исәпләшмичә, берьюлы кайнап китте.

— Кем ул байларныкын көтеп йөрүче? Минме, син утка янмас, суга батмас бөкре шайтанны җилкәсендә туйдырып ятучы абыеңмы? Гомердә кияү чыгасы юк синң. Мин булмасам, янә килеп, үзе кимичә сиңа кидерүче әнә ул изге җанлы җиңгәң булмаса, әллә кайчан кеше бусагасы төбендә кәкрәеп каткан кеше булыр идең инде син...

Бик нык кызды Барый да бу минутларда. Әгәр килеп Гыйльмениса сы аның авызын томаламаса яки, иренә сиздермәстән генә, Камәргә хәзергә кая булса да күздән югалып торырга ишарә ясамаган булса, ихтимал, таш коры кызу белән генә калмаган да булыр иде.

Һәм нервысын тота алмас хәлгә килеп арган-йончылган кешеләргә хас булганча, яумыйча узган бу давыллы болыт, бәлки, монда да шулай узып киткән булыр иде. Күрәчәккә каршы, шунда Гыйльмениса йөрәккә үтә торган бер сүз әйтте:

— Кая куймакчы буласың ул бәхетсез кызны? Әгәр синең белән минем канат астында да урын бетсә?

Кинәт берсүзсез аяк-өс катып калды Барый. Аның сүз әйтер чамасы калмаган иде. Хатынының күзләренә карады — икесендә дә яшь тулы иде.

— Мин монда артык кала алмыйм, Гыйльмениса. Син теләсәң нәрсә әйт, мин монда артык кала алмыйм. Хәбри малайлары әнә Донбасска китәргә җыеналар, аларга иярәм дә китәм. Аларда булган аяк-кул миндә дә бар, алар эшләгәнне, шәт, эшләрмен.

Һәм бернинди кыстау-ялварулар да, балаларын һәм хатынын ярату да, саусызлыгына ишарәләп, билгесез язмыш белән өркетүләр дә аны бу карарыннан кире кайтара алмады.

— Сез монда ничек кирәк алай тарта-суза торсагыз, мин байлык артыннан куучы кеше түгел, әзрәк түл җыю белән «җәлт» кайтып житәрмен,— диде ул, аерылганда Гыйльменисасын кочаклап.

— Ә син теге сүзләрне оныт, Камәр, уйлама: абыең әйтмәде аны, абыеңның җеннәре әйтте,— шул сүзләр белән аннары сеңелесен кочаклады, күрмәстәй булып, озаклап, күзләренә карап торды,— җиңгәң белән яхшы гына торыгыз, балаларны карарга булыш. Кайтышлый сиңа, алла насыйп итсә, инәдән-җептән генә чыккан бер кала күлмәге и бер көмеш чулпы апкайтырмын.

— Чулпыны мин җиңги үзенекен тактырганда да такмадым,— дип, мөлдерәп абыйсының күзләренә карап куйды Камәр. Ул бичара булачак «кала күлмәге»нә дә бик канәгать иде.

Бик авыр, ямансу саубуллашу булды бу. Әйтерсең, барысының да өстенә болытлы күк ишелеп төшәргә тора, күкне һәм болытны дәррәү ишелеп төшүдән бары тик иңбашлары белән генә тотып торалар кебек иде. Соңгы күрешүләре һәм соңгы аерылышулары шушы булган икән. Киткәннән соң Барыйдан ярты ел буена берме, икеме тапкыр акча килде, әллә ни зурдан булмаса да, «балаларга» дигән булып, күчтәнәчләре дә килә торды һәм, аның өстенә, атна саен диярлек сагыну-саргаю сүзләре белән тулып хатлары ява иде. Бу Донбасс якларындагы хат язу остасы теге Мамадыш юлын салганда туры китергән остадан күп мәртәбәләр өстен, хатны читен-почмакларын буяу карандашлары белән чәчәкләп-чуклап тутырган кәгазьгә яза һәм хатның азагына һәрвакыт бәләкәй генә кош томшыгы төшереп (ул, күрәсең, аныңча сандугачмы, былбылмы вә башка шундый җырларга кереп тә, дөньяга килергә әле өлгермәгән берәр кошмы?), шул томшыктан як-якка канатлы-канатлы юллар чыгарып:

...ал кадыйм түшләреңә, гөл кадыйм түшләреңә,
Былбыл булып, гөлгә кунып керәсең төшләремә,

— дигән җырны язып куя торган иде. Башка җырларны белмәгәннән яки яратмаганнан түгел, кабатлап-кабатлап булса да, гел менә шушы җырны яздырганы өчен дә ярата иде Гыйльмениса Барыен. Ярата иде һәм күрмәстәй булып, киткән юлларыннан күзләрен алмыйча, сагынып көтә иде. Нишләтәсең бу вафасыз дөньяны! Чынлап та, икенче күрешү насыйп булмады аларга. Киткәненә ел тулды, инде кайтыр көннәре дә житә булыр дип, өметләнеп көтеп торганда, Барыйның бергә эшләгән иптәшләреннән, Арча һәм Наласа ягы кешеләреннән, бер дә чәчәкләп-чуклап тормыйча язылган, коточыргыч хат килде: лава ишелеп, мәрхүмнең гәүдәсе сулы, ташлы-балчыклы җир астында күмелеп калган. Эзләп караганнар гәүдәсен, ләкин өстенә шушы хәтле зур гөнаһларны, алдашуларны, җинаятьләрне һәм сагынуларны күтәреп торган авыр җир ишелсен дә, шуның астыннан чандыр гына Барыйны ничек эзләп тапмак кирәк?

Бер имана җирдән сыгып алган бәрәкәтне алты кашыкка тарта-сува бүлеп, житмәгәнен кешегә орчык эрләп, көнлеккә йөреп житкерергә тырыша-тырыша, алай да тулмыйча калган бушлыкны киләчәккә өмет яки сүзсез хәсрәт белән тутырып, кеше рәтеннән ничек тә төтен чыгарып киләләр иде әле. Тагын берничә елдан яңадан җир өләшәчәкләр, аңа хәтле Донбасстан сагынып кайткан Барыеннан, алла кушып, ничек тә бер ир бала булмасмы?.. дип өметләнеп көтеп торганда, күтәрә алсаң — күтәр, күтәрә алмасаң — егыл да үл, Гыйльмениса җаным, итәгенә өч кыз бала һәм кияү чыкмый торган бөкре каенсеңелеңне төяп, ялгыз башың кал инде менә. Ә җир өләшү елы килеп житсә — алла үзе сакласын — шушы күп тамаклы оя Барый иманасыннан да мәхрүм калачак. Закон алар өчен генә чыгарылмаган, ир-атың юк икән, җиргә борыныңны сузма!

## VI

Нишләргә калды хәзер соң бу ояга? Бигрәк тә оя башы Гыйльменисаның үзенә? Кайчандыр, Барыйга кияүгә чыкканда, үзе егылган еламас, дип өздереп әйткән иде ул. Юк, үзе егылганның да елар көннәре була икән! Шулай да, төннәрен бала-чагаларына да, каенсеңелесе Камәргә дә күрсәтмичә, күнеле тулып, бик әкрен елаштыргаласа да, көндез ул аны-моны сиздермәскә тырыша, хәтта хәл белгән атлы булып төпченергә ярата торган күрше хатыннары алдында да әллә ни сер бирмичә:

— Нишләмәк кирәк язмышың шулай кырын торгач? — белән бетермәкче була иде. Ләкин юк, борчуны бетереп булмаган кебек, бер күңел йомшагач сүзне дә туктатып булмый икән. Ни аз сүзле, кырыс табигатьле Гыйльмениса, бер туктап хәл алганнан соң, механик рәвештә диярлек, яңадан ялгап алып китә.— Илдә чыпчык үлми, без дә үлмәбез, үз көнебезне үзебез күрербез, шәт. Әнә чит-ят җирләрдә, иләмсез авыр туфрак асларында ятып калган Барый бичараны әйтегез сез. Монда булса, ичмасам, зират яннарыннан узганда догасын кылыр идең...

Чынлап та, шул чирләшкә Барыен, Гыйльмениса дигәндә, җиргә-суга хаклары булмаган шушы почык борынлы кызлары дигәндә үләргә торган — һәм дөреслектә ул шулар өчен үлде дә инде! — беркатлы ирен һич кенә дә исеннән чыгара алмый. Артык аптырагач бугай, аның кайчакларда, кабынып китеп, гомердә кулы күтәрелмәслек дуамал эшләргә дә ярсып куюларын, ә вакыты белән балалар кебек оялчангакыюсызга әйләнүен, Гыйльменисасы күлмәк алыштыра башласа, карап торырга уңайсызланып, нинди дә булса йомыш белән тизрәк тышка чыгып китүләрен, соңгы сәфәре вакытында озата барырга чыккач, хатынының авызыннан суырып үбәргә бик теләп тә, кеше алдында кый-

мыйча, «хуш инде, нәнәм... балаларынны, үзеңне ничек тә саклый күр!» дигән сүзләр белән чикләнүен, күзләре яшь белән тулган килеш китеп баруларын — барын да, барын да бер-бер артлы күз алдыннан үткәреп, кызгану катнаш сагыну белән өзелеп сагына иде.

Шулай да сагыну белән генә яшәп булмый, нәрсәдер эшләргә, бүтәннәр аяк астында тапталмаска, ничек тә аякка басарга кирәк иде. Шул турыда сөйләшү өчен ул бер көнне иртә белән каенсеңелесе Камәрне һәм, аңласа-аңламасалар, балаларны үз тирәсенә җыеп:

— Я, инде нишлибез, балалар? — дип сүз башлады.— Азмы-күпме ышаныр кешебез этиегез иде, ул хәзер юк. Яңадан җир өләшкәнче аннан калган шул бер иманабызны, шәт, тартып алмаслар. Анысын ничек кирәк алай суздык та, ди. Биш җан ул бер имана белән генә кая барырбыз? Ярый ла әле, аны кеше шикелле вакытында чәчтерә алсак? Шуннан тагын кая сугылырбыз?

Монда анын, хәзергә бик каты бәгырьле булып торса да, туган этисе барлыгы, үтә авырга китсә, аңарга барып егылырга мөмкин булачагы һәм аның ятимнәрне ничек тә ташламаслыгы күңеленә килде. Ләкин ул моны актыккы чара итеп саклый, хәзердән үк кешегә ышанып үзен тынычландыруны горур җаны күтәрә алмый иде. Шулай да бер башлагач, анысы да бәреп чыкты:

— Сез уйлыйсыздырмы-юктырмы, ә мин төннәр йокламыйча уйлыйм. Сугылырдай капкалар бар. Әйтик, менә Камәрнең ялгыз үзен генә калдырып, миңа балаларым белән яңадан эти йортының бусагасына кайтып егылырга? Күңеле йомшак чакка туры килсәк, шәт, бусагасыннан ук куып чыгармас. Аларның миннән башка балалары юк. Илла да мәгәр, алдан ук әйтеп куям, тәндә җаным бар чакта мин Камәрне ялгыз үзен генә калдырмаячакмын. Калдырсам, мәрхүм Барый миңа мәңге риза-бәхил булмаячак.

Шундук тагын — һич урыны түгел бер вакытта — күңелдә мондый вәсвәсәле уй да чагылып алды: «Әгәр дә мәгәр чит кеше балаларын асрап үстерергә бик тә теләп риза булган берәр дөнья әүлиясы килеп чыгып, мине кияүгә сораса? Ходайдан яшермәгәнне үземнән яшергән юк: мин әле кияүгә ошамаслык кеше түгел. Чыгарга булыр иде, ник булмасын. Мәгәр ул чагында да аякка әлеге шул «әгәр дә мәгәр» дигән богау салынып тора. Беренчедән, хәзергә әле бер яктан да андый адәм әүлиясы килеп чыгардай күренми. Күренсә дә, ул турыда уйларга иртә, мин ул турыда уйламаячакмын: уйлаганга карап кына, ул минем ятимнәремә Барый этиләре кебек эти була алырмы? Шулай булгач, болай уйлау иртә генә дә түгел, бөтенләй гөнаһы ук, әстәгъфируллатәүбә, мин уйламадым моны, шайтан күңелгә китерде. Юк, юк, мин балаларымны үзем үстерергә тиеш! Ничек кенә читен булмасын, үзем үстерергә, үзем, үзем... Өченче бер юл бар: шул өч ятимне кайсын житәкләп, кайсын кулга алып, хәер сораша чыгып китәргә. Бу юлга аягым атламаячак. Ике аягымның берсе дә. Ике аяктан башка бит әле минем ике кулым, бер йөрәгем бар. Җибәрәчәкләрме алар мине мондый хурлыклы кәсепкә?»

Яшен тизлеге белән янә шундый каршылыклы уйлар узды Гыйльменисаның күңеленнән. Узды, ләкин — аллага шөкер — ул моны теленә китермәде. Шулай да, хәтта теленә китермәгән хәлендә дә, Камәре, әйтерсең, моның күңелендәгеләрен укып торган — сизгер була диләр шул андый китек күңелле кешене.

— Уйламыйксана, туганым-җиңги, җыен юк-бар уйларны,— дип кинәт урыныннан торып, күзләрен читкә борды һәм, балаларданмы, үзеннән үземе оялып, кабаланып, кече якка таба атылды.

Бераз сулыш алганчы һич сүзсез, шул ук вакытта утырган урыныннан да купмыйча, торып калды Гыйльмениса. Аннары Камәрне яңадан үз янына чакырып китерде.

— Җылауны мин үзем дә булдыра алам, Камәр жаным,— дип башлады ул, бер үк вакытта иркәләгән дә, кисәткән дә тон белән,— илла да мәгәр җылап утырып кына безнең тамакны туйдырмаячаклар. Ә безгә тамак туйдыру, кеше арасында ялангач йөрмәү турында уйларга кирәк.

Бераз суына төшкәнче ул янадан сүзсез калды, балаларына — әле берсенә, әле икенчесенә кулы белән кагылгалап куйды һәм кинәт, житди эш турында сөйләүдән арып, уен-көлкегә күчкәндәй, хәтта авыз чите белән генә елмайгандай итеп, Камәрнең кулларына тотынды. Аның кулларын — икесен дә — үз кулларына алып, соклангандай беравык карап торды. Карап торды, ләкин сүз башларга ашыкмады.

— Күптәннән күзәтә йөрим, Камәр, зинһар, юри әйтә дип уйлый күрмә,— Гыйльмениса хәтта бераз ялварырга да әзер кебек иде бу минутта. Шулай да Камәрнең кулларын ычкындырмаган иде әле,— кулларың, бигрәк тә менә бармакларың матур синең. Үзләре озын, үзләре житез, гармунчы бармакларымыни? Беләсеңме, оста гармунчыларда була шундый озын, житез, биеп тора торган бармаклар. Барый абыеңда, мәрхүмдә, андый бармаклар юк иде, булмаганны бар дип әйтер хәлем юк. Аның каравы Барыйның, мәрхүмкәйнең, жаны матур иде, андый матур жанлы кешеләрне чәчеп үстереп булмый бу дөньяда.

— Беләсеңме нәрсә, Камәр жаным,— кыска паузадан соң, ул кинәт дәртләнеп һәм янындагы кешегә дә дәрт кертә торган итеп дәвам итте,— мин синең бу матур бармакларыңа үзләре кебек матур эш табарга уйлап торам әле. Берьюлы коеп ук куярсың, дип әйтмим, тора-бара өйрәнерсең. Мондый матур кулның, мондый житез бармакларның өйрәнмәгән эше булмаска тиеш.

Физик яктан кимчелекле кешеләр болай да тәэсиргә тиз бирелүчән булалар, үзе турында моңарчы гомумән беркемнән дә, бер ягы турында да мактау сүзе ишетмәгән Камәр жиңгәсенең бу сүзләрен ишетеп кинәт аптырабрак калды: «Ничек аңларга икән моны? Үзе ямьсез кешенең кулы гына матур булуы мөмкин микәнни?»

Аның нәкъ менә шушы гажәпләнү катыш әчке уяну вакытын төгәл туры китереп, жиңгәсе Гыйльмениса сандыктан бер оч тамбур жебе белән тамбур энәсе алып килде, шундук тагын бер кисәк ак бәз эзләп тапты. Бу соңгысы Барыйдан посылка төреп жибәрелгән бәс кисәге иде булса кирәк, ныклап юылып, өтеләп куелган булуына да карамастан, анда әле шәмәхә карандаш белән калын итеп язылган адрес эзләре бетеп үк житмәгән иде.

— Тамбур белән чигешне безнең авылда белгән дә, тоткан да кеше юк, ә ул, бер рәтен белеп алсалар, иң зат эшләрдән санала. Мине менә ул чигешкә калада яшәүче алмапаларга жибәреп өйрәттеләр. Шаярма, Әлмөхәммәт бай кызы ич, яр асты Барыйга ябышып чыгасын кем белгән аның...

Гыйльмениса, уенын-чынын бергә кушып, шулай сөйләнә-сөйләнә, элеге теге посылка капчыгыннан сүтелгән бәс кисәген киергегә тарттырды. Камәр күреп торсын өчен ул моны юри әкрен, тәмам жиренә житкереп, бер дә ашыкмыйча эшләде. Шул арада үзе:

— Бозылса, бусы әллә ни бәла түгел, кул өйрәнер өчен дип шөйлә шундый искене сайладым. Киергене менә болай, сул кулың белән кочаклап тотасың, уң кулыңда энә, анысы менә болайрак йөри... Юк, юк, син алай текә тотма, тимер сәнәк белән тирес казымыйсың ич. Бик алай басма да энәгә...

Балалар төрлесе төрле яктан әле яшелле-зәңгәрле җепләргә сузылгалап, кечесе дисәң, ул терекөмеше әнисенең култык асты аша алдына, алдыннан сөт чишмәләренә үрелеп, комачауларга бик тырышып карасалар да, Гыйльмениса бу эшкә бик чынлап тотынган күренә, ә ул чынлап тотынган эшен ахырына житкермичә кала торган кешеләрдән

түгел иде. Камәр дә бик күңел биреп азаплана, чөнки җиңгәсе бу зат эшнең киләчәктә кияүгә чыгарга әзерләнә торган кызлар арасында базары югары булачагын әкренләп-әкренләп аңарга тәмам сеңдереп җиткергән иде. Аннары бит Камәр үзе дә хыялдан бөтенләй үк мәхрүм калган кеше түгел, шул бер уңайдан ул күңеле белән хыял нәкышләре чигеп барырга да өлгерә: «Белмәссең бу тәкъдирнекен... шулай авылда юк эш белән дан җибәреп, берәрсенең колагына барып керсә... насыйбы аныкы да йоклап ятмый торгандыр, бәлкем!»

Аннан да бигрәк, Камәрнең җиңгәсе күреп алган куллары, чынлап та, эш рәте белә торган куллар булып чыкты. «Оста куллар» дип үк әйтергә әлегә иртәрәк, әмма әнәне-җепне ярыйсы гына тиз йөртә башлады. Шуның да өстенә җиңгәсе — хәйләкәр төлке — төрлечә кодрәтләндереп, каенсеңелесенең көннән-көн күңелен күтәрә бара иде. «Илдә күренмәгән» бу чигеш турындагы сүз шундук кеше теленә менде, авылда кияүгә чыгуны өмет итеп йөрүче кызлар шактый күп иде, ә кайсы кәләшнең соң килен булып төшкәндә, «илдә юк» бүләкләр алып барып, кияү йортындагыларны һуштан яздырасы килмәс икән?

Камәр түрдә, чистада гына утырып эшлисе бу эшкә тәмам өйрәнеп җиттем дигәндә генә «туганым-җиңгәсе» аңарга өстәмә эшләр дә тапты.

— Түрдән төшкәләргә туры килер сиңа, Камәр җаным,— диде җиңгәсе бер көнне бик җитди итеп,— мин иртәгә Гайни Сәхипләренә көнлеккә барам, тары утарга. Куркырлык түгел, берьюлы өч кыз бала кала сиңа иптәшкә. Олысына — Факиһәсенә кечесен так, тартып йөрсен нәни арбасы белән. Бик җылый башласа, әнә мич кырыенда бер шакмак шикәр калдырам, шуннан китеп алып, ипи белән имезлек чәйнәп каптырыгыз. Кара аны, шикәр шул гына, күп умырырга бирмә. Көндез кайтып үзем имезеп китәрмен — дөньяның уен түгеллеген кабык арбада ятканда ук белеп ятсын. Ә уртанчысы — Фасиләсенә тимә генә, анысы аның акыллы: ипи әләксә, шикәр кушмыйча да бик әйбәт суыра. Тик бер ягын кара: төрле җирдә ятып йоклый торган гадәте бар. Кояш астында йоклап калып, башына кызу капмасын.

Шулай тезде-тезде дә, баерга өмет итмәсә дә, тамак уздырырга һәм шул исәптән күз мәлендә Гайни Сәхипләреннән иманага тигән җирен эшкәрттерү өмете белән, итәккә тагылырга торган балаларын, ничек кирәк алай юатып, тизрәк чыгып китү ягын карады.

Камәргә, әлбәттә, «туганым-җиңги» тезеп китканчә генә туры килмәде. «Акыллы» дигән уртанчысы чәчен-башын туздырып керде дә, әллә кайдан апасы Факиһәнең тасмасын кулга төшереп, Камәр апасына, чәчемне шушы тасма белән кушып үр, дип сагызланырга тотынды. Каршы килә алмады Камәр апасы. Каршы килеп кара, бер яры китмичә, ишек алдына чыкмыйча, көннең көнозын колак төбендә, ачылыр-ачылмас теле белән нидер лыкылдый-лыкылдый җылап утырачак. Ә Камәргә, кулын яңа эшкә күнектергәндә, барыннан да элек, тынлыктынычлык кирәк. «Иң акыллы»сы белән эшне җайлап, авыз читләрен, күз яшьләрен сөрткәләп, тузгыган башына ничек әләксә шулай әлеге зәңгәр тасманы тагып чыгарып җибәргән генә иде, ярты сәгать үттеме икән, берәү урынына икәү җылап кайтып керделәр. «Олы»сы, тагып чыгарган арбасын ук ташлап, уртанчысы белән әлеге тасманы бүлешә алмыйча, гауга күтәреп кергән: янәсе, әнисе аңа дип, Факиһәгә дип алган бит аны сөякчедән. Акчага да, күкәйгә дә түгел — андыйларга бүтән нужалар да бетмәгән — Факиһә үзе, күрше-тирә ишек алларыннан, бакча башларыннан, чүплекләрдән берәмтекләп җыйган сөякләрне алып барып, шулар бәрабәренә олы кызының үзенә дип атап алган. Әнә шуны, әле Факиһә үзе тагып та карамаган өр-яңа чәчүргеч тасманы, имештер, борын асты да кипмәгән «иң акыллы»сы тагып чыккан. Ул да түгел, урамнан кабык арбасы белән бәләкәен икенче берәүләр

тартып керттеләр, урам уртасында, тузанлы юлда ташлап калдырган «олы» дигәне. Кыскасы, эшләргә дә, як-якка карарга да бирмәсләрдер, ахры, балалар.

— Кая кушасың, шунда үзем барам, түлке синең бу сугыш чукмарларың белән каласым юк,— дип өздереп куйды Камәр, кичен Гыйльмениса эштән кайткач. «Сугыш чукмарларың» икән — сугыш чукмарлары, әйдә, бу дөньяда артык юаш булып та мәгънә чыгарып булмый. Сатулашып торырга бер дә дәрте юк иде Гыйльменисаның, эссе кояш астында көннең көнозын туңкаеп йөреп, җеп өзәрлек хәле дә калмаган иде. Иртәгесен иртәнге акыл уянды:

— Ярый алайса, бүген беребез дә беркая да бармыйбыз, анда уттай кояш астында чүп утап йөрү дә бәйрәм ашы түгел,— дип башлады ул, Камәргә әйтүдән бигрәк, үзе белән үзе сөйләшкәндәй итеп,— әйдә, булдыра алсак, бездән чыксын яңа фасон: чәчтермибез абыеңнан калган имана җиребезне, чәчтермибез и әкренләп ашамыйча гына торырга өйрәнербез.

Артык сүз кирәк булмады Камәргә. Тел белән әйтүгә караганда, күңелдә әйтелмичә калганнардан ул күбрәкне аңлый, җиңгәсенең сүзләре әрнү һәм гаҗизлек белән тулы икәнлекне шунда ук сизеп алды.

— Үз эшемә тотынырга бер генә дә вакыт калдырмыйлар, шуңа әйтүем булгандыр инде,— диде ул, нинди дә булса бер сүз әйтмичә калса, җиңгәсен тагын да ныграк ачуландырудан куркып.

— Җәен безгә тик утырырга туры килмәстер, Камәр акыллым,— Гыйльмениса хәзер тату җайга яткан, шулай ук Камәрне дә үпкәләтеп калдырасы килми иде,— кышын менә икебез тиң кул эшенә утырырбыз. Синнән эш чыгачагына мин хәзер тәмам ышандым, син шул үзеннең тамбурыңда утырырсың, мин стан корып, чүпләмле сөлге-тастымаллар сугарга тотынырмын. Ә ул бик иртә киенергә-бизәнергә ярата башлаган Фасиләне мин аны...

Ул үзенчә бик нык тузынган-ачуланган булып күренергә тырыша, әмма барып чыкмый, идәндә — киң салам түшәк өстендә, кайсы ничек ташланып, рәхәтләнеп йоклап ятучы балаларына бер караш ташлауга ачулануы әчке шатлык белән алышына иде.

— Эш юклыктан шулай азына ул, бер дә бүтән түгел,— дип сөйләнеп куйган булды соңыннан, әлеге шул апасы сөяк җыеп алган тасмага күзе төшкән Фасиләсенә төртеп күрсәтеп,— хәзергә бик матур йоклый, уятсак телебез корыр. Уяныгі, тамагына кабу белән син аңарга эш тап, Камәр җаным. Ич югы, әнә каз бәбкәләрен сакласын. Әйт, котырт: тилгән-козгыннан алдырмыйча, аттан-эттән имгәттермичә, унберен тиң карап үстерсә, әниең әйтте диген: көзгә бәбкә казларны саткан акчага сиңа өр-яңа ситсы күлмәк алырбыз, дип әйтте диген.

— Ә тилгән, бәбкәсе-ние белән бергә, үзен күтәреп алып китсә?

Уйламаганда-көтмәгәндә Камәрдән дә, һәрвакыт аз сөйләп, күп уйланып йөрүче үтә йомык Камәрдән дә әнә нинди йомры сүз килеп чыкты. Моны бары тик яхшыга гына юрарга мөмкин иде: димәк, татулык, өмет, киләчәккә, хәзергә әле ситсы күлмәкле киләчәккә генә булса да, ышаныч урнаша бара иде бу кечкенә өйдә.

Җәен ничек кирәк алай, алдан ук кешегә көнлеккә йөреп, урак урып, ындыр эшләренә булышып, үз вакытында — кешедән элек тә түгел, кешедән бик соңга да калмыйча — имана җирен эшкәрткәч, чәчәсен чәчтереп, җыелганын келәтенә салдырып, өстәвенә тагын Барыйдан ук калган алабашлы сыерына азмы-күпме азыгын да әзерләп, бераз баш-күз алу белән, алар вакыт тигәндә үз эшләренә: Камәре, киергесен алып, үзенең чигешенә, Гыйльмениса, стан корып, чүпләмле сөлгетастымаллык сугу эшенә керештеләр. Балалар арасында да талаш басылды. Җәйге айларда күкәй, көзен чикләвек җыеп саткан акчаларга балаларның азмы-күпме өсте дә бөтәйтелде. Тик хәзергә Камәрнең ге-

нә өстенә юк, ул үзенә күрә түгел, юк-барга риза булмый: «Болай да килеш-килбәтем рәтсез, кигән киемең дә кешенекеннән ким булса, кыз башың белән ничек кеше күзенә күренмәк кирәк» дип киреләнеп куйгалый иде.

Гаҗәп хәл — Гыйльменисаның моңа хәтле һич ишеткәне юк иде — соңгы вакытларда Камәр, бик еш булмаса да, үзенең кыз кеше икәнлеген шул аз сүзлелеге аша да искә төшергәли башлады. Җиңгәсеннән качырып-посырып кына кесәсендә кершән-иннек тә йөртә һәм тагын да гаҗәбрәге: бер көнне моның өстенә иңбашларын күпертмәләп, төймә юлларын яшереп, нәкъ шул заманча итеп теккән зәңгәр плюш бишмәт мендे. Башта ышанмаска тырышып, «үзенеке түгелдер, куеп торган берәр кешенеке белән бөкресен каплап йөрүедер» дип көлеп караучы күрше кызлары, өскә ишелергә торган кыйшык өйдән күзнең явын алырлык зәңгәр плюш бишмәт киеп чыккан Камәрнең чиләкләрен шыңгырдатып чишмәгә суга китүен күреп, төрлесе төрлечә юрарга керештеләр:

— Җиңгәсе бертуган апаңнан да болай, җиңгәсе аркылы, сиздермичә генә, Әлмөхәммәт байныкын тарттыра торганнардыр,— дип аңлатып маташтылар берәүләр.

Икенчеләре наданлыктан һәм көнчелектән тагын да арттырыбрак җибәрделәр:

— Андый бөкре кешенең җен-парилар белән әшнәлеге була, диләр, минә күрербез... берәр җен егете, күзләрен томалап, очыртып алып китәр әле бер дә бер көнне.

— Син күзеңне томаламыйча да китәрнең бик, алып китүче генә юк.

Арада, әлбәттә, дөреслеккә күз йоммыйча әйтә белүчеләр дә чыккалап куя иде.

— Ә син күргәнең бармы соң? Җиңгәсе белән ничек көне-төне кадалып яталар алар.

Чынлап та, сукыр лампа яктысында күзләрен бетереп, икенче-өченче этәчләргә кадәр, Камәрнең киерге өстендә, Гыйльменисаның станда дөмегеп утырганлыкларын күбәүләр белми, белгәннәре дә, кешедән ишетеп кенә белгәнгә күрә, ышанып җитмичәрәк карыйлар иде.

Халык өстенә төшәчәк зур бәлане күңел алдан сизенгән кебек, мең тугыз йөз ундүртенче елгы сугыш башланыр алдыннан берничә ел элек тирә-күрше авылларда кыз бирү, малай өйләндерү шау-шулары көчәеп китте — зур зилзилә кубу алдыннан халыкның, инстинкт буенча диярлек, адәм рәтле бер яшәп каласы килә иде булса кирәк. Әлбәттә, челтәрле сөлгелек, ашъяулыклык суктырырга, нәкышле чигеш эшләренә дә сорау көчәеп китте. Мондый чакта йокы яки «кәрәчин» белән исәпләшеп булмый. Вакытны белү өчен сәгать-мазар дигәннәре юк, беренче этәчкә хәтле, аннан икенчесенә хәтле, билләре-аркалары кәкрәеп катканчы эшләп утыралар иде.

Гаҗәп хәлләр белән тулы бит бу дөнья. Әнә шундый, вакытны һәм йокыны онытып, эшләп утырган кышкы төннәрнең берендә, тәрәзә алдындагы нигездә кар шыгырдаган кебек булып китте. Моны иң элек Камәр ишетте һәм, сискәнеп, киергесеннән йөзен күтәрде.

— Тәрәзә алдында кар шыгырдады, берәрсенең мыскыл итеп йөрүе түгелдер ич, туганым-җиңги? — дип, җиңгәсенә текәлде ул. Күңеленә аның «берәр егет-җилән шаяртып йөрми торгандыр бит?» дигән сорау да килгән иде, тик алай әйтергә кыймады: «Оялмыйча... егет-җилән, имеш... аны, Камәрне күзли килмәгәннәрме тагы?»

Җиңгәсе Гыйльмениса бу сүзгә игътибар бирмәгәнгә, хәтта аны ишетмәгәнгә үк салышты. Әмма Камәрнең аның саен җаны уйнаклый: «Ә килсәләр соң! Килсәләр соң! Әллә мин кеше түгелме?»

һәм Камәр үз гомерендә беренче мәртәбә, тыштан аны-моны сиздермәсә дә, күңеленнән иләсләнеп куйган кебек булды: чынлап та, килсәләр соң! Камәр кеше түгелмени? Тамбур энәсе белән чигелгән нәкышләрдәге бизәкләрне авылда тагын кем шулай оста итеп сала белә? Камәр, аның бай күңеле сала ул бизәкләрне!

Ә җиңгәсе, хәйләкәр Гыйльменисса, болай үзе ишетмәгәнгә салышкандай утырса да, эченнән кинәт тәшвишләнә куйды: «Тишекле сөяк җирдә ятмый, диләр... Кара әле, кайчан булса да бер эше килеп чыгуы бар бит бу Камәрнең дә... Шулай була калса, алла сакласын, Гыйльмениса кем белән торып кала соң бу дөньяда? Берсеннән-берсе чәчбирәк булып туган өч кызы һәм аннары... Барысының юк-юкта искә килеп төшә торган, үзе кебек, кыюсыз истәлеге беләнме?»

## VII

Бер кире китсә, гел кире китә бит ул! Инде җайланып килә, ирсез тормышка иялаштем, кызларым-чәчбиләрем көннән-көн калка, яшьләренә күрә сүз тыңлаучаннар, берсе икенчесенә күз-колак, Камәр сеңелкәшем дә чын иптәш булып, кулы эшкә өйрәнеп, авыл арасында булдыклы дигән даны таралып килә дигәндә генә — юк икән, бетмәгән икән Гыйльменисаның күрәселәре! Унөченче елны яңадан җир өләшү килеп җитте. Рахмановлар гаиләсе, ир-ат булмаганлыктан, иманадан бөтенләй төшерелеп калдырылды. Уйлап карасаң, кызык килеп чыга: кеше җирдә яшәргә тиешле, шул ук кеше җиргә лаек булып та саналмый. Бу очракта Гыйльмениса ялгыз үзе генә дә түгел, өч кызы, бер каенсеңелесе белән. Шуның да өстенә тагын, мең тугыз йөз ундүртенче елгы сугыш башланып, кешеләрдән туй, малай өйләндерү, кыз бирү хәсрәте очты, кешеләрнең башына зуррак хәсрәт авып төште. Үзеннән-үзе аңлашыла: чупләмле сөлгеләр, тамбур нәкышләре белән чигелгән өстәл ашъяулыклары, поднос яулыклары хәстәрләү кайгысы да китте. Озакламый фронт якларыннан кара тәреле шомлы хәбәрләр кайта башлады: сезнең ирегез... сезнең әтиегез... сезнең улыгыз фәлән фәләнич уртак мәмләкәтебезнең изге туфрагын саклап, патша гали-җанапләренә верноподданныйлык хисләрен югалтмаганы хәлдә, фәлән-фәлән җирдә чын каһарманнарча шәһит булды. «Верноподданныйлык хисләре» дигән чит сүзләре аңлашылмаса да, «шәһит булды» дигән сүзләре бик аңлашыла иде, моннан соң рәтле тормыш көтмә ахырысы инде...

Бер караганда, бу сугыш дигәннәре Гыйльменисага күп кенә ишләр дә китереп өстәде, хәзер инде ялгыз тол хатын ул үзе генә түгел, аның кебек яшьләй тол калганнар өй борынча булмаса да, шулай да күбәйгәннән-күбәя бара иде. Кайгы уртаклашыр кешеләр җитәрлек, шул ук вакытта өмет белән яшәүчеләр дә юк түгел иде. Кулы язу белгән кеше итеп, солдаткаларның күбесе хат яздыру өчен Гыйльменисага килеп егыла, өмет белән хәсрәт арасында кысылып яшәүнең ачысын-төчесен шактый татыган кеше Гыйльмениса хатларны килештереп яза. Тормышның көннән-көн кысыла килүен, хуҗалык алып бару эшенең авырлыгын, авылда булып торган бәла-казаларны, кемнең сыеры зыянлавы, кемнән үлгән хәбәре килүенә хәтле — барысын да бер дә ирөнмичә тезә дә, ахырга таба, әллә үзенең дә сөю-сөелү хисреслеге чыгып бетмичә, яшьләй тол калганлыктан, шул бер очтан үз күңелендәгеләрне дә кушып, бик үк тәкатьсезләнеп түгел, шулай да «кайчан булса да бер ястыкка икәү башны куеп йоклаулар булырмы икән? Күрербезме икән андый бәхетне?» кебек, тулып ташкан сагыну хисләрен чайпалдыра торган итеп язуны булдыра иде. Шуңа күрә хат яздыру нияте кузгалган яшь солдаткалар күбрәк аның янына киләләр иде. Хәтта, ахыр чиктә, тормышының ертык урыннарына ямау салырлык кайбер «кештәкләр»не хат яза белү осталыгы белән дә эшли алган булыр иде Гыйльмениса —

килештереп хат яздырырга теләүче киленчәкләр булган байлыкларын кызганмаган булырлар иде. Гыйльмениса башта ук кистереп әйтеп куйды: әгәр шул юк эш өчен ни дә булса алып килә торган булсагыз, ике кулымның берсен дә кыймылдатмаячакмын, диде. Шулай да кешеләр һәрвакыт кешеләр булып калалар, бигрәк тә хәсрәтле чакларында күңел кыллары нечкәргән, Гыйльменисаның үзенә биреп булмаса, һич югы, ятимнәренә — кызларына дип, кесәләренә берме-икеме күкәй кыстырмыйча килә алмыйлар һәм бу бүләкләрен әниләре күрсә-күрмәсә, ничек тә балаларның кулларына төртеп китәләр иде. Шулай итеп, халык өстенә төшкән бу зур бәланың Гыйльмениса балалары өчен бер бәйрәме дә чыгып куйды: тегеләр хәзер чәчүргеч тасма өчен алай талашмыйлар, хәтта күкәйне һич әрәм-шәрәм итмичә җыеп, уртанчысы — купшыланырга ярата торган әлеге Фасиләсе — кырык тартмачыдан муенына мәрҗән дә алып такты.

Бу хат язу һөнәре, бер яктан, Гыйльменисаның үзе өчен дә ярый, кеше хатына үз күңелендәге сагышларны да кушып, хат язган саен бераз бушанып калгандай була. Шуның өстенә ике хатын бергә очрашса, аз-маз кәлә-мәлә сөйләшеп, эчләрен дә бушаталар, арада, әлбәттә, кызыклы-кызыклы гына гайбәтләр дә чыккалап куйгалый иде. Ах алла, Гыйльмениса да кеше ич, гел тормыш турында уйлап, ут йотып йөргәнче, арада вакыт-вакыт кеше гайбәте тыңлап, бераз онытылып тору да зыян итми торгандыр.

Әнә шундый телгә беткән яшь солдаткаларның берсе, башта, Гыйльмениса хат язганда, берничә тапкыр лышык-лышык елап алган булды да, хат язылып бетеп, конвертлангач, шактый ук тынычланып һәм һич истә-оста юк чагында:

— Кара әле, Гыйльмениса малай,— дип кызык кына итеп сүз башлады,— без бүген Мәүлихәләрдә белгән-күргән өч-дүрт кенә кеше җыелып, кич утырмакчы идек. Мәүлихәнең бианасы күрше авылга кызына киткән. Киндер орлыгыннан җылгыр[1] пешерергә дип сөйләштек. Аннары синнән яшерен-батырыны юк, килсәләр-килмәсәләр, Хисмәт писарь белән Гата хәлфә дә килер кебек әйткәннәр.— Инде бөтенләй күз яшьләре кипкән, хәтта күләчкә үк әйләнгән бу яшь солдатка, шул ук вакытта сүзләренә уен-көлке төс бирергә теләгәндәй, шактый ук гөрләтеп өстәп тә куйды.— Кирәк тапсак, Гата хәлфәдән корьән укытырбыз, яңа орлыктан пешкән яңа җылгырны котлатып...

Әлек бераз аптырабрак калган Гыйльменисаның күзләрендә кинәт яшерен калып булмастай очкын чәчрәп чыкты:

— Кара әле, син кемгә саныйсың мине, Солтания? — диде ул берьюлы кабынып китеп. Тегесе, бу кыек эшнең үтмәслеген шундук төшенеп, ничек тә шаярткан атлы күренергә тырышып, сүзне сузарга уйлаган иде дә, Гыйльменисаның хәтта шаярып сөйләшеп торырга да теләге юклыкны сизеп, тегесе тизрәк ишек тоткасына таба ашыкты.

— Бүтән вакытта хат яздырырга икенче кеше тап, әйтмәдең дип әйтмә,— дип, кунагының артыннан кычкырып калды тәмам җене чыккан Гыйльмениса. Җене чыгуын чыкты, шулай да күңеленең кайсыдыр бер почмагы — бик яшертен, бик эчкәреге почмагы — уйнаклап калды бит. «Кара әле, ни кыланалар кешеләр, үзе иренә хат яздыра килгән, җылаган була әле җитмәсә...»

Аннары тагы хат яздырырга килүчеләрнең берсе — бусы Гыйльмениса белән күрәшче Хафиз арасында элеккеге, кыз вакыттагы яшертен «сандугач туйдыру»ларны белепме, әллә белмичә, тик болай, ишеткән

---

[1] Җылгыр — төелгән киндер орлыгы төбеннән зур пилмән кебегрәк итеп казанда пешерелгән, соңыннан шул киндер маена ук манып ашала торган аулак өй ашы. Автор искәрмәсе.

яңалыкларыннан берсе итепме — сүздән-сүз чыгарып, һич уйлап тормастан, мондый яңалык әйтеп ташлады:

— Гомере бетмәгән булса, алла боерса, безнекеләр дә кайтыр. Әнә бит, гомере бетмәгән булгач... Күпер төбе Хафизны әйтәләр. Караплары белән батырганнар, ди, бер чак. Батырганнар, ә башына җитә алмаганнар. Булнистән булниско йөртә торгач, инде килеп, үзебезнең Казан бульнисенә үк кайтарып җиткергәннәр, ди. Ничәмә-ничә еллар күзгә-башка күренмәгән кеше, кайтып төшәр әле менә бер заман...

Кинәт,ток тоткандай, дерелдәп куйды Гыйльмениса, я хода, әле ярый, балалар өйдә юкта туры килде, аннары тагы Камәр сүс өмәсенә киткән чак иде. Камәр дигәннән, ул да хәзер теге вакыттагы йомылып ята торган Камәр түгел. Кул эшенә уңганлыгы белән авылда даны чыккан. Җиңгәсе белән туганнарча тату торуын да мактап телгә алалар. Аннары теге буранлы кичтә тәрәзә алдындагы нигездә кайсыдыр бер билгесез адәмнең кыштырдап куюы да күңелне алгысыткыч шом калдырган иде. Шуның да өстенә тагын, куак кыштырдаганны ишетеп, «йөз бүре күрдем!» дип шапырынучылар монда да бар: Камәр турында «ул инде үзенә ике сандык мал әзерләгән, ди. Калага алып барып сатса, берсе-берсе бишәр сум торырлык күпертмәле чигеш белән эшләнгән поднос яулыклары гына да бернichә дистә, ди» кебек имешмимеш сүзләр чыккалап тора. Болар барысы да ул серкәле башны җилкендерү өчен җитә кала: битенә кершән-иннек, тырнакларына кына ягынып җибәрә кызый, өстендә әлеге зәңгәр плюш бишмәт, әйтмәссең теге вакыттагы йомыкый Камәр дип. Әлбәттә, тәндә җаны бар кешенең, болай купшыланып та алгач, кияүгә чыгасы килү теләге дә уяна булса кирәк, шулар барысы бергә кушылып Камәрне хәзер тәмам терелткән, терелткән һәм тилерткән, «алам» дип әйтүче булса, «барам» дип сикереп чыгарга Камәрең бик әзер, тик хәзергә менә «алам» дип әйтүчесе генә күренми иде әле. Шулай да Гыйльмениса хәзерге минутта бер нәрсә өчен шатланып бетә алмый: ярый, Камәр өйдә чагында әйтмәделәр әле теге хәбәрне! Әлеге шул күпер төбе Хафиз турындагы хәбәрне. Аннары тагы шунысына бик шөкер: ялгыз баш калган чак түгел. Берсеннән-берсе тупырдабрак өч кызы үсеп килә, олысы Факиһәсенә быел унике тулды. Башкасын әйткән дә юк: кечесе, Фәниясе, «быел кыш мин дә абыстайга сабакка йөрим» дип тәтелдәп торган була. Бу бәләкәй тәтелдеге тагын шуның белән аналарыннан уздырып җибәрде: бабасы Әлмөхәммәт белән уртак тел табып алган. Һичнн белән исәпләшеп тормый: «Син минем кибетче бабам бит! Алай булгач ник син мине киндер ыштаннан йөртәсең?» дип сөйләнә-сөйләнә, бара да сарыла икән тегеңә. Әлмөхәммәт бай да кеше бит, әллә күңеле йомшаган чак туры килеп, әллә, ярлы тәкәббер булып, һаман буй бирми йөргән Гыйльменисасын үртәргә теләүдән, шулай бара-кайта сырпаланып йөрүләренең берсендә бу бәләкәй тел бистәсен шәһәрдән генә алып кайткан өр-яңа сатин күлмәк-ыштан, яулык-тасма белән чын-төзү итеп киендереп җибәрә.

Менә шулай тора хәзер эшләр! Шулай торуын тора да, нишләп соң «Хафиз кайта!» дигән хәбәрне ишеткәннән бирле Гыйльмениса тәтәйнең болай жае китте әле? Кайдан чыккан, нигә дип чыккан хәбәр булды соң әле бу?

Ләкин Хафиз кайта дигәне күпмегә чын булгандыр — чынмы, уйнап чыгарылган сүз генә булдымы ул? — Әмма Гыйльмениса тормышында һич көтелмәгән һәм хәтта уйга килүе дә мөмкин булмаган бер яңалык килеп туды.

Көннәрдән бер көнне аларның авыл башындагы кыйшайган өйләренә аркасына юл капчыгы аскан, капчык өстенә корымланып беткән котелогын бәйләгән, солдат хезмәтеннән кайтышы икәнлеге тышкы кыяфәтеннән, кием-салымыннан, арган-алҗыган килешеннән үк күренеп

торган, ләкин сөйләшүенә, арада көлдерә торган шук сүзләр дә кыстыргалап җибәрүенә караганда, әлегә бөтенләй үк сыгылып бетмәгән урта яшьләрдәге бер мосафир килеп керде.

— Рәхәт булды әле, шакып торасы капка да юк икән монда, безнең ише килгән-киткәнне рөхсәтсез кабул итүчеләр булса кирәк,— дип, керешли үк үзеннән-үзе сөйләнә-сөйләнә керде һәм шундук, «рад стараться» дип, механик рәвештә диярлек солдат сүзләре кыстыргалап, җилкәсендәге капчыгын салып атты, гимнастерка җиңе белән маңгаен сөртте.

— Бала-чага йөрүдән туктамый, ишеккә ябылып торырга чират тигәне юк,— дип, җор телле кунак җаенарак ятып, кече яктан, сызганган җиңнәрен төшерә-төшерә, Гыйльмениса килеп чыкты. Алар икесе дә, нишләптер, бер мәл сүзсез калдылар. «Хафиз дигәннәре шушы көнгә калмагандыр ич?» дигән хәфевле уй үтте Гыйльменисаның башыннан. Унбиш-уналты еллар күрми торуына карамастан, ул көрәшче Хафизны әле һаман элеккечә мәһабәт, киң иңбашлы, көләч бер егет итеп күз алдына китерә иде. Ләкин кунак аңарга озак саташырга юл калдырмады:

— Әйтүләренә караганда, Барый Рахмановлар өе шушы була торгандыр? — дип сорады ул, һаман шулай солдат кыюлыгы белән.— Сез аның сеңелесе-мазары түгелдер ич?

— Мин аның хатыны идем,— дип әкрен генә әйтеп куйды Гыйльмениса, нишләптер бу кешедән оялган кебек, түбәнгәрәк карап.

— Алай ди-ген,— әлеге җаваптан аптырабрак калгандай, сүзә төште кунак һәм кинәт тукталып калды. Анысы да, түбәнгә карап, беравык тынып торды. Аннары авыз эченнән, бары тик үзе өчен генә сөйләнгәндәй мыгырданды,— мондый җиңгәйне калдырып, ашыгыбрак киткән икән шул бичара.

— Утырыгыз, мин тагын бөтенләй онытылып ук киткәнмен,— дип, Гыйльмениса, татар гадәте буенча, кунакның астына киез китереп салды, урын тәкъдим итте,— менә бар булганы белән чәй куеп җибәрербез.

Гыйльмениса кабаланып кече якка кереп китте, аның ул якта самовар куеп кайнашканы ишетелә, шул ук вакытта ул, үзе күренмәгәч, бераз батырая төшкән сымаграк та сизелә иде.

— Сорарга да куркып торам, сез соң, алла кушып, кайчан да булса безнең Барыйны күргән, Барый белән очрашкан кеше түгелсез?

— Без аның белән бергә елга якын бер баракта торып, бер хуҗаның шахтасында эшләдек.

Тагын тынлык урнашты. Тынлыкны кече якта кулдан төшеп киткән чыра-пычак тавышы бүлде. Шулай да сүз ялганып китми иде әлегә. Тәкъдим ителгән урынга әле һаман утырмыйча идән уртасында аптырабрак басып калган кунак шулай да бу тынлыкны артык күтәрә алмады — аңа, дөнья күргән кешегә, бер үк вакытта әллә ничегрәк: «Ник кердем?» дигән дә төсле, бик ул хәтле искитәрлек эш тә юк кебек күренә иде.

— Була дөньяда хәлләр, сеңелкәш, сезнең белән бездән генә калмаган,— дип сөйләнеп куйды ул үзалдына. Аннары кече якта, сиздермәскә тырышып, шул ук вакытта эшен дә караган булып, лышык-лышык җылап, борынын тарткалап йөрүче хуҗа хатынны тынычландырырга тырышып булса кирәк, әйтеп куйды: — Бичара-мәрхүм тагын бер айдан илемә кайтам, дип ашкынып йөри иде, нишлисең бит, тәкъдирең шулай булгач...

— Син үзең берәр мулла-мәзин нәселеннән түгелсең бит? — дип, әллә ачуланып, әллә аптырагannan, кырыс кына сорап куйды Гыйльмениса. Аңа бүлмә тактасы аша сөйләшү ул хәтле читен түгел, җитмәсә

тагын, аңарга кунакның «тәкъдирең шулай булгач» дип шомартып сөйләргә тырышуы да бер дә ошамый иде.

— Мулла-мәзин булып, әллә җиназа намазы өчен түләтергә килгән кеше дип шүрләдеңме, апакай? — Кунакның тавышында янадан элекке уенчаклык ноткалары яңгырый башлаган иде инде.— Юкка хәвефләнмә, минем үземне дә җиназасыз-нисез берничә тапкыр теге дөньяга озата язып калдылар. Күреп өлгермәдегезмени әле, әйләнчек сарык кебек кырын-кырынрак йөргәнне. Үземнән элек минем сулъяк иңбашым йөри, оҗмахка да, тәмукка да иң элек шул сулъяк иңбашым белән барып керәчәкмен.

Самовар кайнап, чәй урыны әзерләп, солдатның керләнеп беткән кучтәнәч шикәре белән берәр чынаяк чәй эчкәнче болар тәмам таны-шып, аңлашып җиттеләр: кайчандыр Гыйльменисаның Барые белән бер баракта торып, бергә шахтада эшләгән бу гидай бәндә дөньяда хәзергә исән-сау селкенеп йөрсә дә, соңыннан сугышта булып, яхшы ук чәрдәкләнгән һәм, үзе әйтмешли, тәмугыга җантыгы белән кереп бара торган бер адәм булып чыкты. Лазареттан лазаретка йөртеп, озак кына тинтерәтеп тә, рәт чыгарлык җирен тапмагач, өенә кайтарып җибәрергә булганнар. Кайтуына үзенең әллә ни исе китми, авылдан алган хатларына караганда, кайтып, аны тәрәзәсе кадакланган өйдән бүтән нәрсә каршы алмаячак. Ә болай әле, әйтмәгәне булсын, ике нәрсәсе үзе белән: әнә шомарып, каешланып беткән солдат капчыгы да, үзеннән алда кырынлатып чаба торган җимерек иңбашы. Шулай да сүзләренә, уенкөлкесенә караганда, солдат хәзергә әле тәмукка төшеп китәргә бик ашыкмый, хәтта ачыктан-ачык ук әйтмәсә дә, сүз араларыннан шул аңлашылып калды: иргә аптыраган берәр чүпрәк баш очраса, билләһи-газыйм, өйләнүдән дә бер дә качачак кеше түгел имеш.

Чәй янында нәкъ шушы тема тирәсендә сүз барганда — алламы, иблисме туры китерде — өйалдына кереп тулган тавыкларны пыранлата-пыранлата, өйдә кунак — ят ир кеше утырудан һич хәбәре булмаган шау-шулы Кәмәр кайтып керде. Ул кайдандыр кыр эшеннән кайткан, көне шулай туры килгәнме, юлда берәрсе арбасына утыртып алып кайтканмы, авыз бик җырык, күлмәк тә бик югары кыстырылган, итәк белән оек балтыры арасыннан күрми күргән күңелгә яхшы ук васвәсә салырлык булып кызыл ыштаны җемелдәп күренә иде.

— Бу шушы Кәмәр буламы инде? — дип, шундук чәй яныннан торып, ике кулын сузып, күрешә килде солдат. Ләкин Кәмәр кулын сузарга бик ашыкмый иде. Ул, кунакка караудан да бигрәк, «Бу кем? Син кемне болай тора тартып минем өскә җибәрәсең?» дигән кебегрәк итеп, җиңгәсенә текәлеп карап тора иде. Шул ук вакытта, әле Кәмәр турында бер сүз дә булмаган килеш бу әрсез солдатның, чебешкә ябалак очып кунган кебек, ишектә күренүгә сикереп торуы һәм әлеге алдан йөри торган янтык иңбашы белән Кәмәрнең янына ук килеп басуы, барыннан да бигрәк, һич ишетмәгән, телгә кермәгән килеш, әллә кайдан исемен белеп, «Кәмәр!» дип гөрләп торуы туганым-җиңгәсенең дә өнен алган, ул да ни әйтергә белмичә, шаккатып калган иде.

— Дөресен әйткәндә, туганкайларым, мин сезнең бу дворецны шушы Кәмәр дип эзләп килдем дә инде,— солдат үзен генерал алдындагы солдатчарак тота: әзрәк каушаган, шул ук вакытта каушаганлыгын сиздермәскә дә тырыша, шуңа өстәп белгән-ишеткән яңгыраулы русча сүзләр кыстыргалап җибәрүдән дә әллә ни тайчанмый — солдат муштрасы аның канына сеңгән иде. Дәрья бит кеше күңеле, башта аптырабрак калган Кәмәрнең күңеленнән яшен тизлеге белән «әллә теге төнне тәрәз каршындагы нигездә кар ерып, эз ясап йөргән адәм дә шушы булды микән?» дигән уй узды. Ләкин хәзергә ни әйтергә дә белми, җитмәсә, җиңгәсе дә сүзсез калган, ә сүзсез калган ике хатын-кыз каршында, шулай ук сүзсез калып, эндәшми-тынмый басып тору солдат

кешегә бөтенләй килешми иде. Шунлыктан, бу юлы инде ул баягы кебек батыр итеп түгел, хәтта бер дә батыр итеп түгел, хәтта чак кына уңайсызланган да кебегрәк итеп, әкрен генә сүзгә кереште:

— Ни дип башлап китәргә дә белмичәрәк торам, сүзе шундыйрак, апайлар,— дип башлады ул, һаман күтәрелеп карарга кыймыйча.— Барый мәрхүм белән бергә, бер шахтада эшләвем турында әйттем инде, ул чуттан кабатлап тормыйм. Шул Барый дусның бер васыяте калды минем өстә, әледән-әле әйтә торган иде шуны: шахтага эшкә киткәндә Камәр атлы бертуган сеңелесен рәнҗеткән булган, имеш. Кул беләнме, сүз беләнме — анысы миңа билгеле түгел, но булган булса кирәк шундый бер күңелсез эш. Шуны әледән-әле телгә алып сөйли иде мәрхүм. Дөнья хәлен белер хәл юк, Таҗи дус,— дия торган иде, әйтерсең, күңеле алдан сизгән. Андый-мондый хәл була-нитә калса, ди торган иде шуңа өстәп,— ерак түгел авылларыбызның арасы, барып чык безнең Ташлыярга, эзләп тап минем җиде җилгә сәлам биреп утыра торган гурнәчәне. Камәр атлы булыр ул минем сеңел, хурланма, оялма, каршысына барып, аяк очына башыңны орып, минем исемнән гафу үтен: җан ачигысы белән, тормышка-эт ормышка ачу чыкканнан әйтелгән сүз, зинһар, рәнҗеп, күңелендә саклап йөртә күрмәсен, ди торган иде.

Камәр һәм Гыйльмениса, бу чит-ят кеше алдында һич уңайсызланмыйча, икесе бердән үксеп елап җибәрделәр. Таҗи солдатка да, әлбәттә, җайсызрак булып китте...

— Нишләтим соң? Васыятьне җиренә җиткермичә кала алмадым,— дип сөйләнеп алды ул үзалдына,— белгән юк, бәлкем, мин әнә шул васыять аркасында сугыш мәхшәреннән исән-сау калганмындыр...

Артык чәй эчү дә, сөйләшеп-тәфсилләп утыру да булмады, чөнки бирсенә дә җиңел түгел иде. Гаҗәп бит кеше күңеле, әле яңарак кына тәмам тулышып, нечкәреп калган Камәр, елаганнан соң әллә кинәт җиңеләйде, әллә башына берәр җүләр уй килеп төште, солдат китәргә кузгалгач, аны-моны уйлап тормастан, җиңгәсен бер читкәрәк тартып алды да пышылдап кына:

— Туганым-җиңги, ачулансаң ачуланырсың, мин бу кешене Тегермән тавына хәтле озата барам. Килешмәгәнен беләм, әйтер сүзем дә юк, ә бармыйча булдыра алмыйм. Абыем кебек булып китте ул миңа ничектер...

Нәрсә әйтә алсын Гыйльмениса? Аннары ул Гыйльмениса эшемени? Таҗи солдат: «Кирәкми! Юлны мин үзем дә беләм!» дип караса да, тыштан гына әйткән булгандыр, кыз ияргәч, бик шатланып риза булды. Һәм Камәр, өстен алыштырмаган, елаганнан соң битен-күзен юмаган Камәр китте дә барды ияреп.

Сөйләшә торгач, сүзләре дә табылган булса кирәк, әйләнеп кайтканда, Камәрне алыштырып куйган кебек иде.

— Ул бик яхшы күңелле кеше булса кирәк, туганым-җиңги,— дип, үзен тота алмастан, сүз башлады кайтуы белән,— миңа «җаным!» диде, миңа моңарчы берәүнең дә «җаным» дигәне юк иде. Мин бөтенләй, шушы чыгып китүдән үк ияреп китмәкче идем аңарга. «Тукта, кайтып, тәрәзәгә кадакланган такталарны алыйм, өйгә бераз якты керсен, юкса, мин сине ничек танырмын, караңгы өйдә?» дигән була. Шундый әйбәт, шундый көлдереп сөйли, абыйның үлгән хәбәре килгәннән бирле минем әле бер дә болай көлгәнем юк иде.

Нәрсә әйтә алсын Гыйльмениса? Аннары ул Гыйльмениса эшеме? Гыйльмениса эше — менә тагын бер югалту: көзен, кыр эшләре беткәч, Таҗи солдат — ул әле һаман шомарган солдат гимнастеркасын салмаган иде — кайдандыр тарантаслы ат табып, дугасында кыңгырау янгыратып килде дә, Гыйльмениса — «туганым-җиңги»не өч кызы белән үзен генә калдырып, Камәрне үзенә — бу юлы инде бөтенләйгә алып китте.

Кул эше, һәртөрле чигеш-нәкыш эшләре белән генә тамак туйдыру мөмкин булмый башлады. Дөресен әйткәндә, авылның башка нужалары муеннан ашкан, өйләндерерлек егетләр калмаган, андыйларны сугыш машинасы үзенә алып, йота алганын йотып, тамагыннан үтмәгәнен чәрдәкләп кайтара тора иде. Шундый чакта да халык җорлык саклаган була, әллә кияүсез калган кызлардан көлеп, әллә аларны җәлләп, кайчагында «яшь этәчләр»нең, җитлекмәгән тавыш белән һәм мулла, мәчет тирәсен һич санга сукмыйча:

Шыбыр-шыбыр яңгыр ява өй түбәсе калайга,
Инде, кызлар, сез калдыгыз кузна уйнаган малайга,

— дип җырлап узуларын ишеткәләргә туры килгәли иде. Камәрдән аерылу Гыйльмениса өчен, бер яктан, канаты каерылу булса, әмма шундый егетләр кытлыгы вакытында аны башлы-күзле итеп калдыруы өчен ул сөенеп бетә алмый. Чакырып ук ала алмаса да, килгәндә бары белән кунак итә, мунчасын ягып кертә, хәтта — күрше-тирәләренең теленә керүдән һич шикләнмичә — элеге теге янтыгы белән алгарак чыгып йөрүче кияве өчен кайдандыр «кумушка»сын да табып кайта иде. Тегеләре дә буш кул белән килмиләр, хәер. Килгән саен Гыйльменисаның әле кызларыннан берсенә, әле үзенә яулыкмы, алъяпкычлык ситсымы кыстыра киләләр — Тажи кияү, янтык булмагае, чорт булсын, атаклы Шириязданн байларның алар авылына ачкан кибетенә приказчик булып кергән, газета яздыра, дөнья хәлләре белән танышып бара, килгәндә-киткәндә, әллә чак кына мактанырга теләп, әллә дөнья хәлләрен алданрак «сукалап», җиңгәсе Гыйльмениса алдында:

— Әле, туганым-җиңги, уйлама болай гына булыр, дип. Ширияз әфәндемнең кибетен ялынып-ялынып миңа сылар көннәре алда әле, менә, сугыш бетеп, аннан атчайныйрак егетләр генә кайта төшсен,— дип тә җибәргәли иде.

Гыйльменисаның сугыштан кайтыр кешесе булмаса да, мондый хәбәрләргә ул да бик рәхәтләнеп колак сала, ни генә димә, аның да көтәр нәрсәләре бар: беренчедән, әгәр сугыш бетсә, дөньяга тоз чыгар иде — күпме вакытлар менә рәтләп тоз күргәннәре юк. Икенчедән, кем белгән, бәлки хатын-кызларны да кертеп, җирне яңадан өләшерләр иде. Өченчедән — бусы кайдадыр, күңел тирәнлегендә генә саклана торган уе — анарда да берсе артыннан икенчесе өч кыз үсеп килә ич. Ашка чеметеп салырга да тоз исәпле бер заманда кызларны тозлап куеп булмый, ичмасам, ходай бәхетләрен ким итмәсә, сугыштан сөяген-санагын түкми-чәчмирәк кайткан егетләр күзе төшмәсме үзләренә?

Кыскасы, дөнья үзгәрә бара: мәчет, мулла турыннан гармун уйнап, юкны-барны җырлап узучы «яшь этәчләрне» әйткән дә юк, әле тегендә, әле монда җеннәре чыккан ач солдаткаларның алпавыт амбарларын талауларын ишеттергәләп торалар, уйнаштан бала табулар да ешаеп китте, мыскыл итсәләр итәләр, бәет чыгарсалар чыгаралар, әмма элеккеге кебек, адәмнең адәмлегеннән көлеп, мыскыллап, кыйнап-җәберләп урам йөртүләр бетте, дөньясының кырылып баруы әкренләп иске йолаларның да кырыла башлавына дәлил бугай, әмма яңасын уйлап табучылар хәзергә күренми иде әле.

Гыйльмениса боларның барысын да белеп-ишетеп тора, артык киртә сикерүчеләр турында ишетеп, чиркангалап та куя — табыла бит бер нәфсесенә баш була белмәгән кешеләр. Ләкин шул ук вакытта, тамак тәмугыга кертә дигәндәй, Гыйльмениса да түбә җирдә генә басып кала алмады: уналты белән бара торган кызы Факиһәне өйгә «күз-колак» итеп куйды һәм буш вакытларында кадакланып киндер станына утырырга кушты. Кече яшьтән үк купшы киенергә яратучы ундүрт яшьлек

Фасиләсен Казанга — әнисе ягыннан үзләренә «чыбык очы» тиешле казылыкчы Моталлап байга асраулыкка бирде. Уникe яшендәге кечесен каз бәбкәләре, бозау карау эшенә беркетте, шуның да өстенә бусы көнгә ике тапкыр — төшкә хәтле бер, төштән соң бер — кечкенә арба белән урманнан утын, чыбык-чабык алып кайтырга тиеш. Шулай итеп, берсенә дә буш торырга, юкны-барны уйларга вакыт калдырмыйча, балаларын эшкә кушып бетерде дә үзе урман артындагы урыс алпавыты Колокольников утарына дуңгыз караучы булып ялланды. Авылда, әлбәттә, бу эшне өнәп җиткермичә телгә кертүчеләр дә булды, эше дә чистадан түгел, кайткач, бөтен җире сап-сары юылып куелган өеннән дә дуңгыз абзары исе килгәндәй була, эштә киеп йөри торган халатын утынлыкта ук салып калдыра, иртә таңнан һәм кич караңгы капкач урман аша үтеп йөрүләр дә шикләндерә, шулай да эшли. Тормыш ләмкәсен тартырга кирәк, шуның өстенә карт һәм борынгычарак уйлый торган либерал алпавыт Колокольников билгеләгән жалуньясын нәкъ үз вакытында төгәле белән биреп бара, хәтта кайвакытта: «Менә бусын, ятим балаларыңа бирәр нәрсә алырсың, дип бирәм, эшеңне яхшы башкарганың өчен мөкяфәть» дип, бирәр сумны артыгырак та төртә, икенчедән, читен булса да кайтып-килеп, өйгә, балаларга күз-колак булып йөрү рөхсәт итела,— әлеге дуңгыз абзарына бөтенләйгә үк кадакланмаган иде.

Ләкин кайчагында артык либераллыкның да кызык хәлләргә китерүе мөмкин икән. Алпавыт Колокольников якшәмбе көнгә каршы кичләрен хезмәтчеләрен, бигрәк тә күрше авыллардан килеп эшләүчеләрне, берике сәгатькә алданрак җибәрә һәм җае чыкканда, күрше алпавытлардашнәләре алдында үзенең бу киң күңеллелеге белән мактанырга да ярата, үзенә карата мужикларның тыйнаклык саклауларын шуның белән аңлата иде.

Ул хәтлесенең нечкәлекләренә кермәстән, хәер, атнага бер көн булса да болай иртәрәк, көнгә караңгылык капканчы өйгә кайтырга чыгу Гыйльменисa өчен бик-бик ярап куя иде. Хәер, либерал алпавыт Колокольников нечкәрткән кебек нечкәртеп торырга Гыйльменисаның вакыты да юк, башы да эшләми, аңарга шул булган хәтлесе дә җитеп тора, якты көздә урман аша чыгып, өйгә — балалары янына кайту үзе бер бәйрәм иде. Ә менә шундый якшәмбе алды кичләреннән берсендә якты көздә урман аша чыгу аркасында ул һич көтмәгән, күңелгә килмәгән тамашага юлыкты.

Галәмәт бер хәл булды бу бер караганда. Ләкин Гыйльменисa андый «галәмәт»ләрне һич тә көтмәгән иде шул. Кинәт аптыратып, искәндереп, хәтта бер мәлгә берни дә уйлый алмас хәлгә китереп бастырды ул бичара Гыйльменисаны. Урманның бу як авызында, Ташлыяр авылы яртылаш, бигрәк тә чак кына авыша төшкән мәчет манарасы белән, инде күренеп торган җирдә, хәтфәдәй яшел үлән өстендә, тезләрен кочаклап, уйланып калган бер ир кеше утыра иде. Аның бер ягында уникe-унөч яшьләр чамасында картузлы бер малай кырын әйләнеп төшкән, икенче ягында җиде-сигез тирәләрендәге кечерәге, шундый ук картузлы, сухарины, агач каерысымы кимереп утыра һәм, әледән-әле утырган җиреннән сикереп торып, арткы яктан этисенең муенына килеп сарыла иде. Мосафир үзе яланбаш, чигә чәчләре ике яклап коелган. Ләкин эре гәүдәсе, киң иңбашлары әле үз урынында, бәлки, авыл ягына карап, уйланып утырганныкыдыр, җилкәсе чак кына бөкрәя төшкән кебек күренә иде. Картузлы малайларына тирә-юньне күрсәтеп, ял итеп утыручы берәр урыстыр, дип эндәшмичә-тынмыйча, хәтта адымнарын мөмкин хәтле җәһәтрәк атлап үтеп барганда, Гыйльменисаның колак төбендә гаҗәп якын һәм үз булып бер эндәш яңгырады, туктамас җиреннән туктап калды Гыйльменисан.

— Бу безнең Ташлыяр авылы шушылай кечерәеп калдымыни? —

дип сорап куйды ир, утырган урыныннан кузгала төшеп.— Арткы урамны, Караташ сыртын бөтенләй бетергәнсез ич.

Әйткән сүзе бары тик шул булды, аннары тынлык, аптырап, күрер күзгә ышанмыйча бер карашып тору, аннары тагын тынлык — бу юлгысы инде уйлану, танырга тырышу, бер үк вакытта гаҗәпләнү белән тулган иде.

— Тукта әле, тукта! Гыйльмениса түгелме соң син? Гыйльмениса ич син!

Моны ике малаен ике кулына җитәкләгән, ләкин нинди дә булса адым ясарга әле базмыйчарак торган әлеге шул ир кеше әйтте. Гыйльмениса инде өнгә килеп өлгергән, аның каршында картузлы ике малай җитәкләгән кеше, картайган, яхшы ук суырылган, ләкин күз карашындагы яшькелт утын, Ташлыяр авылында бүтән берәүдә дә булмаган-күренмәгән моңсу-яшькелт утын әле дә булса югалтмаган, тавышындагы ягымлы җылылыкны да югалтмаган кеше — я, мәүлә! — бу бит шул, кайчандыр төшләргә кереп йөдәткән, хәзер инде онытылган һәм һичсүзсез онытылырга тиешле кеше — Хафиз... Хафиз үзе иде ләбаса!

Малайларның берсе, зуррагы, нәрсәдер сизенгән кебек, әтисенә туры гына карап, русчалатып нидер эндәште, ләкин Хафиз аны ишетерлек хәлдә түгел иде.

— Менә шулай, Гыйльмениса,— дип куйды Хафиз, малаеның сүзен искә дә алмыйча,— исән кешеләр бер очраша икән.

Тагын тынлык: Хафиз Гыйльменисаның нинди дә булса сүз әйткәнен көтә, ә Гыйльмениса һаман сүзсез, ул әле малайларга, әле Хафизның үзенә карап, нәрсә дип сүз кушарга да белмичә, телсез калган иде.

— Әйдә соң, атлый торыйк,— дип тәкъдим ясады Хафиз, бу юлы инде яхшы ук кыюлана төшеп,— безгә бит бер якка таба.

Аңы белән түгел — нәрсәне булса да аңлый һәм нәтиҗә ясый алырлык дәрәҗәдә түгел иде Гыйльмениса,— дөресрәге, эчке сагаю һәм, искәрмәстән килеп чыккан бу кинәтлектән, әле һаман сискәнеп туктамаган шөбһәле күңеле белән, Хафизның бу соңгы сүзләрен ишетеп алды хатын һәм бусы, озак еллар онытылып торудан соң, аны иң куркыта торганы булды.

— Болар әллә синең малайларыңмы? — дип сорады Гыйльмениса, кызыксынудан да бигрәк, гаҗәпсенеп. Аны, барыннан да элек, малайларның әллә нидә бер русчалатып сүз кыстырып куюлары гаҗәпләндерә иде.

— Ә кемнеке булсын, минеке булмыйча? — Хафиз сорауга каршы сорау белән җавап кайтарды. Ул бераз шаярткан кебек тә күренергә тырыша, ләкин Гыйльменисаның — кайчандыр бөтен нәрсәне нәкъ үз вакытында, нәкъ үз дөреслеге белән тотып ала торган булып хәтеренә сеңеп калган Гыйльменисаның — шушы ап-ачык хакыйкатьне, ягъни яныннан тырык-тырык атлап килүче картузлы бу ике малайның Хафиз малайлары икәнлеген аңлар-аңламас килүе аны — болай да әйләнәтирәдәге үзгәрешләргә исе китеп кайтучы кешене — эчтән нык кына уйландырып калдырган иде. «Ә өйдәгеләр... Эти белән әни карчык ничек карар татарча белми торган бу пацаннарга?» дигән сорау да узды аның миеннән.

— Ә әниләре соң? Соңыннанрак кайтачакмыни әниләре?

Бәлки, кирәк булмагандыр, урынсыз куйгандыр Гыйльмениса бу сорауны. Ләкин нишләтәсең, аналык инстинкты, балалар язмышы белән кызыксыну чиште бугай телен, ычкынды бит шундый уңайсыз сорау. Хафиз беравык телсез калды.

— Беркайчан да кайтмаячак әниләре,— диде аннары, күз карашын аска алып. Кинәт аның тавышы сынды, шуны сиздермәскә тырышып сүзсез барды, аннары салмак кына янә башлады.— Ишеткәнең юк идеме Севастополь дигән бер кала турында. Кара диңгез буендагы пор-

товой бер кала. Минә шунда артналет вакытында үлеп калды әниләре. Маша исемле иде. Береговой охранада медсестра булып эшли иде.

Озак кына сүзсез барганнан соң, эчке халәтен бераз җиңеләйтергә теләп булса кирәк, көтәренкерәк тавыш белән өстәде:

— Менә шулай кайтып киләбез инде Ташлыярга. Казанга хәтле поезд белән. Казанның бу ягын тәпи-тәпи,— аннары, бөтенләй уенга әйләндерергә теләгәндәй, болай дип тә өстәде,— ни урыс, ни татар дигәндәй, ике малай җитәкләп. Кертерләрме авылга, юкмы?

Гыйльменисага кинәт бик авыр булып китте — нилектән икәнлеген үзе дә белми, бәлки, анасыз калган балалар язмышы өчендер, бәлки, дөньясының шулай катлаулы булганлыгы өчендер, бәлки, үз язмышы кинәт башына китереп органдай булгандыр — ләкин Гыйльменисага бик-бик уңайсыз булып калды бу минутта.

## IX

Хафиз кайтышлый, урман юлында Гыйльмениса белән беренче очрашканда ук, уйный-көлә: «Ни урыс, ни татар, ике малай җитәкләп кайтабыз менә. Кертерләрме авылга, юкмы?» дип бөтенләй юктан гына әйтмәгән, өйдәге картларының үтә иске фикерле диндар кешеләр булганлыгын чамалап әйткән икән. Озак аерылып торудан да ара яхшы ук суынган, шуның өстенә кайтучы кеше мәкәрҗәдән түгел, бүләк-саналары юк, кесә ягы да буш, һич урынсызга телдән ычкынгалап китә торган, ләкин мондагыларга аңлашылмый да, аларны шаккатыру өчен әфсенле көче дә булмаган диңгез терминнарыннан һәм ялтыравыклы төймәләр тезгән кителеннән бүтән байлыгы хәзергә күренми. Шул «юк» өстенә тагын татарча бер авыз сүз белми торган ике малай да өстәлгәч, тыныгча өйрәнгән карт белән карчык әллә нишләбрәк калдылар. Әлбәттә, кайту белән үк — берьюлы сиздермәделәр. Булганы белән кунак иттеләр. Хәтта картузлы малайлар белән әби арасында бармаклар белән төртеп сөйләшү, һәртөрле ымлаулар ярдәмендә кызыклы-кызыклы гына аңлашып караулар да булды. Шулай да бу кунакчыллык озак дәвам итә алмады, әбинең җыела килгән үте бер көнне тышка ук бәреп чыкты.

— Туйдым мин бу күл белән төртеп сөйләшүләрдән,— дип, хәзергә әле карты алдында гына булса да, үтен түкмичә кала алмады Сәрби әби.— Җитмәсә тагын сүз ишеттерә торалар. Бер көнне су юлында Хабра карчыгы Әсхап күзгә бәреп әйтә: марҗадан туган ул сөннәтсез малайларны безнең мөселман җирендә озак асрарсызмы икән? Әнә абыстай әйтә, ди, анда: сугыш зилзиләсенең болай озакка сузылуы да, уйнаштан туган балалар да, мәчет манарасының тора торгач бер якка кылая башлавы да, сөннәтлесенең, сөннәтсезенең бер коедан су эчүе дә, дип әйтеп әйтәдер, ди...

Ул әле тагын да сузмакчы иде, карты Хәсәнша:

— Куйсана шул Хабра карчыкларын да, разный анда мәет козгыннарының сүзләрен,— диде сүзен кырт өзеп,— сөйләшсәм мин үзем, ир кеше белән ир кеше, сөйләшермен. Ә малайларга, сөннәтсез, дип тел тидерәсе булма. Болай да җиреннән-суыннан, туган аналарыннан язган балалар алар.

— Ничек тел тидерим, ди, кайчан мин аларның телләрен гүпчи дә белмим,— дип мыгырданып калды карчыгы. Ләкин бу әле аның карты белән килешүе дигән сүз түгел, эш кайсы якка булса да бер якка хәл ителмәсә, ул әле, әлбәттә, мыгырданып кына калыр кебек күренми иде.

Шулай да Хәсәнша карт башламады ул җитди сүзне. Хафиз үзе башлады — ул борынгычарак уйлый торган картларының ашына кара таракан булып төшкәнлеген үзе дә сизеп йөри иде.

— Болай тора эшләр, эти,— дип башлады ул бер кичне өйдә әтисе картның ялгыз үзен генә туры китереп,— син үзең дә элекке солдат кеше, аңларга тиешсең: шушы Русия мәмләкәтен саклап, ничәмә-ничә еллар тозлы диңгез сулары гизгән, берничә тапкыр ранный булган кешеләрнең — без солдат, морякларның — урыны хәзер ишек төбендә түгел, өйнең түрендә булырга тиеш. Безнең братва моны әле тиздән күрсәтәчәк.

Әти белән сөйләшкәндә сүзнең митингда сөйләшкәндәге кебегрәк килеп чыгуын һәм үзенең урынсызга кыза башлаганлыгын сизеп, Хафиз шундук әкренрәк җайга ятты, сүзенә тизрәк йомгак ясарга ашыкты:

— Тел белмәгән балалар белән әнигә җиңел түгеллеген мин сизеп йөрим. Сөйләшәсе кешеләр белән сөйләштем: без Зәки солдат өенә күчмәк булабыз. Зәки минем элекке дус иде, нишләмәк кирәк, башын шул без йөргән туфракка ук салган, хатыны икенче иргә чыккан, өе буш, тәрәзәләре кадакланган. Ә безгә — державный линкорларның көлен күккә очырган диңгез бүреләренә — тәрәзәгә кадакланган такталарны каерып ату нипочем не стоит!

Җитди башланып, ярым шаяргандай очланган шушы аңгәмә җитте, бүтән сүз кузгатып торуның кирәге булмады. Икенче көнне үк эшкә керештеләр. Эшкә керешү дигәне шул: барып, Зәки солдатның сугыш алдыннан гына салдырган өенең тәрәзәләрендәге тактаны кубарып аттылар. Сәрби эби килеп өйне җыйгандай итте, көннәр җылы, әлегә ягарга кирәк түгел, ике малаен янына алып, түшәлеп йокларга сәкесе бар — башкасын күп уйлап тормады Хафиз. Әлеге теге картузлы ике малаен ике кулына җитәкләде дә, иңенә яңа шул шомарып беткән солдат капчыгын җиңелчә генә элеп, күчте дә килде буш өйгә.

Күчеп килде һәм кинәт аптырап калды: карасана, түшәмнән урмәләп, каядыр караңгырак почмак эзләп баручы озын ботлы котсыз урмәкүчне телгә алмаганда, бөтенләй шыр икән ләбаса монда: тавыш-тын юк, авыз эченнән мыгырданып йөрүче әни карчык юк, аш пешереп торасы юк, су юк, әгәр солдатның үзе белән йөрткән калай кружкасын исәпләмәгәндә, су эчәргә стакан-мазар шулай ук юк...

— Борынны салындырмыйк, хлопцы. Тиздән безнең Севастопольдән үзебез төреп салган багажларыбыз килеп җитәргә тиеш,— дигән булды ул, бердән оеп, сүзсез сеңеп калган малайларына җан өрергә теләгәндәй. Ләкин ул багаж дигәнендә дә рәтле-башлы нәрсә булмаганлыгын ул үзе белә, балаларын юата барган саен, бу тынчу бушлыкта үзе әкренләп-әкренләп буыла башлаган кебек иде.

Шулай да озак дәвам итмәде бу ташландыклык хисе. Ничек кенә авыр булмасын, сугыш чорының җәфасы-югалтулары күңелләрне ничек кенә ташка әвереллдермәсен, шулай да әйләнә-тирәдә кешелекле кешеләр бетмәгән, күңелләрдә мәрхәмәт хисе сүнмәгән иде.

Иң элек, күчеп килүчеләрнең кайнар эзләренә үк басып дигәндәй, әни кеше Сәрби эби килеп керде. Ул инбашына зур төен күтәргән, килеп җиткәнче тәмам алҗыган, ишектән керүгә көч-хәл белән сәкегә җитеп, иңендәге йөген сәкегә әйләндереп төшерде һәм, бераз сулыш алганчы, ләм-мим сүз кушмыйча, хәйран калып утырды.

— Менә бусы салып ятырыгызга,— диде ул төргәктән өч мендәр, зур бер киез һәм бер юрган чыгарып,— атыбыз булса, барысын бергә төяп китерер идек дә бит... Сүз ялганып китәргә өлгермәде, ишектә шулай ук күтәренгән, шундый ук мышкылдаган Хәсәнша карт күренде: анысы искерәк булса да бер самовар, беркадәр чынаяк-савыт һәм, ни уйлаптыр, бик зур буш кәрзин китергән иде.

— Ычкына башладыңмы әллә, башыңа ат типкән карт,— дип шундук аны шелтәләргә тотынды карчыгы,— нәрсәгә, ди, аларга синең бу буш кәрзинең? Иөк итеп шуны күтәреп килмәсәң.

— Нәрсәгә дә ярый торган әйбер ул, тимә,— карт игътибарсыз гына җавап бирде һәм аннары Хафизга карап, ләкин аңарга әйтүдән дә бигрәк малаеның малайларына ымлап, өстәп куйды.— Хәзергә әнә аларның вак-төяк әйберләрен шунда ташлый тор, соңыннан, алла кушып, тирәнгәрәк тамыр җәя башлагач, каз утырту өчен менә дигән оя.

Тик шуннан соң гына, бу юлы инде бик җитди рәвештә, хәтта карчыгының аңсызлыгы өчен ачулангандай итеп, өстәп куйды:

— Әллә каз асрамаслар дисеңме син аларны? Артларында гына шундый күл була торып.

Әле бүген кичке ашау-эчү якларын карыйсы бар вакытта, әллә кайчан булачак каз оясы турында кайгыртып, буш кәрзин күтәреп килгән Хәсәнша картның сүзләре, бер яктан, азрак көлке тоелса да, чынлыкта Хафизга ошады — йөрисен йөрде, чынлап та, оя корып җибәрергә иде аның исәбе. Һәм Ташлыярга кайтып, булган яңалыклар белән танышуга ук, яшьлек хыялы Гыйльменисаның бүгенгесе көндә өч кыз белән ирсез көн күреп азаплануын ишетеп, бөтенләй үк «шулай булмагае?» дип уйларга базмаса да, күнеленең әчкәрәге бер почмагында: «Ай-һайла! Бу яртылаш ватылган ике ояны бергә кушып, малайларны әниле, кызларны әтиле иткәндә, бер дә начар булмас иде» дигән уй, кыяркыймас кына булса да, баш калкытып узган иде. Дөресен әйткәндә, туган нигезеннән алай ансат кына чыгып китүенең сәбәпләреннән берсе дә шул иде: тынычка өйрәнгән карт белән карчык әни култыгына берьюлы тагын биш — монысы ике, Гыйльменисаныкы өч — бәбкәне сыйдырып булмастыр бит.

Буш кәрзиннән һәм киләчәктә булачак каз оясыннан башланган сүз Хафизны бераз күтәренкерәк җайга салды:

— Синеке дә дөрес дөреслеккә, эти,— диде ярым шаярту белән,— каз үрчетмичә торып булмас, даром что-ли, ничә ел буе сугышып йөрдек. Но бит әле, ни.. Менә бүгенге кич турында уйлыйсы бар. Кунак булып килгәнсез парлап, яңа нигезне котлап әйберләрен алып килгәнсез, нәрсә дә булса кыландырырга иде бит дигәнем.

Шуны гына көтеп торган кебек, кунак өстенә кунак, ишекне зур ачып, күрше Сафа килеп керде. Ул камзул чабуы астына яшеребрәк нәрсәдер тоткан, уң кулы тирсәк тиңтен киселгән — яше ягыннан Хафиздан кайтышрак булса да, сугыш машинасы аның да бер кулын алып калырга өлгергән иде инде. Ничек күрешергә белмичә бер мәл аптырабрак торганнан соң, әлеге киселгән кулының калтышкасы белән Хафизның җилкәсенә бер шапылдатып алып, сөйләнергә тотынды:

— Кайтканыңа күпме вакыт, бер күреп, гәрләшеп утырган да юк. Өйгә чакырып булмый, чебен дә бала-чага баскан өйне. Менә болай күршегә үк килгәч, тукта, мәйтәм,— ул уңайсызланып кына Хәсәнша картка карап алды,— син ничек, Хәсәнша абзый, ястү намазына барырга ашыкмый торгансыңдыр ич?

Карт бу сүзләрдәге кыек атып туры тидерергә тырышуны дөрес аңлады, ястү намазы белән татулыгы бик булмаса да, Сафаның камзул чабуы астына яшерелгән «кунак кызы»ның иркенгәрәк чыгарга теләвен ул бик чамалый иде.

— Живо, энкәсе, чап өйгә. Бер кат кирәген, савыт-саба, чынаякчәшкә дигәндәй, аннан килеп, бер бөтен икмәк белән бер савыт тоз кыстырырга онытма,— дип солдатларча команда бирде карт. Һәм карчыгыннан элгәрәк үзе ишеккә атлады,— ипи-тозны беренче булып кертергә иде ишектән, без шул каткан агач — мажик тек мажик.

Ләкин Сәрби әби ашъяулыкка төрелгән икенче төенчеген һәм ипитоз күтәреп килеп җиткәнче, мондагылар елтырашып өлгергәннәр, Сафа тиз генә чыгып, берничә пар чынаяк һәм каба торырга дип бер тәлинкә эчәк бөккәне, ә малайларга бер бүрек пешкән кукәй алып кереп өлгергән иде.

— Безнең монда, татар җирендә, тавыклар буяулы күкәй салмыйлар, шабаш,— дигән булып, бар күк русчасы белән иң элек малайларны сыйларга тотынды ул,— но күкәй есть күкәй, мин салган нәрсә түгел. Утырыгыз, ашагыз, без сезнең табынга кысылмыйбыз, сез безнекенә. И канис шуның белән...

Бусагадан беренче булып ипи-тоз кермәсә дә, күрше-тирә, авыл халкы әнисез калган ике малай белән кайтып, ялгыз өйгә килеп урнашкан Хафизны ташламады. Мендәр өстенә мендәр килә торгач, бер вакыт сәке почмагындагы мендәр өеме түшәмгә житә язды — малайлар, баш асларына гына түгел, асларына да мамык мендәр салып ята башладылар. Күрше кызлары суын кертә, икенчеләре кереп, Хафиз үзе өйдә юкта иданен-сәкесен юып чыгара, бу мәшәкатьнең ике якка да файдасы тия: шул йомышны йомышлаган арада күрше кызлары, кызыксынып, Толя белән Мишадан берәр генә сүз булса да русча отып калырга маташсалар, бәйрәм ашы-кара каршы дигәндәй, үз нәүбәтләрендә Толя белән Миша да ул ерык авызлы кызлардан татар сүзләрен тартып алырдай булып сорашалар, аңлаганын аңлап, аңламаганын кул ишарәләре белән ничек тә сөйләшеп китәргә тырышалар иде.

Хафиз үзе, кайтып бераз канат-каурыйны җайга кую белән, һәртөрле җәмәгать эшләрендә — солдатлар комитеты оештыру, җирне яңадан бөлешү, ирләре фронтта үлеп калган солдатка семьяларына ярдәм оештыру эшләре белән мәшгуль булганлыктан, күп вакыт өйдә малайлар үзләре генә кала, алар инде өй эшләренә дә өйрәнеп киләләр, сәкесен Мишасы юса, идәнен олырак абый буларак Толя юа, бүтән эшләрне дә шулай үзара бүлешеп, тату гына башкарып чыгалар иде. Шулай да, бер иялэшеп киткәч, аларга малайлары да, кызлары да гел кергәли йөри, кай көннәрдә, балаларча өйне бөтенләй онытып, малайлар белән Кыялы-Яр күленә балыкка да киткәлиләр иде.

Бу ялгыз нигезгә күчеп килгән беренче кичне онытып, без үзебез дә малайларчарак алга йөгердек. Ә бит анда, ул беренче кичне дигәнем, әлеге Сафа күршенең камзул чабуы астына качып яткан оялчан «кунак кызы» дөньяга чыккач, аларның телләре-күңелләре чишелепмечишелде. Хафиз кайткан дигән хәбәрне ишетү белән, Сафа, хатынын жылата-жылыта, «мәрәк дусты» өчен үзе самогон кудырган һәм б; «үзекудырган»ның күздән яшь китерердәй зәһәрен, яшелле-зәңгәрлесен, менә биш көн буена саклап торган булган икән... Димәк, телләрг чишелерлек сәбәп булган монда. Әле алар икәү генә булсалар, ихтимал үзләре дә кәкрәеп төшкән булырлар иде, башлаган сүзләре һәм гамәләре кызып барганда гына, «ут күргәч кердем» дигән булып, алар янына өченче бер фронтовик — нинди:дер бер эш майтаруы аркасында күкрәгенә «Георгий» тәресе эләктергән һәм туган җиренә үн көнгә побывкага җибәрелгән яшь солдат Хәбир дә килеп керде. Солдат солдаттан җәлләми, шуннан алар калган байлыкны өчкә бүлә башладылар. Үзеннән-үзе аңлашыла, алданрак авыз чылата башлаганнары кыза төшкән иде, шундук яшь солдатны котыртырга тотындылар.

— Син, Хәбир брат, еракка үрләрсең, парень, бу килештән. Бару белән күкрәгеңә бу «тавык тәпие»н эләктергәч, тора-бара алар синнән генерал ук ясап куймагайлары,— дип, әллә мактап, әллә көлеп, әлеге теге киселгән кулының калтышкасы белән яшь солдатның җилкәсенә сугып куйды Сафа.

— Анысы шулаен шулай да,— Хафиз «әйтергәме-юкмы?» дигәндәй сузып торды, ләкин күзләренә бәреп чыккан зәһәрле очкыннары авылдаш хакын хаклап торырлык дәрәҗәдә түгел иде,— анарчы бит, хлопцы, я Хәбирнең үзенең башы очып төшүе бар, я... царь Николашканың башын өзеп куймагайлары. Дөнья бит ул, Чалдый Гобәе әйтмешли, күләсә...

— Әйдә, политикага тыгылмыйча гына утырыйк әле, өч авылдаш, өч верноподданный бергә туры килгәнбез икән,— әллә яшьлеге аркасында, әллә янарак кына тагылган «тавык тәпие» тәэсиреннән, «ут күреп кергән» Хәбирнең ничектер бик аек каласы килә иде. Ләкин кызу канлы Сафа «йомырканың тавыкны өйрәтүе» белән килешергә теләмәде.

— Мин верноподданный түгел, бутама мине үзең белән,— дип, тавышын нык кына күтәреп, исән кулы белән өстәлгә китереп сукты,— ярый ла синә, чебен дә тешләмәгән көйгә, награда чәпәгәннәр, ә минем менә бу кулым кайда? Әнә Хафиз белә, ике потлы герне «эһ» тә димичә ун мәртәбә һавага чөя торган идем мин бу кул белән...

Нык кына чымырдаган кунаклар, кайсы кайсына һәм нәрсә өчен рәхмәт әйтергә тиешлекне белмичә, рәхмәтен дә, «гүр такталарын»да бергә кушып, ишек-капка тирәләрендә бераз буталышканнан соң, шулай да таралыштылар. Хафиз ялгыз калды, ишек бусагасында бер ялгызы тәмәке тартып утырды, уйланды, малайларын искә төшереп, өйгә кермәкче булды, кермәде. Тагын беравык шулай эленке-салынкы уйлана торгач, жил капканы шыгырдатмыйча гына ачып, урамга чыгып китте. Һәм аны-моны уйлап тормыйча, эчемлеккә якын да килмәгән ап-аек кеше кебек, тип-тигез атлап, беләсезме, кая таба китте? Тегермән очына, Гыйльмениса тора торган якка китте. Әлбәттә, нинди дә булса дуамал бер ният белән түгел, кайтканнан бирле, урман ягыннан кайтышлый бергә юллары туры килгәннән бирле, Хафизның аны рәтләп күргәне дә юк — нинди дуамаллык турында уйларга мөмкин! Шуның өстенә, Гыйльменисаның үзен сүз тидермәслек итеп тота белүе, каенсеңелесен булганы белән зурлап озатуы, балаларын эшкә өйрәтеп, кеше арасында ким-хур итмичә үстерүе турында колагына мактаулы хәбәрләр дә кергәли башлаган иде. Мөмкинме шундый кеше турында ни дә булса хәтта күңелгә китерергә?

Шулай да, ни белән аңлатмак кирәк, Хафиз шул очка таба китте. Гыйльменисаның өе читтә, кеше-кара күзенә чалынасы түгел, һич югы, аның шул очка барасы, Гыйльмениса яшәгән өйгә бер ялгызы, берни дә уйламыйча, бер кешегә дә күренмичә, озаклап-озаклап бер карап торасы килә иде.

Төннең бер вакытында йокы аралаш сискәнеп киткәндәй булды Гыйльмениса. Кайдандыр ялгыз бер адәм озын һәм моңлы көйгә урам тутырып җырлап килеп чыкты да, моның өе тирәсенә җитәрәк тукталып булса кирәк, сүзләрен аермачык ишеттерергә тырышкандай, озак кына сузып торды.

...Талдин талга кунып сайрый микән
Таң алдыннан сары ла сандугач,
Сандугачлар тавышы моңлы икән,
Сөйгәнеңне өзелеп сагынгач...

Сискәнеп китте Гыйльмениса һәм кинәт куркынгандай булды. Таныды ул бу тавышны. Бу — аның тавышы, Хафиз җырлады моны! Ә нишләп? Нигә болай соң? Кемгә дип җырлады ул моны? Менә син карт тиле.

## X

Авылга кайтышлый урман юлында беренче кабат очрашканнан бирле Гыйльменисаның Хафиз белән, урамнан үтешли яки кеше арасында туры китереп баш кагып исәнләшүләрен искә алмаганда, рәтләп очрашканы юк иде. Элекке хәлләрне истә тотучылар да бардыр, дип уйлый, үзенең дә биргән сүзендә тормыйча, ашыгып Барыйга кияүгә чыгуыннан уңайсызлана иде. Ничек кенә булмасын, Хафиз күзенә чалынудан мөмкин чаклы качыбрак йөри иде ул. Әмма бу курку, бу уңайсызлану үзе үк аның инде элекке тынычлыгын югалтканлыгы турында сөйли

иде. Теге төнне очраклы рәвештә йокы аралаш колагына кереп калган җыр да килеп кушылгач, аның тәшвишләнүе вакыт-вакыт нык кына сиздерә башлады. Шул ук вакытта: «Булмаганны. Ошамаганны... күңелгә нәрсә килмәс ул!» дип, үзен тынычландырырга да тырыша иде. Шулай да Хафизның күпме еллардан соң яңадан авылга кайтып төшүе Гыйльменисаның тышкы тормышында, үзен тотышында, киемендә-салымында бернинди дә үзгәреш китереп чыгармады, хәер, көне-төне кеше эшендә чабып, моңарга аның вакыты да юк иде.

Әмма бер көнне туры килде. Юк, качып калу мөмкин булмады бу туры килүдә! Гыйльмениса авылдан шактый ерак Зирекле елгасы буеннан ялгыз яшәүче Хәерниса карчыкның җитенен җәеп кайтып килә иде. Көзге көн, берничә тапкыр өзек-төтек яңгыр да явып киткәнлектән, өсте-башы юешләнгән, пычрак җитен учмаларыннан биткә-кулга йоккан «кершән-иннекне» искә алмаганда, аны нинди дә булса бик үтә мөһим бер очрашуга әзерләнгән кеше дип күз алдына китерерлек түгел иде. Җитмәсә тагын аягындагы чабатасы да тишелеп, арттан «канат ярып» кайта иде. Менә шунда, нәкъ шушы кыяфәтендә чакта, аны арттан атлы бер юлчы куып җитте.

— Әйдә, утыр, авылдаш,— диде атлы юлчы, Гыйльмениса турына килеп җитүгә атын туктатып. Күтәрелеп тә карамастан, тавышыннан ук танып алды Гыйльмениса: бу — Хафиз иде. «Кайдан бу? Үзенең аты юк ич аның», дигән уй үтте Гыйльменисаның башыннан. Аның Хафизны үзеннән бик алай өстен кеше итеп таныйсы килми, хәтта вакыт-вакыт аның Хафизны бөтенләй дә танышы килми: «Кайтты да йөри әллә кем булган булып. Кәмитетләр оештырып. Дөньяны кырмакчы үзенчә». Шулай дип тә уйлаштыргалый иде ул кайчагында. Инде менә тәмам карага катып, чыланып, җәяүләп кайтып килгәндә, тегенең атта куып җитеп, утырырга тәкъдим итүе Гыйльменисаның горурлыгына ук тиде.

— Күп калмады, болай да кайтып җитәрмен,— диде ул, утырырга бик ашыкмыйча. Шулай да йөзеннән, кара тапларны басып, алсу-кызыллык йөгереп узмыйча кала алмады.

— Утыр, минем дә үз атым түгел. Кеше атына миңа кемне утыртып кайтсам да барыбер.

Сизелеп тора: Хафиз яланда Гыйльмениса белән икәүдән-икәү генә очрашуга бик тә шат, бу — аның тавышына ук чыккан иде. Ул, атын һаман кузгатмыйча, Гыйльменисаның утырганын байтак кына көтеп торды. Гыйльмениса да, гәрчә тыштан туңган-җебегән кебек күренсә дә, ихластан әйткәнне аңламаслык дәрәҗәгә үк килеп җитмәгән иде. Кинәт йомшарып, җылынып калгандай булды, шулай да арбага менеп утырырга ашыкмады.

— Юк инде, Хафиз абый, рәхмәт,— диде ул кинәт яктырынып, алсуланып, каушап,— кеше күрсә, әллә ни уйлый башлар. Кайткан кайтыйм инде.

Ул, туктап торган арбалы атны урап, җәяүләп узып китте — дөресен әйткәндә, аңарга болай да бик рәхәт иде бу минутларда. Аяклары үзләреннән үзләре атларга торалар иде. Ләкин Хафиз атларга ирек бирмәде. Ул, шундук атны атлата төшеп, Гыйльменисаның алдына килеп чыкты һәм, дилбегәне арба карамасына урап куеп, үзе җиргә сикереп төште, арткарак калып, Гыйльмениса белән рәттән арба артыннан җәяүләп бара башлады. Сүз югыннан сүз булсын, дигәндәй, үзенең нindидер бер юк эш белән йөрүче кешене озата барганлыгын әйтте, ләкин кайдан килгән кеше һәм нинди эш белән йөрүче кеше икәнлеген әйтеп үк бетермәде. Ничектер, серле кешечәрәк тота иде ул үзен бу минутларда. Шуны бераз йомшарту өчен булса кирәк:

— Ярты гомер читтә йөреп уздың, үзең беләсең, Гыйльмениса,— дип, яңадан сүз башлады, әйтеп бетермәгән сүзләре өчен Гыйльменисадан гафу үтенгән сыман,— фронтовик кешенең нинди генә дуслары булмас.

Лазареттан гына чыккан килеш җәяүләп авылына кайтып бара, ә авылы моннан егерме ике чакрым. Җизнидән атын теләнеп, шул ватык солдатны озатып кайтып килешем.

Аннары. әңгәмәгә җиңеллек, уен-көлке төсе бирергә теләгәндәй, өстәп куйды:

— Болай арба артыннан җәяүләп бару лутчы кызык икән. Курыкма, тартырга җиңелрәк калган өчен күңеленнән генә ат та рәхмәт әйтә торгандыр әле.

— Аның да күңеле була микәнни? Белмидер нем,— дип, сүзне уенга борды Гыйльмениса да. Хафизның ихлас күңеллелеге, нәкъ шул Гыйльмениса өчен арбадан төшеп, тигезле-тигезсез юлдан бергәләп җәяүләп барырга риза булуы, шуның өстенә уен-көлке сүзләр дә кыстыргалап җибәрүе — никадәр генә керпедәй энәләрен калкытып күренергә тырышмасын — Гыйльменисаны да әкренләп эретә-йомшарта бара иде. Аннан соң алар, бик үк тирәнгә кермичә генә, авыл хәлләреп сөйләшкәләп бардылар, балаларына күчтеләр, Хафиз үзенең картузлы малайларының әкренләп авылга, малайларга ияләшә башлавы белән мактанып алды. Әллә чынлап, әллә шаяртып, хәзер менә артык расход чыгарга торганлыгын, әле кайтканда гына алган өр-яңа картузлары була торып, малайларының, башка малайлардан күреп, түбәтәй сорап йөдәтүләрен сөйләп, Гыйльменисаны авыз чите белән генә көлемсерәргә дә мәҗбүр итте.

— Минекеләр юкны-барны сорап йөдәтмиләр, алайса. Әтиләре Барый мәрхүм кебек, булганына канәгатьләр,— дип сүзне тизрәк түгәрәкләп куярга ашыкты Гыйльмениса. Балалары белән мактанасы килүдән түгел, бу очракта Барыен сагынып искә төшерүдән дә түгел — булган да инде узган, искә төшерүдән кемгә файда,— авылга якынлашып килгәнлектән, сүзне тизрәк очлыйсы килүдән һәм, аннан да бигрәк, Хафизның сүзне әллә кая — икенче якка борырга маташуыннан курыкты ул. Шулай да авылга кайтып житкәнче бик әһәмиятле һәм әле берсе дә кагылмаган бер сүз калган булган икән. Ир һәм элекке моряк кеше Хафиз бу яктан тәвәккәлрәк булып чыкты.

— Синекеләр нәрсә? Синекеләр зурлар инде,— дип, Гыйльменисаның кызларыннан тотынды ул, сүзне бик еракка җибәрмичә. Шул ук вакытта дуамаллык күрсәтүдән дә шикләнә иде. Ләкин, үзе дә сизмәстән, бер дуамаллык ычкындырмыйча кала алмады.

— Әйт әле, Гыйльмениса, монда без икәүдән икәү генә, только яшермичә әйт: яратып чыктыңмы син Барыйны?

— Яратып чыктым,— дип, берьюлы өзеп салды Гыйльмениса. Ике төрле уйларга урын калдырмады. Ләкин Хафиз ике уйламыйча булдыра алмады, Хафизга ике уйламыйча мөмкин түгел. Чөнки ул, беренчедән, узган эш турында сораша, ләкин хәзерге — нәкъ менә шушы минут белән яши, ул Гыйльменисаны, өсте-башы чыланган, чабатасы тишелә башлаган, инде яхшы ук төс салган, ләкин үзәкне өзеп карый торган моңсу кара күзләре, тыйнаклыгы, азсүзлелеге сакланып калган шушы Гыйльменисаны әле хәзер дә, тартып алып, күкрәгенә кысардай булып ярата, икенчедән, Гыйльменисаның нинди сәбәпләр нәтиҗәсендә Барыйга барып егылуы турында ул инде авыл кешеләреннән күп мәртәбәләр ишеткән иде.

— Яратып чыктым, яратып чыктым! — дип, тавышын күтәргәннәнкүтәрә төшеп, рәттән ике мәртәбә кабатлап куйды Гыйльмениса. Аның күзләре яшь белән тулган, ул аны түкмичә көчкә-көчкә генә тыеп бара иде. Шул ук вакытта, аның Хафизга әйтәсе сүзләре дә бетмәгән иде. Ниһаять, менә әйтелде ул сүзләр,— син икенче кабат минем Барыема тел тидерәсе булма. Хафиз, гөнаһысыннан курык.

Һәм ул, ерганак буенча урманнан үлән, утын, җиләк ташучы җәяү-

леләр салган тар сукмакка борылып, хәтта рәтләп исәнләшеп тә тормастан, тиз-тиз атлап, ашыгып кире якка китеп барды.

Чынлап та, кире якка киту булды шул бу. Яман ният белән кузгатмады шикелле ич Хафиз сүзне. Гыйльменисаның элекке ире Барый турында да, бераз дуамалрак чыкса да, яман ният белән әйтмәде кебек. Тавышыннан, балалар турында кызыксынып сораштыруларыннан, атыннан төшеп, Гыйльмениса белән рәттән җәяүләп баруларыннан ук һәм моңарчыга кадәргесе дә — очраган саен җылы көлемсерәп, түбәнчелек белән исәнләшеп йөрүләреннән үк сизә һәм тоя килә иде Гыйльмениса: нәрсәдер Гыйльменисага әйтәсе сүзләре бар иде кебек Хафизның. Бик мөһим сүзләр булырга тиештер кебек тоела иде ул сүзләр. Кемгә ничектер, Гыйльмениса, һәрхәлдә, шулайрак тоя иде. Юлда да шул турыда уйлап кайтты ул, кайткач та уйлап йөрде, кызлары кайсы кайда эштә иде, өйнең ялгыз булуы аның бу аяныч катыш өметле уйлануларын тагын да көчәйтеп җибәрде: «Соң нәрсә булган? Әйтәсе сүзен әйтсен иде кеше. Сүздән соң... Янсә бер арбага утырып кайтудан соң нәрсә була? Сөйләгән кеше сөйли бирсен... авызына теле сыймаганы... Менә хәзер син аны үпкәләттең инде... Үпкәләткәнсеңдер инде...»

Кич белән Факиһәсе эштән кайткан вакытта Гыйльмениса казан астына яккан, ашын салган хәлдә, караңгырак бер почмакта мендәргә йөзтүбән капланып ятып тора иде.

— Башым авыртып тора никтер. Җил кактымы дип әйтим,— дигән булды ул, кызына аны-моны сиздермәскә тырышып. Хәер, Факиһәсе, аның үзе кебек үк, күп төпченүчән түгел, артык тирәнгә китмәде. «Аш булганчы мин чишмәгә суга барып кайтыйм әле», дип, чиләк-көянтәсен алып, шундук чыгып китте.

Бераздан анысы алып кайтты икенче бер аптыраткыч хәбәр.

— Ир-ат та бала-чага, суга барып йөрү кыендыр, дип, Хафиз абыйга бер көянтә чишмә суы керткән идем,— дип сөйләп китте кызы, үзенә күрә бер яңалык ачкан кебек итеп.— Кисмәкләре чишмә суы белән тулы, идән-сәкеләре юылган, өйләре җыештырулы, шул ике малае өйдәге бөтен эшне эшләп тора икән. Күреп исем китте, минем белән татарча сөйләшеп маташалар.

Ә Гыйльменисаның үзенең, Факиһә әйтүенә караганда, бигрәк тә бүтән нәрсәгә исе китте: Хафиз шулай да, кисмәкләре тулы булса да, Гыйльмениса кызы керткән суны алып калган, урын тапкан. Әле, чын булса, болай дип тә әйткән кызга:

— Гыйльмениса кызы керткән су особый тәмле булыр инде ул. Без аны чәйгә генә тотарбыз,— дигән.

«Барыбер... барыбер, Хафиз, үз кызларымны үз кулым белән урнаштырып бетермичә торып, берни дә чыкмаячак. Уйлама юкны, чыкмаячак» дип, күңеленнән, үзенә-үзе сүз биреп куйды Гыйльмениса.

## XI

Хафиз кайтканнан соң Гыйльмениса тышкы яктан кеше күзенә ташланырлык үзгәреш күрсәтмәсә дә һәм моңарга аның вакыты булмаса да, шулай да авылда, нәкъ аның кебек, мәшәкать чигеп ятим калган балалар үстереп азапланучы икенче бер тол кешенең барлыгын белеп тору ничектер эчке тынычлык биргән кебек иде. «Юк, мин генә түгел мондый китек язмышка дучар булган кеше!» Теге, юлда туры килеп, арба артыннан бергәләп җәяүләп кайткан чагында Хафизның, Барыйны искә төшереп, «яратып чыктыңмы син Барыйга?» дип, кабыргасы белән сорау куйганы өчен Гыйльмениса күңеленнән аңарга бераз рәнҗеп йөрсә дә, өйдә ялгыз гына калган тын сәгатьләрдә уйлана торгач, моның да үзенә күрә аңлатмасын тапты. Кем белә, бәлки Хафиз Гыйльменисаның үз авызыннан ишетәсе килгәндер, кешедән ишетү бер нәрсә,

кызыксынган кешенең үз авызыннан ишетү икенче — димәк, Хафиз әле Гыйльмениса белән кызыксынудан туктамаган дигән сүз. «Алайса үз авызым белән әйтеп бирим,— ди ул, ялгызлыкта Хафизга җавап кайтарган кебек, күңеленнән үзе белән үзе сөйләшеп,— ничек чыкканымны уйлап торырга вакыт калдырмады шул безнең бай этиебез. Тик шуны гына беләм: Барый мине ярата иде, үләрдәй булып ярата иде. Чыккач, бергә тора башлагач, кинәт, үзем дә сизмәстән, мин дә аны ярата башладым — яраттыра торган яклары ачыла барды мәрхүмкәемнең!»

Вакыты-вакыты белән күңеленнән шулай әрепләшсә дә, шулай да авылда Хафиз барлыгын белеп яшәү аңарга тел белән әйтеп булмый торган ниндидер тынычлык биргәндәй иде. Шулай ук Хафизның гел күзгә-башка чалынып йөрүен дә аңлый, аңларга тырыша иде: «Әнә бит... нинди генә сүзләр йөрми дөньяда. Җыен солдатлар — кайтканнары да, тегендә калганнары да — үзара сүз беркетеп, шунда ук кала кешеләрен, төрле һөнәрдәге мастеровойларны — завод эшчеләрен дә кушып, теге ни атлы соң әле... стуҗин дигәннәрен дә үз артларыннан ияртеп патшага каршы чыгарга, сугышны туктатырга йөриләр ди түгелме соң? Теге көнне җизнәсеннән ат алып, белмәгән-күрмәгән аксак солдатны егерме бер чакрымга озатып йөрүе дә тикмәгә булмагандыр әле».

Болай уйлау, бер үк вакытта, Хафизны Гыйльмениса каршында үстерә, ничектер, үрелеп буй җитмәслек серле бер кешегә әверелдерә, икенче яктан, күңеленнән аның белән мавыгуын, яшертен мавыгуын ныграк сизгән саен эчтән яшәрә, чәчәк ата бара кебек иде.

Шулай да, Гыйльмениса Хафиз турында «үрелеп буй җитмәслек серле кешегә әйләнә бара» дип уйлап йөрсә дә, көннәрдән бер көнне Хафиз вакыт тапты, «серле» дигән кешебез күңелендәгесен ап-ачык итеп әйтте дә салды.

— Кара әле, Гыйльмениса,— диде ул, тегенең кызлары эштә чак бер мәлне туры китереп,— бер киңәш белән килдем сиңа. Болай ялгыз яшәү һәм шул ялгыз баштан, үзең ир заты була торып, балалар үстерү миңа да ансат түгел, сиңа да бик үк бәйрәм түгелдер. Әгәренки, әйтик, без менә болай итсәк: ике ояны бергә кушып, син шул оянын әнисе, мин шул оянын әтисе булсам? Онытмаган булсаң, без бит кайчандыр бер-беребезне күз карашыннан ук аңлыйдыр идек...

Һәм ул ничектер моңаеп, ярдәмгә мохтаҗ кеше сыман тилмереп, шул ук вакытта Гыйльмениса нәрсә әйтсә — шуңа күнәчәген алдан ук сиздерергә теләгәндәй, томырылып карап торды. Гыйльмениса хатын-кыз сизгерлеге белән шундук сизеп алды: яшь чагында, берсе кыз, берсе егет чакларында да, вакыт-вакыт шулай үзәкне өзә торган итеп томырылып карап торгалый иде ул Хафиз. Онытырга мөмкинме соң андый карашны!

— Минекеләр зур инде, бер ояга гына сыйдырып булмас аларны,— дип, әллә чынлап, әллә шаяртып, җавап кайтарды Гыйльмениса һәм үз чиратында бусы шулай ук, тегенең күзләренә карап, уйланып калды. Шундый җитди, шундый хәлиткеч бер минут килеп туды ки, моннан инде сүзсезлек белән дә, уйнап-шаярып кына әйткән сүзләр белән дә котылу мөмкин түгел иде. Шуны бөтен җитдилеге белән тоеп, күңеленнән Хафизны кабул итәргә бик-бик ашкынган хәлдә дә үзен тыеп, гаять җитди кыяфәттә аннары өстәде,— юк инде, Хафиз, ашыкмыйк без бу эшкә: мин үз кошларымны үзем үстереп, үз кулым беләнияләренә тапшыргынчы ул турыда уйламаска булдым. Мәрхүм әтиләре алдында сүз бирдем. Үзең үк күреп торасыңдыр, минекеләрнең канат-каурыйлары инде өсләрендә... очып китәргә күп калмаган.

Чынлап та, бик җитди сөйләшү булып чыкты бу. Моннан соң кабат ул темага сүз яңартып тору Хафизның үзен дә вакландырыр, Гыйльменисаның чынлап әйткән сүзен санга сукмау булыр иде.

Бигрәк тә тагын шунысы: дөньяда моннан башка да эшләр кузгалып китте. Авыл халкының теленә кереп, очы-чачагы Гыйльменисага да килеп җиткән әлеге хәбәрләр дөрес булып чыкты. Авылга бер-бер артлы яңа хәбәрләр кайта торды. Патшаны төшерү белән халык шундук сугышның бетүен, солдатларның шау-гөр килеп кайтып җитүен көткән иде, анысы булмады. Тагын әллә нинди сүзләр китте, тагын болгана башладылар, тагын комитет артыннан комитет оештырырга тотындылар, бу комитет дигәннәре берсе икенчесенә охшамаган, берсе сөйләгәнне икенчесе юкка чыгара тора иде. Бу ыгы-зыгылы айларында Хафиз атналар буена өендә күренмәс булды. Кайда монда үз оя турында уйларга, халык үзе, оясы тузгытылган шөпшәләр кебек, тузгып, кем кемне чагарга белмичә тузгып ята. Гыйльменисаның үз мәшәкатьләре дә җитәрлек, ул күпкә тыгылмый, шулай да теге көнге җитди сөйләшүдә кузгатылган «оя кору» мәсьәләсен онытып та бетерә алмый — Хафиз үзе өйдә юкта, кеше-кара күзенә бик чалынмыйча гына барып, аның малайларына күз-колак сала, ямасын ямап, юасын юып, тегеләрнең яртылаш русча әйткән сүзләрен, аңласа-аңламаса, бик аңлагандай итеп, аларга үз телендә яхшылап, аңлый торган итеп киңәшләр биреп киткәли иде.

Аннары, озак та үтмәде, аның икенче көткәне, Барые исән чакта, Барые белән бергәләп көткәне, Барые үлеп, биш хатын-кыз бер имана җирсез утырып калгач, күңеленнән ул вакыттагы законны каһәрли-каһәрли көткәне шаулап килеп җитте: тирә-юньдәге алпавытларны кайсын кая олактырып бетергәч, аларның җирләрен дә кертеп, имана җан башыннан өләшенде. Гыйльмениса дәррәү дүрт җанга дүрт имана җирле булды. Ирләр арасында кысылып йөрүдән һич тайчанмыйча, басудан басуга үз өлешенә тигән җирләренә туктап, үз адымнары белән үлчәп, үз тамгасын салып чыкты Гыйльмениса. Берьюлы шул хәтле җирнең хуҗасы булу, әлбәттә, бик шатлыклы иде. Ләкин бу шатлык үзе белән үк борчуын да алып килде: бу хәтле җирне ничек, нәрсә белән игәргә? Нәфес бар, кеше рәтенә керергә дәрт тә бик бар, ә менә ат юк. Ул дүрт имана җирне тырнак белән сөреп булмас ич аны! Хафизның кирәклеге башны бергәләп мендәргә кую өчен генә түгел (дөресен генә әйткәндә, анысын да бик тансыклаган иде инде Гыйльмениса, бичара!), Хафизның кирәклеге тормыш кору турында бергәләп кайгырту өчен дә икән — икәү бергә булсалар, бу хәтле кыйналмас иде Гыйльмениса.

Әле ярый, революциядән соңгы беренче язны, Хафизны бик көтеп тә, анысы совет эшләре белән көн-төн чапканда, әллә картая-картая акылга утыра башлаудан, әллә революциядән куркып, бер көнне Гыйльменисаның җил капкасын каерып ачып, һич көтмәгәндә аның онытылган атасы Әлмөхәммәт карт килеп керде.

— Ишеттем, өлешеңә тигән җиреңне ничек чәйнәп йотарга белмичә, авыл буена елап йөрисең икән, кызый,— дип башлады ул сүзне. Юк, әлегә ул үзен һавалы тотуын ташламаган иде әле,— син ярлы тәкәббер булып, этиеңә буй бирмичә йөрсәң йөрерсең, атай картның синең турыда уйлаудан туктаганы юк. Җирләреңне бер көнне Мөхәррәмгә күрсәтеп чыгарсың, ике атка берни дә түгел, үзебезнекеләргә тукталганда, шунда беррәттән синекеләрне дә сукалар, тырмалар. Чәчәр орлыгың юк икән, анысын да рәтләрбез. Соңыннан күз күрер, уртагына дип сөйләшербезме, сипкән орлыкны орлыклата түләрсеңме, үз кешеләр, шат, талашмабыз.

Болай да аптырабрак калган Гыйльмениса, бу тәкъдимдә бернинди дә мәкерле ният күрмичә, шатланып риза булды. Баштан бу кайгы да очты, дип яңадан дәртләнеп Хафизның адашып булса да яңадан бер аның бусагасын атлап килеп керүен көтеп йөргәндә, килә бит бер килә

башласа. Бу очракта, бәлки, китә бит китә башласа, дип әйтү дөресрәк тә булыр кебек.

Бер көнне, әнисе белән өйдә икәүдән икәү генә калганда, Гыйльменисаның олы кызы Факиһә тора торгач кызык кына итеп сүз башлады. Бәлки, яз да тәэсир иткәндер, бәлки, дөньялар алышынып, халыкның дәрте күтәрелеп торганны күрептер, бәлки, тагын да яшеренрәге — соңгы вакытларда, бигрәк тә Хафиз кайтканнан бирле, әнисенең күңеле купшыганны сизенептер, Факиһә бер үк вакытта уйчан да, алгысыган да иде бу минутта.

— Хат танырлык кына булса да укы, укы, дип, кәче-кичедән теңкәмә тиюче кеше ул кем? Син иденме, әни?

— Я, мин булдым, ди. Шуннан нәрсә килеп чыга? — дип, беразаптырабрак, чак кына сагая да төшеп, сорауга каршы сорау белән җавап кайтарды әнисе. Һәм аның бу соравы кызы өчен бик җайлы туры килде:

— Минә аннан нәрсә килеп чыга, әни,— дип, шаярта-көлә әнисен уртәгәндәй, әмма үзе бик житди калган хәлдә, пөхтә төрелгән бер төргәк хатлар китереп тоттырды кыз.— Хат танырлык булып кына калмады безнең эшләр, хатны мин аңарга үзем дә яздым. Ачулансаң ачулан, кыйнасаң кыйна, синнән яшерен серем юк: менә болар минем Түбән авыл мөгаллиме Шәүкәт абыйдан алган хатларым. Без аның белән бер-беребезне яратышабыз, ул бик әйбәт кеше, әни, каршы килмә, мин аңарга кияүгә чыгарга булдым.

Каршы килеп нишләтә алсын, аннары тагы Гыйльмениса ангыра түгел, кызының характерын белә — аның үз кызы, Гыйльмениса тәвәккәллеге анда да бар. Житмәсә тагы мөгаллим абыйсыннан да булгач, сүз әйтерең бармы мөгаллим кешегә — «кара әле, әдәм көлкесен, авызыннан сүзен тартып алыр хәл юк иде башка вакытта. Түбән авылга бер утырмага барган иде, шунда таныштылар микәнни?» Чоры шундый ут уйнап торган чор иде, Түбән авыл мөгаллиме Факиһәне хатын итеп кенә калдырмады, кыска сроклы курслар аркылы үткәреп, аннары һичбер сроксыз, үзе белгәнне кәләше белән уртаклаша-уртаклаша, аны әкренләп китапка, газета-журналга ияләштерде. Өйләнеп карарга да өлгермәде Гыйльменисаң, аның кияве белән кызы икесе тиң укытучылар иде инде — жалуньясын алалар, ягарга мәктәп белән беррәттән утыны-керосины килеп тора, аз булса да паегы чыга... Әни кешене канатландырганы бигрәк тә шул булды: канат чыкты бит кызга, очты бит берсе, үзе генә очуы житмәгән, инде әнә икенчеләргә — балаларга канат куя.

Дөнья һәм кыз бирү мәшәкате белән монда шулай мәш килеп йөргәндә, ул арада калада, «чыбык очлары»нда асраулыкта яши торган икенчесе — уртанчысы — әлеге теге кәче-кичедән киенергә, купшыланырга ярата торганы, әле теге чакларда ук — хат яздырган өчен әнисенә китергән күкәйләрне тиз генә үзенә әләктереп, соңыннан кырыктартмачыдан мәрҗән алып, апасыннан элек муенына мәрҗән, колагына алка тага башлаган Фасиләсе, калада купкан ыгы-зыгыдан үзенчә файдаланып, бер приказчикның башын-күзен әйләндереп өлгергән. Рөхсәт тә сорап тормаган анысы, приказчик белән ирле-хатынлы булып ук тора башлаган. Ул арада анысының приказчигын, сүзгә-язуга оста булуын, сәүдә эшен белүен искә алып, шул сату-алу эше ягыннан ук комиссар итеп тә куйганнар. Тик шуннан соң гына Фасиләсе хат язып, эшнең ничек торганлыгын әнисенә хәбәр итте. Хатының азагында әнисен өч бүлмәле, элекке буржуйлардан калган, идәннән түшәмгә житәрлек көзгесе булган яңа фатирларына кунакка чакырган һәм иң азагында, мактануын яшереп торырга да теләмичә, «мин хәзер Рахманова фамилиясендә түгел инде, комиссар ирем фамилиясенә күчтем, шуны сезгә мәгълүм итеп, Фасилә Кадерметова» дип имзасын

салган. Элек-электән үк бераз шуграк табигатьле бу кызын Гыйльмениса болай да бик үк өнәп бетерми, җене чыккан чакларында «минем кызым түгелсең син, малга-зиннәткә исе китмәс ярлы тәкәббер Барый кызы да түгел, кайдандыр шайтан очырып китереп ташлаган алмаш күзле җен орлыгыннан яралгансың» дип тирги, Барыеның бигрәк тә нәкъ менә шушы уртанчы кызы өчен үләргә торганлыгын сизеп, әйткән сүзләре өчен соңыннан үкенеп бетә алмый һәм кызы йокыда чагында елый-елый аны кочарга, үбәргә, иркәләргә керешә иде. Дөресен генә әйткәндә, Гыйльменисаның өч кызы арасында иң чибәре дә шушы уртанчысы иде. Купшылыгы өстенә, бәлки, шул чибәрлеге белән дә масаюы булгандыр, әнә бит, алдан энисе белән киңәш-табыш итүне дә кирәк тапмаган. Комиссар кияүдән колак кагармын, дип уйладымы икән әллә, юньсез? Бөтенесен, бөтенесен берьюлы күңеленнән кичереп, хат алу белән утырып бер елады Гыйльмениса һәм шуннан соң бушанып калгандай булды: «Үзе егылган җыламас, ярый инде, ахыры хәерле булсын» белән бетерде. Ләкин калага кунакка чыгып китәргә ашыкмады. Чөнки төене бетсә дә урыны калган, әзләүсез-сораусыз шулай башбаштакланып йөрүе өчен кызын алай тиз генә гафу итәрдәй күренми иде. Шулай да ана күңеле тынгысыз иде. Шуның өстенә тегеләре дә, үзе вакыт таба алмаса, Фәнияне җибәрүне сорап, хат артыннан хат яза торгач, ниһаять, тәмам йомшарды. Җәйге эшләр җиңеләйгәнрәк бер вакытны туры китереп, бар күге белән киендереп, Фәниясен җибәрде. Һәм бу анын, үз карашыннан чыгып әйткәндә, балта белән юнып та кырып төшерә алмаслык икенче бер хатасы булды. Моңа хәтле Ташлыяр авылыннан, аның да иң очындагы, башка йортлардан бераз аерылыбрак торган кыйшык йортыннан бүтән нәрсә күрмәгән, ә яше ягыннан да иләс-миләсрәк бер вакыты — тиз оныта, тиз кызыга, тиз алдана торган бер чагы булган унбиш яшьлек Фәниясе беренче мәртәбә шәһәр шау-шуын, шәһәр ялтыравыкларын, комиссар җизнәсе өендәге җиһазларны күрүгә кинәт иләсләнеп калды. Авылда калган энисен шундук онытты, онытмаса да, авылга кайтып китәргә ашыканлыгы бер дә сизелми иде. Апасы белән бергәләп, эниләрен чакырып, тагын бернечә тапкыр хат язып карадылар, «хәзергә өйне ташлый алмыйм, килер эле вакыты, барырмын» дигән сүзләрдән башка җавап алмадылар. Ниһаять, көз җитеп, Казанда әнә шундый Фәния кебек авылдан килгән балалар өчен интернатлы һәм дәүләт стипендиясе түләнә торган мәктәп ачылачак икәнлеген ишетеп, комиссар кияү, яшьләрне укытырга — кеше итәргә кирәклекне, илнең яшь кадрларга мохтаҗ икәнлеген, Фәниянең бик аңлы, укырга — күпне белергә бик тә омтылучан сәләтле бер кыз булганлыгын кат-кат исенә төшереп, укып, фән белән коралланып чыкса, аның бик зур кеше булып җитешәчәген әйтеп, каенанасының күңелен эретергә тырышып, бер дә иренмичә үзе хат язды. Моңа хәтле күрмәгән-белмәгән кияү кешенең балдызы турында болай кайгыртып, аңарга зур киләчәкләр вәгъдә итеп, тәфсилләп язган, шуның да өстенә тагын, менә ничәнче кат инде түбәнчелек белән кунакка чакыруларын искә төшергән бу хатны алып укыгач, Гыйльмениса берьюлы эреп төште. Кунакка җыенуын вәгъдә итәргә ашыкмастан, Фәниясен әлеге интернатлы уку йортына ала калсалар, бу эшкә үзенең һич тә каршы түгеллеген белдереп, шундук җавап хаты язды.

Һәм әнә шулай итеп, кайчандыр өч кызы, бер каенсеңелесе, ялгыз бер өе һәм бик күп нужасы белән ирсез, жирсез каңгырып яшәгән Гыйльмениса кинәт баш җитмәслек хәлләр алдында торып калды: кызлары үсеп җитеп, кул арасына керә башлаган иде, кинәт кенә алары берсе артыннан икенчесе йорттан китеп бардылар. Революция диделәр, гарык булганчы җирен бирделәр, ә ул җирне нәрсә белән, кемгә иңне терәп игәсен? Революция юк иде, укыган кешеләр кирәк, баланны укырга җибәр, дип әйткән кеше дә юк иде, барын-югын белән бергә оешып

тора бирә иде. Революция булды, илгә укыган кешеләр кирәк булып чыкты, аның актык кызын тартып алдылар. Революция юк иде, аның каравы авылның теге очында, күпер төбендә, Гыйльмениса кебек ук, балалары белән ялгыз этләнүче Хафиз бар иде, әледән-әле Хафизны күреп ничектер җан тынычлыгы, мәшәкатьле дөньяда үзенә иш тапкандай була иде Гыйльмениса. Революция булды, Гыйльменисаның Хафизын үзенә тартып алды — хәзер инде Хафиз әнә «совит кешесе», күзгә башка да күренми. Менә шулай әллә ничегрәк, каршылыклырак булып килде Гыйльменисаның революциясе.

Тиз генә аңлатып булмастай гаҗәп-кызык хәлләр: шул ук вакытта искәрмәстән генә өмет кайтты Гыйльменисаның өенә: кара әле син аны, балалары кеше булырга тора бит! Һәм кинәт яшәреп киткәндәй булды Гыйльмениса. Төшләр күрә башлады. Төшендә нәрсә күрә диген? Әле сабан туе, әле печән өсте. Сабан туенда да башкалар арасыннан гел шул көрәшче Хафиз килеп чыга. Печән өстендә дә өлешләре, имештер, гел берәттән туры килеп тора. Үзе каерылып-каерылып печән чаба Хафиз, үзе шул арада бу якка — Гыйльмениса ягына таба да каерылып бер карап ала Хафиз.

Аннары кинәт, гомердә булмаган хәл, бит юарга исле сабын кирәкләгән исенә төшерде Гыйльмениса. Кешедән ишеткәне колагына кереп калганмы, әллә кырык тартмачысы шундый теләнә салынган кеше туры килдеме, имештер, битне көн саен «Гөлҗиһан» сабыны белән юсаң, биттәге сипкелләрне бетерә. Бер үк вакытта, үзе аптырый, үзе күнеленнән генә көлемсери Гыйльмениса: нигә кирәк булды соң әле аңарга биттәге барлы-юклы сипкелләрне бетерү? Кемгә комачаулады алар? Карасаңа, әле көлүне дә онытмаган икән Гыйльмениса. Үзенә үзе икърар итәргә уңайсызлана, ләкин шулай икәнлеген күңеле белән сизенә: кызлары китте, яшьлеге кайтты Гыйльменисаның. Йокысы качты, көләчләге кайтты Гыйльменисаның. Көлмичә соң, яшен иллегә җитеп килгәндә, биттәге сипкелемне бетерәм дип көн дә «Гөлҗиһан» сабыны белән бит юарга тотын әле син! Җитмәсә тагын хәтере дә яңарып, әллә кайчандагыларны искә төшереп тора: бик-бик күптән, әле Барыйга чыкканчы ук, әле шул җәйге дымык бер кичтә, әрәмәлек буенда бергәләп сыер эзләп йөргәндә иде шикелле, әйткән иде аңарга Хафиз. «Мин сине әнә шул бит очындагы ике сипкелең өчен яратам», диган иде. Әлбәттә, шаяртып, мыскыл итеп әйтүе булгандыр. Шулай икән, нигә мыскылга урын калдырырга? «Гөлҗиһан» сабыны белән юынып, нигә төбе-тамыры белән юк итмәскә ул «ике сипкел»не!

Аннары тагы, адәм әйтеп ышанмас, килде бер вакыт, үзенең егерме биш ел торган, балалар үстергән өендә төннәрен ялгыз калырга курка башлады Гыйльмениса. Кемдер килер дә, тәрәзә чиертеп тә тормыйча, турыдан-туры ишекне каерып, өйгә килеп керер кебек. Өйнең авыл читендә булуы аның соңга калып кузгалган бу балаларча шүрләвен тагын да куерта төшәргә бер сәбәп иде.

Болары шулай. Ләкин айнык акылы белән карап, боларына ул игътибар да итмәгән кебек күренергә тырыша иде: кемнең аңарга йомышы төшсен, кем килеп керсен аның ялгызлыктан җир астына чумарга торган бәләкәй өенә? Ләкин тора-бара игътибар итмичә кала алмаслык бер фактны күрә башлады Гыйльмениса: Хафиз үзе совет йомышлары белән чапканда өйдә ялгыз калган малайлары көннән-көн чыгырларыннан чыга баралар. Я бөтен күрше-тирә малайларын җыелып, өйне урыныннан күчерердәй булып котырыналар, я, бөтен нәрсәне ачык һәм аяк астында калдырып, үзләре каядыр чыгып олагалар иде.

Шуларның барысын да искә алып, аларыннан да бигрәк, инде моннан да ары Хафизны төштә күрү белән генә чыдап тора алмастай хәлгә җитеп, ниһаять, артык тыеп калып булмастай хатынлык инстинкты белән һәм бу юлы инде беркем сүзеннән дә курыкмыйча, туп-туры

Хафизның үзенә — Совет йортына килде Гыйльмениса. Килгәндә бик өзеп әйтердәй булып, батыраеп килде ул. Хәтта әйтәчәк сүзләрен дә күңеленнән ясап, әзерләп килгән иде. Мәсәлән, менә болайрак башламакчы иде ул сүзне:

— Хәтерендәме, Хафиз? — дип башламакчы иде чама белән һәм, әлбәттә, бу сүзнең икесе өчен дә көтелгән сүз, кире кагылмаячак сүз булырына ышанган иде,— син бер вакытны миңа әйткән иең, ике ояны бер итү турында сүз кузгаткан иең. Ихлас булган булса шул сүзең, менә килдем мин, каршыңа үзем килдем, ал мине үзеңә хатын итеп. Үземнекеләрне очырып бетердем, инде синең балаларыңа ана буласым килә! — димәкче иде. Ләкин килеп җитеп, Совет йортына кергәч, ничектер каушабрак калды. Телен әйләндереп сүзен әйтә алмыйча торды. Яшь кызлар кебек кызарды. Әмма бу оялчанлык, сүзен әйтә алмыйча кызарып-алсуланып торуы аңарга бу минутларда үзенә хас, август ае иртәләрендәге кебек, өлгергән бер матурлык өстәде, сизелер-сизелмәс кенә яшәртеп җибәргәндәй булды. Шул ук вакытта Хафиз да, нинди дә булса сүз башларга ашыкмыйча, сүзсез генә аңарга текәлеп калды.

— Ник килдең дип, ник сорамыйсың, Хафиз? — Беравык тынып торганнан соң, сәер генә итеп шулай сорап куйды Гыйльмениса һәм шул пауза бөтенесен хәл итте булса кирәк. Калганнарын ул артык тотлыгып тормыйча, хәтта арага чак-чак кына уен-көлке дә кыстыргандай итеп әйтте:— Ничегрәк уйлыйсың, Хафиз, синең ул әнисез малайларың башлары белән йөри башладылар түгелме? Син өйдә юк чагында, дим.

— Белгән юк инде, Гыйльмениса малай, артта күзем юк,— дип җавап кайтарды Хафиз, үз нәүбәтендә шулай ук җиңелчә генә шаярткандай итеп. Аннары бик җитди, хәтта үпкәләгән дә кебек итеп өстәде: — Әйткән идем мин сиңа теге вакытта бер сүз, тыңламадың ич...

— Ул вакыт сәгате сукмаган булгандыр, бәлкем...

Гыйльмениса әйтер сүзен әйтеп җиткерер-җиткермәс тагын тукталып калды. Ләкин Хафиз өчен артык сүзнең кирәге юк иде инде. Ул шундук бөтенесен берьюлы төшенеп алды: әйе, хәзер менә вәгъдә сәгате суккан, хәзер менә ул, колакка керерлек бүтән бер йомышы да юк килеш, әлбәттә, аның янына тикмәгә генә килмәгән...

Монда, ихтимал, бүтән сүзләр дә, үзара шартлар куешу-фәлән дә булмыйча калмагандыр. Ләкин безнең өчен дә, аларның үзләре өчен дә иң әһәмиятлесе алары түгел, иң әһәмиятлесе шул булды: алар шул көннән башлап, ЗАГСта язылышып, бергә тора башладылар: утыз елдан соң беренче мәхәббәте яңадан әйләнеп кайтып, Хафизга хатын, аның әнисез калган малайларына әни булды Гыйльмениса.

## XII

Хафизның элекке хатыныннан калган Толя белән Мишага йомшак күңелле ана булу өстенә, югарыда бер әйткәнебезчә, Гыйльменисага яшьлеге яңадан әйләнеп кайтты: илле яшькә җиткән, кызларын кияүгә биргән олы яшьтәге хатын, кеше көләр, гайбәт азыгы булырмын дип куркып тормады — күрәсең, андый фани исәпләрдән өстен торган көч — табигать көче, яшәргә, үрчергә тырышу көче сакланып калган булган аңарда — Хафиз белән кушылып тора башлагач, берсе артыннан ук икенчесен, тагын ике кыз бала тапты. Һәм аларын да үстерде. Җиткән вакыты булгандыр, җитмәгән чагы туры килгәндер, берсен дә кешегә чыгармады, юк-бар зарлану белән Хафизны эшеннән бүлмәде... дип үк әйтсәк, чынлыкны чак кына бозу булып чыгар. Шулай да булды аның Хафизга бәйләнеп йөргән берничә вакыты...

Егерме тугызынчы елның азакларында тынгы белмәс Хафиз җиң сызганып колхоз төзү эшенә керешеп китте. Болай да кызу канлы кеше, дингез сугышлары да күргән, бу яңа һәм шау-шулы хәрәкәт аның җа-

нын кузгатып ничектер яшәртеп, усаллландырып җибәргәндәй итте. Авыл советы эшен бүтән берәүгә калдырып, мәрәк Хафизның башы-аягы белән шул тынычсыз эшкә чумды. Усалланырга сәбәпләре дә бар, авылда бу яңа эшкә каршы килүчеләр, астыртын аяк чалучылар да юк түгел иде. Шундыйларның берсе Хафизның бабасы Әлмөхәммәт кулак булды. Кайтып, кызына кияү булып, кан катышуга да карамастан, Хафизның Әлмөхәммәтләр бусагасын атлап кергәне юк иде, ә менә колхоз файдасына тегенең сбруйлары белән ике атын, урак машинасын һәм сабан-тырмаларын алып чыкканда, аннары тагын, карт белән карчыкны иске аш өендә калдырып, зур яңа өйләрен авыл уртасына колхоз идарәсе итеп күчергәндә, алар беренче тапкыр йөзгә-йөз туры килмичә кала алмадылар.

— Бик очынма, кияү, чабып барганда йөзтүбән капланып төшеп, борыныңны канатудан саклан,— диде карт, якын итеп, алдан кисәтеп кую тоны белән.

— Безнең өчен борчылма, кайнатай, без канны күргән кешеләр,— дип җавап кайтарды Хафиз, артык ачусыз гына. Аннары, үз чиратында бусы да картны кисәткәндәй, тавышын тигез генә тотып өстәде.— Иске өендә, үз нигезендә түгелмичә-чәчелмичә утырып калуыңа рәхмәт әйт. Югыйсә, синең ишеләрне, салкын вагонга төяп, Себер якларына озатырга да күп алмыйлар хәзер.

Бу очрашу да, әлбәттә, җиңел узмаган иде Хафиз өчен — ни генә димә, хатынының атасы бит ул Әлмөхәммәт. Ләкин моннан да авыррагы әле алда булган икән. Бу шау-шулы эшләрнең барысын да күреп-белеп торган һәм ул эшләрдә иренең атаманнардан берсе булып йөрүен, хәвефләнү аралаш, эчке ризасызлык белән күзәтеп йөргән Гыйльмениса, бигрәк тә Хафизының этисе Әлмөхәммәткә каты бәрелүен ишеткәч, берничә көн бөтенләй телсез калып, нәрсә әйтергә, ничек сүз башларга белмичә, авызын турсайтып йөрде. Моңарчы чукердәшеп яшәгән ир белән хатын арасында кинәт мондый тартынкы сүзсезлек урнашып калуы аларның үзләре өчен дә читен, моны бигрәк тә балалар, аеруча үсмер егет булып килә торган Толя сизә иде.

— Нәрсә булган ул безнең этигә? — дип сорау бирде ул бер көнне тора торгач,— ашый да торып чыгып китә, ашый да торып чыгып китә. Килгән кеше кебек.

Тавышыннан, серле итеп әйтүеннән үк сизелеп тора: ул моны этисеннән дә бигрәк, әнисе өчен борчылып әйтә иде, югыйсә. Ләкин Гыйльмениса аны-моны сиздермәде, берни дә булмаган кебек:

— Мәшәкатьләре күп бит аның хәзер. Күрмисеңмени, нинди зур эшләр купты авылда,— дип, кыска гына җавап бирү белән бетерде. Ләкин үз күңелендәгесе шулай да бетеп үк җитмәгән икән, бер кичне — балаларның йоклардае йоклагач, олысы чыгып киткәч, ялгыз икәве генә калгач, ир белән хатын арасында башка, җылырак, ягымлырак сүз әйтелер бер вакытта, үпкә һәм рәнҗү тулган тонык бер тавыш белән әйтте Гыйльмениса:

— Китереп житкерделәр: минем эти белән әнине, себер җибәрмичә, өсләренә җимерелергә торган иске өйләрендә алып калуың өчен, алардан рәхмәт ишетергә теләгәнсең икән, Хафиз,— Гыйльменисаның тавышы калтыранып куйды, сиздерергә тырышмаса да әллә кайдан сизелеп тора, елап әйтә иде ул бу сүзләрне,— шулай инде ул безнең эти, гомергомергә каты бәгырьле булды. Аның өчен менә мин әйтәм: рәхмәт инде, Хафиз, бик зурладың син хатыныңның этисе белән әнисен... картайган көннәрендә мунчага ябып куеп...

— Ник мунча булсын, үзләренең гомер иткән өйләре ич,— диде Хафиз, бүтәнчә ни әйтергә дә белмичә. Ул үзе дә, әлбәттә, сизде: бу — әлеге минутта әйтелә торган сүз түгел, ул моны әйтергә теләмәгән иде. Гыйльменисаның моны хәтта ишетмичә дә калганлыгын, аның бик нык

рәнҗегәнлеген ул шулай ук сизеп тора иде. Ләкин нишләтсен соң ул үзен, башка сүз килмәде ич тел очына.

Байлык белән түгел, татулык һәм мәшәкать белән тулы, ләкин асылда кеше белми, кешегә әйтеп тә булмый торган бәхетле гаилә тормышы өстеннән, яумый узган болыт кебек, салкынча җилле беренче күләгә, беренчесе һәм соңгысы, әнә шулай узып китте.

Икенчесе дә булды. Ләкин анысы болай күңелне рәнҗетеп түгел, әллә ничек, бер дә көтмәгәнчә, бераз җиңелчәрәк, хәтта шуграк та булып, бу ике кешенең характерын якынтын белмәгән кешеләр өчен чак кына көлкерәк тә күренгәндәй, җәйге тын җилдәй битләрне сыйпап узды. Турысын гына әйткәндә, әле дә рәхәтләндереп сыйпап тора.

Шул ук җилле-давыллы вакыйгалар әле басылып та бетмәгән иде, әле авыл кешеләренең өчтән бер өлеше диярлек, «керсәм ничек тә, кермәсәм ничек?» дип бүрекләре белән киңәш итеп туктамаган көннәрдә, шулай да кергән хәтлеләре, Хафиз председатель житәкчелегендә, мәш килеп беренче уңышны җыеп маташканда, уттай эш өстендә, ире Хафизның төн йокламыйча чапканын күреп, аңарга ничек тә булышасы, эшен җиңеләйтәсе килгән Гыйльмениса — кирәк бит, беркем әйтмичә, шуны уйлап чыгарырга! — көннәрдән бер көнне Хафизы алдына мәсьәлә китереп куйды.

— Кара әле, Хафиз,— дип башлады ул, бик тә җитди кыяфәт белән,— уракка кешем житми дип сукранасың, балалы хатыннарны эшкә чыгарып булмый, дисең. Әгәр без, әйтик, болай итсәк? Бушаган йортларның берсен ачабыз да көндезге эш вакытында балаларның бөтенесен шунда җыеп апкалабыз. Безнең Сәкинә белән Сәлимә дә шунда ук булыр. Үзем карыйм, икмәген-итен колхоз бирсә, сөтен шунда тәрбияләнүче балаларның ата-аналарыннан чиратлашып китертербез,— ул үзенең бу сүзләреннән, аларны алай җиңел генә әйтә алуыннан үзе дә бер мәл аптырабрак калган кебек күренә иде,— юк-бар сылтауга урын калмас ие, колхоз эшенә күбрәк чыгарлар ие, дигән сүзем инде.

— Ә колхоз председателе үз хатынын күләгәдә генә тота, димәсләрме соң? — дигән булды Хафиз, сүзне чынга алырга теләмәгәндәй күренергә тырышып. Күңеленнән исә ул моны хуплый гына түгел, бу фикернең моңарчы үз башына килмәве, аны нәкъ менә аның Гыйльменисасы уйлап тапканы өчен гаҗәпләнеп бетә алмый торды.

Әлбәттә, ансат кына әйләнеп китмәде. Төрле сүзләр, гайбәтләр таратырга сәбәп булып, баштарак балаларны авырлык белән генә, ялыныпялварып кына китереп булса да, шулай да Гыйльмениса кузгаткан идея үз юлын тапты, «Якты көн» колхозында беренче балалар бакчасына әнә шулай нигез салынды һәм ул көннәрдә кулаклардан калган йортның берсендә, кирәкле әсбаплары, савыт-сабасы һәм уенчыклары житкерелмәгән килеш, ничек кирәк алай ачылып киткән ул бакча, соңыннан киңәеп, махсус йорты, мәйданчыклары ясалып, хәзерге көнгә кадәр дәвам итә, диделәр.

Ә менә Гыйльменисаның олы яшьтә яңадан әйләнеп кайткан бәхете — тынгысыз йөрәкле Хафизы, кызганычка каршы, дәвам итә алмаган, ул башлаган эшне хәзер башкалар — яшьрәкләр дәвам итәләр. Хафизны, данлыклы көрәшче Хафизны, шул шау-шулы елларда, кайдандыр киңәшмәдән кайтышлый, ике авыл арасындагы чокырда, башына капчык кидереп, арба кендеге белән кыйнап, үтереп киткәннәр инде.

Шулай итеп, безнең Гыйльменисабыз картайган көнендә, инде инде куеп, бергәләп атлар кешеңнең — жан дустының кирәклеге аеручанык сиздергән бер вакытта, бу юлы инде дүрт баланы кул астына җыеп, тагын ялгыз кала.

Бик-бик авыр кичерә бу югалтуны Гыйльмениса. «Хафизым кайда? Хафизымны табып китерегез!» дип, дөньяга кычкырасы килгән минутлары була. Үзен, картайгач дөньяга килгән балаларын бәхетсезлектә

гаепли. Соңгы вакытларда ничектер оныткан, инде хәтереннән үк чыгарган Барыен кабаттан исенә төшерә, «Бактың исә, бу әле шуның каргышыдыр... Бик бирелеп киттең син, Гыйльмениса, дөньясына», дип үзен-үзе тирги, аннары, курка-курка булса да, аны — Гыйльменисаны — гел болай түбәләп торучы алласын каһәрли башлый.

Шулай өзгәләнә Гыйльмениса, йөрәге пәрә-пәрә килеп теткәләнеп беткәндәй була. Шулай уза көннәр, шулай уза атналар, шулай уза айлар, атасыз калган балалар әкренләп калка, була елаган вакытлары, була жырлаган чаклары, бөтенесе Гыйльменисаның колагында, бөтенесе Гыйльменисаның күз алдында һәм тормыш яратучы, кешеләр яратучы, мәшәкать яратучы таза рухлы Гыйльмениса, пәрә-пәрә килгән шул тетмәләр арасыннан яңадан терелеп чыга, башын калкыта, күзләрен ача алган хәтле киңрәк ачып, дөньяга карый...

Аннары соңгы вакытларга чаклы Гыйльмениса җәйге кыр эшләре чорында станнарда — тракторчыларга, куна-төнә эшләүче колхозчыларга аш-су пешерүче булып эшли. Балалары укып, кайсы кая таралыша, һәрберсе үз эшендә белгеч булып эшли, алардан, акчалата булсын, кирәген-кирәк түгелен белер-белмәс тутырылган әйбер посылкасы булсын, әледән-әле килгәләп тора. Иң кечесе — үзе янында калган Сәлимәсе колхозда сыер савучы булып эшли. Начар эшләүчеләрдән түгел, елның елына бәйрәме саен, эшкә йомгак ясалган саен бүләкләп торалар кызны. Ә колхозда, үзегез беләсездер, андый «йомгаклар» әледән-әле ясалып кына тора. Язгы кыр эшләре бетә — бер йомгак. Җәйге кыр эшләрен тәгәлләләр, дәүләткә сатасын саталар, колхозчыларга бирәсен бирәләр, инде нәрсә эшләргә? Тагын йомгак ясарга. Ел бетә, үзеннән-үзе аңлашыла, еллык эшкә йомгак ясарга кирәкме? Кирәк. Шулай итеп, Сәлимәсе бер яктан, Гыйльмениса үзе икенче яктан, «йомгак» саен ташып кына торалар бүләкне. Инде аңарга: «Гыйльменисаттәй, булды сиңа, эшлисен эшләдең, инде, давай, пора на боковую!» диләр. Хәйләкәр хәзерге яшьләр, карчык кеше аңламас бу сүзне, аш-суны бик тәмле пешерә, селкенәсе килә икән, әйдә, яшьләргә акыл өйрәтеп булса да селкенә бирсен, дигән булуларыдыр инде үзләренчә. Картуздан күчеп түбәтәй астына кергән, соңыннан янә картуз астына күчкән ике малай үстереп кеше иткән кеше Гыйльмениса, кирәк икән, моннан шәбрәкләрен, татарчадан русчага, кирәк икән, русчадан татарчага әйләндереп салырга әзер.

— Китми торсын әле «на боковую»,— ди ул, кинәт кабынып,— менә бер дә бер көнне аягымны бөтенләйгә сузармын, «боковуегыз»га да куеп тормассыз, берьюлы каберга илтеп тыгарсыз, ә хәзергә тәндә җан бар чакта дигәндәй...

Тик кышын гына бераз баш-күз алып торалар карчыктан. Кышын тракторчыларга аш пешерергә кирәк түгел, кышын әле бер кызына, аннан икенчесенә, аннары малайларына кунакка йөри карчык. Хәер, анысы да бераз кызыграк, әллә ничегрәк. Гыйльменисачарак килеп чыга. «Бер ай торып кайтырмын, туйдым бу он иләүдән дә ипи салудан», дип китә, атна да узмый, Сәлимәсе егет белән йөреп, ирек ачып калырга тик исәп итеп кенә өлгерә, тың итеп кайтып төшә карчык. Кайтып төшә һәм шундук боргычлап ала кызны. Шуның өстенә, җәйгә каршырак туры килсә, боргычлап ала колхоз председателен.

— Сез монда авыз ачып утырмагыз,— ди ул, идарә йортына махсус шуның өчен килеп,— язга-җәйгә әзерләк сабан-тырмаларны көйләп кую белән генә бетми ул, фермагызда, һич югы, ике-өч сарыкны, аерым ашатып, симертеп куегыз. Гыйльменисаттәйнең ашы тәмле була, дигәч тә, теге ни... Гыйльменисаттәегез ашка бармагын турап салмас. Аш тәмле була ул тәмле ит салсаң, ит тәмле була — малы гәүле булса. Ашатсаң, икенче төрле әйткәндә...

Менә бу чаклысында, бөтенесен тик иткә генә аударып, бераз кызыбрак китә Гыйльмениса. Аш тәмле булсын өчен ул, шул әлеге тәмле ит өстенә тагын, борычын, укробын өйдән алып барып сала. Өйдә андый бәрәкәте саега башласа, кызларына яки малайларына — бер салганда берсенә, икенче юлы икенчесенә — хат яза.

Әле бер көнне этисе урынына Севастопольгә китеп эшкә кергән малае Мишадан татар сүзләрен рус сүзләре белән аралаштырып бутап бетергән, шулай да Гыйльмениса тәтән сүзлексез «сукаларлык» хаты, аннары кулдан тарта торган тегермәне белән унлап пачка борчаклы борыч төрелгән посылкасы килде. «Мин синең борыч яратканыңны беләм, кадерле әнкәем, в данный момент тартылган әзер борыч порошогы таба алмадым, кулыңа физкультура булсын дисәң үзең тартырсың, үземә көч килер дисәң, колхозда көчләрен кая куярга белмәүче пацандубинкалар бетәсе түгел, шулардан берәрсен чакырып тарттырырсың. Барыбер колхоз файдасына китәчәк борыч икәнлеген алдан ук белеп торам мин анын», дип, теленә салынып язган иде хатын. Иң элек утырып елады Гыйльмениса, аннары, тегермәнен бер култыгына, борыч пачкалары төрелгән посылканы икенче култыгына кыстырып, күршеләренең әле берсенә, әле икенчесенә керә-керә: «Менә Миша улымнан килгән. Әкәмәт ана җанлы булып чыкты анысы да, бер дә башына килмәгән, җибәрмәгән әйбере юк», дип мактанып йөрде.

* * *

Менә шул кешенең — зур авырлыклар белән берсеннән-берсе уңганрак бер көтү балалар үстереп, үзе җитмеш яшендә дә бала җанлы булып калган Гыйльмениса Рахманованың бөтен тирә-як колхозларны шаулатып үткәрелгән юбилеена туры килдем мин. Мине башта бераз гаҗәпкә калдырган бердәнбер кызыл флажок аның өе өстендә җилфердн иде. Дөресен генә әйткәндә, сугыш арты авырлыкларын көчкә-көчкә генә сөйрәп баручы бер колхозда тора торгач болай бәйрәм ясап уйнаулары мине башта яхшы ук гаҗәпкә калдырган иде. Шуңа күрә бу кеше турында бөтен ваклыклары белән язып тутырган блокноттан мин редакция көткән унай «материал»ны, әлбәттә, эшли алмадым. Блокнот минем китапханәмдә, астагы шүрлекләрнең берсендә, башка бик күп кәгазьләр, блокнотлар һәм хатлар арасында аунап ята бирде. Тик еллар узып, керәсе акыл кереп, чыгасы тилелек чыгып беткәч, аннан да бигрәк тирә-юнемдә, байлык белән торып та, бер яки ике баланы рәтләп үстерә алмаучы, яки кияүгә чыгып бер-ике ай тору белән, «характерлары туры килмәгәнлектән», тизрәк әти-әнисе өенә йөгереп кайтучы, ә шулай да әлеге шул кыска гына вакытта башка нәрсәләре туры килеп, соңыннан этисез баласын олы яшьтәге үз әнисенең муенына тагарга, үзе тагын «кыз»га әверелеп чабарга әзер торучы кайбер йөгәнсез яшьләрне күргәли башлагач, мин ул блокнотны яңадан тартып чыгардым. Юк, бик тә гыйбрәтле материал күтәреп кайткан булганмын мин. Дөресен генә әйткәндә, шатлык һәм борчулар белән тулган безнең бу гүзәл җиребез, ышанычлы бүтән күп кенә җилкәләр белән беррәттән, әнә шул Гыйльмениса кебек тырыш аналар җилкәсендә дә тора.

*Июнь, июль, август, 1968 ел*

## Шәйхи Маннур

# ДИҢГЕЗ ДӘФТӘРЕННӘН

### Нинди булыр иде...

Ярга каплый авыр дулкыннарын,
Ачулана диңгез,
Ярсына,
Егетләрнең хәтта кыюларын
Ябыштырмый көмеш ялына.

Ул бирүзә мәйдан тота бүген,
Актарыла,
Дулый сызланып,
Төбендәге бөтен пычрак чүбен
Яр читенә ташлый чыгарып.

Ни генә юк!
Ник соң адәм кулы
Юмарт шулай пычрак түгәргә?
Һич яратмый, ахры, диңгез моны,
Рәнҗи төсле әллә кемнәргә...
Иртәгесен инде ул, сафланып,
Көлә иде кояш нурында.
Кешеләрне,
Бишегенә салып,
Тирби иде иркә дулкында.

Нинди рәхәт диңгез киңлегендә,
Әгәр ул
Гел шулай саф булса?!
Нинди булыр иде
Кеше күңеле дә
Пычранудан
Мәңге сак булса?!.

### Мираж гына...

Диңгезгә мин таңнан төшеп җитәм:
Колач җитмәс тынлык тирбәлә.
Шигырьдәге кебек ялгыз җилкән,—
Син киләсең төсле көймәдә.

Кап урталай ярып тын диңгезне
Кайтып килә ярсу «Метеор».

Көрештерер сыман кинәт безне,
Дулкын кагып ярга туктый ул...

«Ту» гөрелди күкләр диңгезеннән,
Түбәнәя килә мәйданга.
Кул изәрсең төсле тәрәзеннән,
Баш очымнан узып барганда.

Җан ыргылып кала һәркайсына,
Дүрт күз белән карыйм дүрт якка.
Әмма болар
        Бар да мираж гына...
Син юк...
        Син юк...
                Син шул
                        Еракта...

Ник син
Очып кына килеп җитмисең дә,
Кочып кына китеп бармыйсың?..
Ялгыз бит мин.
        Ялгыз...
Ә ялгызның
Моңаймаган көне бармы соң?
Таң-иртәдән ярга төшеп җитәм,
Эльбруска кояш менгәнче.
Синең төсле итеп көлүен көтәм,
Хәер көткән кебек теләнче...

Юк!
Горур мин, горур!
        Мескен түгел!
Ник садака көтим тилмереп?
Тик тыңламый мине
        Түзмәс күңел,
Сагына ул сине тилереп.

Ник син
    Очып кына килмисең дә,
Кочып кына китеп бармыйсың?
Минем өчен,
    Әллә белмисеңме,
Синнән дә зур шатлык бармы соң?

## Яңгыр

Бик һәйбәт бер яңгыр явып узды,
Рәхәтләнеп калды җир өсте.
Буыннарын бодай буйга сузды,
Чәчәк белән чәчәк күреште.

Кайчагында шундый сусый күңел,
Шундый кирәк
        Күңел яңгыры.
Гөлләр яшәртерлек күп тә түгел,
Тик бер генә тамчы тамгыры!

Юк шул, булмый.
Булмый көткән өмет,
Яңгыр дисәң — сиңа боз ява.
Куырыла жаның яфрак кебек,
Йөрәгеңә кара кан сава...

Ә бит язын яңгыр көтә күңел,
Шундый кирәк күңел яңгыры.
Гөлләр яшәртерлек күп тә түгел,
Тик бер генә тамчы тамгыры,
Тик бер генә тамчы...

## Бере җирдә, бере күктә

Йөри бер кыз бала ап-ак керләр элеп,
Бер югала
Ак җәймәләр арасына кереп,
Бер күренә тагын шул ара...

Карый кояш аңа күктән көлеп,
Бер югала
Ак болытлар арасына кереп,
Бер яңадан көлә ул аңа...

Бере күктә,
Бере җирдә торып,
Уйный мәллә болар качышлы?
Мин сокланып калдым,
Гашыйк булып,
Кыз янынннан узып барышлы.

Икесе дә шундый гүзәл инде,
Икесе дә алар бер төсле.
Икесен дә үзем сөяр идем,
Күңелдәге изге бер хисне
Икесенә тигез бүлеп...

## Кыен уен

Яхшылардан булмасам да үзем,
Яратам мин яхшы кешене.
Әйбәт эшен күргәч,
Балкый йөзем.
Әйтер сүзем:
— Рәхмәт төшкере!

Миңа йога аның кыюлыгы,
Мин дә телим шундый булырга: —
Күтәрергә бөтен кыюлыкны
Яхшылыкның изге юлында!

Шулай уйлау
бик тә рәхәт була,
Күңелем дә чиксез нечкәрә,
Күзләремә хәтта яшьләр тула,
Ә күкрәктән гайрәт,
көч бәрә!

Тик тотынсам шул көч белән эшкә,
Бөтенесе китә кирегә:
Яхшылык дип эшләп маташканым...
Әшәкелек булып күренә.

Гаҗәп итәм:
Нигә бу яхшылык —
Телдә җинел,
эштә бик кыен?
Әллә шуңа микән,
байтакларга
Сүздә генә ошый бу «уен»...

## Хатын-кыз иптәшләргә

Үзәгемә күпме үттегез сез,
Үкенүләр күпме,
әрнүләр...
Сөйли китсәң...
Бер дә үз түгел сез,
Тик түзгәнмен инде мин җүләр.

Иләштегез башта юаш кына,
Юаттыгыз моңсу чагымда.
Мин ышанып гашыйк булгач кына,
Тераттегез кәкре каенга!

Әйләнеп тә бер карамам! диеп,
Антлар эчкән сүзем —
йөрәктә.
Күпме йөрдем башны җиргә иеп,
Берегезне дә бер күрмәскә,
Берегезгә дә бер көлмәскә
Теләп...

Ләкин булмый...
Без шул чарасызлар,
Җитми төсле кояш яктысы.
Чөнки сез бит,
Иптәш хатын-кызлар,
Бу дөньяның олы яртысы!

Ничек итеп инде кешелектән
Ярты ягын читкә кагасың?
Күзегезгә качкан сихрилектән
Алдавыннан мәхрүм каласың?
Шул күзләрдә булган эсселектән
Утыннан тыш ничек янасың?
Ничек итеп яши аласың?..

Юк, яратам сезне
Күкрәгемә кысып,
Кыз һәм кояш итеп яратам!
Плюс-минусларыгызны
Бергә кушып,
Дус һәм юлдаш итеп яратам!

## Ялгыз учак

Яр буенда ялгыз учак
Әкрен генә яна-яна,
Тәмам сүнеп бетә бер чак,—
Актык күмер генә кала,
Актык күмер генә...

Кайтып килә шул чагында
Балыкчы карт төнге аудан.
Ярка салып учагына
Ут тергезә ул яңадан,
Ут тергезә.

Балыкчы карт тагын шулай
Диңгезенә китеп бара.
Аның күңеле хыялга бай:
Зур балыклар кабар аңа,
Зур балыклар!..

Мин дә нәкъ шул ялгыз учак:
Кала фәкать актык күмер...
Юри генә килеп шул чак,
Чыбык-чабык ташлый кемдер,
Чыбык-чабык...

Тагын көйрәп киткән булам,
Хәтта дөрләп куям берчак.
Ләкин тагын бетә янып,
Барлы-юклы чыбык-чабык...
Тагын сүнә
Әкрен генә
Яр буенда ялгыз учак,
Ялгыз учак...

## Дулкыннар җыры

Дулкыннарның кичке җырын тыңлап,
Яр буенда ялгыз утырам.
Әйләнәмдә барлык дөнья тынган
Һәм кояш та күктә юк сыман...

«Күктүбә»ләр өсте күксел сөрем,
«Карадаг»та коңгырт болытлар.
«Чатырдаг»та миңа
Ачмый серен,
Ник бу яклар шундый боеклар?..

Ак дулкыннар
Яр буйлатып чаба —
Йөгерек тайлар кырдан кайтканмы?
Кемне эзләп алар тояк кага?
Ник ачмыйсың, хуҗа,
Капканны?..

Ул күренми...
Шәһәрләре калган,
Авыллары,
Батырына куйган һәйкәле,
Исем биргән таулар һәм сулары —
«Туган илем!» диеп әйткәне...

Кая киткән соң ул,
Кая киткән?
Бар табигать моңга уралган:
Күп йөз еллар бергә гомер иткән
Дусты аның
Кая югалган?..

## Котлау шигыре

Бәйрәм табынында
Синең янында
Була алмасам да үзем,
Иң изге теләкләр белән
Котлау сүзем
Яз кошыдай барып житсен.
Ярларында үзең йөргән
Монсу диңгез жырын
Сиңа бүләк итсен.

Открыткам арт ягында
Ялкын чәчәк:
Шул чәчәктәй ялкынланып яшә,
Балкып янып яшә,
Матурланып яшә,
Куырмасын хисләреңне
Тормыштагы зәһәр рәшә.

Күңелеңдә язгы гөрләвекләр
Тулып аксын,
Бар кайгыңны, хәсрәтеңне
Юып атсын.
Гөлчәчәктәй ялкынланып яшә,
Матурланып яшә.

## Шаян кояш

*Нәниләр җыры*

Көн буе эссе койгач,
Күкләрдә гизеп туйгач,
Инде тәмам кич булгач,
Алтын сукмагын салып
Диңгезгә төшә кояш.

Ул да тели су керергә,
Күк читеннән сикерергә.
Колач ташлап йөзәргә дә
Ак болытка сөртенергә.

Юк, сөртенми,
Йөзә һаман
Ерак-еракларга табан.
Йөзеп тәмам кызара да,
Соңгы тапкыр елмая да,
Көнбатыштан төпкә чума.
Төн буена чумып йөреп,
Иртәгесен тагын көлеп,
Көнчыгыштан килеп чыга!

Чыга да нурда уйный,
Алтын сукмагы буйлап
Тагын күккә менә ул,
Көн буена көлә ул.

●

Табигатькә һаман тарта күңел:
Яланнарга,
Сулар буена.
Вак хаҗәтләр
Берсе кирәк түгел,
Тик саф теләк тула уема.

Кочагыма жыеп язлар жилен,
Күзне текәп күкләр очына,
Жыр әйтәсем килә
Аңа минем,
Йөрәгемне салып учына.

Белүе дә кирәк түгел аның,
Күрмәсен дә иде бер читтән,
Тик бушанып калсын иде жаным,
Хыялый жан өчен шул житкән.

●

Уйлап-уйлап
Уйлар тыелмаса,
Һаман йөрим
Янып,
Борчылып:
«Жыр оянда чыпчык чыелдаса,
Буламыни лачын очырып?..»

Бар гомерен буе казганасын,
Баш очында һаман шул кылыч:
«Бушка алданасың!
Чүп язасың!..»
Нинди куркыныч!
Әй син... бул тыныч?..

Ничек белим болай түгеллеген?..
Юатмасмы килеп таң кызы?
Ник борчыла һаман күңел минем
Диңгез җырын тыңлап ялгызы...

## Фаил Шәфигуллин

### Мәңгелек ут

Аяз көнне ул бер гади чәчәк,
Җәлеп итми кебек һичкемне.
Дошманыннан соңгы үчен алып,
Ярсулары бетеп, тынычланып,
Сүнеп барган йөрәк шикелле.
Давылларда кинәт дөрләп китә,
Яраланган коштай талпына.
Байрак сыман горур җилферди ул,
Киң мәйданны гүя тарсына...
Факел тотып бирәү чаба кебек
(Ялкын яллы аты — канлы күбек)
Киләчәккә, еллар каршына.
«Уяу булыгыз, кешеләр!» дигән сүзләр
Уелып кала мәйдан ташына.

●

Төнге күктән атылып төште яшен,
Төренеп җәйге җылы яңгырга.
Офыкларны инләп тамырланды,
Теләп җиргә берегеп калырга.

Яндырды ул зифа наратларны,
Сылу каеннарны яндырды:
«Тик мин генә яшим,— диде җирдә,
Мин бит,— диде,— ялкын тамырлы».

Күк күкрәтеп көлде горур яшен
Җир күкрәгең телеп узганда.
Тик тапмады җирдә яшәр мәйдан,
Каберен генә тапты ул анда.

Илемә дә утлы кылыч тотып
Нинди генә яулар килмәде.
Бирсә бирде кабер ил аларга,
Тик яшәргә мәйдан бирмәде.

### Кызык хәл

Һәрбер якның була юләре,
Бездә дә бар иде бер юләр.
Үлгәч тә бит алар хакында
Кызык хәлләр сөйләп йөриләр.

Бер вакытны, әйтсәк бабайча,
Муены гына астына килгере —
Акбай атлы безнең ана эт
Алты йомры бала китерде.

Әниләрен имгәч аунатып —
Көчекләрнең бәхет түгәрәк.
Алтысы да мамык туп кебек,
Алтысы да үсә тәгәрәп.

Без, малайлар, карап шуларга
Онытабыз хәтта ачлыкны.
Кырыс бабай гына шатлыктан
Аерырга безне ашыкты.

Каш астыннан йөртеп күзләрен:
«Үсә,— диде,— артык тамаклар.
Башларына житәр боларның,
Чакырып килсәк, юләр Шәйгаттар».

Килде юләр, и ач, и ябык,
Ничек кенә тора монда жан.
Әшәке эш булса шуңа куш,
Үзеңне дә суяр ашатсаң.

Бер кулында балта ялтырый,
Бер кулында елый көчекләр.
Бабай әйтте: «Бар, бар бакчага,
Анда аулак, анда кычыткан».

Озак тормый юләр күренде
Кулына тотып ялтыр балтасын.
«Суйдым,— диде,— кызыл кан акты,
Алты жиргә күмдем алтысын...»

Бабай күкәй бирде: «Аша»,— дип,
Тик Шәйгаттар никтер алмады.
Башын иеп, тешләп иренен,
Капкага таба атлады.

Базны ачкач Акбай ук кебек
Атылып чыгып чапты бакчага.
Кинәт абый сөенеп кычкырды:
«Карасана, бабай, баксана!..»

Ул күрсәткән якка карасак,
Мунча сукмагында кызык хәл:
Әниләрен узып, пыр тузып;
Йөгерешәләр безнең көчекләр.

Без көләбез тотып эчләрне,
Бабай көлә, көлә түзәлми.
Алтысы да исән икән ич,
Юләр димә икән юләрне!

Һәрбер якның була юләре,
Бездә дә бар иде бер юләр.
Үлгәч тә бит алар хакында
Кызык хәлләр сөйләп йөриләр...

## Диңгез

*Еврейчадан*

Бер бит шигырем суга төште минем
Йөргән чакта диңгез яры буйлап.
Зәңгәр язуларны юып алгач,
Зәңгәрләнде диңгез гүя ныграк.

Түзалмадым, дәштем диңгезгә мин,
Хәсрәтләнеп, телгәләнеп бәгырем:
«Нигә соң ул бөек тирәнлеккә,
Нигә соң ул? Бир, кире бир шигырем!»

Чайкалды да әкияттәге сыман
Төсен бозды зәңгәр киңлек менә:
«Мин музыка язам,— диде диңгез,—
Юләр малай, синең сүзләреңә!»

## Эш коткара

Нишләр идем эш булмаса,
Эч пошканда?
Салкын сүздән жаным тунса,
Эш коткара.

Рәнжетелгәч бер хаксызга
Йөрәк яна.
Әйләнми ул ләкин көлгә:
Эш коткара.

Гел сызласа күңелдәге
Әрсез яра —
Тешем кысып эшкә тотынам:
Эш коткара.

## Идрис Туктар

# Әйтемнәр

Үз-үзеңне тәрбияләүдән дә зур тәрбия юк.

Гайбәт кирәкми, әйбәт кирәк.

Деталь әсәрне үстерә дә, үтерә дә.

Язучы зур яки кечкенә талантлы була алган шикелле, укучы да зур яки кечкенә талантлы була ала.

Кайберәүләр тузланган саен тузсызланалар.

Иң зур белем — белмәгәнеңне белергә тырышуда.

Оптимист — пессимистлыгын яшерә белгән кеше.

Сәләмә тәндә — сәләмә акыл.

Түе узган, туны тузган — карт түгел, гомерен бозган, күңеле тузган — карт.

Яшьлегеңнең кадерен саклау — бөтен гомереңне аклау.

Яратулары мактаулы — кавышулары катлаулы.

Сүзең көмеш, эшең алтын булсын.

Тәмәкеңне дә ташлый алмагач, какуй син пенсионер?!

Әрәмтамакка буш табак та әрәм.

Кеше — эшләре, ат — тешләре, солдат — батырлыгы, чәчәк — матурлыгы белән мактала.

Ул аерылышу өчен генә кавыша иде.

Егет була алмаган — ир була алмас, ир була алмаган — кеше була алмас.

Син премия эзләмә, премия сине эзләсен.

Анын кимчелекләре шулкадәр күп ки, ул аларның берсен бер хәтта күрә дә белми.

Эчкечене эчертмә, үзе эчкәне дә җиткән.

Юләрлеген аңлаганның юләрлеге кими.

Иске ярны ташладым дип, яңа ярга ташланма; яңа ярым ташлады дип, биек ярдан ташланма.

Кул кулны юа да, пычрата да.

Теләсә нәрсә турында теләсә ничек язып булмый.

Юләрлеген яшерергә теләгән дә юләр, зур акылын күрсәтергә ашыккан да юләр.


Балаңны дошман күрсәң, син аңа акча бир.

Әсәр никадәр кыска язылса, гонорар шулкадәр мул, никадәр озын язылса, шулкадәр аз бирелсә — һәркем кыска язар иде.

◆ ◇ ◆

Габдрахман Әпсәләмов

# БЕЗ ҺӘРВАКЫТ ЛЕНИН БЕЛӘН



Мин бөек юлбашчы турында истәлекләр язарга дип тырышмадым, истәлекләр яза алмыйм, чөнки Владимир Ильич Ленинны бер тапкыр да, ерактан гына булса да, күрмәдем, шулай ук аңа багышланган материаллар өстендә эшләүче дә түгелмен. Әмма Владимир Ильич үзенең гүзәл идеяләре, югары кешелек сыйфатлары белән совет халкы тормышына шул хәтле тирән кергән, ул безнең кайнар сулышыбыз булып әверелгән, без аңардан башка бер генә минут та яшәмибез, яшәешне аңардан башка күз алдына да китермибез. Кешелеккә алга барыр өчен нәкъ ленинизм кирәк. Шуңа күрә бу язмаларымда миллионнарның менә шул уй-тойгыларын бирергә тырыштым.

## Без—яшь ленинчылар

Дөньяда бик бәхетле буын кешеләре бар: алар даһи юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинны күреп кенә калмаганнар, бәлки аның ялкынлы сүзен тыңлаганнар, аның кул астында подпольеда, Октябрь көннәрендә һәм Совет властеның беренче елларында эшләгәннәр. Без аларны Ленин гвардиясе дип атыйбыз һәм аларга сокланып карыйбыз.

Без бала чактан ук шул батырлар йогынтысында тәрбияләндек, алардан көч һәм үрнәк алдык. Ленин әйткәннәр безгә закон иде.

Еллар үтә барган саен, бигрәк тә Бөек Ватан сугышында — иске дөнья белән яңа дөньяның иң зур кораллы бәрелешендә — Совет иле гитлер ордаларын җиңеп чыккач, 1917 елда нинди бөек социалистик ил туганлыгын, көч җыеп мәйданга басканлыгын дошманнар да аңладылар. Бөтен дөньяның яхшы теләкле кешеләре бар ышаныч белән Ленин гвардиясенә — Коммунистлар партиясенә текәлделәр, чөнки бары тик ул гына мәсьәләгә ачыклык кертә, аңлата, төшендерә ала. Бары тик Ленин нуры яктысында гына совет кешеләренең дә, совет иленең дә чын асылы һәркемгә ачык булып күз алдына килеп баса. Шуңа күрә, хәтта космоста беренче кеше — совет гражданины дигәч тә кешелек дөньясы гаҗәпләнмәде, киресенчә, шундый тиңдәшсез батырлыкны ул бары тик Ленин иленнән генә көтте.

Тере Ленинны күрергә насыйп булмаса да, язмышка үпкәли алмыйбыз, чөнки без беренче яшь ленинчылар буыны идек. Безне берничек тә

даһи Лениннан аерырга мөмкин түгел, иң хәтәр давылларда да безнең гомер юлында Ленин маяклары балкып торды.

Мин үз-үземне белә башлаганда Ленин бабай исеме — ул чакта без аны бары тик шулай гына атый идек — караңгы бер татар авылына килеп җиткән иде. Карт ялчылар, ярлы крестьяннар Ленин турында күп сөйлиләр, аның рәсеменә озак-озак карап торалар иде. Безгә, балаларга, дөнья түгәрәк әле, революция давыллары да, гражданнар сугышы ялкыннары да, ачлык-патша да безгә бик хәтәр җил-янгыр булып кагылмады, ә «большевиклар» турында халык телендә яхшысы да, яманы да җитәрлек сөйләнде. Тик без, балалар, нинди сүзнең кайдан чыкканын гына, кем нинди максат белән сөйләгәнен генә аермыйбыз. Ә ялчылар, кайчак безнең исне китәреп:

— Анысы, брат, шулай без мулланың яшел тышлы китабын укымаган, туда, сюда белмибез, может Пәрәм большәвниклыкка ярамый торгандыр да, ул бер караңгыдан икенче караңгыга хәтле сука сукалый. Кеше аты белән кешегә сукалый, ә үзенең бер сукыр әни кәбәсен ашатырга даикмәге җитми. Анысы нигә алай? Ленин бабай без мәхлукларга шуны аңлата выты,— дия иде.

Билгеле, без әле дөньяның капма-каршы ике сыйныфка бүленгәнен аңламыйбыз. Безнең тирәдә алпавытлар булмаган, әллә нинди зур байлар да юк, аннары без, ыбыр-чыбыр малайлар, күбрәк үз очыбызны гына беләбез. Ә безнең очта барысы да яңа гына башка чыккан кешеләр.

Ниһаять, мине Мәскәүгә алып бардылар. Билгеле, Мәскәү турында авылда да күп сөйлиләр иде. Ул безгә әкият дөньясы сыман тоела. Чыннан да, әкият дип әйтерлеге бар икән. Мин, авызымны ачып, биек таш пулатларны исем китеп карап йөрим. Малайлардан сораштырасы килә дә, русча ипилек-тозлык та белмим. Авылда барысы да татарча гына сөйлиләр иде, ә монда зур-зур кешеләр дә татарча белмиләр икән. Урамга чыксам, гел ялгыз. Өйгә керсәң, тагын искитмәле. Без чыра яндыра идек, бәйрәмнәрдә генә бишле лампа кабызабыз. Монда утлары керосинсыз яна икән, үзе нинди якты.

Бер вакытны кайгылы хәбәр әйттеләр: Ленин бабай вафат. Бу хәбәр миңа ничектер бик көчле тәэсир итте. Нәрсәдәндер куркып елый башладым, аннары подвал тәрәзәсеннән урамга бик озак карап тордым. Урамда йөрүчеләрнең аяклары гына күренә. Ботинкалы аяклар тротуарга шак-шок басалар һәм бик тиз үтеп китәләр, киез итекле кешеләрнең аяк тавышлары ишетелми. Әни булса мине кызганыр, әкке кичерешләремне аңлар, караңгы төшеп килгән урамга карап торма, дияр иде. Ул юк, ул авылда, ә ирләрнең бала-чагада ни эшләре бар!

Безнең авылларда, мәетләрне күмгәндә, җеназа алдыннан ике малай бара, алар кырык адым саен туктый-туктый: «Яхшы кеше иде!» дип кычкыралар. Минем үземнең дә шулай кычкыра-кычкыра барганнарым бар. Ленин бабай алдыннан да: «Яхшы кеше иде!» дип кычкыра барырлардыр инде. Русча белсәм, бәлки, миңа да кушарлар иде, дип уйлыйм эчемнән.

Икенче көнне күрше абыйлар белән урамга чыктык. Күр инде: бөтен Мәскәү купкан, чат саен учаклар яна, бик каты салкын. Бу кадәр халыкны күргәнем дә юк әле. Барысының да йөзләре кайгылы.

Без Сретенка урамында тора идек. Бу — үзәктән ерак түгел. Мин, өлкәннәргә ияреп, Кузнецкий мостка таба киттем. Ленин бабайны Советлар Йортына куйганнар, дип сөйләделәр.

Урамнарга халык тулганнан тула бара. Бер сәгать, ике сәгать тордык — бер адым алга китеш юк. Мин: «Барабыз да Ленин бабайны күрәбез», дип уйлаган идем, кая ул болай булгач!

Халык арасында татарлар да очрый.

— Аләмәт, агайлар, күрми калабыз выт, Ленин бабайны, маем. Әй,

эни кәбәм, нинди кеше үлгән бит. Аның урынына мин фәкер үлгән булсам, ярамас идеме әмән,— дип өзгәләнде шактый олы яшьтәге бер агай.

— Кеше каберенә кеше керми, Алюк абзый. Вакыты житкәч, барыбыз алла тәлә каршына барырбыз,— диде безнең арадагы бер кеше.

— Һай, алла тәлә! Безнең ише мәхлукларга карыймы соң ул. Халәйнеке без күпме — миллион! Ленин гына бөтен кеше турында кайгырткан, ә алланың бик исе киткән әта безгә, күбрәк садака биргән кешеләрне дә чутламый торгандыр әле, әкият.

— Әй, Алюк абзый, үзең олы кеше, үзең әллә нәрсәләр сүлисең.

— Сүләмәс идем дә, маем, йөрәк әрни бит. Ленинга барып, халык кайгысын сүли ала иде, ә аллага сүли алган кеше бармы? Аллага түгел, хәзрәтеңә дә безнең ише галадраннарны якын җибәрмиләр иде. Син әт миңа: шундый салкында мин ни өчен урамга чыктым? Соңгы мәртәбә Ленинга баш иясем килде. Мин карт эшче, патшасына да, баена да, түрәсенә дә, чорты-явылына да баш имәдем, ә Ленинга баш иям, чөнки ул үзебезнең брат булган! Казак аркага камчы белән сыптыргач күздән яшь чыкмаган иде, ә хәзер яшь үзеннән-үзе ага, Ленин бабай жәл. Революциягә дә катнаштым, граждannар сугышына да, чөнки Ленин бабай безгә шулай кушты.

Безне һаман этәләр-төртәләр. Аннары кинәт бөтен халык йөгерә башлады. Без дә йөгердек, егылып калучылар да булды бугай. Бераздан халыкны тагын туктаттылар. Алюк абзый каядыр күздән югалды.

— Өй түбәләреннән узып карасаң,— диде безнең бер агай һәм миннән: «Туңмыйсыңмы», дип сорады. Минем өстемдә кара тун иде. Суык эчкә үтә башлаган булса да, мин сер бирмәгән булдым.

Ул арада халык арасында кузгалыш башланды, бер минут эчендә агайлар күздән дә югалдылар. Мин тирә-ягыма карадым: халык кара болыт шикелле, бар да мин белмәгән, күрмәгән ят кешеләр. Инде кая барырга, өйне ничек табарга? Күзгә яшь килде. Бер рус хатыны башымнан сыйпап нидер әйтте. Мин төшенмәдем, күзләренә генә карадым. Күзләре зур, коңгырт, хәсрәтле. Ул миңа тагын нәрсәдер әйтте. «Ленин не умер, сынок, Ленин жив!» дигән сүзләрен генә әзрәк төшендем, чөнки бу сүзләрне еш кабатлыйлар иде.

Ул чакта, билгеле, Ленинны күрә алмадым, өйгә ничек кайтканымны да хәтерләмим. Ләкин ул көннәр минем өчен бушка үтмәде: дөрес, мин башкалар кебек антлар бирмәдем, ләкин мин халыкның тирән кайгысын да, юлбашчыга булган тирән мәхәббәтен дә үз күзем белән күреп калдым. Еллар үтү белән бу истәлекләр, әлбәттә, тирәнәя баргандыр, мин бит бу турыда кайта-кайта уйландым.

Мәктәптә укытучылар безгә Владимир Ильич турында күп сөйләделәр, Ленин рәсемнәре безнең класс саен бар иде. Без үзебезне яшь ленинчылар дип йөри идек, укытучыларыбыз да безгә шулай дип дәшә торганнар иде. Андый чакларда мин һаман Ленинны күмгән көнне хәтерли идем.

Ул чакта Кызыл Мәйдан аркылы трамвайлар йөри иде әле. Мин мәктәпкә барышлый һәм мәктәптән кайтышлый, көн саен, Ленин мавзолеена карап үтәм. Мавзолейга керергә чират торган кешеләрне күрәм. Үземнең дә Ленин бабай янында буласым килә. Бер көнне, май аенда булса кирәк, безне, мәктәп балаларын, мавзолейга алып киттеләр. Үзем куркам да: үлгән кешегә карарга куркыныч, диләр. Бик юашланып, башны аска иеп атлыйм. Ара-тирә күз кырыйларым белән өлкәннәргә карап алам: аларның да йөзләре хәсрәтле, моңлы, хәрәкәтләре әкрен.

Мавзолейга кергәч, бигрәк тә пыяла калфак эчендә яткан Владимир Ильич яныннан үткәндә, минем исем китте: утлар бераз карангылатылган булса да ярыйсы якты, җир асты дип әйтерлек бер нәрсә-

се дә юк, Ленин бабай йокыга гына киткән, менә хәзер-хәзер керфекләрен селкетеп ачар шикелле. Үзе никадәр таныш, якын — монысы инде рәсемнәрдә күп күргәнгә шулайдыр. Яңа бер көч белән теге вакытта рус хатыны әйткән сүзләрне хәтерләдем: «Ленин не умер, сынок, Ленин жив!» Әйе, Ленин үлмәгән, ул тере, тик бераз арыганга күзләрен генә йомган, дип уйладым, мавзолейдан чыкканда.

## Ленин рәсеме

Ленин образы минем хәтергә әкренләп сеңә барды.

Менә бала чакта күргән һәм гомер буе истә калган бер Ленин рәсеме. Билгеле, истә калуы эшләнеш ягыннан түгел. Ул чакта мин сәнгать әйберләренең нечкәлекләрен белми дә идем. Бу урамнарда ябыштырыла, кибет тәрәзәләренә куела торган гади плакат-рәсем. Ул — рәсемдә яланбаш кеше, киң һәм шома маңгай, игътибарлы караш. Юлбашчының киң таралган рәсемнәреннән берсе бу. Миңа ул ошый, мин бары тик шулай итеп кенә аны күз алдыма китерә алам. Башка кешеләрнең дә күңелләрен яктырта торган, аларга аеруча ошаган Ильич рәсемнәре бардыр инде.

Бу рәсемне мин үсмер чагымда ерак авылда күрдем. Ни өчен ул онытылмаган? Безгә дә бит давыллар аша үтәргә туры килде. Әллә үсмер чакның хәтере бик нурлымы? Шуңа онытылмыймы, шуңа истә торамы?

Үсмер чакта мин бу турыда яхшылап уйламаганмын, дөресрәге, уйлый белмәгәнмен, шуңа күрә сәбәбен дә төшенергә тырышмаганмын, бары тик үсмер акылы ирешмәс шул бинниһая байлыкны күңелемә бикләгәнмен һәм бик озак еллар буе төбенә кадәр ачып карарга курыкканмын. Менә хәзер шул турыда уйлыйм һәм, караңгы төндә аҗаган утын күргән кебек, хикмәтен шәйлим кебек. Совет халкыннан гаҗәеп күп көч һәм рухи бөеклек сораган җиңүләрнең сере дә шунда түгелме? Безнең буын кешеләренә дөнья бер генә тапкыр гаҗәпләнмәде бит, болар кешеләр түгелдер, югыйсә кеше түзмәс нәрсәгә түзә алмаслар иде, дип безнең турыда сөйләмәсләр иде. Сталинградта туфрак, таш янган, таш биналар ишелгән, тимер булып тимер чыдамаган җирдә совет кешесе чыдады, Ленинградта блокада тырнагында ачлыктан интеккәндә дә якты өметен өзмәде ул, дошманның үлем лагерьларында тереләй мичтә яндырылганда да изге антыннан ваз кичмәде, палач балтасы астында да туган илгә турылыклы булып калды. Мондый мисаллар санап бетергесез.

Безнең авылның кояш батышы ягында, ике-өч чакрымда, Яңа Аллагол дигән зур татар авылы бар. Анда атаклы кызыл керәшче һәм шагыйрь Галимҗан Акчурин, Муса Җәлилнең көрәштәше яшь шагыйрь Әхмәт Симаев туган. Бала чагымда Яңа Аллаголда еш булгаласам да, яшьтәшем Әхмәтне белмәгәнмен. Танышу соңыннан Мәскәүдә булды.

Яңа Аллаголның аргы очында, тау башында — Тенеш авылы. Уртада инеш, инеш буйлары — әрәмәлек. Бер вакыт шунда кунакка баргач, әнинең апасының малае Сәфәргали мине әрәмәлеккә алып китте. Ул бик матур итеп кызау урә белә торган иде. Сәфәргали күз алдымда пәкесен уйнатып алды да, чыбык кисәргә дип, әрәмәлеккә чумды. Мин су буена төштем һәм шып туктап калдым: кемдер Тенештәге ике катлы йортның стенасына тышкы яктан Ленин рәсемен кадаклап куйган. Кояшта ялтырап торганга, бу зур рәсем-плакат инеш буеннан апачык күренә, әйтерсең, нәкъ авыл өстендә йөзә.

Мин шул рәсемгә әрәмәлектән шактый озак карап торганмын, ахрысы. Күрәсең, яр буеннан узган сукмактан үтеп баручылар да моңа

игътибар иткәннәр. Бер вакытны минем янымa, ауган агач өстенә, кулына шома таяк тоткан, озын ак күлмәкле, ялпак түбәтәйле, аягына юкә башмак кигән бер бабай килеп утырды. Мине инде өлкәннәр белән сәлам биреп исәнләшергә өйрәткәннәр иде. Кунакка килгәч, бигрәк тә игътибарлы буласың инде.

Бабай минем сәламемне алды. Миңа да утырырга кушты. Бу вакытта җәй урталары иде, җылы, кояш көлә, төкле туралар чәчәктән чәчәккә кунып бызылдап очып йөри, кайдадыр су керүче бала-чагалар шаулаша. Ә бирәдә тын, күләгә, һәм тау башындагы Тенештә ап-ачык булып ике катлы өй стенасында Ленин рәсеме күренә.

— Улым, танымыйм, син кем баласы буласың? — диде бабай, ак кашларын кыса төшеп. Аның түгәрәк сакалы да көмеш кебек иде.— Каядыр күргән дә кебек үзеңне.

Мин Иске Аллаголдан икәнемне, монда бары тик кунакка гына килгәнлегемне әйттем.

— Алай икән, Иске Аллаголныкы буласыңмыни. Бик яхшы, бик яхшы. Кем баласы?

Мин әйтеп бирдем. Бабай, күрәсең, безнекеләрне белми иде, кайсы очта торуыбызны сорады. Мин Тукай очында торабыз дигәч, ул башын гына какты. Күрәсең, Тукайны да белми иде. Байтак вакыт эндәшми торды. Мин инде бабай яныннан китәргә дә уйлаган идем, ул кинәт башын күтәрде.

— Баядан бирле сурәткә нәүмизләнеп багып торасың, улым, әллә таныйсыңмы әтәм?

— Бу — сурәт түгел, бабай, бу — Ленин! — дидем мин, бераз мактана төшеп.

— Шулаймыни? Ленин дисеңме? — Бабай ерактагы өй стенасына кадакланган плакатка шактый озак текәлеп торды.— Әтәм йөзе сөйкемле... Яратып күзләреңә баккан кебек әмән. Минем күзләр, аллага шөкер, ерактан яхшы күрәләр әле. Менә якыннан Ленин бабайны күрергә насыйп булмады. Син үзең Ленинны каян таныйсың, улым?

— Мәскәүдә мондый рәсемнәр күп.

— Син Мәскәүдә булдыңмыни?

— Мин анда укыйм, бабай.

— Әтәм дә бераз башкачарак сүләшәсең. Без выт авылда да сабакка йөри алмадык, һаман буразнада аунап үстек, дөньяның яхшысын күрмәдек. Яшьләр хәзер Мәскәүдә укыйлар. Ленин бабайга мең рәхмәт инде, безнең юше ярлы-ябагайга чын туры юлны күрсәтмәсә, без каян белер идек. Яшьрәк булсам, сикереп торыр идем дә Ленин юлыннан китәр идем, рас. Картлык чабудан тарта. Ибрук арбасы кебек, бөтен авылга җеназа укып атлыйсың әмән... Алай,— бабай ерактагы рәсемгә кулындагы таяк белән күрсәтте,— Ленин бабай дисең? Җыен йортында да Ленин рәсеме бар. Ну анда башкачарак, күкрәгендә кызыл лента. Монысы чын юлбашчы кебек. Маңгаен күрәсеңме? Башлы кешенеке ул. Башлы кеше булмаса, бөтен дөнья гыйлемен белер идеме? Бөтен кешенең хәленә керер идеме? Выт мин Исмай бабай булам. Күлмәгем озын, акылым кыска. Андый акыл нәзем төяргә генә ярый. Вет әт, Ленин бабай мине белгәнме? Белмәгән. Ул бәлкем Тенешне дә, Яңа Аллаголны да, Иске Аллаголны да белмәгәндер. Рәсәйдә андый авыллар миллион, ә күңелдәгеңне түкми-чәчми әтеп биргән! Выт ул акыллы кешенең эше. Исмай бабай может буразнага утырып елагандыр да, язмышын да эрләгәндер. Халык тормышында төрле чагы була, улым, кайчак дөньясына карамас идең. Нужа бабай үрле-кырлы сикертә башлагач, аппаруга аңгы-минге буласың. Син выт Мәскәүдә булдым дип әтәсең, ә мин нибары Дырбу базары белән Тәрбию станциясенә генә барганым бар, анда да байны каршы алырга гына. Шунысы ярый, Ленин кешеләре безнең авылга килеп җиттеләр, дөнья тишегә

дип тормадылар. Ак белән караны аңлаттылар. Ачлык елларда Ленин Мәскәү эшчеләренә икмәк сорагач, авыл байларыннан тартып алып бирдек. Яңа Аллаголда, өй түбәләре выны моннан да күренә, бер бик башлы адәм бар иде. Революция елларында шул безгә дөнья хәлләре турында да, Ленин бабай турында да сөйли иде. Хатыны — доктор. Әтеп булмый, бик яхшы хатын. Бервакыт шулай авырган идем, үләм дип торам, бәхилләшә башладым. Тиф иде, ахрысы. Шул хатын аякка бастырды үземне. Әҗерен дә алмады. Выт нинди яхшы кешеләр бар дөньяда... Сакалымны сыпырам да уйлап куям: шундый яхшы адәм булырга ана Ленин кушкандыр.

Мин күптән инде Сәфәргалине оныткан идем. Бабайның сүзләре мине ничектер биләп алды. Мин Ленинны җирләргә баруымны, ләкин барып житә алмавымны уйладым. Аннары мавзолейда Ленинны күрүемне хәтерләдем. Бәлки хәзер ул уянгандыр, дип уйладым һәм хәзер ук Ленин бабай янына барасым, Исмай бабай синең турыда менә нәрсә сөйли бит, дип әйтәсем килде. Менә Ленинның Исмай бабай белән гәпләшүен тыңласаң иде! Ул Исмай бабай янында минем кебек авызына су кабып утырмас иде. Әй сөйләшерләр дә сөйләшерләр иде!..

Исмай бабай белән күрешкәннән соң, мин Ленинның нинди кодрәткә ия булуына беренче тапкыр төшендем бугай. Гомере бозауларга кибәк аерып үтсә дә, Исмай бабай Ленин турында әнә ничек сөйли! Бу — халыкның юлбашчыга булган чын мөнәсәбәте, аның йөрәк түреннән чыккан кайнар мәхәббәте. Билгеле, ул чакта мин моны тулысы белән аңламаганмындыр, Ленинның бөеклеген аңлау тора-бара килгәндер...

Халык фантазиясендә халыкның кайнар өмете дә ярылып ята. Караңгы авыл халкы ул чакта ук Ленинны чиксез кодрәтле итәргә тырышкан. Монда реаль чынбарлык, һичшиксез, хыял белән кушылган. «Башлы адәмнәр дә», шәһәрләрдә булып кайткан авыл кешеләре дә Ленин турында күп сөйләгәннәр. Җыенда, җыелышларда гына түгел, табын янында да, өргә өстендә дә, кырга эшкә барганда да, дүри казыганда да гәп өзелмәгәндер. Ленин! Халык аңа чиксез ышанган, үзенең барлык яхшы өметләрен аның белән бәйләгән. Шуңа күрә Исмай бабай ерактагы Ленин рәсеменә шулай якын итеп карап торды түгелме? Мин хәзер дә, бик күп еллардан соң да, бу карашны ачык күрәм һәм анда әйтелмәгән серләр дә бар кебек. Мин бит Исмай бабайның тормышы, балалары турында бер нәрсә дә белмим. Картның уйлары җир белән күк арасындагы уйлар түгел бит, алар тормышка, бабайның балаларына һәм балаларының балаларына бәйләнгән. Никадәр тирән, никадәр борчулы уйлар булырга тиеш алар! Исмай бабайлар, аның кебек меңнәр, миллионнар Ленинны күңелләрендә йөрткәннәр, ана һәм аның үлемсез партиясенә ышанганнар.

## Октябрь бәйрәмнәре

Минем әле үсмер малай чак...

Уйласаң, ул чактан бирле дистәләрчә еллар үткән, күп сулар аккан, ләкин мин барыбер үземне үсмер чактагыча хис итәм, бер нәрсә дә үзгәрмәгән кебек. Әллә яшь чактагы хәтер шундый тереме? Кеше үсә, башыннан күп нәрсәләрне кичерә, олыгая, ә үзе, күңел тирәнлегендә, һаман да шул үсмер малай — чәчрәп күләргә, уйнарга, чабарга ярата. Бер нәрсәгә яхшылап игътибар итеелмәгән сыман, чәчәктән чәчәккә кунган гамьсез бал корты сыман, шул ук вакытта никадәр «бал» җыелган — гомер буена җитәрлек, артып та китәрлек.

Минем хәтеремдә үсмер чакта кичерелгән бәйрәмнәр якты бер

истәлек булып саклана. Бу вакытта мин инде авылда түгел, Мәскәүдә идем. Гарәфә көннәр, дини бәйрәмнәр берсе дә хәтердә юк, алар булганмы, булмаганмы, күңелдә һич тә эз калдырмаганнар, ә менә Беренче Май, Октябрь бәйрәмнәрен һич онытасым юк. Беренче Май бәйрәме үзенә бер төрле, якты, аеруча нурлы үтә иде. Укулар бетәргә дә күп калмый, син инде үзеңне хөр итеп сизә башлыйсың, күңел табигать кочагына, урманнарга, болыннарга ашкына. Син әле Беренче Майның тирән эчтәлеген бик үк төшенеп җитмисең, Мәскәү урамнарындагы кызыл флаглар, төрле лозунглар, плакатлар сиңа бары тик бәйрәм бизәкләре генә. Октябрь бәйрәмендә син инде бераз җитдирәк, беркадәр сабыррак, нәрсәгәдер бик нык ышанасың, алга карасаң — барыр юлың якты. Билгеле, яшеңнән олы була алмыйсың, ура кычкырасың да кул болгыйсың. Көрәш романтикасы — синең баш өстендә генә, йөрәгеңә купмаслык булып кереп утырмаган әле. Вакыйгаларны син күбрәк тышкы яктан кабул итәсең дә, күңел тирәнлегендә инде нәрсәдер җыела бара, тик син әле балалык гамьсезлеге астында көчле елгаларның мул агышын сизмисең.

Октябрь бәйрәмнәренә мин бала вакыттан ук катнашып килдем. Кайсы елдан икәнен тәгаен генә хәтерли алмыйм. Октябрьның ун еллыгы аеруча истә калган. Бу, беренчедән, юбилей елы, шуңа күрә ул, моңа кадәр күрелмәгәнчә, тантаналы үтте, демонстрация искиткеч зур булды. Аннан соң кырык елдан артык вакыт үткән, ләкин ул чактагы энтузиазм, рухи күтәренкелек әле булса күз алдымда. Тарих хезмәт ияләренең шундый зур бәйрәмен беренче тапкыр күрә иде бит. Без, яшь булганлыктан, Октябрьның дөнья күләм тарихи әһәмиятен әле аңлап та бетермәгәнбез, бары тик йөрәк белән генә сизгәнбез, әмма өлкәннәр моны аеруча аңлаганнардыр. Иске дөньяны җимереп ташлаган Октябрь давыллары аларның күз алдында үткән бит, алар үзләре дә аңа турыдан-туры катнашканнар.

Мин Кече Татарский тыкрыктагы Әсәдуллаев мәктәбендә укыйм. Безнең бәйрәм колоннасы башта Пятницкий урамы буйлап Климетовский тыкрыкка кадәр килде, аннары, кире борылып, Новокузнецкий урамы буйлап Зацепага таба киттек. Калужский мәйданында тагын унга борылып, Культура һәм ял паркы яныннан үттек, аннары Таш күперне кичеп Манежга таба юл алдык. Моннан инде Кремль буйлап Кызыл Мәйданга да ерак калмый. Бу араны без бик озак бардык. Иртән сәгать сигездә чыккан идек, хәзер ике тулып өченче инде, без һаман әле юлда. Озак-озак тукталып тордык, җырладык, биедек, уйнадык. Көн әле җылы, кар яумаган, урамнар халык белән тулы, музыка бертуктаусыз уйнап тора, бөтен җирдә — кызыл флаглар, лозунглар, плакатлар, күңелле тавышлар.

Кайдадыр, Калужский мәйданы тирәсендә, безнең колоннага олы гына бер абый кушылды. Башында кепка, озын мыегы тәмәке төтеннәннән саргайган, өстендә кыска пиджак, аягында резин галошлы кара чесунка, пиджак якасына кызыл бант таккан. Кулында таягы бар, үзе аксый төшә. Колоннага чит кешеләрне кертергә ярамаса да, бу абыйны әллә шул кызыл бантына, әллә көлеп-шаярып сөйләшүенә карап, ничектер үз иттек. Безгә бит, балаларга, көләргә генә булсын. Абый бер сүз әйтсә, без урамны яңгыратып дәррәү көләбез. Абый үзе дә кеткелди, кулындагы кәкре башлы таягын селкеп-селкеп ала, ә без аның таягын эләктереп качарга гына торабыз. Ул бер дә усал түгел, тәмәкедән саргайган мыек чылгыйларының тырпаюында, аксый төшеп аяк атлауларында нindидер мәзәклек тә, картларга хас йомшак эчкерсезлек тә, балаларны чиксез яратуы да сизелә. Бу абый шәһәр балаларына аеруча таныш булган водопроводчикка, котельщикка яки дворникка бик тә охшаган, сөйләшүе дә аларчарак. Бигрәк тә куллары безгә ошады: һәр нәрсәне булдыра ала торган зур, сөялле куллар. Бу вакыт-

та инде без мәктәптә хезмәт дәресләре утә идек. Мин итекчеләр дәресенә йөрсәм дә, күбрәк китап төпләү һәм слесарьлык эшен ярата идем. Әллә инде ил ныклап торып индустриаллаштыру эшенә керешкәнгә, тимер эше күңелгә якынрак иде. Соңыннан слесарь булып китүем дә шуннан башлангандыр инде.

— Значетсы, татарчата буласыз, елки-палки,— диде абый русча һәм рәхәтләнеп көлеп җибәрде.— Күрәм күзләрегез ялтырый, ох, ничек ялтырый, елки-палки.

Бу вакытта инде без русчаны төшенә идек. Безгә барыннан да бигрәк абыйның «елки-палки» дигән әйтеме ошады. Анда шул әлеге шаянлык, үз һәм якын күрү бар иде. Әйләнәбез дә «елки-палки», дип кычкырабыз. Шуннан ничектер үзеннән-үзе килеп чыкты: абыйның үзенә дә Елки-палки дип кушамат тактык.

— Елки-палки абый, буржуй килә, буржуй! — дип кычкырабыз хор белән.— Кач, ашый үзеңне!

— Ә мин аларны күп күргән, елки-палки, өркетми. 1917 елда без аларның киракләрен бирдек, әле дә төшләрендә күреп куркып уяна торганнардыр.

— Елки-палки абый, Чемберленны да күрдеңме?

— Чемберленнымы? Чемберленны күрмәдем. Күрсәм, сөйләшә белер идем, елки-палки. Ну күрмәдем.

— Һи-и, ата буржуйны да күрмәгәч. Алайса, нигә кызыл бант тактың? Кызыл Мәйданга җибәрсеннәр өченме?

— Юк, кадерлеләрем. Анда мине болай да җибәрәләр. Мин — кызылгвардеец, менә кем, елки-палки!

Шунда малайларның кайсыдыр:

— Шуром-буром, старья берем,— дип кычкырып җибәрде һәм чәчрәп көлә башлады.

Ул чакта култык астына капчык кыстырган, сай бүрекле, озын җиләнле, салынып торган нечкә мыеклы старьевщик татарлар Мәскәү урамнарында еш күренәләр иде әле. Кумер сатучылар белән шул старьевщикларның көйгә салыбрак кычкырган тавышлары әле дә колак төбемдә. Елки-палки абыйның да, безне җиңелчә үчекләп, шуром-буром дип кычкыруын һич онытасым юк.

— Ләкин мин белгән татарлар, җан кисәкләрем, «шуром-буром, старья беремнар» түгел иде,— диде Елки-палки абый аннары.— Чын эшчеләр, завод эшчеләре иде. Эшче дуслары өчен во ничек тордылар! Берсен без Ахтям дип йөри идек. Боевой егет иде, удалой. Сызылып киткән кара мыек, озын буй. Бер тапкыр, Октябрь революциясе алдыннан, жандармнар безнең кызыл флаг тотып барган бер эшчене мылтыктан атып яраладылар. Шул Ахтям егылган иптәшнең кулыннан флагын алды да, баш өстендә селкеп:

— Ну, живодерлар-канэчкечләр, мине дә атыгыз, әмма эшче хакыйкатен барыбер ата алмассыз! — дип кычкырды. Менә нинди иде ул, Ахтям, елки-палки! Жандармнар булып жандармнар янадан атарга курыктылар. Ә сез, шуром-буром. Юк, дусларым, эшче халыкның бүтән горурлыгы бар!

Шаярулар, ничектер, үзеннән-үзе туктады, без Елки-палки абый янына тыгызрак сыендык. Мин Елки-палки абый янында ук идем, аның авызына ук карап тордым.

— Менә, нәни туганнарым, Кызыл Мәйдан да күренә,— диде Елки-палки абый,— шунда аяк бассам, барысы да искә төшә. Менә аягым авыртса да, бөек бәйрәмгә килмичә түзә алмыйм. Владимир Ильич Ленинны шунда күрдем бит мин. Моннан ун ел элек, 1918 елда, Октябрьның беренче еллыгына катнаштым. Бу — безнең беренче эшчекрестьян бәйрәме иде! Ә тормыш ул елда хәтәр, зрә хәтәр иде. Империалистлар безне эчтән дә, тыштан да буарга тырыштылар. Ләкин

безнең командир — Ленин бер нәрсәдән дә курыкмады. Курку белми торган иде ул, елки-палки! Бәйрәмебезне бөтен дөнья хезмәт ияләре күрсен дип тырышты ул. Әле алтынчы ноябрьда, кич белән, Кызыл Мәйданда иске дөнья эмблемасын керосин сибеп яндырдык. Икенче көнне иртә белән Кызыл Мәйданга халык агыла башлады. Иң беренче булып безнең резервтагы эшче полклар килде. Ул чакта мин менә болай, Матрена әби кебек, аксамый-туксамый идем, кулда да менә бу елки-палки түгел иде. Бар иде безнең дә гайрәтле чаклар! Һич онытасым юк, Кремль стенасы буенда Октябрь революциясе геройлары хөрмәтенә мемориаль такта ачу тантанасы булды. Владимир Ильич үзе ачты ул истәлек тактасын. Аннары ул биек трибунага менеп ялкынлы речь сөйләде. Аның якасында, менә минеке төсле, кызыл бант бар иде. Шуңа күрә мин һәр бәйрәм саен аны тагып чыгам. Аңлыйсызмы моның нәрсә икәнен? Яшьрәкләр шул әле, аңламыйсыздыр. Шул кызыл бант кебек, йөрәктә Ленин кабызган сүнми торган ут яна кебек. Менә ничек!

Күктә моторлар гүләве ишетелде. Без, башларыбызны күтәреп, һавага карадык. Елки-палки абый да карады, аннары, тавыш тынгач, әкрен генә:

— Ул чакта да аэропланнар очты, прокламацияләр ташладылар,— диде.

...Хәзер, кырык бер елдан соң, хәтерне яңартыр өчен шүрлектән Ленинга багышланган китапларны, газета-журналларны алам. Укыйм. 1918 елда, Кызыл Мәйданга килер алдыннан Ленин Революция мәйданында Маркс-Энгельска вакытлы һәйкәл ача. Революция мәйданы аркылы узганда, бала чакта, ул һәйкәл нигезе алдында мин дә басып торганмындыр инде. Тик миңа сөйләүче, аңлатучы булмаган. Күп еллар үткәч, шул ук Революция мәйданында, Партиянең XXII съезды делегаты буларак, Карл Маркс һәйкәлен ачу тантанасына катнаштым. Бу турыда ул вакытта «Культура и жизнь» газетасында язып та чыктым.

Һәр кеше күңелендә кадерле минутлар була. Тик кайчакта, көндәлек тормышның гади вакыйгалары арасында, ул кадерле минутлар ничектер бик тиз үтеп китә. Хәлбуки, ул кадерле минутларның агышын ничектер әкренәйтәсе, аларның бөеклеген түйганчы бер күңелдән кичерәсе иде. Хәер, вакытны туктатып тору — бер хыял гына. Ләкин безнең кулда икенче бер куәт бар — кешеләр хәтерли ала, хәтер җимешләрен кәгазьгә төшерергә мөмкин. Кәгазьдәгене исә бүген дә, иртәгә дә, аннан соң да укый аласың.

## Күз карасы кебек

Совет халкына борынгылардан калган һәм изге күреп саклана торган васыятьләр бик күп. Шуларның берсе, иң изгесе, туган илне, хезмәт ияләре Ватанын явыз дошманнардан күз карасы кебек саклау — Ленин васыяте. Утызынчы елларда бу, безнең ише сугышны күрмәгән яшьләр өчен, теоретик пландагы бер нәрсә иде, аны яхшы үтәргә ант итү дә әллә ни кыен түгел иде. Бөек Ватан сугышы башлангач, илне саклау һәркем өчен дә конкрет мәсьәлә булып китте, тик хәзер сүз кирәкми, эш кирәк иде.

Яшьләргә хас бер дәрт белән газиз туган илне сакларга ыргылганда, без, яшь солдатлар, ялгыз түгел идек, иң алда, безнең күңелләрне күтәреп, кыен минутларда киңәшләр биреп үлемсез Владимир Ильич Ленин бара иде. Ул һәр солдатның якын дусты, ышанычлы иптәше иде. Аның исеме белән без сугышка кердек, аның исеме белән иң мәкерле дошманны җиңеп чыктык: кызыл байракларыбызны данга күмдек. Бу дәһшәтле сугышта без Ленинның социалистик дәүләт өчен кем булганын тагын да тирәнрәк аңладык, Владимир Ильич безнең

Армия сафында беренче ротаның беренче отделениесенда уң флангта барган батыр солдат иде. Ул Социалистик Ватанның туган сәгатеннән үк аның иминлеге турында уйлый башлаган, бөтен чараларны күргән, җиңү юлларын сызган. Хәзер, бөек Ватан сугышының һәркемгә дә билгеле бөек нәтиҗәләренә карап, әйтә алабыз: совет солдатлары Ленин күрсәткән юлдан тайпылышсыз барып, Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә үзләренең ил алдындагы бурычларын батырларча үтәп чыктылар, фашистлар изүе астында сыкранган халыкларга азатлык илттеләр.

Бу — мактану түгел, бу — сугышның реаль нәтиҗәсе. Ул яна сугыш чукмарларын да бик нык уйландырырга тиеш.

Җиңү безгә ансат килмәде, дошман безнең башкалабыз — Мәскәү каласына үк килеп җитә язды, икенче башкалабыз — Ленинградны камап алып, аңа туплардан атты. Социалистик туган ил язмышы, эшче-крестьян Ватаны язмышы, кыл өстендә калды. Дошман, кәпрәеп, җиңү сәгатьләрен санады. Бу иң кыен минутларда күп миллионлы совет халкы, аның Кызыл Армиясе һәм флоты революция бишеген, героик башкалабызны теләсә нәрсә булса да дошманга бирмәскә ант итте. Совет кешеләренең анты нәрсә икәнен хәзер барлык дошманнар беләләр булса кирәк. Онытсалар — үзләренә үпкәләрләр.

Сугышта бераү дә герой булыр өчен сугышмый. Батырлык туган илне яратудан, аңа актык сулышына кадәр турылыклы булудан килеп туа. Ил үзенең сакчыларыннан кемнең нәрсә эшләвен бик яхшы күреп тора, соңыннан лаеклы рәвештә билгеләп үтә. Бераү дә онытылып калмый. Батырлык җирдә ятмый.

Без, солдатлар, ил өчен ул авыр елларда Владимир Ильич Ленин турында, социалистик Ватан турында күп уйландык. Безнең уйлар нинди юнәлештә булуын сугыш елларында Коммунистлар партиясенә һәм комсомолга керүчеләрнең саны бермә-бер артуы бик ачык күрсәтә булса кирәк. Безнең күбебез партиягә сугыш кырында керде, партия билетын да шунда алды. Ә аңарчы безнең комсомол билетлары һәм солдат кенәгәләре эчендә бер кәгазь йөрде: «Үлсәм, коммунист дип санагыз!»

Хәзер шул көннәргә борылып карыйсың да уйга каласың: бу бит кемнең булса кушуы яки нинди булса исәп буенча эшләнмәде, үлгәннән соң инде исәп кирәкми. Кеше шул өч сүзгә үзенең бөтен тормышын, ышанычын, изге күргән идеалларын сала. Бераү дә аның кесәсендә шундый язу барлыгын белми, бу язу аның йөрәгенә уелган, тик үзе үлсә генә аны башкалар укыячаклар. Икенче төрле әйтсәк, бу аның иң изге васыяте, ул йөрәк каны белән юылгач кына көчкә керә.

Миңа сугыш кырында туган ил өчен башларын салган солдатларның кесәләреннән шундый язуларны алып укырга туры килгәләде. Бу иң югары ант, иң изге кәгазь кисәге. Кеше үзе юк инде, ә аның партиягә кайнар ышанычы яши, партия аның мөкатдәс теләкләрен, һичшиксез, тормышка ашырыр. Мондый ышаныч моңарчы дөньяда бер илнең солдатында да булмаган.

Миңа взводның «Боевой листогын» редакцияләү эше йөкләнгән иде, агитатор да булдым, ара-тирә рота күләмендә дә политзанятиеләр үткәргәләдем. Әллә шуңа күрәме, әллә язучы гадәте буенчамы икән, иптәшләргә күз салгалый идем: миңа аларның йөрәк түрендә йөрткән иң изге уйларын белү кирәк иде. Болай бит солдатлар бер-береннән әллә ни аерылмый, бар да тире туннан, малахайдан, киез итектән. Холыклары, билгеле, төрле-төрле. Берсе көләргә, көлдерергә ярата, солдат тормышыннан кызык хәлләр сөйли, икенчесе үз алдына елмаеп кына утыра, командир кушканны берсүзсез үти. Ә уенда, йөрәгендә нәрсә? Турыдан-туры сорасаң, сина бераү дә бер нәрсә дә әйтми, әйтсә дә, дөресен әйтәме? Кешеләрнең чын уй-тойгыларын белү бик авыр.

Синең такылдавык икәнеңне белсәләр, гомумән, ераграк булырга тырышалар.

Бер вакытны бер солдатның ком өстендә яки яңа яуган кар өстендә төрле кыяфәттә Ленин рәсемнәре ясавына игътибар иттем. Гүя ул уйнап кына сызгалый. Ә рәсемнәре шактый тере чыгалар. Аларда тагын нәрсәдер бар иде. Мин моны тиз генә тотып ала да алмадым. Билгеле, ком яки кар өстендә ясалган рәсемнәрнең сәнгать камиллекләре турында сөйли алмыйсың, ләкин алар карашны тарта, уйландыра, син аларга гади кызыксыну белән генә карамыйсың, алардан нәрсәдер эзлисең, тапкач, үзең дә сизмичә әкрен генә елмаеп куясың. Бер көнне, батальоннан кайтканда, шул рәсемнәрне кар өстендә күреп, барсын да аңладым: Ленин безне, солдатларны, явыз дошманны җиңүгә чакыра иде. Урман сукмагында мин бер үзем идем, ләкин күңелем ташып китте. Ихтимал, моны башкалар әллә кайчан аңлаганнардыр инде, шуңа күрә аларны бер вакытта да бозып китмиләр.

Көннәрдән бер көнне әлеге иптәшне тагын шул эше өстендә очраттым. Ул, каядыр барышлыймы, каяндыр кайтышлыймы, алан читендә туктаган да чаңгы таягы белән кар өстенә Ленин рәсемнәрен ясый. Соңгы көннәрдә кар яуган, иске рәсемнәр барысы да күмелеп калганнар иде.

— Ленин рәсемнәрен ничек шулай охшаш итеп ясый аласың, дускай? — дип сорадым.

Ул чак кына елмайды.

— Охшыймыни?

— Минемчә, бик охшый.

— Синеңчә... Син дә чагыштырмыйча әйтәсең ич. Бәлки, бу сызыгы алай түгелдер.

— Юк, шулай! Юлбашчының һәр рәсеме минем күңелдә.

— Алай булгач, минем дә күңелдәдер инде. Бәхәсләшеп торасы юк шикелле.

Мин аның бу турыда күп сөйләшәсе килмәгәнлеген төшендем. Иҗат эшенә үземнең дә беркадәр бәйләнешем булганга, бу миңа бик аңлашыла иде. Күрәсең, шул сыйфат иҗат кешеләренең барысында да азмы-күпме бардыр инде.

— Боларны кәгазьгә төшереп, Ленин землянкасына элеп куясы иде, туган. Карасыннар иде сугышчылар.

— Мин кәгазьдә ясый белмим, бигайбә,— диде иптәш һәм бик тиз китеп барды.

Мин, әлбәттә, аның сүзләренә бик үк ышанып бетмәдем. Юл өстендәге бу рәсемнәргә башка иптәшләр дә игътибар иткәннәр иде. Ленин көннәрендә кемдер: «Бу иптәшне взводка чакырырга иде»,— диде. Бу тәкъдим барыбызга да бик ошады. Бу вакытта аларның взводын икенче батальон участогына күчергәннәр иде. Мин, взвод командирыннан сорап, аны эзләп киттем. Ләкин юлым уңышлы булмады. Моннан ике көн элек иптәш каты яраланган, аны госпитальгә озатканнар иде.

— Ленин рәсемнәрен зрә оста ясый иде. Землянкабыз өстендә әле дә бар алар. Кар яумаса, озак торырлар,— диде бер олырак солдат. Мин аның тирән кичереш белән сөйләвен күрдем.

Кайтышлый, чаңгы юлы өстендә, Ленин рәсемнәрен үзем дә күрдем. Бая ничектер күземә артык чалынмады, әллә чаңгыларда кызу килдем, әллә кояш яктысы ул җиргә төшмәгән иде. Хәзер ялтырап тора. Мин беравык алар янында туктап та тордым. Соңыннан карангы землянкада ятканда да ул рәсемнәрне түшәмдә бик ачык күрдем — күрәсең, ул минем күңелемдә балкый иде. Ленин көннәре җиткәч, ротада да сөйләдем. Ничек сөйләгәнмендер, хәзер тәгаен генә әйтә алмыйм, ләкин бер иптәш әңгәмәдән соң:

— Бик дулкынланып сөйли беләсең икән. Мин политрук кушканны гына үтисең дип уйлаган идем,— диде.— Рәхмәт.

Аптырап калдым: нигә бу рәхмәт әйтә икән? Мин, гомумән, оста сөйләүчеләрдән түгел. Шулай да дулкынлану булгандыр инде, рота алдында гына булса да, халык каршына чыгу уен түгел бит. Ләкин аның өчен нигә рәхмәт әйтергә? Менә иптәшләрнең күңелләрен бераз кузгата алсам, солдат йөрәгенең яшерен кылларына кагыла алсам, анысы бик әйбәт.

Ул чакта мин фронт тормышыннан бик аз язган идем әле. Вакыт та юк, кәгазь дә юк, аннары землянкада караңгы, тышта — салкын, бияләй белән күп язып булмый. Иң мөһиме: үземнең эчке уйларымны тәртипкә китереп җиткермәгән идем. Уйлар бик күп, берсе өстенә берсе өеләләр, буталалар, кайдан башланганнарын, кайда беткәннәрен яки тукталганнарын үзең дә белмисең. Шуннан адәм рәтле итеп язып кара инде. Җитмәсә, кат-кат күчереп тә булмый.

Ул чакта әлеге иптәш белән ничектер яхшылап сөйләшә алмый калдым, әллә ашыгыч заданиега киттекме, әллә тартындыммы? Бик төпченә башласаң, үзеңнең кечкенә генә эшеңне бик зурга куеп мактанасың сыман килеп чыгар иде. Ә менә хәзер, бик күп еллардан соң, шушы юлларны язарга утырыр алдыннан уйландым: без, бөек Ватан сугышы солдатлары, һәрберебез үз күңелләребездә әйтелмәгән серләр йөртә идек. Күп вакытта без аларны әйтергә сүз дә таба алмый идек, ихтимал, әле алар сүз булып оешып та җитмәгән булгандыр, тик ак томан шикелле, күңелдә генә айкалалар иде. Мин Ленин турындагы әңгәмәмдә солдатларның шул күңел тирәнлегендәге ак томаннарга кагылдым бугай. Әгәр шулай булса, минем теге иптәш белән сөйләшә алмый калуым хәерлегәдер, чөнки ул барыбер күңелендәгеп әйтә алмас иде. Шуннан кайта-кайта тагын кар өстендәге Ленин рәсемнәре турында уйлыйм: теге солдат-художникның күңелендә бик тирән уйлар булган булса кирәк. Ул аларны сүз белән иптәшләренә әйтә алмаганмы, әллә курыкканмы? Сүзнең, никадәр ачык әйтсәң дә, икенче мәгънәләре кала. Әгәр солдат иптәшләре: бу үзе өчен тырыша икән, дип шикләнеп куйсалар? Ә кар өстендәге рәсемнәрнең мәгънәсе бер генә: ул солдат күңеле турында сөйли. Чыннан да, әгәр солдат күңелендә тирән уйлар булмаса, үлем каршында ул Ленин рәсемен ясар идеме? Әгәр гомумән рәсем ясарга бик һәвәс булса, нигә ул башка рәсемнәр ясамаган, солдат тормышында аларның җитдиләре дә, көлкеләре бик күп бит. Миңа калса, кар өстендәге Ленин рәсемнәре белән комсомол билеты яки солдат кенәгәсе эчендәге «Үлсәм, мине коммунист дип санагыз!» дигән язу арасында туры бәйләнеш бар, монда — совет солдатының яшәү фәлсәфәсе. Нинди идеалларны ул алга сөргән, кемгә охшарга теләгән, кемнән үрнәк алган. Иптәшләре дә моны бары туры мәгънәсендә аңлаган. Чөнки бу — хакыйкать. Солдат барысын да, хәтта гомерен дә туган иленә бирә, үзенә бер нәрсә дә сорамый.

Солдат-художник госпитальдән яңадан безгә әйләнеп кайтмады. Әллә сугышта алган яраларыннан үлеп калдымы, әллә ерак тылга озатылдымы, әллә башка частька эләктеме — белә алмадым. Ләкин ул минем хәтеремдә бер легендар кеше булып калды. Карелиядә карлар да эреп бетте, яңадан бөтен җир яшәрде, ә мин юл чатында һаман да күңел күзе белән аның рәсемнәрен күрә идем. Ильич гүя чын тере, күзләрен чак кына кыса төшкән һәм еракка-еракка карый, гүя солдатларны да шул ераклыкларга чакыра, анда — Җиңү.

*Ахыры бар.*

## Ләви Сафаров

### Кулларын күчерә килеп

...Такыр юлдан пар ат чаба,
Күчер тоткан дилбегә,
Әремнәрне җил бөгә...

Дилбегәне тарткан саен
Тизлек артканнан арта...
Бәй, карасаң, дилбегә юк,—
Кулларың рульдә ята...
Чакрым баганалары
Йомылып ага артка...
...Тизлек артканнан-арта...

Бәй, карасаң, йолдызларга
Табан юнәлгән юлың,
Рульдә түгел,
Космик кораб
Штурвалында кулың...
Кулларын күчерә килеп
Дилбегәдән штурвалга
Омтыла илем алга...

### Ник читләргә кылыч күтәрик без

Нәрсә пычагыма жире кирәк,
Суы кирәк безгә читләрнен,—
Үзебезнең җир-су шундый иркен —
Кояш күрми күктән читләрен.

Җиребезнең ел әйләнә шиңмәс
Гөлләре бар,
Эремәс кары бар,
Күлләре бар: зуры, бәләкәе,
Сулары бар, киңе, тары бар...

Ниемә хаҗәт безгә читләр малы,
Үзебезнең байлык аз түгел,
Алтын, алмазларга кытлык түгел,
Азык-төлеккә дә ач түгел.

Татар кумәчләре, башкорт балы,
Балтик балыклары,
Өстәүгә,—
Грузин чәе, үзбәк йөземнәре
Тулып ята безнең өстәлдә...

Нәрсәгә дип инде сугышыйк, ди,
Эш юкмыни безнең кулларга,—
Изгерәк бит, каннар кою түгел,
Тирләр кою барыр юлларда.

Изгерәк бит, җиргә окоп түгел,
Өйләр итеп салу эзләрне...
...Ник читләргә кылыч күтәрик без
Күтәрмәсә алар үзләре?!.

## Музей

Бер музей бар,
Бу музейда
Кыргый скифларның затлы
Савыт-сабаларын саклый
Гасырлар бер-бер артлы.

Монда ихтиозаврларның
Ята ак сөякләре,
Ята шведның кылыч, калкан
Кебек вак-төякләре...

Ашадан-аша дистәләп,
Дәүләт күкрәген тишкән
Наполеонның сөңгеләре
Шушы музейга күчкән.

Биредә куе тут төшә
Браухич пычагына...
Бар да сыйган бу музейга,—
Кара җир кочагына...

## Килә берәү

Килә берәү болын аша
Куе үлән арасыннан,
Бал кортлары колак төбен
Ярып оча ядрә сыман.

Таянган да таякларга,
Бер аяклы берәү атлый,
Баскан җирдән кош атыла,—
Гүя кинәт мина шартлый.

Килә берәү. Аландагы
Уйдыкларга күзе төшә,
Тамчы-тамчы кан чәчрәгән
Төсле булып җиләк пешә.

...Күпме еллар таң сызыла
Тыныч җирне алга буяп.
...Килә берәү. Килгән кебек
Һаман сугыш кыры буйлап.

## Шундыймын шул

Шундыймын шул,
Кара төндә
Ак каенга усал тешле
Пычкы тисә,
Шушы пычкы
Мине төптән кисә төсле...

Шундыймын шул,
Яшел җирне
Явыз куллар бомба ярып
Яраласа,
Минем тәнем
Кала төсле кара янып.

Ләкин берәр ерак илдә
Ата икән таңның зуры,—
Кичекмәстән
Килеп төшә
Минем йөзгә шул таң нуры.

Егермене узгач, исертмәс, дип,
Июнь гөлләренең хуш исе,
Хафаланма әле, дус кеше!
Хафаланма әле, чапкан аттай
Яшьлек язым ярсып узар да
Мөмкин булмас диеп,
Кулыңдагы
Тальяныңны тартып-сузарга...

...Утызда да баш өстендә йөзгән
Тулган айга төбәп карашың,
Яшь егеттәй хәйран каласың,
Утызда да башың әйләндерер
Язгы кичтә ландыш исләре,
Утызда да көмеш тавыш белән
Тальян әйтер синең хисләрне.

...Чәчләремдә чаллар ялтырый, дип,
Җитеп киләмен, дип, кырыкка,
Бер дә юкка, дустым, курыкма!
Кырыкта да сине таң калдырыр
Чәчәкләрнең күге, аклары,
Кырыкта да әле тальяныңның
Сандугачтай сайрар чаклары...

## Бозлар китә, кызлар китә

Язлар килгәч, кояш көлгәч
Елгаларда бозлар китә,
Заман җиткәч, туып-үскән
Йортларыннан кызлар китә...

Бозлар китә, эреп диңгез
Суларына кушылырга,
Кызлар китә, сөйгәннәре
Белән мәңге куш булырга.

Су бозларны алып төшә
Тыныч кына, елга буйлап,
Ә кәләшләр кыңгыраулы
Пар атларда төшә туйлап.

Кире кайтмас өчен агып
Елгалардан китә бозлар.
Бозлар кире кайтмагандай,
Кайтмасыннар киткән кызлар!

**Гариф Галиев**

# АК БАСУ



Әйе, гадәтем буенча мин тагын республикабызның көньяк-көнчыгыш районнарына килеп чыктым. Мин бу якларда җәй башларында берничә тапкыр булган идем инде. Ләкин игеннәрнең серкәләнү вакыты җиткәч, бу яклар мине яңадан үзләренә тартты.

Дөресен әйтим, табигатьнең тәмам тулыланып җиткән көннәрендә, җәй урталарында авылларда ат белән яки җәяү йөрүне яхшырак күрәм. Шунлыктан, Азнакайга килеп төшү белән, басу юллары буйлап җәяүләп киң Ык елгасына таба юл тоттым. Иртәнге якта көн салкынчарак иде. Әмма, кояш төшлеккә күтәрелә башлау белән, һава бөтенләй алышынды: җирне искиткеч эсселек чорнап алды, агач яфраклары шалпераеп төштеләр, игеннәр башларын иделәр, көтүдәге сарыклар борыннарын җиргә төртеп хәлсезләнеп калдылар. Аның каравы, кигәвеннәр котырына башлады.

Сәпәй тауларын үтеп, Ык буена төшеп барганда басу юлында миңа атлы бер кеше очрады. Ул, мине күрү белән, атын туктатып:

— Әйдә, утыр иптәш, бергә-бергә сөйләшеп барырбыз, сөйләшү юлны кыскарта дигәннәр бит борынгылар. Әйдә, утыр,— диде.

Мин, арба урәчәсенә аякларымны салындырып, аның янына утырдым. Ат, һичбер нинди куалауны көтмәстән, юырта башлады. Чөнки аны чыпчык башы чаклы кигәвеннәр талый иде.

Сүз барышында ат хуҗасының Хөҗҗәт исемле умартачы һәм минем белән яшьтәш икәнлеге беленде. Ягъни без замандашлар булып чыктык.

Ат өстендә өзлексез очып барган кигәвеннәр аның канын эчәләр. Җирән кашка, нишләргә дә белми, алардан котылырга тырышып чаба да чаба. Хөҗҗәт минем белән сөйләшкән арада җирән кашкага да дәшеп ала:

— Түз инде, малкаем, түз, хәзер туктарлар, карабодай басуына гына җитик, аннары тын алырсың,— ди.

Озак та үтмәде, алдыбызда ак басу күренә башлады. Җирән кашка чапканнан чаба бирде һәм без ак басуга якынлаштык.

Катык кебек ап-ак чәчкәдә утырган бу карабодай басуына килеп җитү белән, җирән кашка аз гына тынычлап калгандай булды, юыртуыннан туктап, адымнарын әкренәйтте. Ләкин, кигәвеннәр ябырылуыннан башланган бик авыр газапларны ул әле һаман кичерә: еш-еш сулу ала, ара-тирә хәлсез генә пошкырып куя, яңак сөякләрен тәртә башына тигерә-тигерә ышкынып ала. Аның сыртыннан һәм кабыргалары өстеннән кара кан белән катнаш тир ага. Хөҗҗәт аны куаламый, атка ирек куя. Хәер, ни чаклы гына куаласаң да ул хәзер юыртырлык хәлдә түгел шул. Ул кигәвеннәр һөҗүменнән тәмам интеккән инде.

Хөҗҗәт миңа таба борылып, кигәвеннәрне тагы каһәрләп ала:

— Нәкъ дошман бомбардировщиклары кебек, җирән кашкамны тәмам камап алдылар бит. Бичарам, кара канга батты ләбаса! Каһәр суккырлары! Ә монда, карабодай басуына килеп кергәч, тыны беткән дошмандай, туктап калдылар. Алар бит кан исен ярата, ә бередә, карабодай басуында бал исе! — ди.

Дөрестән дә, күз күреме кадәр киңлеккә җәелгән бу ак басудан тәнгә рәхәтлек бирә торган бал исе бөркелә иде. Бер үк вакытта безнең өстебездән, юк, безнең өстебездән генә түгел, ә бөтен басу өстеннән үзләренә бер төрле «без-без-з-з» итеп торган, ярым тыныч тавыш белән умарта кортлары очалар, алар тамак асларындагы күзгә күренмәслек кечкенә «чүмечләренә» тутырылган кыйммәтле йөкләрне ничек кенә булса да умарталыкка тизрәк кайтарып җиткерү өчен ашыгалар. Һәм алар шулкадәр күп ки, хәтта безнең җирән кашканың дугасын да вакыт-вакыт сырып алгандай итәләр.

Хәзер инде җирән кашка да, Хөҗҗәт тә тыныч. Без шулай әкрен генә ак басу уртасыннан барабыз. Мин эчемнән генә уйлап куям: «И табигать, бу нинди матурлык, бу нинди хозурлык, бу нинди гүзәллек! Җиргә карасаң, ак чәчәкләрнең хисабына, күккә карасаң, бал кортларының санына чыгарлык түгел. Монда эшнең иң кайнаган чагы, мин тагы үзем белән үзем сөйләшеп куям, без боларга уңайсызламыйбыз микән, әллә соң без бирегә ялгыш яки иртәрәк килеп кердекме, бу кадәр кызу хезмәт барган чакта безнең бу ак басу эченнән арба белән үтеп баруыбыз ярый микән соң? — дим.— Әгәр ярамаса, кичерегез безне,» — дип, гафу үтенәм.

Хөҗҗәт минем эчке тойгыларымны сизә булса кирәк:

— Сиңа бик ошады бугай карабодай басуы? — ди.

— Карабодай басуы да, бал кортлары да,— дип җавап кайтарам мин.

Ул көлемсерәп сүзен дәвам итә:

— Алар икесе бергә инде. Карабодай белән бал кортларын әйтәм, икесе бергә алар, бергә! Карабодай бал кортына мохтаҗ, бал корты карабодай чәчкәсенә. Умарта асрыйсың икән — карабодай чәч, карабодай чәчәсең икән — умарта асра. Шул вакытта ярмага да, балга да туенырсың, кесәң тулы акчаң да булыр. Шуңа күрә, без аны ел саен кимендә йөз гектар чәчәбез,— ди ул, эчке бер канәгатьләнү белән.

Без инде кайчаннан бирле карабодай басуы уртасыннан барабыз. Ләкин әле басуның чиге һаман күренми. Алда зәңгәрсу урман сузылган. Бу ефәк җәймә ябынган ак басу, бәлки, шул урманга барып терәләдер. Һәм мин замандашым Хөҗҗәтнең сүзенә куәт бирәм:

— Дөрес эшлисез, йөз гектар чәчәбез, дигән идең, ә быел күпме чәчтегез? Без аркылы үтеп бара торган бу басуның чиге күренми бит әле,— дип сорыйм.

— Быелмы, быел йөз илле гектар чамасы чәчтек,— ди ул, миңа карап.

Мин аның җавабын ишетү белән куанып китәм һәм үзем дә сизмәстән, әйтә куям:

— О, шәп! Һәрбер гектар үзе ни чаклы нектар! — дим.

Замандашым кинәт тагы миңа таба борылып карый:

— Һәрбер гектар үзе ни чаклы нектар дисеңме?

— Әйе, шулай дим.

— Син умартачымы әллә?

— Нигә алай дип сорыйсың?

— «Нектар» дигән сүзне гадәттә умартачылар телгә алалар. Ул бит ширбәт дигән сүз. Умарта кортлары чәчкәдән җыеп алган шул ширбәтне эшкәртеп балга әйләндерәләр. Моның шулай икәнлеген умартачылар гына аңлый. Син умартачымы әллә, дип соравымның сәбәбе шул иде,— ди.

Мин аңа колхозлашу елларында агротехник булып йөргән чакларымны, аннары ничектер җае килеп чыгып, алты айлык умартачылык курсында укыганлыгымны һәм соңыннан инде читтән торып булса да авыл хуҗалыгы институтында укып, сугыш чыгу аркасында аны тәмам итә алмаганлыгымны кыскача гына сөйләп бирдем. Шулай сөйләп бирдем дә, замандашымның үзе кебек, туп-туры йөзенә карап, сөйләгәннәремә йомгак ясадым:

— Һәрхәлдә, минем умарта кортының шәпшә түгеллеген, шәпшәнең умарта корты түгеллеген аңларлык дәрәҗәдә белемем бар,— дидем.

Замандашым кычкырып көлеп җибәрде:

— Бик кызык әйттең. Шулай, шулай... дусны дошманнан аера белергә кирәк. Дошман дигәннән, син сугышта булгансыңдыр, ягъни солдатта хезмәт иткәнсеңдер?

— Иттем, иттем, действительный хезмәттә дә, Ватан сугышында да булдым,— дидем мин.

— Алайса син карабодай боткасының тәмен беләсең инде?

— Һи-и-и, белмимме соң:

Без торасы казарманың,
Бакыр икән токасы,
Солдатларның яратканы—
Карабодай боткасы,—

дип, тиккә генә җырламаганнар инде аны. Солдатларга карабодай боткасын ашату ул бит безнең бабаларыбызның бабалары хезмәт иткән Суворовлар заманыннан калган гадәт. Карабодай боткасына бер нәрсә дә җитми,— дидем мин аңа.

— Дөнья күргән кеше икәнсең, кордаш, аннан да җиңел, аннан да тәмле ризык юктыр дип уйлыйм мин.

Көн кыздырганнан кыздыра бара, ак басу өстен нечкә билләр каплап алган, аларның кайсылары, йөкләрен бушатканнары, чәчкәләргә төшеп кунालар, ә кайсылары нектар төяп чәчкәләрдән кузгалып китә. Алары да, болары да — барысы да өзлексез очалар, күтәреләләр, ләкин һич кенә дә буталмыйлар, бер-берсенә юл куя-куя умарталыкка ашыгалар.

Умарталык дигәннән, башыма сорау килде: «Кайда икән соң боларның умарталыгы».

Табигать тарафыннан бик акыллы, бер үк вакытта бик серле итеп яратылган һәм кешеләргә гел файдага гына эшли торган бу җан ияләренә карап мин хәйран калдым. Һәм секунд эчендә күңелем белән революция елларына кайтып киттем һәм шул елларның бер документы исемә төште. Ул чакларда мин, халык теле белән әйткәндә, «кәнсәләр», ягъни авыл Советы тирәсендә еш урала идем. Шуңа күрәдер инде, бу документ минем хәтеремдә аеруча нык сакланган. Бу РСФСР Халык Комиссарлары Советының «Умартачылыкны саклау турында»гы 1919 ел 11 апрель карары иде. Аңа Владимир Ильич Ленин кул куйган. Бөтен кешелек дөньясын бәхетле итү өчен көрәшкән бөек юлбашчыбыз Ленин илебез төрле яктан дошман тарафыннан камалып алынган әнә шул авыр елларда да бу мәсьәләне карарга вакыт тапкан. Ул ни кадәр кешелекле һәм эшчән булган. Безнең илебездә борын-борын заманнан яшәп килгән умартачылык беренче бөтен дөнья сугышы елларында бик аяныч хәлдә калган һәм аны бик тиз аякка бастырырга кирәк булган. Бөек Ленин шуны алдан күргән, шуңа күрә дә югарыдагы карарны кабул иткән.

Без замандашым белән һаман барабыз. Безнең баш өстебездә һаман бал кортлары очалар, туктаусыз безелдиләр. Ниһаять, без карабодай басуын аркылы үтеп, урман авызына килеп чыгабыз. Замандашым Хөҗҗәт:

— Менә, умарталыкка да килеп җиттек, безнең умарталык шушы урман эчендәге аланда,— ди.— Хәзер бер кулага урын табып атны тугарырбыз да янына төтен салырбыз. Аннары мин сиңа умарталарыбызны күрсәтермен. Бик ашыкма, әле көн уртасы гына, барасы җиреңә барып җитәрсең. Безнең монда кечкенә генә өебез дә бар, шунда кереп яңа бал белән каты чәй дә эчәрбез,— дип дәвам итә ул.

Умартачыларның һәркайсының да үзләрен бик тыныч тотуларын, әкрен һәм йомшак сөйләшүләрен мин яхшы беләм. Шуның өстенә алар бөтенесе дә гаҗәп кунакчыл булалар. Әгәр, юл уңае туры килеп, умарталыктан үтсәң икән, алар сине хөрмәт итмичә җибәрмиләр. Шулай булгач, мин Хөҗҗәтнең бу тәкъдименә ничек каршы килим. Аннары бит мин үз иркем белән дөнья күрергә чыккан кеше. Шулай булгач, аңа рәхмәттән башка нәрсә дисең инде.

— Мин бик риза, замандаш,— дидем аңа.

Без, урман эченә кереп, бер карт имән төбенә туктадык та җирән кашканы тугарып, аны тезгененнән арба урчаесенә бәйләдек. Хөҗҗәт арба төбендәге чалгыны алып, берничә бөтерем печән чапты һәм мин ул чапкан печәнне ат алдына, арбага китереп салдым. Хөҗҗәт, ат тугарган урыннан шактый читкәрәк китеп, чалгысын бер имән ботагына элде дә арба янына килде һәм, тирә-юньнән чүп-чар җыеп, аның өстен яшел үлән белән каплап, төтен салды:

— Үзең дә кайчандыр умартачы булгач, беләсең инде, бал кортлары тирләгән ат исен бер дә яратмыйлар. Шунлыктан, мин һәр вакыт җирән кашканы умарталыктан ераграк булган урынга тугарам. Ярый, бусы да булды. Әйдә инде киттек! — диде.

Без ямь-яшел яфракка күмелеп утырган ак каеннар арасыннан атлый-атлый умарталыкка юнәлдек. Монда бал кортларының очканы күренми. Хәер, аларның умарталыкка кайта торган үз юллары була бит. Алар шул юлдан очалардыр. Һава тын һәм салкынча. Агач яфраклары арасында кояш нурлары уйный. Ул алдан, мин аның артыннан атлыйм. Йомшак күңелле, тәмле телле, ачык чырайлы бу кеше белән сөйләшкәннән сөйләшәсем килә һәм мин аңа үземнең фикерләремне әйтмичә кала алмыйм:

— Карабодай басуы белән умарталыгыгызның янәшә булуы мине бик тә шатландырды. Син инде, Хөҗҗәт замандаш, үзең дә яхшы беләсең, карабодай басуына умарталык якын булса, югары җыем алу тәэмин ителгән диган сүз. Әлбәттә, карабодайны ел саен умарталыкка якын җиргә чәчеп булмый бит. Ул чәчү әйләнешендә кайсы басуга туры килә, аны шунда чәчәсең. Андый вакытта умарталарны карабодай басуы янына күчерә торгансыздыр инде,— дим.

— Билгеле шулай эшлибез. Умарталарның бер кадәресен шушында, ягъни умарталыкта калдырабыз, ә бер кадәресен карабодай басуы янына күчерәбез. Ә инде мәгълүм бер вакыт үткәннән соң, аларны янәдән умарталыкка кайтарып урнаштырабыз,— ди Хөҗҗәт.

Менә без киң генә аланга килеп чыгабыз. Аланның читендә такта белән ябылган кечкенә генә өй күренә. Хөҗҗәт:

— Мин сиңа битлек алып чыгыйм әле,— дип, шунда кереп китә.

Мин төрле-төрле төстәге умарталар тезелгән, ниндидер сәер тынлыкка чумган, мең төрле чәчкәләр белән капланган матур аланга карап торам. Уйларым әллә кайларга китә, без, мин әйтәм, бу җан ияләренең искиткеч хезмәтчеллекләрен, аларның кешеләргә авызлары белән бал җыюларын, аяклары белән үсемлекләрне серкәләндерүләрен һәм бер-берсенә нинди мөнәсәбәттә булуларын, хәтта аларның нектар барлыкны һәм анда кайсы юлдан барырга кирәклекне бер-берсенә биеп күрсәтүләрен дә беләбез. Ә шулай да без бу нечкәбилләрнең бөтен серләрен төшенеп җитмәгәнбез әле, минемчә...

Янәма кулына бер битлек тоткан Хөҗҗәт килеп баса:

— Әйдә, мин сиңа умарталарның кайберләрен ачып күрсәтим әле, өченче көн генә бал аерган идек, бүген рамалар ничек микән,— ди.— Әйдә, кайберләренең өсләрен ачып карарбыз, рамалары тулган булса, бүген-иртәгә суыртырга кирәк булыр.

Мин битлекне киям һәм тагы аның артыннан атлыйм.

Хөҗҗәтнең үзенә битлек-фәлән кирәкми. Аны бал кортлары ят итмиләр. Ул тавышсыз-тынсыз гына, йомшак һәм чиста куллары белән умарталарны ачып, аларның рамаларын карый. Аннары иплэп кенә ябa. Бал кортлары аның бармакларын, беләкләрен сырып алалар. Ләкин чакмыйлар, алар гүяки иркәләнәләр, гүяки без хәзер тагы йөк белән кайтабыз, син безне каршы ал, дигәндәй аның белән сөйләшәләр кебек тоела миңа.

Бераздан соң инде без өйгә керәбез. Хөҗҗәт бусаганы атлау белән борынгы җиз самовар колагына тотына:

— Бик сусадым, син дә сусагансыңдыр, хәзер кайнап чыгар, иркенләп чәй эчик әле,— ди миңа.

Ул самовар куйган арада, мин өйдәге әйберләргә күз салам. Биредә гади генә өстәл, аның янында ике-өч урындык, бер биек кенә имән бүкән, стенада берничә агач чөй, кечкенә генә мич, мич белән стена арасына тар гына чаршау корылган, анда нәрсә барлыгы күренми. Ишек өстенә төтен салгычлар, битлекләр, иске һәм яңа рамалар кебек умартачылыкта кулланыла торган кирәк-яраклар эленгән. Түрдә исә стенага беркетелгән шүрлеккә радиоалгыч урнаштырылган.

Шуларга карап утыра торгач, замандашым Хөҗҗәтнең өйдән чыкканын да күрми калганмын. Менә ул кулына бал тутырылган яшел миски тотып килеп тә керде:

— Подвалга чыккан идем, яңа бал белән чәй эчеп җибәрик. Теләсәң, әнә анда чаршау артында әчесе дә бар. Мәгәр мин үзем аны кулланмыйм. Нәфсең булса, бер касә салып бирим,— диде ул.

— Баллап каты чәй эчүгә ни җитә. Юк, юк, мин дә синең кебек, аеруча мондый эссе көннәрдә андый әйберләрне өнәмим,— дидем мин.

Чәйгә утыргач, безнең әңгәмә яңадан куерып китте. Бая карабодай басуында без бал кортлары турында сөйләшкән булсак, хәзер без карабодай турында сүз алып бардык. Хөҗҗәт карабодай игүнең агротехникасын агрономнар белән бер дәрәҗәдә тирәнтен белә икән.

Ул сөйләде, сөйләде дә аеруча басым ясап әйтеп куйды:

— Мине ялгыш аңлама, карабодайга гына карап торыгыз диясем килми, барлык файдалы культураларны игәргә кирәк. Без, кешеләр, аларның бөтенесенә дә мохтаҗбыз. Аларның һәр кайсының үзенең тоткан урыны бар. Ләкин, умартачы буларак, мин карабодайны игүне тагы да алгарак җибәрү ягында.

Озак сөйләшеп утырдык без аның белән. Ниһаять, миңа китәргә вакыт җитте. Чөнки мин алдагы авылга барып кунарга тиеш идем.

Без өстәл яныннан кузгалганда, кояш шактый түбәнәйгән иде инде. Ул мине урман авызына кадәр озата килде һәм:

— Сиңа уңышлы сәфәр телим, замандаш. Юлың туры килсә дә, килмәсә дә кәз көне тагы бер әйләнсәң иде безнең бу тирәләрдән.

Без саубуллаштык. Ул умарталыкка таба атлады. Мин тиз генә кузгалып китмәдем. Чөнки күзләремне әлеге ак басудан ала алмадым. Минем бу басуны калдырасым килми, аннан аерылырга күңелем теләми, күзләрем өзлексез безләп торган «нечкәбилләр»дән аерыла алмый, күкрәгем бал исе катнаш саф һаваны сулап туймый иде.

...Көз көне республикабыз илебезнең элеваторларына туксан ике миллион поттан артык ашлык салды. Мин шушы зур саннар эчендә карабодайның моңа кадәр мисалы булмаган зур урын алганлыгын күреп таңга калдым. Ә инде Партиябез Үзәк Комитетының Октябрь Пленумында безнең республикабыз карабодай игүдә мактап телгә алынгач, миңа яңа канатлар чыкты һәм мин кадерле Татарстанымның көньяк-көнчыгыш районнарындагы ак басуларга күңелем белән яңадан очтым.

**Нәкый Исәнбәт**

# ТУКАЙНЫҢ ӘЛЕГӘЧӘ ИГЪЛАН ИТЕЛМӘГӘН БЕР ШИГЫРЕ

Реклам-шигырь язу тәҗрибәсе әдәбиятта бар нәрсә. (Әйтик, Маяковскийда да очрый.) Габдулла Тукай да, «Караван» дигән чәй фирмасының чәен рекламлаштыру өчен, озын гына бер шигырь язган. Бу шигырь 1908 елда «Мәгълүмат» дигән җыентыкта («Бәянелхак» нәшере), игъланнар бүлегендә басылып чыккан. «Бәянелхак» газетасы — Печән базары органы, аны карагруһчы Әхмәтҗан Сәйдәшевлар чыгарган. Тукай, билгеле, бу орган белән идея дошманы. Ул «Дин мәгыйшәт» белән бергә аны да өзлексез сатира уты астына ала. Тукайның озын гына бу реклам-шигыре ни сәбәпле язылган һәм ул ничек шул органның нәшере «Мәгълүмат» җыентыгына килеп кергәндер, ул хәтлесе миңа бик үк ачык түгел. Тик шунысы билгеле, Тукай аны Уральскидан Казанга килгәч, җиденче елларда ук язган. Ул Казанга килгәч, шактый мохтаҗлыкка төшә, экспедитор булып та, игъланчы булып та эшли. Аның «көйле игълан» язып ташлавы да, ихтимал, шундый берәр авыр хәл аркасында килеп чыккандыр. Әмма ни генә булмасын, шигырь язылган һәм басылган. Тагын шунысы да бар. Игълан шигырь булгач, Тукай аны үз гомерендә ясаган ике зур хатасыннан берсе итеп санаган, диләр. Бик мөмкин. Бу шигырьнең ашыгыч һәм бер кизәнүдә сызгалап ташланган булуы аның кайбер юлларыннан ук күренеп тора. (Мотив яки сүз кабатланулар.) Әсәрнең 72 юлга сузылган озын шигырь булып китүе дә, бәлки, шуның аркасында килеп чыккандыр һәм Тукай, ихтимал, ул ягын да килештереп җиткермәгәндер. Чөнки ул күп сөйләргә, сүзен кабатларга яратмый. Бу да — аның бер традициясе.

Шуна күрәмедер, яки башка берәр сәбәптәнме, шигырь астында хәтта Тукайның имзасы да юк! Ул шундый көйле бер игъланмы игълан. Замандашларыннан кайберәүләр шигырьнең кемнеке икәнен сизгәннәрдер, әмма без бу шигырьнең чынлап та Тукайныкы булуын 1911 елда «Күңел җимешләре» дигән җыентыгында басылган берничә өземтә юлларга карап кына белә алабыз. Ләкин анда инде бу шигырь «Караван» игъланы итеп түгел, бөтенләй үзенә аерым-башка бер әсәр итеп бирелгән.

Күрәсең, шигырь башта шулай игъланнан гына «килеп чыккан» булса да, Тукай бу иҗатыннан шактый канәгать булган һәм әсәренең бөтенләй югалып калуын үзе дә теләмәгән, өлешчә булса да аны саклап калу чарасын күргән.

Аннан соң Тукай үзе ничек кенә карамасын, аның бу шигыре, шулай имзасыз һәм язмышы да шундый каршылыклы булуына карамастан, иҗаты өчен характерлы һәм

безнең өчен дә әдәби-тарихи кызыклы булуын югалтмый. Киресенчә, бу әсәр, шулай беркадәр эскиз хәлендә булуы белән, безгә Тукайның иҗат лабораториясен, «шигырь кухнясе»н ачарга нык ярдәм итә. Чөнки 72 юлга сузылган бу «игълан-шигырь»дә (хәтта игъланда да!) шигырь өчен кирәкле сюжет һәм Тукайга хас композиция бөтенлеге, шулай ук башка кызыклы компонентлар бар.

Тукай аңа «тәүлек» дип сүзбаш куйган. Анда «вакыйга», дүрт бүлеккә бүленеп, бер тәүлек буена — иртәдән башлап төнгә кадәр алып барыла. Шигырьнең шулай дүрт бүлеккә бүленүе дә матчадан алып, коры бер форма өчен генә эшләнмәгән, бәлки тормышның үз диме буенча, Тукайның да халык тормышын, шул тормышның үз димен сиземләве буенча язуыннан килеп чыккан.

Татарның бит әле тагы шундый бер яхшы гореф-гадәте дә булган: тәүлеккә өч мәртәбә табын янына җыелып чәй эчү. Монда бу күркәм йоланы халыкка кертү һәм алкогольле эчемлекләрне табыннан шул чәй белән кысрыклап чыгару өчен көрәш моменты безнең өчен мөһим. Бу көрәш, бездә кайберәүләр уйлаганча, җиңел һәм юк бер вак эш кенә түгел, сәяси һәм иҗтимагый төс алган көрәш. Чөнки бит империалист патша хөкүмәтенә, чит илләрне һаман да күбрәк һәм тизрәк басып алу өчен, дөнья тутырып казарма белән төрмә салырга, корал коярга кирәк. Ә бу эшләр хисапсыз күп акча сораган. Хөкүмәткә, үзенең тулмас казнасын тутыру өчен, имана-салымнар җыю гына җитмәгән, халыкны тагын да ныграк талау һәм үзенә дә сиздермичә генә талау өчен, аны миенә хәтле агуларга кирәк булган. Моңа иң кулай, иң шәп чара итеп, хәйләкәр патша хөкүмәте кабак ачкан.

Ләкин халык нигездә айнык һәм сәламәт булырга, кырылып бетмәскә, яшәргә тырышкан[1]. Патша хөкүмәтенең бу мәкерле «алкоголь культурасы»на каршы халык, аеклык чарасы итеп, чәй эчүчелекне алга сөргән. Чәйне дә шулай табын яме, мәҗлес йоласы итеп үзләштерү, аны халыклаштыру, әлбәттә, үзеннән-үзе генә килеп чыкмаган, аның өчен шактый гына озак һәм даулы көрәшләр дәвам иткән. XVIII—XIX йөз әдәбиятыбызга каралса, бу көрәшкә күп кенә шагыйрьләр катнашканнар, аңа уңай һәм каршы яктан торып шигырьләр, бәетләр һәм хәтта мөнәҗәтләр дә язганнар. Ахырында чәй аракыны җиңеп чыккан: ул татар җәмәгатьчелегендә төп бер азык һәм табын хөрмәт-сые булып киткән. Азык-төлек, чәй-шикәр кибетләренә аракы кертелмәгән, керсә чыгартып ташланган. «Кәҗүнкә» татар авылларыннан куылган. Казанда да аны «Эт тыкрыгы» кебек урыннарга куып кертканнәр. Шул көрәшләр нәтиҗәсендә, безнең халыкта бу «яшел аждаһа»га каршы «иртә чәй», «төшке чәй», «кичке чәй» дигән күркәм йола ясалып өлгергән. Татар тәүлегенә өч мәртәбә матур итеп «табын корган». Ул «чәй агызмаган», ә «чәй ясаган». Үз завыгынча шундый күңелле чәй табыны әзерләвен халык иҗатында да күп төрле чагылдырган. Мәсәлән:

Түгәрәк-түгәрәк җир күрдем,
Уртасында күл күрдем,
Унике аккош тиң күрдем,
Алтын үрдәк бер күрдем, —

дигән табышмак-шигырендә табынны түгәрәк җиргә, подносын түгәрәк күлгә, чынаякларын аккошларга, самавыр яки чәйнеген алтын үрдәккә тиңләгән.

Тукай, «Караван» чәй фирмасына игълан язу белән бергә, «чәй» һәм «самавыр»ның халык тормышындагы иҗтимагый роленә әһәмият бирә. Ул чәйнең эштән соң тәнгә-җанга ял бирүен мактый, аның күңелләргә завык һәм ямь-тәм бирүен алга сөрә.

---

[1] Документларга караганда, Казан өлкәсендә күпләп кабак ачу бик иртә, Казан алынгач та, патшаның кат-кат үз указы буенча алып барыла. Өяздә калган төп җирле халыкны колонияләштереп, алкоголь белән түндерү, я булмаса «итагатьле христиан» колга «дүндерү» өчен, дингә көчләүләр аракы белән бергә алып барылган. Ләкин ул чагында татарлар патша хөкүмәтенең бу сәясәтенә нигездә алданмаганнар, күрәсең. Мәсәлән, 1581 елда Казанның Нугай юлында ачылган кабак буш тора (эчүче юк!), Мишә тамагы, паром янындагы кабак та буш тора һ. б. (Карагыз: ЦГАДА. 642 эш. Писцевая книга Ивана Болтина Казанского уезда. 1602—1603 еллар. 31 һәм 36 битләр.)

Шуның белән ул элекке «чәйчеләр» йоласын дәвам иттерә. Ләкин Тукай, татарның тәүлеккә өч мәртәбә чәй эчүенә карап, шигырендә дә тәүлекне өчкә бүлми, бәлки аны дүрт тигез буынга бүлә. Игътибар итегез, монда бер кызык хикмәт бар: анычча, татар чәйне шул хәтле ярата ки — гадәт буенча өч мәртәбә эчеп кенә күңеле канмый, дүрт мәртәбә эчә һәм... дүртенчесен йоклагач төшендә эчә. Монысы инде Тукайга хас тапкырлык, юмор осталыгы. Һәм шигырь шуның белән тәмам була.

Менә ул шигырь:

# Тәүлек

Иртә дөнья җанлана,
Мәшрикъ ягы аллана,
Кояш чыгып, нурлары
Төшеп җиргә ялгана.

Яктыра кала, урамнар,
Кырлар, якын урманнар,
Таулар, баглар, бакчалар
Нурга гарык булганнар.

Торды халык, уянды
Шау-шу һәрбер төшләрдә,
Көтү-көтү менмәктә
Күккә житез кошлар да.

Төтен төсле, җирдән дә
Күтәреләдер томан;
Нинди вакыт бу вакыт,
Беләсеңме, и туган!

Бу вакытта йорт саен
Кайный самавыр һаман,
Чәйнекләрдә пешмәктә
Чәй фирмасы «Караван».

Өйдә хуш ис чәчелгән,
Һәркем күңеле ачылган,
Нинди фирма чәе бу
«Караван»дыр, «Караван!»

●

Көн уртасы шәһәрдә
Гадәтчә шау-шу тавыш,
Җанлылык бар һәр җирдә,
Селкенү, йөгерү, кузгалыш.

Ашыкмакта һәркем дә
Артыннан куган төсле,
Барчасы бергә шунда
Бай, ярлы, эшсез, эшле,

Кайный тормыш дулкыны —
Әйтерсең, каты буран,
Шул арада тагын да
Мәшһүр фирма «Караван».

Чәе исләргә төшеп
Халык эшне ташлыйлар,
Тәмле-тәмле сөйләшеп
Чәй эчәргә башлыйлар.

Кич аз-азлап тынлана.
Халык эшне ташлыйлар,
Тәмле-тәмле сөйләшеп
Чәй эчәргә башлыйлар.

Кич аз-азлап тынлана
Шаулап торган бу кала,
Арып-талып юнәлә
Һәркем рәхәткә таба.

Кояш мәгърибкә китә
Тәмле хуш исле һава;
Күңелләрне хуш итә,
Була җаннарга дәва.

Каплый җирне тагын да
Түшәлә башлый томан,
Бу вакыт ял иткәндә
Эчәләр чәй «Караван».

●

Чәен эчә, ял итә
Рәхәт таба арганнар.
Һәрберсе дә үзләрен
Михнәттән коткарганнар.

Төн. Ай күктән караган,
Йолдызлар да парлаган,
Ялт иттергән каланы,
Ай нуры алтынлаган.

Халык сүнгән, йоклаган,
Тәннәрдән чыккан «рәван»,[1]
Эчә болар төштә дә...
Чәй фирмасы — «Караван».

---

Алданмаска лазымдыр
Аерып акны карадан,
Шаять инде мәгълүмдер,
Нинди фирма «Караван».

[1] «Рәван» — монда тир чыгу мәгънәсендәрәк, киная. «Рәван җан» — асылда, төш күргәндә «тәннән чыгып» йөри торган җан дип ышанудан әйтелгән мифик сүз.

Шигырьдә кабатланган «Караван» сүзе, фирма исеме булса да, безгә, бигрәк тә бүгенге укучыга, алай гына тоелып калмый. Ул, ничектер тагы, караван белән йөрү кебек булып та янгырый һәм ул сүз безне, ничектер, элекке Россиядә тимер юллар салынмас борын, каяндыр ерактан, көнчыгыш илләрдән караван белән чәй ташыган заманнарга алып китә. Ягъни, шигырьдә бу сүзнең безнең өчен үзенчә тарихи ассоциациясе, үз тәме бар.

Тукай чәйгә болай шигъри әһәмият бирүеннән шундый бер сорау күңелгә килә: ул үзе чәй эчәргә ярatканмы? Бу биографик мәсьәлә. Яшерен түгел, аны, буйдак Тукайны, Казанга килгәч, кайбер «дус»лары чәйгә түгел мәйгә тарталар. Казанның күп кенә талантларны «имгәтеп ташлый» торган бу начар гадәтне йоктыруы Тукайның саулыгына да авыр тәэсир ясый, әлбәттә. Ничек кенә булмасын, әмма бу шигырьне укыгач, Тукай шуңа чаклы үзе дә чәй яраткандыр кебек тоела. Мөгаен, яраткандыр...

Тукай бу игълан-шигыреннән «баш тарткач», берничә куплетны алып, соңрак «Иртә» дигән исем астында түбәндәгечә икенче әсәр бастыра:

## Иртә

Иртә. Дөнья җанлана,
Мәшрикъ ягы аллана,
Кояш чыгып, нурлары
Төшеп җиргә ялгана.

Яктыра кала, урамнар,
Кырлар, якын урманнар.
Таулар, баглар, бакчалар
Нурга гарык булганнар.

Торды халык, уянды,
Шау-шу һәрбер төшләрдә,
Көтү-көтү менмәктә
Күккә җигез кошлар да.

Шушы вакыт балалар
Мәктәп таба баралар,
Букчалары — артында,
Алар гыйлем дәртендә.

Тукайның бу ике шигырен чагыштырып караганда, әдәбият белгечләре шактый кызыклы кайбер нәрсәләр өйрәнә алырлар дип уйлыйм. Ә менә Тукайның соңгы академик басмасында бу шигырьгә бирелгән аңлатма үзенең гыйльми дәрәҗәсе белән безнең өчен тагын да гыйбрәтлерәк. Сүз шул шигырь уңае белән барганга күрә, бу урында аңа да тукталып үтик. II том, 361 нче битне ачабыз. Анда «171 бит» дигән башлам белән шушындый аңлатма бирелгән:

«Иртә». «Күңел җимешләре» исемле җыентыкта (1911 ел) басылган. Рус телендәге «Утро» исемле шигырьдән файдаланып язылган. Ул шигырь түбәндәгечә:

«Румяной зарею
Покрылся восток,
В селе за рекою
Потух огонек.

Росою окропились
Цветы на полях,
Стада пробудились
На мягких лугах.

Седые туманы
Плывут к облакам,
Гусей караваны
Несутся к лучам.

Проснулися люди,
Спешат на поля,
Явилося солнце,
Ликует земля».

Тукайдагы «Иртә» шигырендә 16 юл. Тукай аннан файдаланып язган дип китерелгән бу русча шигырьдә дә 16 юл. Шулай булгач, бу китерелгән 16 юллык русча текст үзенең бер генә сүзе белән булса да Тукайның аннан ничек «файдаланган» булуын исбат итәргә тиеш иде. Ләкин ичмасам бер генә шундый сүз табылса икән! Хәер, бер сүз бар икән барын: ул да русчадагы «восток», Тукайда «мәшрикъ ягы» (көнчыгыш) дигән сүз очравы. Шул бер сүз аның русча шигырьдән «файдаланып язылган» булуына дәлил була аламы? Андый «восток» сүзе кергән шигырьләр бик күп табылачак бит. Татарда да «шәрык», «көнчыгыш» кебек сүзләр кергән шигырьләр бер Тукайда гына түгел.

Аннары тагын Тукай файдаланган шигырьнең русчасы шушы дип китерелгән әсәрнең авторы күрсәтелмәсә дә, ул Пушкин әсәре бит әле. Анысы бик яхшы. Тик шунысы гына бераз сәер: ул Тукайга караван чәенә игълан язу өчен дә шулай Пушкин томнарыннан актарып, илһам һәм материалны аннан эзләргә кирәк булды микәнни? Шулай итеп, ни бу шигырьнең заманы, тормышы, материалы ягыннан, ни максат һәм вазифалары ягыннан, ни үзенең темасы, формасы, сүзләре, мотивлары, сюжет-композицияләре ягыннан, бер-берсенә берничек тә туры килешми торган бу ике әсәрнең нигезләре бер булуы турында кайбер галимнәребезнең шундый «гыйльми ачыш»ларын күргәч, чынлап та кайбер уйларга төшмичә мөмкин түгел. Бу бит бездә һаман очрап торган хәлләрдән.

Шул уңай белән безгә Тукайның академик басмасына аеруча әһәмият бирергә кирәк. Анда гарәп-фарсы сүзләрен татар орфографиясенә күчләп буйсындыру аркасында Тукай әсәрләрен ритмик бозып бастыру кебек нәрсәләр әле дә бик күп. Тукай әсәре булуы шөбһәле яки бәхәсле нәрсәләр дә бик катгый гына «анык» дип расланып кереп киткәләгән, яки пешми калган җырга мисал кебек шаярып язган әйберләре дә аның мәкалә текстларыннан алып, махсус сәхифәдә Тукайның «пешкән шигырь»ләре рәтендә басылуы кебек хәлләр бар. Бигрәк тә томнарның ахыргы якларында бирелгән академик белешмәләр яңадан бик күп гыйльми җентекләп эшләүне сорый. Аларда баягы текст кебек мисаллар гына түгел, бәлки, әле күрсәтеп үткәнемчә, нигездә дөрес булмаган принципта торып эш итү бәлаләре дә күренә.

Наип Лаисов

# ТУКАЙ ЛИРИКАСЫНДА ЭЛЕГИК МОТИВЛАР

Рус поэзиясендә янсә кайбер башка әдәбиятларда элегиянең[1] бай традициясе бар. Баратынский, Пушкин, Лермонтов, Некрасов элегияләрен янсә әрмән поэзиясендә гасырлар буена тарихи элегияләр язу традициясен генә искә төшерик.

Тукайга кадәрге татар поэзиясендә исә элегиянең, жанр буларак, әдәбият үсеше тарихында сизелердәй эз калдырган аерым этапларын күрсәтеп булмый. Шулай да тарихы гасырларга сузылган татар әдәбиятында да элегик шигырьләр язуның халык иҗатыннан һәм борынгы әдәбияттан килә торган билгеле бер традициясе булган, билгеле. Борынгы лиро-эпик поэмаларда авторларның кайгылы хисләрен белдергән лирик чигенешләр, кайгы-хәсрәт чигүче геройларның лирик монолог-газәлләре, мәрсияләр һәм кайбер башка төр шигырьләр элегик лириканың аерым үрнәкләре булып торалар. Бу традицияләр, XIX йөз һәм XX йөз башы шагыйрьләрендә үстерелә барып, Габдулла Тукай лирикасында чын-чыннан яңарыш чоры кичерәләр. Бөек Тукай поэзиясендә элегия заман кешесенең тормыш турындагы газаплы уйлануларын, аның психологик портретын, явызлыкка нәфрәтен бөтен тирәнлегендә сурәтли алырлык поэтик формага әйләнә.

Тукай лирикасының үзенчәлекле бу төре тәнкыйтьтә әле аз өйрәнелгән. Дөрес, шагыйрь иҗатын өйрәнүнең төрле этапларында аның элегияләренең характеры, аерым үзенчәлекләре турында күп кенә фикерләр әйтелде. Ләкин Тукайга багышланган хезмәтләрдә аның элегияләре махсус өйрәнелмәделәр. Бу күзәтүләр, башлыча, шагыйрь лирикасындагы элегик кичерешләрнең [күп очракта төшенкелек мотивларының] сәбәпләрен ачыклау планында алып барылды.

Әмма Тукай элегияләрен аларның специфик үзенчәлекләреннән, лирик поэзиядә тормышны сурәтләүнең бер формасы буларак, әдәбияттагы функцияләреннән чыгып карау, безнеңчә, мәсьәләне киңрәк планда куярга, элегик кичерешләрнең объектив эчтәлеген, идея-эстетик әһәмиятен билгеләүдә киңрәк нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирер иде. Мәсьәләне махсус өйрәнү шулай ук Тукай лирикасындагы элегик кичерешләрне хронологик яктан да киңрәк рамкаларда ачыкларга мөмкинлек бирәчәк. Чөнки, конкрет анализ күрсәткәнчә, элегик мотивларны, реакция елларында гына түгел, бәлки теге янсә бу формада һәм теге янсә бу күләмдә шагыйрь иҗатының башка этапларында да күрергә була.

Шагыйрьнең беренче әсәрләрендә элегик мотивлар юк диярлек. Моның сәбәпләрен төрлечә аңлатып булыр иде, әлбәттә [Тукайның әдәбиятта әле беренче адымнар гына ясавы, төрле әдәби традицияләрне, поэтик форма һәм жанрларны үзләштерү һәм куллануда тәҗрибәнең аз булуы һ. б.]. Ләкин, безнеңчә, бу очракта мәсьәләне шагыйрьнең социаль карашларының, политик идеалларының чикләнгәнлеге белән

[1] Антик поэзиядә «элегия» (грекча elegos — зар, зарлану) дип кайгы-хәсрәт хисләрен, газаплы уйларны белдергән шигырьләрне атаганнар. Әмма элегиянең эчтәлеге шагыйрьнең шәхси кичерешләре, моң-зары, интим хисләре белән генә чикләнми. Элегик әсәрләр катлаулырак, аларда тормыш турында тирән борчылулар, кайгырулар да белдерелергә мөмкин.

аңлату — тулырак та, дөресрәк тә кебек. «Голүмен бакчасында...» исемле шигырендә, мәсәлән, Тукай: «Мәхәл вармы борынгыдай хәзән, хәсрәт, әләмнәргә!», ягъни элеккечә кайгы-хәсрәт һәм ачынуларга урын бармы хәзер,— дип сорый. Һәм шагыйрь әлеге сорауга кире җавап бирә. Авыр, кайгылы минутлар юк хәзер, «китте хәсрәт, әләмнәр» («Хөррият хакында»), ди ул. Чөнки патша хәзрәте «җуйды халык хәсрәтен» («Иттифак хакында»), «азатлыкның кояшы тугды» («Дусларга бер сүз»). Димәк, аның уйлавынча, «хөррият диңгезләре ташып» торган вакытта хәсрәтле уйлануларга урын юк булып чыга. Күрәсез, конституцион иллюзияләр яшь шагыйрьгә тормышның ачысын-төчесен, халыкның кайгы-хәсрәтен күрергә комачаулый әле. («Дусларга бер сүз» шигырендә Тукай хәтта: «Бу хөррият манифест государьдыр,— кадрен белеп, кирәкләрне сорыйк, имди»,— дип тә яза.)

Дөрес, иҗатының башлангыч чорында язылган шигырьләрендә дә Тукай тормышның күңелсез якларын бөтенләй үк инкарь итми, реаль күренеш буларак, аларның барын таный. Аның «Шәкерт, яхут бер тәсадеф» исемле шигырендә ач-ялангач шәкертне сурәтләве янсә «И каләм!» шигырендә тормыштагы «хәсрәт, хурлык, мескенлекләр» турында язуы шул турыда сөйли. Әмма, беренчедән, күңелсез тормыш турындагы аерым фикерләр шагыйрьгә үзенең мәгърифәтчелек программасын пропагандалау өчен генә кирәк. Тукай әлеге хәерче шәкертне, мәсәлән, тормышта кайгы-хәсрәт калмасын өчен, мәгърифәт җимешләреннән файдаланырга, белем сукмагыннан барырга чакыра. Икенчедән, лирика өчен нинди дә булса хиснең, тормыштан алынган тәэсирләрнең поэтик кичереш төсендә бирелүе шарт. Ә бу шигырьләрдә халыкның борчылулы, кайгылы уйлары шагыйрьнең үз кичерешләренә әйләнми. Бу әле — уйфикерне кичереш процессында бирү түгел, ә атау гына. Хисләрне поэтик кичерешләр рәвешендә бирү ягыннан Тукайның 1906 елда иҗат ителгән газәлләре бик кызыклы. Көнчыгыш поэзиясе традицияләренә ияреп язылган бу шигырьләр («Ифтирак соңында», «Гыйшык бу я!..», «Дәрдеменд дәгелмием!», «Мөхү идәрмисән!») шагыйрь лирикасында үзенчәлекле урын алып тора [1]. Бу очракта Тукай газәлләренең безне кызыксындырган ягы — аларның элегик характерда булуы.

«Ифтирак соңында» газәленең төп эчтәлеге, мәсәлән, гыйшык аркасында «кайгыхәсрәткә баткан» лирик геройның кичерешләрен, хәсрәтле уйларын сурәтләүдән гыйбарәт. Вакытында лирик герой үзенең шигырьләрен, Тукай үзе әйткәнчә, сөйгәненең «илһамы белән яз»са, ә хәзер ул «аерылышу уты белән яна»:

Бетте, вәйран улды шимди асеманым һәм земин,
Дөньями, гокбами ектым ясе вә хирманыңлә бән [2].

Шушы ук мотив төрле вариацияләрдә башка газәлләрдә дә кабатлана. Алар бер-берсеннән лирик геройны, «җанаш» образын бирү белән генә аерылалар.

Әлбәттә, Тукайның без карап үткән әлеге газәлләре реаль шәхеснең интим-мәхәббәт хисләрен белдерүдән ерак торалар (гомумән, Тукай лирикасында мәхәббәт элегиясе зур урын тотмый). Газәлләрдәге геройлар — ниндидер абстракт гашыйк, җанаш. Шуңа да аларның тарихи-конкрет һәм реаль сыйфатларын билгеләве шактый кыен. Ләкин шагыйрьнең интим лирика өлкәсендәге бу тәҗрибәләре иҗатының үсеш юлында эзсез калмый. Интим хисләргә, эчке кичерешләргә корылган бу шигырьләр Тукай лирикасына психологизм элементлары алып килә. Реалистик психологизм ук булмаса да, бу инде шуңа омтылуда, ягъни элегик кичерешләрне реалистик принципларда сурәтләүгә күчү юлында бер адым булды. Бу уңай тенденцияләрнең Тукай элегияләрендә тулысынча җиңеп чыгуын шагыйрьнең Пушкиннан файдаланып язылган «Кемне сөяргә кирәк» (1906, июль) шигырендә күрәбез. Шигырьдә Тукайның борчы-

[1] Газәл — Көнчыгыш поэзиясенең иң борынгы формаларыннан берсе. Кагыйдә буларак, газәлнең эчтәлеген мәхәббәт һәм аңа бәйләнешле шатлыклы һәм хәсрәтле хисләр тәшкил итә. Әмма поэзиянең үсеш дәверендә газәл формасында башка эчтәлек тә белдерелә башлый. Эчтәлек үзенчәлегеннән чыгып, Тукайның бу шигырьләрен дә без интим элегиянең бер төре итеп карадык.

[2] Сүзгә-сүз тәрҗемәсе:
Бетте, тар-мар килде инде күгем дә, җирем дә;
Өметсез һәм мәхрүм итүең сәбәпле, дөньямны да,
ахирәтемне дә югалттым.

лулы уйлары, капитал дөньясының мораль нормаларыннан зарлануы, шагыйрь лирикасында беренче буларак, элегик кичерешләрдә бирелә:

Белү мөшкил кирәк кемне сөяргә,
Үзең аусаң да, аудармый сөяргә?

Син үлсәң (бет!), сине кем кызгана соң?
Синең зәхмеңгә кемнәр сызлана соң?

Бу дөньяда сине кем иркәли соң?
Бәлаләрдән сине кем киртәли соң?

Синең соң хәсрәтең кемнәргә хәсрәт?
Гамеңнең кәсрәте кемнәргә кәсрәт?

Кеше сатмас кеше тапмак асатмы?
Сине соң кайсы дус дошманга сатмый?..

Төп эчтәлегенә бәйләнешле рәвештә, шигырьгә түбәндәге мотив та үтеп керә:

Сиңа, дустым, бу сүз ахыргы сүзем:
Үзеңне сөй! Ярат үзеңне үзең.

Соңгы сүзләр элегиядә сурәтләнгән кичерешләргә нәтиҗә буларак әйтеләләр. Шул ук вакытта шагыйрьнең үз-үзеңне генә яратырга өндәве аның тормыштан качарга чакыруы түгел, әлбәттә. Бу — изүче тормышка карата, пассив булса да, ризасызлык белдерү, капитал дөньясы белән конфликтка керүнең бер формасы иде. Дөрес, шигырьдә әлеге конфликт җәмгыятькә турыдан-туры каршы чыгу рәвешендә бирелми, ә шагыйрьнең нәфрәтле хисләреннән, элегик кичерешләр агышыннан аңлашыла.

«Кемне сөяргә кирәк» шигыре — Тукай иҗатында кайгы-хәсрәт мотивларын реалистик принципларда сурәтләүнең һәм, гомумән, хисне психологик кичереш буларак бирүнең бик матур үрнәге. Ләкин бу әле Тукай иҗатында реалистик элегия тулысынча урнашты дигән сүз түгел. Ул, башка жанрлар кебек үк, каршылыклы юл үтә. 1907 елда язылган «Сөальләр» шигыре, мәсәлән, шул турыда сөйли. Шигырьдә кайгы-хәсрәтле кичерешләрнең конкрет чыганакларын, сәбәпләрен билгеләве кыен. Тукай катлаулы образлар ярдәмендә үзенең кайгылы хәлен, күңелсез настроениесен белдерергә тырыша:

Я ходая! нигә төрле-төрле кылдың бәндәни?
Ни сәбәп соң җөмлә әдна бәндәләрдән бән дәни?

Ник бәни шат итмәдең, ник әйләдең гамь һәмдәми?
Юкса бәхре гамь мәсиле, мансыйбы да бәндәми? [1]

«Бәхтем минем кара», мин «кайгы юлдашы», «явыз бәхетем», «кайгы диңгезе» — шигырьдәге менә шундый сурәтләү чаралары, катлаулы, стандарт образлар куллану Көнчыгыш поэзиясендәге яшь түгү, сыкрану әсәрләрен искә төшерә. Тукай элегик шигырьләрнең иң матур үрнәкләрен лирикасының чәчәк аткан елларында язды. «Өмит» (1908) шигыре, мәсәлән, шундый элегияләрнең берсе. Шагыйрь күңеленең тынычлыгы нәрсәгә бәйләнгән! Трагик кичерешләрнең сәбәбе нәрсәдә! Аларны ничек җиңеп чыгарга! Әсәрдә лирик геройның шушы сораулар турында газаплы уйлануылары бирелә. Шигырьнең беренче юллары ук безне лирик геройның катлаулы кичерешләр дөньясына алып керә:

---

[1] Сүзгә-сүз тәрҗемәсе:
Я ходай! ни өчен кешеләрне төрле-төрле кылдың?
Нилектән соң мин бөтен түбәннәрдән дә түбән булдым?

Ник мине шат итмәдең, нигә кайгы юлдашы иттең?
Әллә кайгы диңгезенең чыганагы да, коя торган урыны да миндәме?

Чыкчы, и фикрем кояшы! Китсен өстеңнән болыт,
Бу үлек вөҗданны җанландыр, җылың берлән җылыт!

Профессор Хатип Госман язганча, «Фикер кояшы» — шагыйрьнең вөҗданына тирәклек көче биреп торучы. Болыт (хата, бозык, реакцион тойгы һәм фикерләр символы), ике арага кереп, шагыйрьнең вөҗданын үлемгә дучар итә...»[1] һәм Тукай алдагы юлларда «вөҗданы үлемгә дучар» булган җанның газабын тасвирлый. Дәрескә, шигырьнең буеннан-буена ике мотив аралашып, үсеп килә: шагыйрь үз рухи халәненең нинди дә булса бер күңелсез моментын атый да, бу хәлдән чыгу шартын, ягъни «фикер кояшы» чыгуны күрсәтә:

Мин адаштым, тугры юлга ул торып күндермәсә;
Дүрт ягым гыйсъян уты, сүнмәс һич, ул сүндермәсә.

Бер бетү чокырында мин, юктыр нәҗат, коткармаса;
Мәңге тотынып нәрсә юктыр, ул килеп җеп салмаса...

Шагыйрь үзенең рухи хәлен, газапларын кат-кат һәм төрле яктан аңлатырга тырыша, һәм бу газаплы уйларыннан котылу «болыт китү»гә, яңадан «фикер кояшы» чыгуга бәйләнгәнлеген әйтә:

И минем яктыртучым! Тик син миңа һәр җирдә шәм;
Нәрсә ул дөнья кояшы, син миңа нур бирмәсәң!

Ниһаять, капма-каршылыклы уйлар, газаплы кичерешләр фикернең оптимистик чишелеше белән тәмамлана. Шигырьнең соңгы юллары хис-кичерешләр үсешендә җиңү аккорды булып яңгырый:

Юк, кояшым, мин беләм, син батмагансың мәңгегә;
Син дә, вөҗдан, бер торырсың, ятмагансың мәңгегә.

Шулай итеп, бер шигырь рамкасында капма-каршы хис-кичерешләрне сурәтләү шагыйрь рухи хәленең бер моментын бөтен тирәнлеге, капма-каршылыклы яклары белән күз алдына китерергә мөмкинлек бирә.

Элегик кичерешләрнең үсештә, капма-каршы хисләр көрәшендә бирелүен, хәсрәтле уйларның оптимистик фикер белән тәмамлануын Тукайның башка элегияләрендә дә күрергә мөмкин. Мондый очракларда шагыйрь үзенең кайгы-хәсрәтле уйлары, күңелсез настроениесе турында яза да, аннан соң бу рухи хәлдән чыгуга ышаныч белдерә яисә шуңа ишарә ясый. Бу яктан караганда, Тукайның «Үкенеч» шигыре бик характерлы. Әсәр шагыйрь күңелендәге күңелсез бер моментны белдерү белән башланып китә:

Электән белгәнем хәлдә кешенең
Тышы яхшы, бозыклыгын эченең,

Ничек соң мин адаштым изге юлны,
Биреп мәлгунь, ходайсызларга кулны?!

Нигә мин алденып ялган көлүгә,
Нифак иттем үземдәге голүгә?!

Шагыйрь үзенең кулын мәлгунь, бозык кешеләргә биреп (ягъни дошманнарына ышанып), вакытлыча адашуга дучар була. Менә бу сәбәп шагыйрьне үкенечле уйлануларга, газапलануларга китерә. Хис-кичерешләрнең үсешендә Тукайның фикере тагын да конкретлаша, шул ук вакытта эчтәлек ягыннан киңәя төшә; хәсрәтле уйларының чыганагы итеп шагыйрь гомумән капитал дөньясын, шул дөньяның караңгы, бөркү атмосферасын күрсәтә:

[1] Х. Госман. Антитезалы тасвир кайпардан килә? «Казан утлары» журналы. 1968 ел. 5 сан. 138 бит.

Әсирмен, ычкыналмам инде мәңге,
Күңелсез һәр ягым, нурсыз, караңгы.

Монафикъләр камап һәр дүрт ягымны,
Күрәлмим мин кояшым һәм аемны...

Һава юктыр, алалмый рух сулыш та,
Кабахәт бөркү уң, сул, аста, өстә.

һәм шигырь менә болай тәмамлана:

Читен хәл: гайрәтең җитсә — ерып чык,
Әгәр җитмәс исә — бет, шунда тончык!

Күрәсез, кичерешләрнең ахырында шагыйрьнең турыдан-туры пессимизмга бирелүе дә янсә бу «читен хәл»дән чыгуга ышанычы да белдерелми. Уй-фикерен Тукай үз-үзенә эндәшү, уйлану белән тәмамлый, нәтиҗәне укучының үзенә ясарга калдыра. Әмма поэтик фикернең үсеш логикасыннан һәм Тукай лирикасының гомуми фоныннан чыгып караганда, әсәрнең соңгы юллары шагыйрьнең «читен хәл»не җиңеп чыгачагына ышаныч булып яңгырыйлар.

Менә без Тукай лирикасындагы элегик кичерешләрнең характерын, шагыйрьнең элегик эчтәлекле романтик газәлләреннән алып реалистик элегияләренәчә, кыскача гына күзәтеп чыктык. Шагыйрь әсәрләрендә элегик кичерешнең эчтәлеге һәм, шул нигездә, лирик геройның характеры тамырдан үзгәрә. Әгәр Тукайның 1906 елда язылган газәлләрендә лирик герой мәхәббәт аркасында газап чигүче, яшь түгүче романтик образны хәтерләтсә, реалистик элегияләрдә исә ул тарихи һәм психологик конкретлык ала, халыкның кайгы-хәсрәтен, газаплы уйларын үз йөрәгендә кичерүче кешегә, халык моңын, иҗтимагый моңнарны җырлаучыга әйләнә.

Без карап үткән шигырьләрдә лирик геройның элегик кичерешләре нәрсәдән булса да зарлану, борчылу, кайгыру һәм хәсрәтләнү рәвешендә биреләләр, аларда тулысынча өметсезлеккә бирелү очраклары юк диярлек. Әгәр кайбер шигырьләрдә шагыйрьнең кичерешләре төшенке характер ала икән, бер үк вакытта Тукай күңелсез уйлардан арынаачагына ышанычын да белдерә.

Лирикада кайгы-хәсрәт хисләрен биргәндә, аларны һәрвакытта да оптимистик кичерешләр белән «тигезләү», «пропорциягә» китерү мәҗбүриме! Ягъни аерым бер лирик шигырь рамкасында элегик кичерешләр һәр очракта да оптимистик хисләр белән тәмамланырга тиешләрме! Тукайның 1909—1910 елларда язылган «Теләү бетте», «Өмитсезлек», «Өзелгән өмит» элегияләре укучыда менә шундый сораулар тудыра. Бу сорауларга гомуми формада гына җавап биреп булмый, әлбәттә. Шагыйрь иҗатындагы пессимистик шигырьләрнең, өметсезлек мотивларының үзенчәлекләрен, Г. Хапит язганча, «нидән гыйбарәт булуын» Тукайның «үз әсәрләреннән, үз фикерләреннән чыгып билгеләү», мондый мотивларга конкрет анализ ясау гына аның «пессимистик» элегияләренә объектив бәя бирергә ярдәм итәчәк.

«Өмитсезлек» шигырендә, мәсәлән, автор кичерешләренең иң күңелсез, иң караңгы моментлары бирелә:

Көлмә син дә бу бозык дөньяга каршы та әбәд,
И кояш! мәңгегә чыкма, бул кара тап, бат кире.
Яз башы дип, башны калкытмагыз, и гөл-гәнҗәләр!
Бел, янарсыз: җир хәзер ялкынлы истибдат җире!
Калмасын дуслык, мәхәббәт, чын сөешмәк дөньяда,
Бу җәһәннәмдер, түгел Ширин илә Фәрһат җире...

Тормышны төрле яклап инкарь иткәннән соң, шагыйрь иҗат кешесе өчен фаҗига булып яңгыраган менә шундый нәтиҗә ясый:

И каләм, син, хакны язма, күз буя, юк-барны яз,
Бумыни соң тугры әшгарны язып иншат җире!!

Күренә ки, әсәрдә шагыйрьнең күңелен тулысынча өметсезлек хисләре билап алган. Әмма шигырьнең эчтәлеге мондый кичерешләр белән генә чикләнми. Әсәрнең характерлы ягы — элегик кичерешләрнең сәбәпләрен күрсәтү, аларга анализ ясау[1]. Дөньяда бөтен терекләкне үз утында көйдергән реакция турындагы сүзләрнең элегиядә өч мәртәбә кабатлануы шагыйрьнең бу шартлардагы рухи хәлен бик ачык сурәтли. «Өмитсезлек» шигырендә менә бу сүзләр әсәрнең идея эчтәлеген тагын да киңәйтә төшәләр:

Сез дә, мазлумнар груһы, хак өчен кул сузмагыз,
Тик кыямәт көнгә калды хаклар истирдат кире.

Ягъни тартып алынган хокукларны кайтарып алу кыямәт көнгә калды, ди шагыйрь. Бу, бердән, азатлык көннәрен сагыну, реакциядән зарлану булса, икенчедән, көрәш юлында җәфа чигүче кешенең рухи газапларын белдерү дә.

«Өзелгән өмит» шигырендә дә шагыйрьнең үз тормышы, иҗат юлы турындагы уйланулары күңелсез нәтиҗәләргә китерә. Ләкин бу очракта да мондый кичерешләрнең сәбәпләре әйтелә:

Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә син,
Һәр ишектән сөрде углыңны мәхәббәт сакчысы.

Гомумән Тукай үзенең шигырьләрендә әледән-әле элегик кичерешләрнең сәбәпләренә тукталa, ул сәбәпләрне төрле яклап аңлатырга, укучыга җиткерергә тырыша. Димәк, Тукай элегияләрендә өметсезлек мотивлары тормыштан туйган, дөньядан ваз кичкән лирик геройның елау-сыкраулары, яшь коюлары рәвешендә түгел, ә һәрвакыт конкрет нигездә туалар, тормышның теге яисә бу күренешләре турында уйланулар нәтиҗәсе буларак биреләләр; шагыйрьнең «хәсрәте дә, кайгысы һәм өметсезлеге дә явызлыкка, караңгылыкка»[2], капитал дөньясының этик-мораль нормаларына аяусыз нәфрәт аша чагылды. Бу урында Тукай шигырьләренең рус элегияләрен хәтерләткән бер үзенчәлеген күрсәтеп үтәргә кирәк. Рус классик поэзиясендә киң үсеш алган бер традиция — элегик кичерешләрнең рухи эзләнүләр формасында бирелүе, мондый хис-кичерешләрнең кеше язмышы һәм тормыш күренешләре турында фәлсәфи уйланулар нәтиҗәсендә тууы. Баратынский шигырьләренең элегик тоны, дип яза В. Г. Белинский, шагыйрьнең тормышка карашыннан, уйларыннан (от думы) туа[3]. Лермонтов лирикасының элегик характерда булуын да тәнкыйтьче шулай аңлата, һәркайда йөрәк әрнеткеч сораулар, ди ул, шагыйрь әсәрләренә анализ ясап[4].

Тукай элегияләрендә дә кичерешләр еш кына лирик геройның уйлары, эзләнүләре рәвешендә бирелә. Мондый алым куллану шагыйрьнең үз язмышы, үз тормышының күңелсез яклары турында язылган элегияләренең дә гомумиләштерү көчен арттыра. Бер-ике мисал китерик:

И мөкатдәс, моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз ахрысы!
(«Өзелгән өмит»)

Үлде рух яшьрен мәхәббәттән, хафа юк үлсә дә,
Нишлим, иркәм кәйфенә килгәч шулай бер җан кыю!
(«Актык тамчы яшь»)

---

[1] «Өмитсезлек» шигыренең объектив эчтәлеген билгеләүче бу үзенчәлек элегиянең төзелешендә, хис-кичерешләр хәрәкәтендә дә бик ачык күренә. Тукай әсәрнең һәр строфасында диярлек «пессимистик» бер фикер әйтә дә, шунда ук бу фикерне белдерергә мәҗбүр иткән конкрет сәбәпне күрсәтә. Мәсәлән: «көлмә син дә», «кояш», бу б о з ы к д ө н ь я г а каршы»; «...башны калкытмагыз, и гөл-ганҗәләр! Бел, янарсыз: җир хәзер ялкынлы истибдат җире!» һ. б.

[2] Г. Халит. Тукай үткән юл. 1962 ел. 183 бит.

[3] В. Г. Белинский. Полное собрание сочинений. Т. VI. Мәскәү. Рус телендә. 1955 ел. 466 бит.

[4] Шунда ук, 503 бит.

Мəлганəт, пычрак вə ялган берлə тулган безнең эч,
Бар начарлыктан, бозыклыктан гыйбарəт безнең эш...

Керлəнə өс, өстенə рух, һич хозур вөҗданга юк,
Ни сəбəптəн җир йөзендə тəнгə — мунча, җанга — юк?

(«Тəлəһһеф»)

Тукай үз-үзенə сораулар куя, газаплы кичерешне төрле яклап тикшерергə, анализларга омтыла. Шагыйрьнең кайбер шигырьлəрендə əйтелгəнчə, кешегə рухи көч, күңел хөрлеге, тормышта «аяз» минутлар зур хəсрəтлəр, яшь түгүлəр («Яшен яшьнəгəндə» шигыре) белəн яулап алына. «Күңел» шигырендə автор болай ди:

Инкисар ит гадəтеңчə, ян, күңел, сызлан, күңел!
Күп сөекледер бөтеннəн тəңрегə сынган күңел.

Шигырьнең алдагы юлларында да шагыйрь үзенең кешелеген «саклау юлында» күңеленең «күп газаплануы» турында яза. Ə «Газаптан соң» шигырендə шагыйрь, аз гына да икелəнмичə, менə нəрсə ди:

Үземə сөенеч бирəм инде бəхет, гыйззəт белəн:
Уйлыймын үткəн газапларны хəзер ләззəт белəн.

Булмадымы шул газаплар бəхетемең ачкычлары!
Җитмəкемнең изге максутка лəгыйль баскычлары!

Шагыйрь үзенең рухи газапларын төшенкелеккə бирелү дип карамый. Х. Госман язганча, «монда шагыйрь карашының бик мөһим яклары ачыла: күңелдəге газап вакытын ул башка килгəн бер бəла итеп кенə карамый. Бу газап — көрəш. Монда «бəхет ачкычы»ын эзлəүче актив көч хəрəкəт итə. Шуңа күрə дə бу көрəштə үзенə аерым лəззəт бар. Шагыйрьнең бу сүзлəреннəн эчке рухи көрəшне үсү, яңару процессы итеп каравы, художник буларак асылда «җан диалектикасы»на үтүе аңлашыла» [1].

Димəк, Тукай лирикасындагы «газаплы кичереш»лəрне тормыш күренешлəренең асылына тирəнрəк төшенүнең нəтиҗəсе, шагыйрь күңелендə барган катлаулы процесслар аша тормыш каршылыкларын сурəтлəүнең бер формасы итеп карарга кирəк. Бу уңайдан Тукайның пессимистик мотивларны поэзиядə сурəтлəүгə карата əйтелгəн үз фикерлəре бик характерлы. Кəбир Бəкер «Тукай Петербургта» исемле истəлегендə менə нəрсə яза: Тукай «Нур» газетасы идарəсендə басылмаска дип хөкем ителгəн шигырьлəрне «карап утырды-утырды да үзенчə берсен кертергə ярый торган итеп тапты. Баштагы ике мисрагын үзгəртеп, ахырындагы бер сүзен алмаштырды да: басарга кирəк, диде. Аңа каршы мин ул шигырьлəрнең мөндəриҗəсендə коры пессимистлыктан (коры бер өметсезлек) башка бернəрсə булмаганлыгын бəян иттем. Шул вакыт ул миңа шулай җавап кайтарды:

— Бернəрсə дə юк бит инде, шулай да əһəмияте бар. Пусть халык башыбыздан кичердекебез көннəрнең өметсез-кара көннəр икəнен белеп калсын. Аның характерның (табигый) ягы шул: бу көн кулына чак калəм тота белгəн татар балаларының бары да шул өметсезлек җырларын җырларга мəҗбүрлəр. Менə шул хəзер матбугатта бик нык сизелеп калырга тиеш» [2].

Əлбəттə, бу сүзлəрдə Тукайның мəсьəлəгə берьяклырак каравы һəм үз эпохасының күңелсез якларына күбрəк басым ясавы күренə [3]. Əмма бу очракта шагыйрьнең «өметсезлек җырларын» җырлауга карата булган карашы бик характерлы. Тукай мондый фикерлəрне үзенең шигырьлəрендə дə белдерə:

Кузгатмакчы булсаң халык күңеллəрен,
Тибрəтмəкче булсаң иң нечкə кылларын,

[1] Х. Госман. Антитезалы тасвир кайлардан килə? «Казан утлары» журналы. 1968 ел. 5 сан. 138—139 битлəр.
[2] Тукай турында замандашлары. Казан. 1960 ел. 183—184 битлəр.
[3] Г. Халит. Тукай и его современники. Казан. Рус телендə. 160—161 битлəр.

Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,
Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен.

Димәк, шагыйрь «хәсрәт көен» көйләүне халыкка аның реаль хәлен аңлату, әйтергә яраса, күзен ачу, хәсрәтле тормышка нәфрәт уяту чарасы итеп, тормышны сурәтләүнең бер формасы итеп карый.

Тукай турындагы кайбер хезмәтләрдә шагыйрьнең «пессимизмын», рухи газапларын, Г. Халит сүзләре белән әйтсәк, «Тукайдагы өметсезлек хисләрен иҗтимагый һәм политик авырлыкларны кичү юлында туган трагизмның чагылышы» итеп карыйлар. Бу — бик дөрес һәм объектив караш.

Әмма бу «трагизм»ны ничек аңларга? Моны шагыйрьнең рухи фаҗигасе, вакыты белән идеалларының җимерелүе дип кенә караргамы яисә Тукайның бу кичерешләрен идеалны эзләү юлында туган газаплар дип һәм, шул нигездә, идеал өчен көрәшнең бер моменты итеп аңларга тиешбезме? Безнеңчә, соңгысы дөресрәк булыр.

Чыннан да, 1907 елда «Дөньяда торыйммы! — дип киңәшләшкән дустыма» шигырендә Тукай, мәсәлән, «тормыйм инде, бу дөньядан туйдым инде» дип зарланса, шушы шигырь артыннан ук ул үзенең көрәш һәм иҗат программасы булып яңгыраган түбәндәге юлларны яза:

Уңга, сулга аумыйм, һәнүз алга барам,
Юлда манигъ күрсәм, тибәм дә аударам:
Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә,
Мәгълүмдер ки, курку белән өркү харам.

Яисә Тукай 1910 елда «Үкенеч» шигырендә:

Кырылды алда изге эшкә вәгъдәм;
Караңгыда күренми чөнки кәгъбәм,—

дип, өметсезлек белдерсә, 1913 ел башында язган шигырендә ул идеал өчен көрәшкә өнди:

Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул;
Алга барганнарга тик табла табылса: алла ул.

Тукай лирикасыннан «өмет һәм хәсрәт» көрәшен күрсәткән мондый мисалларны күп китерергә мөмкин. Шагыйрь кайвакыт, пессимизмга бирелеп, көрәш юлында чигенүләр ясаса, икенче очракта исә, бу хисләрне җиңеп, иркен сулыш ала, яңа көч, яңа дәрт белән җырлаячагын белдерә.

Моны каршылыклардан чыга алмыйча җәфа чиккән, телгәләнгән йөрәкнең газабы дип карап булмый, әлбәттә. Бу — явызлыкның реаль көчен аңлаган бөек характерның чын-чыннан газабы, рухи трагедиясе, әмма эзләнү трагедиясе, икеләнүләр, өметсезлеккә бирелүләр аша алга бару, көрәшү трагедиясе иде.

Әлбәттә, Тукай элегияләрен өйрәнүгә кагылышлы мәсьәләләр болар белән генә чикләнмиләр. Безнең мәкалә исә проблеманың кайбер якларын ачыклау юлында бер омтылыш кына булып тора. Тукай лирикасының бик үзенчәлекле һәм катлаулы бу төре киләчәктә тирәнрәк, җентекләбрәк өйрәнүне сорый.

Рафаэль Мостафин

# ҮЗ ҖЫРЫҢ, ҮЗ КӨЕҢ БУЛСЫН

ИКЕНЧЕ МӘКАЛӘ

## Өлкәннәр итәгенә тагылып...

Моңарчы яшь прозаикларыбыз ничектер әдәби хәрәкәттән читтәрәк, әгәр шулай әйтергә яраса, тәртәнең тышындарак йөриләр һәм аларның исем-фамилияләре дә, гадәттә, исемлек ахырында, «һәм башкалар» алдыннан гына телгә алынып үтелә иде. Әллә өлкән буын әдипләребез бирешә башладылар, әллә яшьләр үзләре бик нык активлашып киттеләр һәм өлгерү-җитлегү чорына аяк бастылар инде — соңгы берике елда яшьләр прозасы кинәт алга, беренче рәткә килеп чыкты. «Казан утлары» журналының 1968 елгы саннарын актарып багыгыз. Г. Ахуновның «Хуҗалар» романы, Э. Касыймовның «Бир кулыңны, дустым», М. Маликованың «Казан каласы — таш кала», Р. Төхфәтуллинның «Агымсу» повестьлары, М. Мәһдиев, В. Нуруллин һәм башка яшь авторларның проза әсәрләре. Кайчандыр яшь һәм башлап язучылар арасында гына йөргән яки бөтенләй исемнәре дә ишетелмәгән кешеләр бүген йөкне арбаның төбенә җигелеп тарталар. Н. Фәттах, А. Гыйләҗев, Р. Төхфәтуллин, Г. Ахунов, Э. Касыймов кебек язучылар исә, күренекле өлкән әдипләребез белән беррәттән, инде бүген үк татар совет прозасын әйдәп баручы төп көчләрдән саналалар. Бу хәл безне яшьләр иҗатына бераз башкачарак ноктадан караш ташларга мәҗбүр итә. Бүгенге яшьләр прозасы ташламалар ясауга да, урынсыз күпертелгән мактауларга да мохтаж түгел кебек.

«Казан утлары» журналының февраль санында басылган беренче мәкаләмдә сүз яшь прозаикларның Ватан сугышы чорына караган әсәрләре турында барган иде. Бу юлы исә аларның бүгенге тормышка, заман темасына багышланган әсәрләренә тукталасым килә.

Әгәр сугыш елларындагы авыл тормышына караган әсәрләрендә яшьләр күпмедер күләмдә өлкәннәр эзеннән барсалар һәм өлкәннәр сурәтләгән тормыш күренешләрен тагын да тулыландыру, тирәнәйтү юнәлешендә эшләсәләр, бүгенге чынбарлыкны тасвирлаганда, бигрәк тә бүгенге яшь кеше образын тудырганда инде аларга күбрәк үзбаш

эш итәргә, үзләренә юл салырга туры килә. Тагын шунысы кызыклы: сугыш еллары турында язганда, өлкәннәр эзеннән барганда, алар ничектер мөстәкыйльрәк тә һәм оригинальрәк тә күренәләр иде; ә менә яшьләрнең заман темасына багышланган әсәрләре хакында сөйләгәндә алай әйтеп булмый. Яңа материал яңачарак караш ташлауны, бүгенге тормыш тудырган конфликт һәм ситуацияләр яңачарак хәл кылуны таләп итә бит. Ә яшьләрнең исә еш кына нәкъ әнә шуңа көчләре җитеп бетми кебек. Бер гадәтләнгән, хәтта иярләшеп беткән сурәтләү чараларыннан һәм сюжет кору алымнарыннан, яман аты чыккан һәртөрле «өчпочмак» һәм «дүртпочмак»лардан баш тарту бик җиңел түгел, күрәсең. Нәтиҗәдә, игътибар беләнрәк тикшереп карарга тотындыңмы, яшьләр сайлап алган иҗат юлы еш кына искергән, шактый тапталган юл булып чыга. Шундыйрак хәлне Э. Касыймовның «Бир кулыңны, дустым» повестен укыганда да күрергә мөмкин.

Әсәр безнең көннәрдә барган вакыйгаларны сурәтләүгә багышланган. Геройлары — баштарак өлкән курсларда укучы студентлар, соңыннан яшь белгечләр. Күләме ягыннан әллә ни зур булмаган бу повестьта автор замандашларыбызның истә калырлык образларын тудыра алган. Менә төз буйлы, таза, киң җилкәле чибәр егет Әхсән; шәп спортсмен һәм сәләтле геолог. Аңа джаз җене кагылган, ул һәртөрле кичәләрне, туристлык походларын ярата, тормыштан алырга мөмкин булганнарның һәммәсен дә алып калырга тырыша торган, икенче төрле әйткәндә, «яши белә торган кеше». Менә тырыш һәм сөйкемле, тыныч холыклы һәм оялчан табигатьле Әлбинә. Әхсәнне яраткан кебек, аны да яраталар; иптәшләре дә, укучылар һәм аларның әти-әниләре дә ярата. Тик бу инде үзенә бер төрле, башка ярату. Әгәр Әхсәнне мәҗлес күрке, ачык йөзле күңелле утырдаш булганы өчен яратсалар, Әлбинәне кешелекле, тыйнак һәм намуслы булганга хөрмәт итәләр. Тагын әле яшереп кенә шигырьләр яза торган һәм муеннан Әлбинәгә гашыйк булган чандыр гәүдәле, аз сүзле, күзлекле егет Роберт, туптай йомры гәүдәле, пошмас табигатьле Гөлсинә, һәммәсенең уртак дуслары Борис белән Светлана бар. Һәм повестьтагы шул геройларның һәрберсенең диярлек үз йөзе, үзенә генә хас холкы-фигыле бар. Без яшьләрнең ничек яшәүләрен, ни рәвештә ял итү һәм күңел ачуларын күрәбез, өлкәннәргә һәм бер-берсенә булган мөнәсәбәтләре белән танышабыз.

Әсәр басылып чыгуга, авторның үзенә һәм редакциягә укучылардан бик күп хатлар килде; повесть күп бәхәсләр кузгатты, капма-каршы фикерләр уятты. Аның буенча әдәби диспутлар, конференцияләр уздырыла. Яшьләр тормышына багышланган бу повестьта күпләрне борчый һәм дулкынландыра торган әхлак мәсьәләләре күтәрелә. Укучылар игътибарын ул, барыннан да бигрәк, әнә шул ягы белән үзенә тартты бугай. Әмма ни генә булмасын, эчтәлегенең тирәнлеге ягыннан да, төп үзәк фикеренең әһәмияте буенча да, «Бир кулыңны, дустым» повесте Э. Касыймовның моннан алда язган «Гомер ике килми» романыннан шактый кайтыш.

Повестьның төп сюжет тукымасына күз салыйк.

Саф күңелле, кешеләргә тиз ышанучан һәм беркатлырак табигатьле Әлбинә алданган, тиздән аның баласы булырга тиеш... Әхсән — баланың атасы буласы кеше — исә бу хакта белергә дә, ишетергә дә теләми. Кыз хурлыгыннан җир тишегенә керердәй булып йөри. Аның турында, укытучы кеше, башкаларны тәрбияләргә һәм аларга үрнәк булырга тиешле кеше турында авыл халкы, балаларның әти-әниләре, бергә эшләгән иптәшләре ни уйлар?.. Әлбинәне, барыннан да бигрәк, мәсьәләнең әнә шул яклары борчуга сала.

Бу хәлне электән үк Әлбинәгә гыйшык тотып йөргән Роберт ишетә, ишетү белән кызны коткарып калу әмәлләрен эзләргә керешә. Әүвәл

Әхсән белән сөйләшеп карый. Аның Әлбинәгә өйләнмәячәгенә ышангач, Роберт кыен хәлгә калган кызга үзе өйләнергә һәм шул юл белән аны хурлыклы язмыштан коткарып калырга карар кыла. Һәм кемнең кем икәнен инде тәмам аңлап өлгергән Әлбинә Робертның бу тәкъдимен рәхмәтләр укып кабул итә...

Сүз дә юк, бу рәвешчә өстән-өстән генә сөйләгәндә, әсәрнең бик күп психологик нечкәлекләре, бик әһәмиятле мәгънә төсмерләре югалып калгандыр, билгеле. Әмма үзенең гомуми сызыкларында повестьның төп сюжет линиясе инде революциягә кадәр үк язылган мелодрамаларда һәм сентименталь романнарда күп кабатланган арзан ситуацияләрдән аз аерыла. Дөрес, автор теләсә кайсы чорда кабатлануы мөмкин булган «мәңгелек» ситуация һәм хәлләргә дә мөрәҗәгать итәргә хаклы. Тик чорына, заманына карап, ул ситуацияләргә салына торган социаль эчтәлек үзгәреп торырга тиеш.

Революциягә кадәрге чорда, хатын-кыз бөтенләй хокуксыз булган һәм изелеп яшәгән чорда, Әлбинә хәленә калган татар кызын күз алдыгызга китерегез. Бу — аның бөтен тормышы җимерелү дигән сүз, аның өчен чын мәгънәсендә фаҗига булыр иде. Ул заманда шундый кыен хәлгә калган кыз баланың намусын яклау, аңа ярдәм кулы сузу — аны үлемнән коткаруга, тормышын саклап калуга тиңләшер һәм мондый эшне үз өстенә алырга нийт иткән кешедән искиткеч зур кыюлык һәм батырлык соралыр иде.

Хәзер эш башкачарк тора шикелле. Әтисез бала үстергән өчен генә хатын-кызны хурлау бетеп бара. Моның өчен генә берәү дә аларны кимсетми, тотып әрләми. Дөрес, алдау һәрвакыт алдау булып кала, ул һәрвакыт кыз балага авыр кайгы алып килә. Әмма безнең заманда бу мәсьәләгә караш-мөнәсәбәт шактый үзгәрде төсле. Юк, элеккеге мәгънәдә, мещаннар аңлаткан мәгънәдә «гыйффәтне югалту» гына хурлык түгел, барыннан да бигрәк, кешегә булган ышанычыңның җимерелүе йөрәкне әрнетә, кире кагылган һәм мәсхәрә ителгән мәхәббәт хисләрең өчен хурланасың, шулар өчен әрнисең.

Э. Касыймов повестенда исә әнә шул мәсьәләләргә заманча якын килү җитенкерәми шикелле. Сүз дә юк, Әлбинә мәхәббәт хисләре мәсхәрә ителгәнгә һәм Әхсәнгә булган ышанычының акланмавына, җимерелеп төшүенә дә әрни, билгеле. Тик ул беренче чиратта һәм барыннан да бигрәк үзенең хурлыклы хәлгә калуы өчен кайгыра, кешеләр ни әйтерләр дип курка. Әгәр паспортында загс печәте булса, бу кадәр үк газапланмас һәм өзгәләнмәс тә иде кебек. Аннан соң, Әлбинәнең бик тиз генә, икеләнеп-нитеп тормый гына Роберт тәкъдимен кабул итүе дә сәерсендерә. Аның Әхсәнгә булган мәхәббәте тирән булдымы икән, дип шикләнергә туры килә. Әгәр чыннан да шулай икән, Әхсән белән алар арасындагы бәйләнеш вак һәм очраклы мавыгу булып кала, Әлбинә үзе тышкы иминлек турында гына кайгырта, халык алдында хурлыкка калмагаем дип кенә курка торган гади бер мещанка булып чыга. Автор үз героен күпме генә яратмасын, аны никадәр генә шәп итеп күрсәтергә тырышмасын, Әлбинә безнең чорның чын герое дәрәҗәсенә күтәрелмәгән. Аны, мәсәлән, «Тапшырылмаган хатлар»дагы Галия белән бер рәткә куеп булмый инде.

Әлбинәнең һәм повестьтагы башка геройларның борчу-мәшәкатьләренә әллә ни җитди төстә карамыйсың да. Әйе, тормышта шундый хәлләр дә очраштыргалый. Тик безнең чорның төп каршылыкларын алар билгеләми. Очраклы, вак нәрсә Э. Касыймов каләме аша узганнан соң да вак булып калган, анда эпоханың киң, зур сулышы сизелми. Шуңа күрә әсәр үзе дә ничектер җиңелчәрәк тоела, өстәнрәк эшләнгәнлек тәэсире калдыра.

Тормыш берөзлексез алга бара. Ул яңа конфликт һәм ситуацияләр, яңа вакыйгалар тудырып тора. Инде шуларны әзер сюжет алымнары,

әзер схема һәм штамплар буенча гына тасвирлый башладыңмы, уңышсызлыкка очрыйсыңны көт тә тор. Бу бер Э. Касыймовка гына кагылмый, билгеле. Безнең башка бик күп яшь прозаикларыбыз да әдәби остазларының бишмәт итәген ычкындырырга куркалар, хәтта әлеге итәк еш кына очракта инде тузып, сөрсеп беткән булса да... Бәлки, безнең үзебезнең Чыңгыз Айтматовларыбыз булмау да шуның белән аңлатыладыр. Чын мәгънәсендәге һәр зур талант әдәбиятка яңа темалар алып килү белән генә чикләнми, ул яңа сурәтләү чаралары да, әллә каян сизелеп, аерылып торган үзенчәлекле стиль дә, тормышка яңача мөнәсәбәт тә алып килә бит. Үзеннән үзе аңлашылса кирәк, бу һәркем кулыннан килә торган җиңел эш түгел, билгеле. Әмма шуңа омтылырга кирәк.

М. Маликованың «Казан каласы — таш кала» исемле повесте да («Казан утлары» журналы. 1968 ел. 4—5 саннар), тулаем алганда, укучылар тарафыннан җылы каршыланды. Повестьта моңарчы безнең әдәбиятта бөтенләй диярлек яктыртылмаган яңа тема — иҗат кешеләре, интеллигенция тормышы күтәрелә. Автор безне проектлар институтына һәм художник мастерскоена алып керә, архитекторлар һәм рәссамнар даирәсе белән таныштыра, өстән-өстән генә булса да бүгенге шәһәр төзелешенә бәйләнешле актуаль мәсьәләләргә кагылып уза.

Соңгысына аеруча басым ясарга кирәк, чөнки дөньяда гомумән кеше, ниндидер абстракт кеше булмый. Теге яки бу профессия, конкрет бер һөнәр кешеләре генә була. Һәм әлеге һөнәре кешенең тышкы кыяфәтенә, зәвык-кызыксынуларына билгеле бер йогынты ясый, хәтта аның эчке дөньясын, характерын да үзгәртә. Шуңа күрә әдәби сурәтләү даирәсенә яңа һөнәр кешеләрен кертү күпмедер күләмдә әдәбиятны яңа штрихлар һәм яңа буяулар белән дә баету дигән сүз. Кызганычка каршы, безнең әдипләр сурәтли торган геройлар даирәсе әле һаман да шактый ярлы һәм бертөслерәк. Тормышта булган күп меңнәрчә һөнәр ияләре арасыннан безнең әдәбият бик азының гына тормышын сурәтли бара. Колхозчылар һәм механизаторлар, укытучылар һәм врачлар, сирәк кенә эшчеләр һәм инженерлар, тагын да сирәгрәк галимнәр тормышы — бөтен булганы әнә шулар кебек.

Шуның өчен дә яшь авторның сәнгать интеллигенциясе тормышын әдәбиятка кертергә тырышуын хуплап каршыларга кирәк. Темасының яңалыгы белән үк инде повесть укучыларның дөньяга карашларын киңәйтергә ярдәм итә, аларны тынгысыз һәм мавыктыргыч иҗат дөньясына алып керә.

М. Маликова — безнең күптәнге танышыбыз. Моңарчы без аны күбрәк кыска-кыска хикәяләр авторы буларак белә идек. Ул каләмен һаман шомарта, хикәядән хикәягә әдәби осталыгын үстерә килде. Һәм зур күләмле шушы беренче әсәрендә үк үзен шактый әйбәт әзерлекле прозаик итеп танытты. Повестьның сюжет-композиция төзелешенә игътибар итегез. Беренче битләрдән үк автор безне әсәрдәге төп конфликтның эченә алып кереп китә.

Проектлар институтын тикшерергә махсус комиссия килгән — Мәрьям өстеннән жалоба булган икән. Аңа мең төрле гаеп өйгәннәр, ди. Җитмәсә, гаилә таркатуда да гаеплиләр, ди...

Шуннан автор әлеге конфликтның асылын ачарга тотына. Безне Мәрьямнең үз эшенә һәм иптәшләренә булган мөнәсәбәте белән таныштыра, аны ире белән аерылышырга мәҗбүр иткән сәбәпләрне ачыклый.

Әсәрне бу рәвешчә кору исә кызыксыну уятырга, укучыларның игътибарын тупларга ярдәм иткән. Дөрес, төбендә бу әле уңышлы табылган алым — әдәби чара гына. Әмма безнең күпчелек яшьләребез шул алымнарны белмәү аркасында харап булалар да. Врачлар кешенең

анатомиясен, механик машиналарның төзелешен белергә тиеш булган кебек, язучы булырга җыенган кеше әдәби алымнарны да үзләштергән булырга тиеш. Бу мәсьәләнең бер ягы. Ләкин ул гына җитми, сәнгать әсәренең төп кыйммәте теге яки бу алымнарга туры килү яки туры килмәү белән генә билгеләнми әле. Автор тапталмаган яңа сүз әйтәме, тормышны аңлавыбызга нинди дә булса яңалык өсти аламы — һәр сәнгать әсәренә куела торган беренче таләп, төп таләп әнә шул. Инде «Казан каласы — таш кала» повестена шул таләпләр югарылыгыннан торып якын килә башладыңмы, авторның шактый өстән йөзүен, еш кына башкалар салган сукмак буйлап атлавын күрәсең.

Повестьның төп сюжет сызыгы моңарчы күп әсәрләрдә очраган, тапталып беткән ситуацияне хәтерләтә. Студент, соңрак яшь архитектор Мәрьям Шәүкәт исемле художник егетне ярата. Үз-үзен онытып, бөтен яшьлек дәрте белән ярата. Ләкин мәшһүр художник булырга хыялланып йөргән Шәүкәт күбрәк үз-үзе белән мәшгуль, кызга ничектер искитмичәрәк карый, ахырга таба исә аңардан бөтенләй суына. Мәрьям, кайгыдан, тота да беренче очраган кешегә кияүгә чыга. Әмма озак та үтми, үзенең элеккечә үк Шәүкәтне, бары тик аны гына яратуын аңлый. Алты елдан соң алар янадан очрашалар, яңадан дөрләп мәхәббәт ялкыны кабына. Мәрьям, баласын алып, Вильданнан аерылып китә. Тик китеп әллә ни күп вакыт үтми, ул Шәүкәтнең әлегрәк игътибар итеп бетермәгән начар якларын күрә башлый. Шул ук вакытта үз ире Вильдан да кызганыч тоела. Кыен хәлдән авария коткара. Ирен мотоцикл таптый, һәм Мәрьям күңеле белән яңадан Вильданга тартыла башлый.

Күрәсез, биредә дә Э. Касыймов повестенда очраган кимчелек — тапталган юллар, әзер сукмак буенча барырга тырышу ачык күренә. Ахыр чиктә хикмәт гомер-гомердән килә торган «өчпочмак»та гына түгел. Э. Касыймов повестенда да, М. Маликова повестенда да тормыш күренешләре өстән-өстән генә сурәтләнә. Хикмәт әнә шунда.

Чибәр һәм акыллы, тырыш һәм үз эшен яратып башкара торган Мәрьямне алыгыз. Автор үз героенын эчке дөньясына, рухи тормышына тирән керә алмаган. Әсәрдә Мәрьямнең Шәүкәткә булган мәхәббәте турында күп сөйләнә, ләкин сөйләнә генә. Язучы әлеге олы хисненң сафлыгын, тирәнлеген һәм көчен күрсәтә алмаган. Мәрьям ничектер җинел генә, артык уйлап тормый гына Вильдан белән тора башлый һәм шулай ук җиңел генә аерылып та китә. Вильдан образы тагын да тоныграк, тагын да өстәнрәк эшләнгән. Без аның музыка белән мавыгуын, детектив романнар укырга яратуын беләбез. Әмма автор аның эчке дөньясын ачарга омтылып та бакмый. Асылда ул җансыз күләгә, ике аяклы манекен булып чыккан. Тик әсәрнең соңгы битләрендә генә Вильдан бераз җанлана төшә. Икенче дәрәҗәдәге образлар: Мәрьямнең дуслары, бергә эшләгән иптәшләре артык томанлы чыккан, алар бөтенләй хәтердә калмыйлар.

Без тормышка, герой психологиясенә тирәнрәк керергә кирәк, дип күп сөйлибез. Әмма моның өчен үз һөнәреңне әйбәт белү, тормыш фактларын тирән үзләштерү генә җитми. Гражданин һәм кеше буларак, авторның үзенең өлгереп җитүе сорала. Соңгысы исә зур тырышлыклар нәтиҗәсендә, иҗат, тормыш һәм хезмәт тәҗрибәсе аша гына бирелә. Безнең яшь прозаиклар алдында беренче чиратта кеше һәм гражданин буларак өлгерү бурычы тора да инде.

Яшьләрдән еш кына үзенчәлек, оригинальлек таләп итәләр. Бу, билгеле, дөрес таләп. Ләкин оригинальлекнең үзен башкалардан аерылып тору, беркемгә дә охшамаска тырышу дип кенә аңларга ярамый. Чын оригинальлек күп мәртәбә җитдирәк һәм тирәнрәк төшенчә. Ул барыннан да бигрәк, дөньяга, тормышка, иялэнгән, гадәтләнгән

нәрсәләргә яңача карый, башкалар игътибар итми узып киткән нәрсәләрне күрә һәм алар турында укучыны уйландырырлык итеп яза белүдән гыйбарәт.

Бу мәгънәдә безнең күп кенә өлкән язучыларыбыз, яшь прозаиклар белән чагыштырганда, күп мәртәбә яшьрәк күренәләр. Мисал өчен И. Газинең «Кызыл томаннар артында» һәм Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» кебек әсәрләрен алыгыз. Эчтәлекләренең тирән һәм мөһим булуы ягыннан, сурәтләү чараларыннан яңа һәм тапталмаган булуы белән дә аларны чын мәгънәсендәге новатор әсәрләр дип бәяләргә мөмкин. Новаторлык, оригинальлек үзебезнең татар әдәбиятының һәм дөнья әдәбиятының иң яхшы традицияләрен үзләштерүне кире какмый. Киресенчә, зур тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе туплаган кеше генә, тынгысыз һәм өзлексез эзләнә торган әдип кенә үз йөзен табарга һәм өлкәннәр итәгенә тагылып йөрүдән котылырга мөмкин.

## Геройның интеллектуаль дөньясы

Әдәбият тормышны гомумиләштергән һәм шул ук вакытта индивидуаль, конкрет рәвештә эшләнгән образлар ярдәмендә чагылдыра. Бу күптән билгеле хакыйкать. Рас шулай икән, инде югарыда әйтелгәнчә, тормышны чагылдыру тирәнлеге барыннан да бигрәк кешенең катлаулы, каршылыклы һәм иксез-чиксез эчке дөньясына тирәнгәрәк үтеп керүдигән сүз була.

Кешенең рухи, эмоциональ дөньясын сурәтләү мәсьәләсендә татар әдәбияты байтак тәҗрибә туплаган. Мәхәббәт, дуслык, көнләшү, нәфрәт кебек хисләр, начармы, яхшымы, безнең хикәя, повесть һәм романнарда шактый күп сурәтләнгән. Ә менә кешенең интеллектуаль культурасын тасвирлау мәсьәләсе белән эш катлаулырак тора. Безнең көннәрдәге үзгәрешләр исә нәкъ шушы өлкәдә барыннан да тирәнрәк һәм кызурак рәвештә бара. Космосны яулау һәм фән-техника өлкәсендәге яңа ачышлар, Вьетнам сугышы һәм якын Көнчыгыштагы хәлләр — болар һәммәсе бүгенге яшьләрне нык борчый һәм алар күңелендә үз эзен калдыра. Һәм язучы, әгәр ул бөтенләй тормыштан артта калырга теләми икән, әлеге зур дөнья мәшәкатьләре белән кызыксынып яшәргә һәм үз геройларын тасвирлаганда заманның сулышын сиздерә белергә тиеш.

Безнең әдәбият кешенең интеллектуаль дөньясын бөтенләй читләтеп уза дисәк, дөрес булмас иде. А. Расихның «Ике буйдак» романын алыгыз. Бу әсәрдәге төп конфликт нәкъ менә фәнни эзләнү даирәсендә бара. Фәнгә төрле караш, тормышка капма-каршы мөнәсәбәт нәтиҗәсендә туган бу конфликтны без нинди киеренкелек белән күзәтәбез.

Кызганычка каршы, безнең мондый характердагы уңышларыбыз азрак шул. Бик күп китапларда, аеруча яшьләр язган әсәрләрдә, замандашыбыз ничектер төссез, кызыксыз, чикләнгән кеше булып чыга. Без ул китаплардагы геройларның ни рәвешле бер-берсенә гашыйк булуларын, үзара дуслашуларын һәм ачуланышуларын күрәбез, әмма ни рәвешле уйлыйлар алар — монысын бөтенләй диярлек күрмибез. Заман героен тасвирлаганда, авторлар гүяки аны тышкы дөнья белән бәйли торган җепләрне юри өзәләр, ә болай аерып кую геройның эчке дөньясын ярлыландырып калдыра.

Шундый характердагырак кимчелек Н. Фәттахның «Бала күңеле далада» исемле романында аеруча нык сизелгән иде. Роман безнең матбугатта тулаем уңай бәя алып өлгерде инде. Чыннан да, ул — үзенчәлекле һәм кызыклы әсәр. Язучы һәр нәрсә турында бары дөресен генә сөйләргә тырышкан. Ашыкмый гына, искиткеч төгәллек белән

ул чирәм җирләрне үзләштерүчеләр яшәгән тар, кысан һәм тынчу һавалы кыр вагоннарын, аларның авыр көнкүрешен, эчке мәҗлесләре һәм сугышларны, вак-төяк ызгыш-талашларны, гыйшкый бәйләнешләрне тасвирлый. Әмма көнкүреш ваклыкларына кирәгеннән артык игътибар бирү вак натурализмга китергән, фактлар дәреслеге фактлар дәреслеге генә булып калган.

Язучының иҗат кредосын аңлау өчен романнан бер эпизод китерү кызыклы булыр. Чирәм җирләрне үзләштерергә килгән кешеләр далада беренче буразна салалар. Һәм шул тантаналы момент менә болайрак тасвирлана. Башта каядыр киткән маякларны эзләп гомер уздыралар. Инде сөрә башладык кына дигәндә юеш җирдән тракторларның ике сабанны сөйри алмавы беленә. Берсен өзеп кенә калдырасы урында, кире беткән бригадир сабанның төрәннәрен сүтәргә тотына. Берне сүтеп ала, алай да тарта алмагач, икенче төрәнне, ниһаять, өченчесен... Борчылып, совхоз җитәкчеләре килеп җитә... Әнә шулай вак сүгенү-талашлар, көндәлек мәшәкатьләр һәм үпкәләшүләр белән беренче көн үтеп тә китә.

Күрәсез, автор юри һәртөрле пафос һәм идеаллаштырудан качарга тырыша. Аның геройлары ашау, йоклау, күбрәк акча күрәү кебек бик гади, хәтта физиологик борчу-мәшәкатьләр белән мәшгуль. Шуңа да алар ничектер артык түбән, канатсыз, омтылышсыз кешеләр булып күз алдына басалар.

Менә романның төп герое — Һарун. Аның ямьсез кыяфәтле, нәкәс, саран булуын, бер тиен өчен үлеп торуын автор басым ясап сурәтли. Аның теләк-омтылышлары да үзе яшәгән пычрак вагон тирәсеннән ерак китми. Хикмәт Һарунның Роден скульптуралары һәм неореалистлар иҗаты белән таныш булу-булмавында түгел, әлбәттә. «Авылдашым Нәби» исемле повестьтан ат караучы Нәбине алыгыз. Ул да гади колхозчы, аз укыган кеше. Әмма аның күңеле никадәр бай һәм матур, тормышның нинди мәсьәләләре генә борчымый һәм дулкынландырмый аны! Н. Фәттах безнең кешеләрнең менә шундый рухи бай булуын ача алмаган, шуңа күрә әсәрнең гомуми тоны да ничектер караңгырак тоела. «Мөдир Сажидә» исемле повестенда инде Н. Фәттах бу кимчелеген нигездә җиңә алган.

Повестьның төп герое Сажидәне авылга эшкә җибәрәләр. Башта бу аңа бер дә ошамый, авыл тормышының һәр ягы аның ачуын китерә, ул ничек тә булса моннан качу, институтка китү турында хыяллана. Әмма алга таба адым саен аның тирәсендәге кешеләрнең характерларында һәм күңелләрендә әйбәт яклар ачыла бара. Бюрократ председательнең салкын, гамьсез мөнәсәбәтенә җене чыккан кыз эш урынын ташлап китәргә карар кылып бетергән була, әмма кешеләр алдында җаваплы булуыңны, башкаларга кирәк икәнеңне аңлау хисе аны карарын үзгәртергә мәҗбүр итә. Язучының уңышы шунда, ул үз героен тышкы дөнья белән бәйләнештә бирә алган. Икенче пландагы персонажлар да үзмаксат белән генә кертелмәгән, алар Сажидә характерын ачыграк яктыртырга ярдәм итәләр.

Әмма Н. Фәттахның гомуми стиленә хас кимчелек бу повестьта да сизелә. Басар алдыннан редколлегия утырышында тикшергәндә дә, басылып чыкканнан соң да аның артык озынга сузылуын әйттеләр. Әбит повестьның журналга тәкъдим ителгән беренче варианты ике мәртәбәгә озынрак иде. Аны төзекләндерү юнәлешендә автор байтак эшләде, икенче дәрәҗәдәге эпизодларны һәм артык әһәмияте булмаган детальләрне кыскартты, әмма озынга китү, сузылганлык һаман сизелә. Нигә шулай?

Инде югарыда бер тапкыр әйткәнчә, Н. Фәттах тоташ вакыйгалар сайларга ярата. Кагыйдә буларак, ул артык озынга сузылмаган вакыт аралыгын ала, һәм геройларының шул вакыт аралыгындагы тормышын

бөтен вак-төяге, бөтен төгәллеге белән сурәтләргә тырыша. Шунда аны бер җитди куркыныч сагалый. Үз тормышыгыздагы теләсә кайсы бер көнне алып, ничек йокыдан тору, киерелү, аннан нәрсә эшләүләрегезне кертеп, протокол төгәллеге белән язып карагыз. Бер генә көнлек тормышны рәттән язып бару өчен дә берничә калын том кирәк булыр, барыннан да бигрәк, ул вак-төяк детальләрнең иң зур өлеше беркем өчен дә кызыклы тоелмавына ышанырсыз.

Сәнгать өчен характерлы, үзенчәлекле сыйфатларның берсе шунда, өзек-өзек вакыйгалар тезмәсе аша да автор чынлык иллюзиясе тудыра ала, шул ук вакытта икенче дәрәҗәдәге, әһәмиятсез, характерлы булмаган нәрсәләрне төшереп калдыра, яисә аларны сикереп уза бара.

Бер характерлы мисал. Хәтеремдә, ниндидер бер фильмда герой төнне йокламыйча, җәфалана-газаплана нидер көтеп уздыра. Беренче эпизод — сәгать телләре кичке унга җиткән, нерваланып беткән герой почмаклы-түрле бүлмә буйлап йөренә. Икенче эпизод — герой һаман шул рәвешчә йөренә. Тик бу юлы инде костюмын салып аткан да галстугы бер читкә шуышкан. Сәгать телләре төнге беренче яртыны күрсәтә, өстәлдә тәмәке төпчеге өеме. Өченче эпизод — башын куллары белән учлаган да герой диванда утыра, тәрәзәдән таң беленеп килгәне күренә. Экранда барлык шушы эпизодлар бик күп булса бер минутка сузыла. Ә үзенне син герой белән йокысыз төн үткәргәндәй сизәсең. Әнә шулай өзек-өзек вакыйгалар тезмәсе аша сәгать ярым вакыт эчендә кешенең бөтен гомерен сурәтләргә мөмкин. Язучының осталыгы үз герое тормышындагы кирәкмәгән, әһәмияте булмаган бөтен нәрсәне төшереп калдырып, иң характерлы, иң мөһим моментларны сайлый белүдә күренә. Шуның өчен дә детальнең, ягъни бөтенне чагылдыра алырлык кисәкнең, әһәмияте аеруча зур.

Менә Ә. Еникинең «Рәшә» повестеннан бер мисал:

«Ә ике айдан соң Зөфәр Гамбәр туташка өйләнеп ташлады. Кыз, ичмасам, диде ул, үзен юаткан булып... Гамбәр туташ та бәхетле иде. Очлы иякле мөлаем йөзен кечкенә көнбагыштай күтәреп, Зөфәренә «хуҗам!» дигәндәй карап кына тора иде ул. Ләкин Зөфәр аңа беренче көннәрдән үк шаярткан булып әйтеп куйды: «Синә, орчыгым, башынны түбән иеп кенә тору килешә!» — диде».

Бары бер генә реплика! Ә геройларның үзара мөнәсәбәте хакында никадәр күп сөйли ул. Зөфәрнең гаилә тормышы турында автор башка берни дә әйтми диярлек, әмма аның үз хатынын яратмавын, аңа өстән торып, хәтта беркадәр кимсетеп каравын сизү өчен шул бер реплика бик җиткән. Беренче карашка Гамбәр үз язмышыннан канәгать һәм бәхетле кебек, әмма без шикләнми әйтә алабыз: бәхет тәтемәячәк кызга, бу йортта башын түбән иеп кенә торырга туры киләчәк аңа. Ә бит теләгәндә, шушы нәрсәләрне әллә ничәшәр биткә сузып тасвирларга мөмкин булыр иде. Хәлбуки, автор андый юлдан китми һәм бу кадәресе аның бурычына керми дә. Ул Зөфәрнең алдагы тормышы ничек булачагына ишарә генә ясый, башкасын укучының үз ихтыярына һәм үз фантазиясенә калдыра.

Н. Фәттах әсәрләрендә исә вак-төяк җентекләү күп, ә менә шундый уңышлы табылган детальләр азрак. Тормыш аның әсәрләрендә таләпчән рәвештә сайлап алынмыйча, ничектер рәттән сурәтләнә, шуңа күрә аның әсәрләре артык сузынкы, артык озын тоелалар. Аны герой тормышының тышкы яклары: ничек йөрүе һәм ничек сөйләве күбрәк кызыксындыра, ә геройның эчке дөньясын ачу һәр очракта да уңышлы булып җитми.

Шундый характердагы кимчелекләр кайбер башка яшь прозаикларга да хас. «Әткәм һөнәре» исемле повестенда, мәсәлән, Х. Сарьян бик белеп һәм бик тәфсилләп үз героеның ничек эшләвен сурәтли. Йорт

салуга бәйләнешле күренешләр әсәрнең яртысын диярлек алып тора-лар. Ә менә геройның мәхәббәте пунктирлар белән генә бирелгән, абыйсына булган мөнәсәбәте турында әйтелеп бетмәгән. Повестьтагы аерым моментлар буенча хөкем йөрткәндә, Гаяз җәмәгать эшләренә һәвәс кеше булырга тиеш. Ул комсомол оешмасының эше белән кызыксынып йөри, бүрәнә урларга йөрүчеләрне фаш итә. Ләкин бу моментларга әсәрдә бик аз урын бирелгән, повестьның төп өлешендә исә Гаязның шабашниклыкта йөрүе сурәтләнә. Икенче бер яшь прозаикның әсәрендә герой күбрәк вакытын машина астында ятып һәм моторда казынып уздыра. Әйтерсең, автор техника ремонтлау белән мавыгып киткән дә, үз героеның эчке дөньясына күз салырга вакыты да юк.

Дөрес, яшь прозаиклар үз геройларының интеллектуаль дөньяларын да ачарга тырышып карамадылар түгел. Шундыйрак омтылыш Р. Төхфәтуллинның «Тамчылар ни сөйли» исемле повестенда ук сизелеп калган иде. Әмма, инде матбугатта әйтелгәнчә, авторның бу повесте аның элекке әсәрләреннән байтак төссез һәм йомшак чыкты. Куптән түгел Р. Төхфәтуллин бүгенге яшь замандашыбыз турында «Агымсу» исемле яңа әсәрен язды. Повестьның кыскартылган варианты «Казан утлары» журналының 1968 елгы 6 санында басылды, тулысы белән ул Татарстан китап нәшриятында чыкты. Кызганычка каршы, авторның бу повестен да укучы шактый суллән каршылады. Шундыйрак бер тәэсир кала, «Авылдашым Нәби»дән соң Р. Төхфәтуллин гел түбәнгә, гел кирегә тәгәри кебек. Хәтта Р. Төхфәтуллинның элекке стилен тануы да кыенлашты. Сүз кадерен белә торган, төгәл һәм пафослы җылы тел белән яза торган авторыбыз күп сүзлегә әйләнде, төче телле була башлады.

Мин повестьның ни өчен болай уңышсыз чыгуы турында күп уйландым. «Агымсу»ның төп герое Хәйдәр — шактый катлаулы язмыш кешесе. Язучы аның сугыш елларына туры килгән бала чагын шактый оста сурәтли алган. Менә Хәйдәрнең әтисе сугыштан кайта һәм улына бер шакмак шикәр тоттыра. Хәйдәр исә, акбур дип уйлап, аның белән стенага язып карарга тотына. Бу күренеш нык тәэсир итә. Сугыш еллары турында аның үзе һәм башкалар тарафыннан моңарчы язылганнарга әллә ни яңалык өстәмәсәләр дә, болар — повестьтагы иң уңышлы битләр. Бала чакта Хәйдәр зур бәхетсезлеккә очрый: кыядан егылып төшеп, умыртка сөяген сындыра. Язучы бик тәфсилләп һәм озын итеп (мин повестьның тулы вариантын күздә тотам) яшь геройның авыр кичерешләре һәм хисләре турында сөйли. Тормышта андый көтелмәгән бәхетсезлекләр сирәк булса да очрап тора, һәркем шундый хәлгә калырга мөмкин. Әмма бу момент әдәби әсәрдә нинди роль уйный?

Яшьли имгәнү Хәйдәрнең бөтен характерына билгеле бер эз салыр, ул үз эченә бикләнер, аз сүзләнер, йомылып калыр, дип уйларга мөмкин иде. Хәлбуки андый хәл булмый. Хәйдәр шат күңелле, кеше белән аралашучан һәм физик яктан гаять көчле. Ул, ике дә уйламый, үзенә һөҗүм иткән кораллы бандитларны дөмбәсләп ташлый, аз гына салып алуга бергә эшләгән нефтьче иптәшләрен читән аша чөя башлый, сандык хәтле ташларны күтәреп күрсәтә, бармак юанлыгы тимер чыбыкларны бау урынына ишә... Мондый көч сирәк кешедә була, бала чакта ук умыртка сөяге сынган кеше турында инде сөйләп тә торасы юк. Р. Төхфәтуллин үз героена шундый гадәттән тыш сыйфатларны өя генә, тик аның гарип калган мескен бер баладан әкият героена әверелүен җитәрлек дәлилләми. Бу исә беренче битләрдән үк укучының ышанычын какшата, укучы белән язучы арасында булырга тиешле эчкерсез мөнәсәбәтне боза, ә шунсыз чын сәнгать әсәре була алмый.

Язучы эзләнә һәм хаталана торган, бик тырышып һәм даими рәвештә үз-үзен тәрбияләү белән мәшгуль булган, кешелек җәмгыяте ирешкән мәдәният казанышларына омтыла торган герой, бүгенге яшь кеше образын бирергә тели. Ул безне, тырышып-тырышып, Хәйдәрнең бик әйбәт кеше булуына ышандырмакчы. Әмма «бал», «бал» дип такъpарлаганга карап кына бал тәмен тоеп булмый, диләр. Шуның кебек, автор безне Хәйдәрнең шәп егет булуына күпме генә ышандырырга тырышмасын, аның шул әйбәт сыйфатларын кылган гамәлләре, вакыйгалар ярдәмендә ачмый торып, без аңа ышанмыйбыз. Иң кыен һәм җаваплы бер моментта Хәйдәрнең үзен ничегрәк тотуын карыйк.

Автор Хәйдәр җаны-тәне белән Надяны ярата, ул аңа кече яшьтән үк гашыйк, ансыз яши алмый, дип ышандырмакчы. Надя Мәскәүгә укырга китеп бара, Хәйдәр ярыйсы гына яшәп ята, алай гына да түгел, Айсылу исемле чибәр генә кыз тирәсендә бөтерелә башлый. Җитмәсә, Надя каникулга кайткач, үзенең бу егетлеге хакында аңа да сөйли. Алар арасындагы мөнәсәбәт акрынлап суына бара, ахыр килеп, Надя башка бер кешегә кияүгә чыга. Хәйдәр Надяның «хыянәтен» (төбендә ул үзе кызны шуңа этәрде) бик авыр кичерә, кая барып бәрелергә белми мотоциклда чапканда авариягә эләгә, әллә ничә җире сынган, аңын югалткан килеш аны больницага китереп салалар. Аны чын күңелдән яраткан Айсылу, төннәр буе саклап, аның янында утыра. Хәйдәр яңадан аякка баса. Үзенең чын дусты кем икәнен, ниһаять, аңлагандыр дип уйлыйсың. Тик бервакыт Айсылуны каршы алырга килгән җирдән, тота да Мәскәүгә — Надя янына китә бу. Повестьның беренче яртысы шунда тәмамлана...

Күрәсез, геройның эшләгән эшләре җитәрлек дәлилләнмәгән, алар аның характерына туры килмиләр, нәтиҗәдә аңлашылмаучылык, каршылык туа. Уйларга сәләтле, интеллектуаль герой килеп чыкмый. Алай гына да түгел, аның хәтта эмоциональ дөньясы да шактый ярлы. Герой — үзенең уй-хисләре белән шактый элементар, хәтта беркатлы кеше. Укучылар да, күрәсең, повестьны шуңа салкын каршылаганнардыр.

Без укучының дөньяга карашы үсү турында күп сөйләргә яратабыз. Һәм бу чыннан да шулай. Ленин китапханәсенә йөри торган гади бер укучының карточкасын ачып карагыз. Татар язучыларының китаплары белән бергә, сез анда К. Симонов һәм К. Паустовский, И. Эренбург һәм М. Шолохов, Э. Хемингуэй һәм Л. Фейхтвангер әсәрләрен, кибернетика, биология, философия буенча хезмәтләрне очратырсыз. Китапханә хезмәткәрләренең сөйләвенә караганда, хәзер матур әдәбият белән кызыксынучылар арасында техника һәм фән кешеләре саны арта бара икән. Нигездә аларның күбесе югары белемле кешеләр, үзләренең төп һөнәрләреннән тыш, алар фән һәм сәнгатьнең төрле тармаклары белән дә кызыксыналар. Һәр яктан тирән мәгълүматлы булу аларның әдәби зәвыкларына да билгеле бер йогынты ясый. Мондый укучылар әдәби әсәрләрдән, барыннан да элек, фәлсәфи тирәнлек, зур гомумиләштерүләр, социаль һәм психологик төгәллек таләп итәләр. Аларны инде озын-озын максатсыз тасвирлаулар, ясалма сюжет һәм уйлап чыгарылган, аннан-моннан гына эшләнгән характерлар канәгатьләндерми. Үз әдәбиятыннан тыш бернәрсә дә белми торган укучы өчен язу — бер эш. Дөнья һәм рус әдәбиятының иң яхшы казанышлары белән таныш булган, әдәби әсәрләрне чагыштырып карый алган укучы өчен иҗат итү — бөтенләй башка нәрсә.

Укучының дәрәҗәсе үскән икән, язучыга куела торган таләпләр дә үсәргә тиеш. Әгәр замандаш образын бөтен тулылыгы белән бирергә, аның интеллектуаль дөньясын бөтен байлыгында күрсәтергә телибез икән, ул чагында без үзебез дә заманның катлаулы фәлсәфи һәм фән-

ни-техник проблемаларыннан артта калмаска тиешбез. Шулай булмаганда, укучы безне узып китәчәк һәм өстән-өстән эшләнгән беркатлы геройларыбыз белән танышу аңа күңелсез булачак.



## Тормыш материалы һәм иҗади хыял

Язучының илһам чыганагы — тормыш. Һәм язучы иҗат иткән образларның ышандыру һәм тәэсир көче, әдәби кыйммәте барыннан да элек аларның тормышчанлыгы белән билгеләнә. Ләкин язучы күзенә нәрсә чалына, шуларның һәммәсен күрсәтеп бара торган җансыз көзге түгел әле. Ул тормышны чагылдырып кына калмый, аны дөрес итеп сурәтли дә, икенче төрле әйткәндә, үз фантазиясе ярдәмендә тудырган әдәби образлар аша, иҗади хыял көче белән тормышны яңадан тудыра. Инде без язучы хыялы белән тудырылган дөнья турында хөкем йөртәбез икән, монда «бу дөрес, бусы дөрес түгел», «бу тормыштагыча, бусы алай түгел» дип утыру гына җитми. Аның иҗатын сәнгать законнарына таянып хөкем итәргә, әсәрнең эчке логикасы буенча хөкем итәргә кирәк. Әгәр ул тормыш күренешләрен тирән үзләштерә алмаган, әгәр аңа нининдидер бер урында зәвык һәм талант җитеп бетмәгән, әгәр ул эстетика кануннарын бозган булса, тормышны бик шәп белү дә язучыны коткарып кала алмый.

Г. Ахуновның «Хуҗалар» романын укыганда, тагын бер мәртәбә шул нәрсәләрнең дөреслегенә ышанасың. Аның берничә еллар элек чыккан «Хәзинә» исемле романын барыбыз да беләбез. Роман кимчелекләрдән арынып бетмәгән иде. Әйтик, автор романның экспозициясен артык озынга сузган, берничә сюжет линиясе һәм конфликт билгеләсә дә, аларның тик берсен — Кәрим Тимбиковның күтәрелү һәм һәлак булу линиясен генә ахырга кадәр җиткергән иде. Шундый кимчелекләре булуга да карамастан, роман үзенең яңалыгы, тормыш материалының кызыклы булуы белән игътибарны җәлеп итте. Автор нефть яклары өчен хас бер төп конфликтны — рекордлар артыннан куу, ялган дан артыннан кууны тотып ала алган һәм Кәрим Тимбиковның фаҗигале язмышы мисалында андый методларның зарарын күрсәтә алган иде. Роман хакында аз язылмады, нигездә аларның күбесе мактау рухында иде. Бу турыда язучыларның күбесе, шулар арасыннан мин үзем дә, Г. Ахуновның уңышын үз геройларының тормышын шәп белүе, аның Казаннан Әлмәткә күчеп китүе, үз геройлары янында эшләве, аларның омтылыш-теләкләрен тирән сиземләве белән аңлатканнар иде.

«Хәзинә»не язганнан соң да Г. Ахунов тагын байтак еллар нефтьчеләр башкаласы Әлмәттә яшәде һәм булачак әсәренең персонажлары белән якыннанрак аралашырга да, нефть якларындагы тормыш һәм өлгергән мәсьәләләр белән танышырга да, һичшиксез, зуррак мөмкинлек алды. Һәм Г. Ахуновның «Хуҗалар» исемле яңа романында бу сизелә дә, аның нефть якларын, ул яклар тормышына хас үзенчәлекләрне, һәртөрле мәсьәләләрне белү дәрәҗәсе тагын да тирәнәйгән. Шул ук вакытта «Хәзинә»дә үк сизелеп калган бер кимчелек тә көчәя, күзгә аермачык ташланырлык була төшкән. Сүз авторның зур күләмле эпик әсәрләрнең композициясен төзи белмәве, күп планлы һәм катлаулы әсәрләрнең барлык элементларын берләштерә, бер ноктага төйни алмавы хакында бара.

«Хуҗалар» — «Хәзинә»нең дәвамы. Монда нигездә шул ук геройлар белән очрашабыз. Дөрес, бу еллар эчендә аларның күбесе үсәргә, бер адым югары күтәрелергә өлгергән. Шуның белән бергә, композицион

төзелеше һәм әдәби идеясе белән дә «Хуҗалар» Мөстәкыйль, «Хәзинә»гә бәйләнмәгән әсәр. Мин әсәрнең идеясе дидем. Һәм шунда ук уйга калдым: «Хуҗалар»ның идеясе нинди соң? Укучыларга автор нәрсә әйтергә тели, аны нәрсә борчый, тынгысызлый, авторның әйтми кала алмаслык нинди яңа сүзе бар? Минем уемча, бөтен бәла дә шунда: романның идеясе бик үк ачык түгел.

Романның беренче битләрендә үк автор төп геройны — промыселлар идарәсе башлыгы Арслан Гобәйдуллинны борчып, газаплап торган мәсьәләләр белән таныштыра. Аларның иң зурысы — факелларда газ яндыру. Әйе, Татарстанның көньяк-көнчыгышында меңнәрчә факеллар дөрли, күпме кыйммәтле чимал әрәм була. Шул ук вакытта авылларда һәм эшче поселокларда ягулык җитешми, бик күп колхозчыларга һәм нефтьчеләр өенә газ кермәгән. Эш шунда, нефть белән чыга торган газны шул килеш, турыдан-туры кулланып булмый, аны махсус заводларда эшкәртергә кирәк. Бу исә — акча, зур чыгымнар дигән сүз. Дөрес, ахыр чиктә андый заводлар барыбер төзелә төзелүен, әмма кирәкле акча табылганчы, проект һәм сметалар төзелгәнче, төзелеш эшләре кызу темп белән башланып киткәнче байтак гомер уза, нәтиҗәдә катлам басымы кими төшә, җир астындагы байлыкның байтак өлеше янып көлгә әйләнгән була.

Әнә шулар өчен янып-көеп йөргән Арсланны Мәскәүдән буш кул белән кире борып кайтаралар. Аның инициативасы буенча эшләнгән проектны мактыйлар мактавын, ләкин заводны салу өчен акча бирмиләр. Йокысыз үткәргән төннәр, проект төзүчеләрнең күпме хезмәте, әйбәт башлангыч — барысы да җилгә оча. Бик үткен һәм тормышчан конфликтның очлары төйнәлде кебек. Тик Арсланның горком секретаре Корбанов янына керүе була — бөтен кыенлыклар җиңел генә чишелә дә куя: завод төзергә дә булалар, ул гына җитмәсә, бөтен бер шәһәр салырга да тотынмакчылар. Шул рәвешчә, оеша башлаган этапта ук конфликт чишелә, ә роман дәвам итә. Автор конфликтны вакларга, бүлгәләргә тотына, героен бер-берсе белән әллә ни тыгыз бәйләнмәгән күп төрле ситуацияләргә куя башлый.

Менә чын мошенник Гозәеров кыйммәтле ковер күтәреп килә. Арслан коверы-ние белән аны куып чыгара. Менә ул эшчеләрнең ике сәгать буе өйгә кайта алмый газаплануларын, ә аларны ташырга тиешле шоферның кыек юлда йөрүен ачыклый. Аның кушуы буенча, юньсез шоферны эшеннән алалар. Арслан карап торышка ук тискәре характерлы горком секретаре Мөстәкыймов белән конфликтка керә. Мөстәкыймов промыселлар идарәсенең партия бюросына үз кешесен уздырмакчы, ә коммунистлар исә үзләре шәп белгән кешене — Вильдановны сайлыйлар. Мөстәкыймов хур була. Моның өчен ул Арсланны гаепле саный, аның өстеннән вак-төяк фактлар туплап, эшен бюрога куймакчы.

Минем үземне Мөстәкыймовның мондый вак үчләшүе ышандырмый. Ярый, ышандырмасын да ди. Ләкин йөз проценты белән унай герой Корбанов, мәсьәләнең асылына төшенми, Гобәйдуллинны тикшергән комиссия кешеләре чыгарган карарлар белән алдан танышмыйча ук торып, промыселлар идарәсе начальнигының шәхси эшен бюрога куярга ничек җөрьәт итә? Күрәсең, автор укучыны билгесезлек белән җәфаларга, аның кызыксыну көчен арттырырга теләгәндер. Әмма Арсланның язмышы өчен артык кайгырырлык урын юк. Без аның гаепсез икәнен, хакыйкатьнең ахыр чиктә барыбер өскә чыгачагын алдан белеп торабыз. Шулай була да. Һәм яңадан укучының игътибарын азмы-күпме тотып торырлык менә бу вак-төяк каршылыкларның барысы да хәл ителеп бетә, ә романның күп булса яртысына гына җитеп килена. Шуннан соң автор күп кабатланган, күп сыналган котылу юлына мөрәҗәгать итә — заводта авария ясый (1968 елда бер «Казан утлары»нда гына

басылган өч әсәрдә — «Казан каласы — таш кала», «Агымсу» һәм, ниһаять, «Хуҗалар»да — сюжет үстерү алымы буларак авария кулланыла). Яңа төзелеп кенә беткән завод яна башлый. Утны тиз генә сүндерә алмыйлар, завод шартлау куркынычы туа. Арслан, үз гомерен куркыныч астына куеп, янгынның нәкъ уртасына, эченә керә һәм заводны шартлаудан саклап кала. Нәтиҗәдә Арслан бик нык пешә һәм аның җуя, ә хатыны һәлак була.

Болай караганда, янгын күренеше гаять оста язылган, ул урыннар кызыксыну белән укыла. Монда очеркистка хас төгәллек һәм дөреслек сизелеп тора. Әмма бөтен роман өчен ул әллә ни мәҗбүри булмаган һәм кыстырып куелган артык новелла кебек кенә тоела. Гомумән, «Хуҗалар» романында әйбәт язылган өзекләр күп кенә. Күңелле сабан туй күренешләрен, буровойдагы эшләрнең ничек баруын тасвирлаган битләрне, партия җыелышы күренешен шундыйлар рәтенә кертергә кирәк. Ләкин ул эпизодлар ныклы бер төенгә төйнәлмәгән.

Мәсәлән, Буяновның алтынның зарары турындагы нотыгы болай бик шәп, ә роман өчен аның кирәге шул кадәр генә. Яисә Арслан хатыны Сәгыйдәнең үз бакчаларына баруын сурәтләгән урыннарны алыгыз. Монда табигать гүзәллеге, ниндидер эчке бер моң, табигатьне төгәл күзәтүләр бар. Ләкин аларны сызып ташлаганда да әсәр әллә ни үзгәрмәс иде. Практикага килгән студентларны эшкә алуга багышланган эпизодлар турында да шуны ук әйтергә була. Әсәрдә теге яки бу дәрәҗәдә уңышлы эшләнгән аерым кисәкләр, аерым-аерым кирпечләр бар, ләкин автор алардан төзек бер бина кора алмаган. Кирпеч өеме үзе генә әзер өй дигән сүз түгел әле.

Бәлки, авторга очерк стиленә кирәгеннән артык бирелү комачаулагандыр. Ул нефть яклары тормышын мөмкин кадәр киңрәк яктыртырга, үз романына күбрәк материал тыгарга тырышкан. Ләкин артык күп әйтергә тырыша башладыңмы, берни дә әйтә алмый калуың бар. Романда шактый уңышлы тасвирланган хезмәт күренешләре, бүгенге тормышка хас билгеләр (яшьләр кафесы, сакаллы практикантлар, алдынгы бригадаларның Себер нефтен үзләштерергә китүләре һ. б. һ. б.) күп. Ләкин бит матур әдәбиятта зур әйберләр вак, бәләкәй нәрсәләр аша күрсәтелә, чор, эпоха кеше җаны, кеше характеры аша тасвирлана. Тормыш материалын сайлап алганда язучы нәкъ әнә шул кулланмаларга таянып эш итә, чөнки язучы туплаган материал бер генә роман кысасына сыеп бетмәячәк. Кызганычка каршы, Г. Ахунов шуларны ныклы, таләпчән рәвештә сайлап ала, үзе күргән һәм ишеткән нәрсәләрне хыялы аша уздырып бергә туплый, берләштерә алмаган.

Ахыр чиктә үз романының формасын автор үзе сайлый. Әгәр язучы тулы канлы образлар тудыра алса, безне сәнгатьчә ышандыра алса, әсәрнең композицион яктан таркаулыгы, конфликтның сүлпәнлеге белән дә килешергә мөмкин булыр иде. Кызганычка каршы, бу да юк. Романның үзәк герое Арслан Гобәйдуллинны алыйк. Тырышып-тырышып автор безне Арсланның шәп кеше булуына ышандырмакчы. Арслан принципиаль дә, эшлекле дә, таләпчән дә, кыю һәм физик яктан да көчле. Күрәсең, ниндидер бер урында автор кирәгеннән артыграк тырышып җибәргән һәм образның эчке логикасын бозып ташлаган. Әйтик, Арсланның Гозәеровны куып чыгаруына, эш өчен янып-көеп йөрүенә һәм горком секретаре белән каршылыкка керүдән курыкмавына да ышанырга була. Ләкин инде физик хезмәт белән шөгыльләнмәгән бер кешенең район сабан туенда батыр калуына ышану кыенрак. Янып торган ут эченә кереп краны да Арслан гына яба алуына ышанып булмый. Махсус өйрәтелгән һәм тәҗрибәле пожарниклар моны әйбәтрәк башкарырлар иде.

Г. Ахунов зур масштаблы яңа тип җитәкче образы бирергә теләгән. Әмма шул ук вакытта ул уңай герой иҗат итү буенча элек тупланган тәҗрибәгә ябышып ята. Ә бит җитәкче кеше өчен физик яктан да көчле булу һич мәҗбүри түгел, аның акыл көчен, интеллектуаль культурасын күрсәтү мөһимрәк. Үзенең ут эченә ташлануы да соралмый, җитәкче буларак, ул аварияне булдырмый калу чараларын күрергә тиеш иде. Героен югары күтәрәм дип, автор буяуларны кирәгеннән артык куертып ташлый һәм нәтиҗәдә укучының ышанычын югалта. Иң мөһиме шунда, ул үз героеның эчке дөньясына үтеп керә алмый.

Арсланның гаилә тормышы бик үк шәптән бармый. Ул хатынына карата шактый кырыс мөнәсәбәттә, аны иркәләми, аның белән сөйләшми, диярлек. Шул ук вакытта ул беренче мәхәббәтен — Мөнәвәрәне оныта алмый. Шушы катлаулы ситуациядән герой ничек чыга соң? Автор иң гади һәм күп тапталган юлдан китә — бернинди кызганусыз Арсланның законлы хатыны Сәгыйдәне үтерә. Һәм, турысын әйткәндә, соңгы күренештә хатынының үле гәүдәсе янында торган Арсланның Мөнәвәрә килүен ишетүгә шатлануы бер дә аның файдасына сөйләми. Автор, янәсе, Арсланның гаилә тормышы да рәтләнәчәгенә ишарә ясый.

Аннан соң, әлеге үлем турында. «Хәзинә»дә төп геройлардан берсенең үлеме белән тәмамланган иде. Әмма анысы әдәби яктан акланган үлем иде. Характерның үсеш логикасы үзе, куркынычсызлык кагыйдәләре белән исәпләшми-нитми рекордлар артыннан куу геройны һәлакәткә илткән иде. Ә Сәгыйдә очраклы рәвештә һәм мәгънәсез үлә. Әйе, тормышта һәр төрле очраклы хәлләр була. Тик инде әдәби әсәрдәге очраклы нәрсә — сәнгать законнарына каршы бару, дигән сүз. «Хуҗалар»да уңышлы гына сайланган образлар да (Вильданов, Мөстәкыймов) бар, әмма Фәйрүзә, Зозуля, Мөнәвәрә, Дияровлар һәм «Хәзинә» буенча ук безгә таныш башка образлар җитәрлек үстерелмәгәннәр. Аларның электән билгеле якларына яңа берни дә өстәлми диярлек.

Г. Ахуновны уңышсызлыкка дучар иткән сәбәпләрнең берсе, бәлки, безнең әдәбиятның искергән традицияләренә иярүдә — дәвамлы романнар язудадыр. Еш кына укучылар авторны хатлар белән күмеп ташлыйлар, аларны геройларның соңгы язмышы кызыксындыра, нәрсә белән беткәнен беләселәре килә. Һәм автор, укучылар соравын канәгатьләндерү йөзеннән, әсәрнең дәвамын язарга керешә. Тик андый хатлар алдаучан була. Әсәр укучыларга уйларга, фикер йөртергә җирлек калдыруы белән кызыклы да. Бөтен мәсьәләләр ачыкланып бетмәгән, укучының үзенең дә кызыксынуы кими.

Дәвамы булган романнар тагын шул яклары белән куркыныч, алар авторны таркаулыкка этәрәләр, идеянең ачык булмавына китерәләр. Бөтен сюжет җепләрен бер төенгә төйнисе урында, иң кирәклесен генә сайлап алып, барлык икенче дәрәҗәдәге нәрсәләрне ташлап калдырасы урында, автор бөтен материалны бер өемгә өяргә тотына, әйтелеп, ачылып бетмәгән нәрсәләрне икенче кисәгендә әйтергә калдыра. Г. Ахуновның яңа романы безне күп язу — күп әйтү дигән сүз түгеллегенә кабат ышандыра.

* * *

Шулай итеп, соңгы елларда яшь прозабыз яңа исемнәр һәм яңа әсәрләр белән баеды. Яшь һәм урта буын прозаиклар чынбарлыкның яңа катламнарын үзләштерәләр, элек тасвирланган күренешләрнең яңа якларын ачалар. Ләкин хәзергә әле яшь прозаиклар (шунда ук урта буын әдипләрен дә кертергә була) күбрәк ияләшкән, тапталган сукмак

буйлап атларга яраталар, авторларның үз йөзләрен күрү кыен. Яшьләр иҗат иткән әсәрләр арасыннан формалары ягыннан да, күтәргән тема-проблемалары һәм идеяләре буенча да чын мәгънәсендә яңа дип саналырлыкларын күрсәтү шактый авыр. Яшьләр прозасына тормышка тирән керү, чын интеллект һәм гражданлык пафосы җитенкерәми. Бер уйласаң, гаҗәпләнерлек тә: һәр язучының диярлек кесәсендә югары уку йорты бетерү турында диплом бар, әдәбиятка алар өлкән иптәшләре туплаган тәҗрибәне үзләштереп киләләр. Үзенең бер чыгышында И. Гази билгеләп үткәнчә, хәзерге яшьләр иҗат юлларын югарырак баскычтан башлыйлар, һәм аларның ераграк китәргә бөтен мөмкинлекләре бар.

Тик коры белем генә җитми икән. Безнең өлкән буын әдипләребезнең байтагының эзлекле һәм тулы белем алырга мөмкинлекләре булмый. Ләкин алар башка мәктәп, тормыш мәктәбе узалар — гражданнар сугышы, Ватан сугышы утында чыныгалар, газап-михнәтне җитәрлек күрәләр.

Яшь буын язучылар өлешенә өлкәннәр күргән газап-михнәтләрне калдырмавы өчен тарихка, язмышка үпкәләү зур гөнаһ булыр иде. Ләкин, мәсьәләгә объектив рәвештә караганда, аларның ихтыярына һәм теләкләренә бәйсез рәвештә, чорның шундый булуы яшьләрнең рухи һәм гражданлык йөзләренә дә билгеле бер эз салган. Аларның гражданин һәм иҗат кешесе буларак өлгерүләре акрынрак бара. Һәм бу безне борчымый кала алмый.

Мәкаләмдә мин яшьләр прозасының кимчелекләренә һәм җитешсезлекларына юри күбрәк тукталдым. Үсеш перспективаларын күз алдына ачыграк китерү һәм булган кимчелекләрдән тизрәк арыну өчен шулай кирәк иде. Моңа безнең яшьләрнең көче җитәр, дип уйлыйм.

Рәхилә Шәмсетдинова

# ЯЛКЫН КЕБЕКЛӘР

*Әдәбиятыбыздагы яңа герой турында кайбер күзәтүләр*

**Яңа сәнгать беркайчан да яңа формалардан башланмый, яңа сәнгать яңа кеше белән туа.**

**И. Бехер**

Егерменче гасырда ирешелгән тарихи казанышлар, барыннан да бигрәк һәм беренче чиратта Бөек Октябрь революциясе, дөньяны сәнгать чаралары белән танып-белүгә, шулай ук сәнгать әсәрләренең эчтәлегенә искиткеч зур йогынты ясадылар. Иске иҗтимагый мөнәсәбәтләрне революцион юл белән җимереп ташлау, электе изелгән милләтләргә азатлык бирү нәтиҗәсендә гади хезмәт кешесе рухи үяну юлына басты, үзен тормышның хуҗасы итеп сизә башлады. Совет язучылары бөек тарихи вакыйгалар тәэсирендә формалашып килгән шул яңа кешене игътибар белән күзәтә бардылар һәм, аны үз әсәрләренә кертеп, зур гомумиләштерү көченә ия булган әдәби образлар иҗат иттеләр. Шулай моңарчы күрелмәгән эпоханың яңа идеяләрен һәм кешеләрен сурәтләүне үз өстенә алган социалистик сәнгать туды.

Яңа сәнгать тудырган күренеш һәм фактларга анализ ясау, аларның асыл мәгънәсен тикшерү һәм бәяләү өчен 20—30 еллардагы татар совет әдәбияты бай материал бирә. Х. Госман, Г. Халит, Х. Хәйри, М. Хәсәнов, Н. Юзиев, Р. Бикмөхәммәтов, М. Мәһдиев һәм башка авторларның хезмәтләрендә бу еллар әдәбиятына хас процесслар һәм үзенчәлекләр шактый тулы яктыртылган. Социалистик реализм методын эшкәртүгә, шулай ук әдәби герой, традиция һәм новаторлык, тормышны сәнгатьчә гәүдәләндерүнең төрле алымнары кебек мәсьәләләрне фәнни өйрәнүгә алар күп өлеш керттеләр. Алар язган монография һәм фәнни мәкаләләрдә татар әдәбиятындагы яңа геройның үсеш эволюциясе күзәтелә, ул геройның характерлы сыйфатлары һәм үзенчәлекләре күрсәтелә, әдәби образларны сурәтләү алымнарының тулы системасы тикшерелә. Татар галимнәренең бу өлкәдә ирешкән уңышлары беркемдә дә бәхәс уятмый.

Ләкин, шуңа да карамастан, татар совет әдәбиятындагы яңа геройга караш мәсьәләсе, безнең уебызча, тагын да әтрафлырак һәм киңрәк төстә тикшерүгә лаек. Бу мәкалә 20—30 еллар татар прозасындагы яңа геройның эмоциональ-рухи дөньясын тикшерүгә багышлана. Мәсьәләне һәрьяклап һәм ахырынача хәл итүне дәгъва кылмастан, автор, 20—30 еллар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләренә таянып, иҗтимагый, социаль, әхлакый факторлар тәэсирендә яңа шәхеснең формалашу процессын тикшерергә бер омтылыш ясап карый. Соңгы еллар әдәбиятында образларны юри кечерәйтү, юри түбәнгә төшерү, кешене иҗтимагый идеаллардан аерып карау кебек тенденцияләр сизелүен, шул берьяклы тенденцияләрне хәтта фәнни дәлилләргә тырышучы аерым «белгечләр» дә очравын

исәпкә алсак, югарыда әйтелгән мәсьәләләрне өйрәнүнең никадәр мөһим һәм актуаль булуы, шаять, аңлашылыр.

Әгәр инде күп милләтле совет әдәбияты туплаган бай тәҗрибәгә күз салсак, шуны күрәбез: мәдәниятебезнең алтын фондына керерлек иң яхшы әсәрләр чынбарлыкны бөтен катлаулыгы белән һәм үсештә чагылдырган, тормышны бөтен каршылыклары белән сурәтләгән авторлар тарафыннан иҗат ителгәннәр.

Билгеле булганча, батырлык, геройлык тормышыбызның төп тенденциясе санала. Халкыбызның һәм революцион, һәм хезмәт юлын дөрес чагылдыруны үз өстенә алган әдәбият исә мондый факторларны читләтеп уза алмый иде, әлбәттә. Һәм беренче адымнарыннан ук совет әдәбияты яңа җәмгыять төзүче гади кешегә дан җырлауны үзенең төп вазифасы итеп кабул итте. Идея һәм эстетик эзләнүләр өлкәсендә нинди генә юллардан бармасын, егерменче ел татар әдәбияты да яңа тормышны пассив рәвештә күзәтеп тору белән генә чикләнмәде. Революция һәм гражданнар сугышы аның төп темасы иде. Бу теманы хәл итү шәхеснең психологик, әхлакый һәм рухи яңаруын өйрәнүдән аерылгысыз барды.

Ул елларда язылган роман, повесть, хикәя битләрендә изүгә һәм җәбер-золымга каршы күтәрелеп революция ясаган гади хезмәт кешесенең кызыклы образы теркәлеп калган. Үз замандашларын тасвирлаганда әдипләр төрле юллар белән барганнар. Геройны романтик югарылыкка күтәреп сурәтләү алымы исә аеруча характерлысы булган. Бу, күрәсең, яңа кеше образының әлегә тулысынча формалашып һәм ачылып җитмәве, аның сәнгатьтәге сурәте яңа туып кына килүе белән бәйләнгән булгандыр. Гадәттә, урнашып, формалашып җитмәгән материалны һәм тормыш күренешләре арасындагы бәйләнешләрне, аларның үсеш логикасын тотып-эләктереп алу бик кыен була. Аннан соң бөек эпоханың зур үзгәрешләрен сизеп яшәгән әдипләр үзләре дә үсү, формалашу процессы гына кичерәләр иде әле.

Егерменче еллар әдәбияты революция ясаган халыкның монументаль образын иҗат итте. Моңа ул беренче чиратта революцион көрәшкә күтәрелгән массаларның үзләрен сурәтләү аша иреште. Рус әдәбиятында А. Малышкинның «Даирның җимерелүе», Д. Бедныйның «Төп урам», В. Серафимовичның «Тимер ташкын»ы кебек әсәрләр язылды. Революцион чынбарлык һәм пролетариатның авыр көраше ул әсәрләрдә «эре план» белән, ә киң массаларның тормышы гомумиләштерелгән монументаль образ аша гәүдәләнде. Шул ук вакытта, ул әсәрләрнең һәрберсендә диярлек (А. Серафимовичның «Тимер ташкын» романы исә бу җәһәттән аеруча характерлы) без истә калырлык итеп эшләнгән колоритлы характерлар, аерым шәхесләрне дә очратабыз.

Давыллы, шашкын чор вакыйгаларын массалар хәрәкәте аша күзаллау К. Нәҗми һәм Ш. Усманов әсәрләренә дә хас. Дөрес, Ш. Усмановның «Кызыл байрак астында» исемле әсәрендә кеше, шәхес буларак, тышкы яктан болай мөстәкыйль, ул бары үзенә генә хас сыйфатлары белән дә бирелә-бирелүен. Өстән-өстән генә булса да, автор үз геройларының эчке дөньяларына күз ташларга, аларның тормыш юлларын, ничек формалашуларын күрсәтергә дә онытмый. Әмма кызыл байрак астында дошманга каршы сугышып йөргән меңнәрчә каһарманнарның берсенә генә дә аерым игътибар күрсәтелми, аларның берсе генә дә әсәрдә үзәк урынга куелмый. Әйтерсең лә, үз геройларының уй-хисләрен, эчке кичерешләрен автор юри каплап-күмеп калдыра. Әсәрдә күбрәк хезмәт халкын азатлык, бәхет өчен көрәшкә күтәргән сәбәпләр турында, бер-берсенә бөтенләй охшамаган кешеләрне берләштергән теләк-омтылышлар турында сөйләнә. Ш. Усманов өзлексез алмашынып, үзгәреп торган вакыйгалар һәм кешеләр ташкынын күзалларлык эпизодларны гына алган, шуларны кәгазьгә төшереп калдырган. Бүлектән бүлеккә давыллы революция ташкынының, тормыш картиналарының бөтенлек хисе үсә, көчәя бара сыман. Илдә барган вакыйгаларны берберсен итеп бирергә, халыкның активлыгын һәм көрәшнең массовый төс алуын күрсәтергә тырышу гомумиләштергән образ иҗат итүгә китергән. Шулай повестьның төп герое, ягъни революцион массалар образы туган. Күпмедер дәрәҗәдә индивидуальләштерелгән аерым персонажлар бар икән, алар әлеге революцион массаларны, аларның аерым сыйфатларын характерлау өчен генә кертелгән. Отряд командиры Мансур да, комиссар Хәйдәр дә һәм, ниһаять, пулеметчы Шәйхи дә нигездә коллективның торган саен ныгый баруын, кызылармеецларда аңлылык үсүен раслар өчен генә алынганнар. Аларның эш-хәрәкәтләре аша илдә барган вакыйгаларга миллионнарның мөнәсәбәте сурәтләнә. Әгәр Ш. Усмановның бу

әсәрен Д. Фурмановның «Чапаев»ы белән янәшә куеп карасак, вакыйгаларны бу рәвешчә гомуми романтик төстә генә тасвирлауның чикләнгәнрәк булуын да күрербез. Фурманов әсәрендә халык язмышы аерым шәхесләр язмышы аша күз алдына баса. Ш. Усманов исә, индивидуаль характерлар иҗат итүгә азрак игътибар биреп, нигездә массаларны әдәбиләштерә.

Шул кадәресен дә билгеләп үтәргә кирәк, кайбер галимнәр революция вакыйгаларын шул рәвешчә сурәтләүне бу еллар әдәбиятының көчсезлеге, дип бәялиләр, геройның эчке дөньясында барган үзгәрешләрнең ышандырырлык итеп бирелмәвен дә шуның белән аңлатырга тырышалар. Алай гына да түгел, массалар образын сурәтләү егерменче еллар әдәбиятының төп һәм бердәнбер үзенчәлеге дип караучылар да очрый. 20—30 еллар әдәбиятының үсеш тенденциясе турында сөйләгәндә, бу үсешне кайберәүләр революцион масса образыннан аерым шәхесләр тудыруга күчү төсендә барды кебегрәк итеп аңлаталар. Мондый караш тарафдарлары революциянең беренче елларындагы әдәбият массаны, бары тик талпаны гына сурәтләде, кеше характерларына, аның рухи дөньясына бөтенләй игътибар итмәде, дип ышандырырга тырышалар.

Безнеңчә, мондый караш әдәбият үсешенең реаль картинасын төгәл чагылдырмый. Дөрес, Совет властеның беренче елларында язылып, массалар хәрәкәтен җанландыруга багышланган аерым әсәрләр теге яки бу характердагы кимчелекләрдән азат түгелләр иде, үз геройларын өстән-өстән генә тасвирлаган өчен бу әсәрләрнең авторларын орышырга, схематизмда гаепләргә мөмкин. Әмма революция һәм гражданнар сугышына багышланган әлеге әсәрләр иҗат ителгән тарихи эпоханы, ул еллар әдәбияты алдында беренче чиратта торган бурычларны да онытырга ярамый. Аның характерын билгели торган шартларны исәпкә алмый торып, әдәбият хакында дөрес хөкем йөртеп булмый.

Яңа тормыш әдәбият алдына тарихның революцион барышын дөрес гәүдәләндерә алырлык яңа стиль, яңа алымнар булдыру бурычын куйды. Һәм, үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, чорга лаек әдәбият тудыру бурычы төрле юнәлештәге эстетик эзләнүләр алып баруны таләп итте. Революция халык массалары кулы белән ясалды дип уйлаган һәм шуңа ышанган бик күп язучылар чорның бөеклеген көрәшкә күтәрелгән аңлы массаларның үзләрен сурәтләү аша чагылдырырга уйладылар. Һәм бу бик аңлашыла торган нәрсә иде.

Нәтиҗәдә халык массаларының көчен, ролен чагылдырырга, бер хис, бер уй белән янган меңнәрне сурәтләргә омтылыш көчәйде. Вакыйгаларны тасвирлауга романтик гомумиләштерүләр аша якын килүнең төп өстенлеге әнә шунда иде. Бу — чорның үз ихтыяҗлары тәэсирендә туган һәм үзенә күрә новаторларча бер күренеш иде.

Шуның белән бергә, яңа эпоханың асылын дөрес аңлый барып, язучылар социалистик җәмгыятьне төзүче аерым шәхесләрнең әдәби образларын коярга, икенче төрле әйткәндә, революцияне кеше күңеле аша күрсәтергә дә омтылдылар. Революция тудырган геройның җанына, рухи дөньясына тирәнгәрәк керүне куәтләп язылган фәнни хезмәтләр һәм мәкаләләр күбәя башлады. А. В. Луначарский, мәсәлән, язучы тарафыннан сурәтләнгән вакыйгалар чылбырына, тормышның тышкы күренешләре белән беррәттән, чынбарлыкның кешеләр аңында, әгәр шулай әйтергә ярасә, аларның күңелендә бара торган өлеше, һәм бик мөһим өлеше дә кертелергә тиеш, дип язды [1].

Кешенең эмоциональ һәм рухи дөньясын тирәнтен ачмый торып, яңа тарихи эпоханың әһәмиятен һәм асыл мәгънәсен аңлау һәм яңа эпоханы бөтен катлаулылыгында күрсәтү кыен булачагы хакында язучылар торган саен күбрәк уйлана башладылар. Кешенең характерын күрсәтми, аның эчке дөньясына керми торып, революцион юл белән чынбарлыкны үзгәртеп корырга алынган халыкның тормышын дөрес чагылдыру мөмкин түгел иде. Менә шуңа күрә дә татар совет әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре итеп катлаулы, бай рухлы, шуның белән бергә, күпкырлы характер тудыруга багышланган әсәрләр исәпләнә. Шуның ачык бер мисалы — Галимҗан Ибраһимов иҗаты.

Галимҗан Ибраһимов әсәрләрен кеше характерларын һәм чынбарлыкны сәнгать чаралары белән танып-белүнең менә дигән үрнәкләре итеп карарга мөмкин. Әдип тормыштагы яңаны эзли; тормышның нинди күренешләре җимерелергә һәм ни өчен җимерелергә, нәрсә калырга һәм ныгырга тиеш — Ибраһимов әнә шул нәрсәләрне

[1] А. В. Луначарский. Статьи о советской литературе. Рус телендә. Мәскәү. 1968 ел. 222 бит.

аңларга тели. Теге яки бу шартларда шәхес үзен ничегрәк тотар? Бу катлаулы һәм давыллы эпохада ул нинди юлны сайлар? Иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең яңа формалары шәхеснең үсүенә ниндирәк йогынты ясар? — Язучыны әнә шундыйрак сораулар кызыксындыра. «Кызыл чәчәкләр» повестенең дә үзәгенә шул ук мәсьәләләр куелган. Иҗтимагый укладны яңарту һәм үзгәртү белән бергә, социалистик революциянең кешенең үзен дә яңартып корырлык көч икәнлеген аңлау һәм ачу җәһәтеннән карaганда, Г. Ибраһимов үзенә кадәрге бөтен татар язучыларыннан югары күтәрелде.

Кеше үзенең хокукы, бәхете һәм кешелек горурлыгы өчен көрәшергә тиеш иде. Сыйнфый көрәшнең рәхимсез логикасы бөтен кискенлеге белән бер мәсьәләне хәл итүне — «кем белән» бару мәсьәләсен хәл итүне таләп итте. Шул ук сорау бөтен җаваплылыгы белән «Кызыл чәчәкләр» повестеның үзәк герое Солтан каршында да тора. Бу образда әдип, авыр сугыш һәм революция сынаулары аша узып, күзе ачылган, рухи яңарган кешенең характер сыйфатларын гәүдәләндерә. Халыкның түбән катлавыннан чыккан меңнәрчә яшьләр кебек үк, Солтан үзенең чын кеше булуын, тормышның яңаруын аңлый башлый. Характердагы бу үзгәреш гаять киң тарихи планда күзәтелә: Солтанның күзе империалистик сугыш кырларында, Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы фронтларында көрәшеп йөргәндә ачыла.

Әле бала чакта ук Солтан дөньяның тигез түгеллеген, байларның гел рәхәттә, ярлыларның җәбер-золым, кыенлык күреп яшәүләрен төшенә. Тик көрәш юлына кинәт кенә басмый ул. Крестьян психологиясе белән тәрбияләнгән егет дөньялар бер рәтләнер, тормышы җайга салынып әле, дип ышанып яши. Ул, тизрәк үсеп җитеп, акча эшли башлау һәм чүплек башындагы өйләрен зур урамга күчереп салу турында хыяллана. Үсеп җитүгә, читкә китә, ярыйсы гына акча туплап кайта, балачактан килгән куптәнге хыялын тормышка ашыра: зур урамда яңа йорт торгыза. Әмма бәхет өчен болар гына аз булып чыга. Сугыш авырлыклары, революция давыллары аша узган Солтан азатлык өчен көрәшү генә чын бәхет китергәнен, бәхет өчен бүтән юл булмавын аңлый.

«Кызыл чәчәкләр» әсәрендә язучы, кеше язмышларының катлаулы борылмаларын күрсәтеп, шәхес җәмгыятьтән, җәмгыятьнең барышыннан аерылган хәлдә яши алмый, дигән карашны уздыра. Геройлар тормышындагы рухи һәм социаль күренешләр, шәхси һәм иҗтимагый нәрсәләр шулкадәр тыгыз, аерып ала алмаслык булып үрелгәннәр, гүяки алар кеше җәмгыятьтән тыш яши алмый, дигән тезисны тагын бер мәртәбә раслап торалар.

Ибраһимовның геройлары җәмгыять, үзләрен тудырган дөнья белән тыгыз бәйләнгән. Яңа социаль процесслар кешеләрнең күңелләренә аларның уй һәм хисләренә дә тәэсир итми калмый. Тормыш төбендәгеләр үзләрен дөньяның хуҗасы итеп аңлау югарылыгына күтәреләләр.

Повестьтагы төп социаль конфликт Солтан белән Галинең үзара бәрелешендә ачык гәүдәләнгән. Алар — капма-каршы сыйнфый позиция кешеләре. Гали кебек эгоист табигатьле кешене шәхси милекчелеккә корылган иске дөнья тудырган. Ул үзе кебек кешеләр өчен генә бәхет яулау турында хыяллана. Шул хыялы аны революция дошманнары лагерена алып килә. Аның сыйнфый дошманлык хисләре шул дәрәҗәгә җитә ки, Гали балачак дусларыннан Гыйлаҗны үз кулы белән җәзалый. Иске, кеше бәхетенә дошман сыйныф вәкиле булганга күрә дә, Гали җиңелә, аның тормышы түбәнгә тәгәри, ул рухи яктан череп таркала... Ә яңалык тарафдары, яңа тормыш вәкиле Солтан һаман үсә, рухи байый бара. Шәхси тормышында нинди генә авырлыкларга юлыкмасын, аннан, Солтаннан, тормыш шатлыгы бәрелеп тора, повестьның оптимистик яңгырашын әнә шул «җиңү шатлыгы» билгели дә инде. Кеше бөтен буйга тураеп баса, аңарда кешелек горурлыгы уяна. Хезмәт кешесенең азатлыгы өчен көрәшкәндә, үзендә дөньяга яңача караш тәрбияләгәндә генә кеше үз бәхетенең иҗатчысы һәм хуҗасы була ала — Г. Ибраһимов гуманизмының төп асылы әнә шуңа кайтып кала.

«Кызыл чәчәкләр»дә язучы халык әкиятләре алымыннан шактый киң файдалана. Әсәрнең төп герое (вакыйгалар исә аның авызыннан сөйләнә) романтик буяулар кулланып һәм күтәренке тон белән чынбарлык күренешләренең иң катлаулы картиналарын җанландыра. Ибраһимов көчле сәнгать чаралары ярдәмендә ышандырырлык итеп шул еллар тормышына хас романтик пафосны бирә алган. Кызыл чәчәк образы әсәрдәге романтик хисне, әкиятләргә хас серлелекне тагын да көчәйтә төшкән. Бу символик образ геройның гүзәл идеалларга омтылуын гәүдәләндерә.

Повесть мосафир карт калдырган кызыл орлыкларны искә төшерүдән башланып китә. Ләкин әлеге кызыл орлыклар язын вакытында тишелеп чыкмыйлар: кемдер орлыклар өстенә тирес түккән, ниндидер бер явыз кара таш белән аларны бастырып киткән. Тиресне себереп түгеп, ташларны читкә алып ыргыткач, җылы яңгырлар ява, якты кояш карый: бакча бердән яшелләнеп китә. Көзен әлеге чәчәкләр кызыл орлыклар бирә. Тиздән әлеге орлыклар бөтен авылга, аннан бөтен тирә-якка тарала. Моның белән язучы яңа тормышның җиңеп чыгуына һәм яңа, азат кешенең туу процессына ишарәли. Авыр тормыш сынауларын узганнан соң, герой кызыл чәчәк образының асыл мәгънәсенә төшенә. «Шаһбаз белән Гыйлаҗи,— ди Солтан,— бервакытта да күңелемнән чыкмыйлар. Бу ике иптәш минем йөрәгемә революция белән бергә бәйләнып кереп утырдылар [1]. Явыз, кара көчләр өстеннән җиңү символы булган кызыл орлыкларны җир йөзенә шулар сибеп калдыра. Аларның күбесе көрәш кырларында үлеп калса да, калдырган орлыклары, һаман күбәя, һаман ишәя барып, бөтен җир йөзенә тарала. Г. Ибраһимов повестенда традицион кызыл чәчәк образы яңадан тергезелә һәм авторның да, төп геройның да иҗтимагый идеалларын ачыграк аңларга булыша. Шулай иске, традицион форма яңа социаль эчтәлек белән баый.

«Кызыл чәчәкләр» социалистик реализм принципларын гәүдәләндергән беренче әсәрләрдән иде. «Галимҗан Ибраһимов» исемле монографиясендә М. Хәсәнов «Кызыл чәчәкләр»не, социалистик реализм алымы белән язылып, татар совет әдәбиятының алтын фондына кергән гүзәл әсәрләрнең беренче үрнәге итеп саный. Г. Ибраһимов повестеның төп уңышы шунда: автор чынбарлык күренешләрен бөтен төрлелегендә, үсеш, үзгәрештә чагылдыра, кешене иҗтимагый тормыш һәм җәмгыять белән тыгыз бәйләнештә күрсәтә алган.

Шулай итеп, егерменче еллар татар совет прозасында һәр ике тенденция: массаларны сурәтләү дә (Ш. Усмановның «Кызыл байрак астында» исемле әсәре) һәм конкрет характер сыйфатларына ия булган индивидуаль образ иҗат итү дә (Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» повесте) шактый ачык булып күзгә ташлана.

[1] Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. II том. Казан. 1956 ел. 502 бит.

Киеренке, драматик ситуацияләрне тасвирлау, шуның белән бергә, геройның эчке дөньясына керергә тырышу К. Нәҗми кебек талантлы прозаикның бу еллардагы әсәрләрендә дә төп тенденциягә әйләнә. Революциядән соң язган беренче әсәрләрендә үк инде («Чыныгу», «Шобага», «Иң соңгысы») ул аерым кешене сурәтләргә, һәр геройның үзенчәлекле якларын табарга ныклы омтылыш ясый. «Шобага» исемле әсәрендә, мәсәлән, гражданнар сугышы чорына хас иң кискен бер эпизод сурәтләнә. Әсәрнең төп герое — бер төркем кызыларымеецлар, ягъни массалар. Әмма әсәрдә аерым шәхес образын иҗат итүгә дә җитди игътибар бирү сизелә. Язучыны барыннан да бигрәк Хәйрулланың — авыр, куркыныч көрәш юлы узган кызыларымеецның — эчке кичерешләре кызыксындыра. Эчке монолог, төш күрү, үткәннәрне искә төшерү кебек образны психологик яктан ачардай чаралар ярдәмендә К. Нәҗми кешенең хис һәм кичерешләр чыганагын күз алдына китерергә, кеше характерын формалаштыра торган фактларны ачыкларга тели. К. Нәҗминең 20 еллардагы хикәя һәм повестьларына югары бәя биреп, М. Җәлил: «ул тормыш каршылыкларын чынбарлыктагыча күрсәтү ягында тора, шуңа күрә аның образлары тулы канлы, тормышчан булып чыгалар» [2],— дип язган иде.

Геройның эчке дөньясын сурәтләү җәһәтеннән караганда, А. Шамов («Рәүфә» повесте), М. Максуд («Изге көрәшкә», «Каравылда», «Елама, Рәшидә, елама» кебек нәсерләре), Г. Толымбай («Нигә кыр урдәге булмаганнар», «Кызыл Армиядән кайткач» дигән хикәяләре) әсәрләре дә кызыклы ачышларга бай.

Совет әдәбияты тормышчан, зур мәсьәләләр күтәрде һәм хәл итте. Чынбарлыкның күп төрле һәм гаять катлаулы материалларын үзләштерү язучылардан илдә барган тарихи яңарышның закончалыкларын күрә алуны, аналитик төстә уйлый белү сәләтләрен үстерүне таләп итте. Тормыш күренешләрен һәм фактларын аңлауда яңа баскычка күтәрелү, аерым шәхестә һәм бөтен җәмгыятьтә барган тирән процессларны сурәтләүгә яңача, новаторларча якын килү — болар һәммәсе яңа иҗат методының, социалистик реализм методының туып, формалашып килүе хакында сөйли-

[2] Современная татарская литература. Рус телендә. Мәскәү — Ленинград. 1933 ел. 7 бит.

лэр иде. Һәм яңа методның татар әдәбиятындагы иң күренекле вәкиле булып Галимҗан Ибраһимов санала икән — бу бер дә гаҗәп түгел. Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышының актив солдаты, күренекле җәмагать эшлеклесе Г. Ибраһимовка социалистик идеяләрнең шифалы тәэсире аеруча зур була. Революция һәм социализм төзелеше хезмәт иясе массаларының агымына алып килгән үзгәрешләр белән ул якыннан кызыксынып яши.

«Кызыл чәчәкләр» турында сөйләгәндә, Ибраһимов иҗатына хас новаторлык сыйфатларының кайберләренә тукталган идек. Әдипнең 1928 елда язылган «Тирән тамырлар» романы да үзенең яңалыгы белән аерылып тора. Роман, барыннан да бигрәк, шәхес турындагы концепциясенең яңача булуы белән игътибарны җәлеп итә. Кешене аның психологиясендәге, кичерешләрендәге, хисләрендәге бөтен үзенчәлекләре белән күрсәтергә, аның дөньяны үзгәртеп корырга тиешле һәм шул эшкә сәләтле көч икәнен дәлилләргә — бу әсәрдә Г. Ибраһимов алдында торган төп бурыч әнә шул иде.

Әле 1920 елда ук, «Яңа кешеләр»дәге Шәйбәк, Тимеркәй кебек кечкенә батракларның аңлы көрәш юлына аяк басуларын сурәтләп, Г. Ибраһимов геройның социаль активлыгын шәхеснең теге яки бу сыйныфларга, теге яки бу идеяләргә хезмәт итәргә омтылуында күргән иде. Бу — ниндидер абстракт гуманизмга өндәү түгел, ә социалистик гуманизмны, Горький өйрәткән гуманизмны раслау иде. Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романында да без тормышны үзгәртеп корырга сәләтле актив, зур ихтыяр көченә ия булган кеше образы белән очрашабыз.

«Тирән тамырлар»... Еш кына әсәрнең исеме шәхси милекчелеккә корылган иске дөньяның тамырлары белән көрәшне аңлата, диләр. Безнеңчә, бу — берьяклырак караш. Роман партия солдатының үлеменә багышланган. Кеше үзе һәлак була, әмма аның исеме халык күңелендә кала. Ул кешеләр күңелендә тирән эзләр калдыра, әнә шуңа да кешенең фаҗигале тарихын сурәтләүгә багышланган әсәр якты рухлы, оптимистик рухлы булып чыккан.

Роман күп планлы, масштаблы булуы белән игътибарны җәлеп итә. Күләме белән әллә ни зур булмаган әсәрдә әдип бик күп кешеләр катнашкан зур вакыйгаларны җанландыра, берничә конфликт сызыгы ала һәм аларның һәммәсен бик оста рәвештә чишәргә дә өлгерә. Ибраһимов иҗатын өйрәнүчеләр романның оригиналь композициясенә һәм сюжет төзелешенә күп тапкырлар игътибар иттеләр. «Сюжет җепләренең нәфислеге һәм көтелмәгәнчә булуы, вакыйгаларның әле салмак кына, әле искиткеч тизләнүе,— дип язды Г. Халит,— менә болар барысы да «Тирән тамырлар» романына сәнгатьчә үзенчәлек һәм композицион оригинальлек бирәләр» [1]. Романның бу рәвешчә корылуы сурәтләнә торган тормыш материалының үзенчәлекле булуы белән аңлатыла. Автор әз-әзләп һәм әкренләп җыеп барган гаять йомгагын сүтә. Хикәяләү бүгенге заманнан үткән чорларга күчә, ул да түгел, кабат бүгенге көннәргә әйләнеп кайта. Көтелмәгән күчешләр, вакыйгаларның алмашынып торуы яңа тормышның үз темпына да тәңгәл килеп тора. Яңа дөнья да бит чагыштырмача кызурак темп алды, кешеләрнең характерларына һәм чынбарлыкны танып-белүләренә билгеле бер эз салды, ахыр килеп, күпмедер күләмдә романның структурасын да билгеләде. Әсәрнең бөтен сурәтләү чаралары геройларның характерларын мөмкин кадәр тулырак һәм күпьяклырак итеп ачарга булыша, тормыш барышының һәм яңа шәхес туу процессының драматизмын көчәйтергә ярдәм итә. Тасвирланган вакыйгалар һәм кеше язмышларының драматизмы аша яңаның, туып килә торган тормышның бөеклегенә басым ясала.

Социализм өчен көрәш, яңа иҗтимагый мөнәсәбәтләр өчен көрәш романның төп конфликтын тәшкил итә. Вәли Хәсәнов белән Фәхри нәкъ әнә шул җирлектә бәрелешәләр. Беренче юллардан ук Фәхринең кем булуына, кем интересларын яклавына басым ясала. «Фәхрине яраталар иде. Үз итеп, туган итеп, авыр йөкне төптән җигелеп өстерәүче итеп яраталар иде. Аның үлеме, аның үз араларыннан, тормыштан китүе — күңелләрдә ятимлек тойгысы уятты» [2]. Фәхринең үлүе турында хәбәр иткән, аның гәүдәсен һәм үтерүчене эзләүгә багышланган эпизодлар аерым эмоциональлек белән сугарылган.

Халыкның яраткан Фәхриенә кем кул күтәргән? Аның үлемендә кем гаепле? Катлаулы тормыш күренешләрен тасвир-

---

[1] Г. Халит. Герои, рожденные Октябрем. Рус телендә. Казан. 1967 ел. 114 бит.
[2] Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. II том. 10 бит.

лауда, кешеләрнең бик тә тормышчан һәм фаҗигале язмышларын сурәтләүдә Ибраһимов зур осталык күрсәтә. Вакыйгаларның, геройларның эчке киеренкелеге, хис һәм характерлар бәрелеше ахырга кадәр биттән-биткә гел үсә, көчәя бара. «Вәли Хәсәнов караңгы төндә урманга чыгарылып атылды. Үлекне шунда чокырга күмгәч, тау артыннан сызылып таң атты. Киң Идел өстендә, нуры белән дөньяны балкытып, якты кояш күтәрелде»[1]. Якты кояш күтәрелү — явызлыкка үлем алып килгән яңа тормышның җиңүе билгесе иде.

Тарихны кирегә борып булмый. Язучы иҗтимагый хәрәкәтнең мәңгелек булуы, социализмның, яңа иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең котылгысыз рәвештә җиңүе турында сөйли. Фәхри һәм аның иптәшләре Вәли байларга каршы көрәшкә күтәреләләр. Бу яңа, көрәшче кешеләр иске көчләрнең каршылыгын җиңеп чыгалар. Шул көрәш процессында алар үзләре дә яңара, камиль шәхес булып формалаша баралар. Иске тормыш җиңел генә бирешергә теләми, әлбәттә. Ибраһимов ике капма-каршы көчнең аяусыз көрәшен тасвирлый, бу көрәштә Фәхриләр җиңеп чыга. Автор берьяктан шәхеснең рухи үсү һәм яңару процессын, икенче яктан мәгълүм иҗтимагый-тарихи шартлар тәэсирендә аның таркалу, җимерелү процессын тасвирлый һәм шушы ике процессны һәрвакыт, даими рәвештә бер-берсенә каршы куеп килә.

Романның төп герое Фәхри — давыллы эпоха тудырган яңа кеше. Аның бөтен гомере аңлы көрәш юлында уза: «...Февраль революциясе. Аннан Октябрь. Аннан кызыл фронтлар. Аннан партия-совет эшләре»[2]. Бу — революцион көрәш мәктәбе узган «татар крестьян активистының» иң гади биографиясе иде. Мондый биографияле геройны иҗат итү эшенә татар әдәбияты элегрәк тә алынып караган иде. Һәм беренче чиратта Галимҗан Ибраһимов үзе үк. Без Батырхан («Яңа кешеләр» драмасы), Шаһбаз, Солтан («Кызыл чәчәкләр») кебек образларны күздә тотабыз. Тик Батырхан, Шаһбаз, Солтаннар искиткеч давыллы сыйнфый көрәш елларында батырлык күрсәтсәләр, Фәхри башкарак шартларда көрәшә: инде канлы бәрелешләр тынган, кулга корал тотып сугышасы түгел. Әмма Фәхринең көндәлек тормышы, гадәти тормышы, үз-үзен аямыйча халыкка хезмәт итүе шулай ук геройлык, батырлык белән тулы. Кешеләргә кирәкле һәм файдалы булу — аның төп идеалы. Фәхри үз тормышының мәгънәсен әнә шунда күрә. Кешенең кыйммәте халкы, җәмгыять каршында күрсәткән хезмәтләре белән билгеләнә, ди язучы.

Бәхет төшенчәсен яңача аңлау, Фәхри уенча, турыдан-туры кешенең үз-үзенә азатлык яулау көрәше белән бәйләнгән иде. Иске тормышның колы булудан ваз кичеп, кан коеп табылган бәхетнең хуҗасы булырга кирәк. Фәхригә мещан бәхете кирәкми. Аның аңлавынча, бәхет ул — киләчәккә бару юлында торган киртәләрне җимерү, крестьян массалары арасында революция алып килгән яңалыкны раслау дигән сүз.

Садыйк Миңлебаев та шундый ук герой. Үз героеның рухи һәм әхлак көче нидә булуын аңларга теләп, Ибраһимов Садыйкны зур революцион вакыйгалар, кискен сыйнфый көрәш фонына куеп сурәтли. Садыйк — үз язмышын халык язмышы белән бәйләгән, большевистик идеяләрнең дөреслегенә ышанган кеше. Аның көче әнә шунда иде. Садыйкның хатыны Нәгыймә «бер сәгать, бер минут эчендә бөтен йөрәге белән, мие, җаны белән үткен рәвештә аңлап алды. Менә хәзер кайнаган көчле пролетариат революциясе белән ул Миңлебаевларның элекке зинданнары, сөргеннәре, эш ташлаулары — һәммәсе бернәрсә, һәммәсе бер диңгезгә төшә торган ерганаклар, бер агачны үстерәчәк тамырлар кебек күрде»[3].

Тормыш Садыйкны үз хокукларын яклап көрәшергә, тартышырга өйрәтә. Ләкин моңа гына да түгел. Ул аның күз алдында кеше бәхетенең яңа кануннарын ачып сала. Менә шуңа да Садыйк үзенең һәр эшен, һәр адымын коллектив эш, гомуми эш позициясеннән карап бәяләргә сәләтле. Бер кешенең бәхете бүтәннәрнең дә бәхетле булуына бәйләнгән икәнен Садыйк яхшы аңлый. Чөнки кеше исәбенә, башкалар исәбенә яуланган бәхет шатлык китерә алмый, тулы була алмый...

Шулай романда шәхеснең формалашу һәм аякка басуында иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең роле дигән мәсьәлә калкып чыга. Кешене чолгап алган тирәлек, иҗтимагый шартлар я аның үсүенә ярдәм итәләр, я шәхеснең таркалуына китерәләр. Фәхри һәм Садыйк кебекләр яңа тормышның үз

[1] Шунда ук, 256 бит.
[2] Шунда ук, 33 бит.
[3] Шунда ук, 92 бит.

гымы белән шәхес буларак формалашалар. Тикшерүчегә биргән җавапларында, мәсьәләнең әнә шул якларына басым ясап, Җиһанша бабай болай ди: «Язсаң ярый. Ачык итеп яз. Акташлар, диген, сәвит өчен дә, кызыл Татарстан өчен дә менә шулай кан түккәннәр, диген... Бу эшләргә Садыйк акыл биргән, Фәхри җигелеп тарткан, диген...» [1]

Яңа кеше проблемасын Г. Ибраһимов барыннан да бигрәк социаль яктан актив шәхес формалашу, аның кешеләрне, җир йөзен яңарту өчен үзен җаваплы санавы, дип аңлый.

Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы — 20 еллар әдәбиятындагы күренекле вакыйга. Һәм бу чор татар әдәбияты социалистик реализм сәнгатенең туу һәм ныгуын раслый торган байтак әсәрләр белән баййи. Революция һәм шәхес, халык бәхете өчен аяусыз көрәш — егерменче елларда язылган иң яхшы әсәрләрнең төп темасы әнә шулар иде. Буржуаз язучыларның әсәрләрендәге кебек кешене канатсыз итеп, түбән итеп күрсәтү кими барды. Яңа әдәбиятның герое горур һәм кыю кеше иде. Хезмәт кешесен коллыктан азат итү кебек изге максат өчен ул герой көрәш мәйданына чыкты. Революция кешене тыныч хезмәт юлына, «яңа тормышны мәстәкыйль төстә иҗат» итү юлына чыгарды. Халыкның һәм шәхеснең тыныч хезмәтен күрсәтү 30 еллар совет әдәбиятының төп темасына әйләнә. Бу законлы күренеш иде. Беренче бишьеллыклар, илдә барган социалистик төзелеш әдәбияттан, язучылар игътибарыннан читтә кала алмый иде.

Яңа дөнья кору, яңа тормыш төзү кешенең үзен үзгәртеп кору, яңа караш-зәвыклар һәм гадәтләр тәрбияләүдән аерылгысыз барды. Рус совет әдәбияты М. Шолоховның «Тын Дон»ы, Ф. Панферовның «Бруски», Ф. Гладковның «Цемент» һәм «Энергия»се, Л. Леоновның «Сот»ы кебек әсәрләр белән баеды. Аларда кеше психологиясе һәм халык тормышында барган үзгәрешләр җанлы рәвештә гәүдәләндерел калдырылган.

Шул ук процесслар татар әдәбияты өчен дә уртак иде. Тормыш берлеге, теләк-омтылышларның гомумилеге уртак темалар, уртак проблемалар тудырды. Язучыларның Беренче бөтенсоюз съездында ясаган докладында К. Нәҗми болай диде: «Татар совет әдәбияты ирешкән зур казанышы шунда: ул милли чикләнгәнлектән, тема һәм проблемалар чикләнгәнлегеннән котылу юлында, яңа социаль һәм культура-көнкүреш мәсьәләләрен чагылдыру юнәлешендә зур уңышларга иреште» [2].

«Социаль тәҗрибәне» (М. Горький) үзләштерү, үсешнең гомуми перспективаларын аңлау, тормышны өйрәнү буенча тупланган бай күзәтүләр — боларның һәммәсе кеше образын сәнгать чаралары ярдәмендә таныл-белү эшенә дә җитди үзгәрешләр кертте. Яңа төзелешләр, авыл тормышын үзгәртеп кору кебек темалар кешенең психологиясе үзгәрү, аның рухи дөньясы яңару белән тыгыз бәйләнештә яктыртылды. Яңа җәмгыять төзү генә түгел, ә яңа кеше тәрбияләү дә — язучылар социализмның төп мәгънәсен әнә шулай аңладылар.

«Матур туганда»... Татар әдәбиятындагы бу яңа романның инде исеме үк тарихны яңача сизәмләү, кеше хезмәтен, яшәү мәгънәсен яңача тою турында сөйли иде. Татар әдәбиятының классик язучысы Ш. Камал үзенең бу әсәрендә татар халкының тормышын дөрес итеп, кешеләргә тирән мәхәббәт белән сурәтли.

Романның үзәгендә кешеләрдә яңача дөньяга караш формалашу мәсьәләсе тора. Авылдагы тормыш уклады үзгәрә; шуның белән бергә кешеләрнең аңы, дөньяга карашлары, гадәт-йолалары да үзгәрә. Иске тормыш вәкиле Садыйк хаҗи җирдә матурлык калмады, гадел законнар калмады, дип зарланган бер вакытта Кигәвенле авылы коммунистлары яшәүнең һәм кеше бәхетенең мәгънәсен яңача аңларга өйрәнәләр, җирдә иң гадел җәмгыять төзеп йөрүләр. Кешеләр арасында искиткеч гүзәл һәм акылга ятышлы мөнәсәбәтләр туып килә. Әсәрнең төп пафосы шунда.

Коммунист образлары Ш. Камал тарафыннан үсештә, үзгәрештә бирелә. 20 елларда иҗат ителгән башка образлардан аның геройлары нәкъ шул яклары белән аерылып торалар да. Совет властеның беренче елларында язылган әсәрләрдән аермалы буларак, хәзер инде авылда яңа кешеләр ялгыз түгелләр. Ш. Камал күтәргән һәм уңышлы рәвештә хәл иткән эстетик проблеманың асылы крестьяннарның активлыгы үсүен, авылда ныклы коллектив формалашуын күрсәтүдән гыйбарәт. Үз авылдашларының тормышы өчен борчылып

[1] Шунда ук, 45 бит.

[2] Первый Всероссийский съезд писателей. Стенографический отчет. Рус телендә. Мәскәү. 1934 ел. 67 бит.

яшәү, үзләре сайлаган идеалга турылык, халыкның иҗади көченә ышану, әхлак сафлыгы — романдагы күп кенә персонажларны әнә шундый гомуми сыйфатлар берләштерә. Аларның барысы да диярлек зур революцион көрәш мәктәбе узган, илнең экономик һәм иҗтимагый тормышында барган үзгәрешләрнең бәрәкәтле йогынтысын татыган кешеләр. Геройларның тормышы ил, халык язмышыннан аерылгысыз. Игътибар тегә яки бу образның төп, асыл сыйфатларын ачыклауга бирелсә дә, ул образларның һәркайсы диярлек бары аңа гына хас индивидуаль сыйфатлардан да мәхрүм түгел. Кеше, гадәттә, һәрвакыт берәр төрле гаиләгә яки берәр социаль группага карый. Бу аларның характерларына да билгеле бер эз сала. Мостафа, Фәтхи, Каюм, Мәдинә яңа кеше, яңа буын вәкилләре буларак бирелгәннәр. Бу буын кешеләренә хас сыйфатлар барыннан да бигрәк партия оешмасы секретаре Мостафа шәхесендә тулырак гәүдәләнә. Кеше образларын Ш. Камал аның башкарган эшләрен күрсәтү аша тудыра, геройның позициясен билгели торган чыганакларны ачыкларга, аның эчке дөньясына керергә тырыша. Мостафа башкарган эшләр, аның кешеләр белән мөнәсәбәте, характерындагы максатка омтылучанлык, үз идеалларына бирелгәнлек кебек сыйфатлар белән билгеләнә. Автор үз героена төрле яктан якын килә. Кыен көннәрдә бөтен коллектив язмышы өчен кайгыртуны Мостафа икеләнми үз өстенә ала. Үзенең гражданлык бурычын ул бүтәннәргә хезмәт итүдә, аларның кайгылары һәм шатлыклары белән яшәүдә, бөтен кешеләрне бәхетле итүдә, дип аңлый. Ш. Камал аны башкалардан берни белән дә аерылып тормый торган гади җир кешесе итеп сурәтли. Кешеләрне кыр эшләренә оештырамы, партия җыелышы алып барамы, волком кушкан эшләр артыннан чабамы — Мостафа боларның һәммәсен вөҗданы кушуы буенча башкара, намус эше дип саный. Мостафа коммунаның һәм авылның бүгенге көне белән генә яшәми. Авылда эшләнгән һәрнәрсә өчен ул үзен җаваплы саный. «Хәзер кешеләргә гади уйлау гына җитмәвен, мәсьәләнең асылына тирәнрәк, киңрәк карарга кирәклеген ул бик яхшы аңлап эш итә. Кешеләргә тормышта үз урыннарын табарга булышу, хис һәм кичерешләрнең катлаулы оттенокларын аера алырга сәләтле булуы аның Мәдинәгә мөнәсәбәтендә ачык сизелә. Мәдинәнең кеше буларак терелү, күтәрелүе Мостафа өчен гадәти бер күренеш кенә түгел. Шәхеснең бәхете, хатын-кыз азатлыгы белән бәйләнгән мәсьәлә. Кеше иҗат итәргә, уйларга, кайгырырга, кичерергә мөмкинлеге булганда гына үзен бәхетле саный ала, ә моның өчен исә ул ирекле булырга тиеш. Кеше кысанлык, җәбер-золым күреп яшәргә тиеш түгел. Кешенең үз-үзен тотуы турында яңа әхлак нормаларын раслау, кеше тормышының кыйммәтен яңача бәяләү — Мәдинә образы аша Ш. Камал әнә шундый мәсьәләләрне хәл итә.

Мәдинә тормышы, беренче карашка, бик гади кебек. Аның язмышы туган авылы, татар халкы арасындагы традицияләр белән бәйләнгән. Әмма Мәдинә характерында яңа тормыш китергән яралгылар да байтак. Яңа иҗтимагый мөнәсәбәтләр татар хатынын чолгап алган элекке киртәләрне җимереп ташлыйлар. Хатын-кызларга ирләр белән бердәй хокуклар бирелә. «Матур туганда» романында социаль һәм мораль факторларның аерылмаслыгы тикшерелә. Мәдинә характерында барлыкка килгән яңалык яралгыларын язучы яңа иҗтимагый мөнәсәбәтләр туу, коллектив хезмәт, авылда коммунистлар урнаштырган дөрес, гадел тәртипләр белән аңлата. Мәдинәнең характеры искелек белән каты көрәштә, үз өлешенә төшкән авырлыкларны җиңү өчен барган көрәштә ачыла. Башка татар кызлары кебек үк, аны яратмаган кешесенә көчләп кияүгә бирәләр. Ул да түгел, сугышта ире үлеп, тол кала. Төрлечә кимсетү һәм мыскыллауларга түзә. Авыр көрәштә Мәдинә җиңеп чыга: ул тормышта үз урынын таба, үзен кеше итеп сизә башлый, саф мәхәббәт хисләренең көчен татый.

Социалистик революция кешеләрнең иҗтимагый мөнәсәбәтләренә генә түгел, интим хисләренә дә билгеле бер эз сала. Мәдинә белән Фәтхи арасындагы мәхәббәт тарихына зур һәм гыйбрәтле мәгънә салынган. Романда мәхәббәт кешегә шатлык, рухи канәгатьлек китерә торган хис итеп кенә түгел, ә аны шәхес буларак камилләштерүче көч итеп тә сурәтләнә. Фәтхи белән Мәдинә арасындагы мәхәббәт линиясенә зур эчтәлек, гомуми кешелек өчен уртак мәгънә салынган.

Мәдинә язмышы аша Ш. Камал гаять зур проблемаларны күтәрә. Ш. Камал гуманизмының көче саф кешелек хисләрен күрсәтүдә, бәхетле булу өчен яралган яңа кешене күрсәтүдә ачык күренде.

Менә шуның өчен дә Мәдинә һәм Фәтхи арасындагы мөнәсәбәтләргә Ә. Нигъмәтуллинның «Ш. Камал» исемле китабында бирелгән трактовка белән килешеп бетәсе килми. Романның бу линиясе белән автор беренче мәхәббәтнең көчен раслый, ди әлеге монография авторы. Үз героен төрле сюжет ситуацияләрендә, төрле конфликтларда сурәтләп, Ш. Камал кешенең күтәрелү, аның рухи азат булу процессын дөрес күрсәтә. Ул алдан билгеләп куелган әзер схема буенча гына бармый, ә характерлар һәм вакыйгаларның үсеш логикасын күзәтеп, тикшереп бара. «Матур түгәндә» романындагы әдәби образларның өстенлеге — аларның ышандыру көчендә.

Ш. Камал зур иҗтимагый-эстетик яңгырашка ия әсәр тудырган. Яңа тормыш төзү өчен оешкан бәләкәй генә бер коллектив мисалында әдип зур гуманистик идеяне гәүдәләндерә алган. Кешеләр гомер буе хыялланган яңа тормыш туа, тормыштагы **матурлык**, кешеләр күңелендәге **матурлык** туа, кешеләр арасындагы мөнәсәбәттә **матурлык** туа. Язучы безнең кешеләребезнең гүзәл киләчәк турында хыялларын гәүдәләндерү белән генә чикләнми, ә тормыштагы яңалыкның туу процессын тирәнтен төшенә алган һәм шуны Кигәвенле авылы коммунистлары мисалында сәнгатьчә гәүдәләндереп калдырган.

30 елларда иҗат ителгән күп әсәрләрнең аерылып торган төп сыйфаты шунда, аларда язучыларыбыз кырыс чынбарлыкны сурәтлиләр, аеруча көчле басым ясап, тормыштагы яңалык пафосын тасвирлыйлар. Бу социалистик шәхеснең, яңа совет кешесенең тууын дөрес итеп сурәтли алган «Агыйдел» повестена да, һәрчак бары тик алга омтылучан, көчле кеше характеры турында хикәяләүче «Тапшырылмаган хатлар» повестена да, И. Газиның хикәя һәм повестьларына, Г. Бәшировның «Сиваш»ына да карый.

Кешенең рухи яктан яңадан тууы, күзе ачылуы, аңарда яңа характер сыйфатлары формалашу процессы хатын-кыз язмышына багышланган әсәрләрдә аеруча ачык гәүдәләнә. Хатын-кыз образлары, гомумән, татар әдәбиятында үзәк урынны били. Бу аңлашыла да. Хатын-кызның җәмгыятьтәге урыны мәсьәләсе турыдан-туры шәхес азатлыгы, мораль, көнкүреш кебек проблемалар белән тыгыз бәйләнгән. Октябрь революциясе хатын-кызга ирләр белән тигез хокук бирде һәм хатын-кыз үзен яңа җәмгыять төзергә сәләтле көч итеп сизә башлады. Бу яктан караганда, Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» исемле әсәре аеруча характерлы. «Тапшырылмаган хатлар» совет әдәбиятының иң зур казанышларыннан саналырга хаклы. Повестьның төп герое Галия язмышы аеруча кызыклы һәм гыйбрәтле итеп бирелгән. Әсәрнең беренче битләре буенча безнең алга ул гадәти бер кеше булып килеп баса. Аның тормыш биографиясендә, башкарган эшләрендә искитәрлек берни дә юк кебек. Ул меңнәрчә татар хатын-кызларына хас тормыш юлы уза: бәхетсез балачак, рабфак, институт, эшли башлау. Ләкин укучы игътибарын ул үзенең активлыгы, акыл һәм рухи сыйфатлары белән җәлеп итә. Г. Кутуй үз героен рухи азат шәхес итеп бирү белән генә канәгатьләнми, Галия характерының социаль юнәлешен дә мөмкин кадәр ачыграк, үткенрәк итеп күрсәтергә тырыша. Галиянең эчке кичерешләре аша әсәрдәге төп конфликтны — ике мораль, тормышка ике төрле карашны — чагылдыра. Геройның үсеш юлы борчу-газаплар, тормышны танып белү ләззәте, рухи әләнүләр һәм шатлык белән тулы. Искәндәргә булган мәхәббәте баштарак аңа әйтеп бетергесез шатлык хисләре китерә, әлеге мәхәббәт Галия тормышының мәгънәсенә әйләнә һәм аның рухи ныклыгына беренче җитди сынау да була. Искәндәр әшәке, салкын бәгырьле эгоист бер кеше булып чыга. Безнең алга Галиянең кискен драматизм һәм каршылыклар белән тулы авыр язмышы килеп баса. Әмма тормышның барлык сынауларын ул уңышлы уза, алардан тагы да чыныккан, рухи көчәйгән хәлдә чыга. «Мин хөрлек кадерен, үз теләкләреңне тормышка ашыру кадерен аңладым», дип яза Галия. Шәхси азат булуны да ул иҗади эш өчен азат булу, халыкка хезмәт итү өчен азат булу дип аңлый. Галия өчен тормышның мәгънәсе ул үзе яшәгән бүлмә белән генә чикләнә алмый. Аңа кешеләрне ярату кебек гүзәл сыйфат хас. Галия — совет чорында иҗат ителгән хатын-кыз образларының иң уңышлысы, иң мөлаеме.

Шул рәвешчә, 30 еллар ахырына татар совет әдәбиятында яңа тип совет кешесенең типик образы формалашты. Әдәбият чынбарлыкта туган һәр яңалыкны күрә һәм чагылдыра барды. Кеше һәм аның эшләре яңа идеаллардан, яңа әдәби позицияләрдән, шул чорга хас иҗтимагый һәм эстетик кретирийлардан чыгып бәяләнде. 20 елларда әдәбиятта яңа кеше концепциясе бил-

геләндә, ә 30 елларда инде ул тулысынча расланып өлгерде. Геройның социаль активлыгы, халык язмышыннан аерылгысызлыгы, мораль йөзенең сафлыгы — бу чор әдәбиятына хас геройның төп сыйфатлары әнә шулар. Г. Ибраһимов, Ш. Усманов, Ш. Камал, М. Максуд, М. Әмир, Г. Кутуйларның яңа геройлары — аңлы рәвештә тормышны үзгәртеп коручы кешеләр, үзләренең төп вазифаларын Ватанга, халыкка, революциягә хезмәт итүдә күргән кешеләр. Алар өчен максатлар берлеге, идеаллар берлеге, иртәгесе көнгә ышанып яшәү хас. Шуның белән бергә алар берберсен кабатламыйлар, аларның һәрберсе үзенчәлекле характер сыйфатларына ия. Язучылар, кеше характерларын тирәнәйтә барып, һәр геройның үзенчәлеген катлаулы тормышчан конфликтлар аша күрсәтteләр.

Революция, гражданнар сугышы, яңа тормыш төзү кебек проблемалар кешенең рухи үсешеннән аерылгысыз иде. Геройның эчке дөньясы җитди үзгәрешләр кичерде. Революция, социаль үзгәртеп корулар, яңа иҗтимагый мөнәсәбәтләр шәхескә көчле тәэсир ясый тордылар, аның рухи һәм әхлакый үсешенә булыштылар. Солтан, Фәхри, Садыйк, Мәдинә, Фәтхи, Мостафа, Галия, Рәүфә кебек образлар, кырыс тормыш сынаулары аша үтеп, үзләрен дөньяны үзгәртеп корырга сәләтле кешеләр итеп күрсәтteләр.

Чынбарлыкны үзгәртеп кору һәм кешенең үзен камилләштерү пафосы, героизмны раслау — татар совет әдәбиятына хас төп тенденцияләр. Аларның күбесе 20—30 еллар әдәбиятында ук ачык төсмерләнде, сугыш һәм аннан соңгы елларда алга таба үстерелде. М. Җәлил, К. Нәҗми, Т. Гыйззәт, Г. Бәширов, М. Әмир, Х. Туфан, И. Гази, Ф. Хөсни, Г. Әпсәләмов, С. Хәким һәм башкаларның иҗаты кешене, аның уйхисләрен, эчке дөньясын сурәтләүгә багышланган. Төп сыйфатлары 20—30 елларда формалашкан татар әдәбияты моннан соңгы барлык сынауларны уңышлы узды.

# ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ

Моннан бер ел элек Мәрҗанинең тууына 150 ел тулды. Шул уңай белән Татарстан китап нәшрияты «Шиһабетдин Мәрҗани» исемле бәләкәй генә бер җыентык та бастырып чыгарды. Җыентыкка XIX йөз уртасында Казанда яшәгән һәм күп санлы фәнни-тарихи мирас калдырган зур галим, күренекле мәгърифәтче, үз чорының танылган җәмәгать эшлеклесе Мәрҗанинең тормышына, иҗат юлына багышланган мәкаләләр, шигырьләр һәм әдәби әсәрләрдән алынган аерым өзекләр тупланган.

Китап филология фәннәре кандидаты Хәй ага Хисмәтуллинның Мәрҗани хакындагы очеркы белән ачыла. Очерк безне галимнең тормыш юлы, аның гаять бай, шул ук вакытта гаять катлаулы һәм каршылыклы иҗат мирасы белән таныштыра.

Шиһабетдин Мәрҗани үз чорының, үз заманының тарихи бер шәхесе булган. Ә В. И. Ленин исә: «Тарихи хезмәтләр турында тарихи эшлеклеләрнең хәзерге таләпләр белән чагыштырганда нәрсәне бирмәүләренә карап түгел, бәлки аларның үз элгәреләре белән чагыштырганда нинди яңа нәрсә бирүләренә карап хөкем итәлә»,— дип язган иде. Китап юлбашчының шул күрсәтмәләрен күздә тотып төзелгән диясе килә.

Халык шагыйре Габдулла Тукайның «Шиһаб хәзрәт», Г. Сөнгатиның «Мәрҗани хәзрәтләре» исемле шигырьләре, Г. Ибраһимовның «Бөек остазымызның кайбер тәэлифләре», Ф. Әмирханның «Безнең хыялларда Мәрҗани күләгәсе» дигән мәкаләләре, С. Кудашның «Яшьлек эзләре» исемле китабыннан алынган өзек белән танышкач, без Мәрҗанинең никадәр күп кырлы, ачык фикерле, киң карашлы гуманист булганлыгын күрәбез.

Кызганычка каршы, китап артык юка чыккан. Шиһабетдин Мәрҗанинең бай мирасын күз аллау өчен бу бик аз, әлбәттә. Киләчәктә аңа багышланган җитдирәк җыентыклар чыгар, дип ышанып калабыз.

**К. МОСТАФИНА.**

# САРЫ ЯФРАКЛАР КОЕЛА

Гурий Тавлинның берничә новелласы заманында республика газета-журналларында күренеп үткән иде. Татарстан китап нәшрияты узган ел аның новеллаларын аерым китап итеп бастырып чыгарды. Исеме — «Сары яфраклар коела». Китапка барлыгы унөч новелла урнаштырылган.

Сүзне «Көзге бер төндә» дип исемләнгәненнән башлап китәсе килә.

Көзге бакча. Бертуктаусыз яфраклар коела. Тын бакчадагы эскәмияләрнең берсендә карт белән карчык утыра. Төн урталары җитүгә карамастан, һаман өйләренә кайтырга җыенмыйлар: алар сугышта югалган улларын юксыналар...

Кинәт көчәеп киткән җил тавышында карчык бер улының авазын ишеткәндәй була. «Карт, без монда утырабыз утыруын, хәзер менә малайларның берәрсе кайтып өйгә керә алмый интегеп торса... Әйдә кайтыйк тизрәк»,— ди карчык. Һәм алар ашыга-ашыга өйләренә юнәләләр... Сугышның тәмамлануына чирек гасыр тулып килә. Әмма, күргәнегезчә, ул китергән кайгы-хәсрәтләрнең бетәсе юк икән әле. «Еллар үткәч» исемле новелланы укыганда без моңа тагын бер мәртәбә ышанабыз.

Кайбер башка новеллаларындагы кебек үк, Г. Тавлинның бу әсәрендә дә укучыларның күңелләренә тияргә, эмоцияләренә тәэ-

сир итәргә тырышу нык сизелә. Әгәр автор үз әсәренең тормышчанлык дәрәҗәсен һәм ышандыру көчен арттыру юнәлешендә дә шундый ук тырышлык күрсәтсә — бигрәк шәп буласы икән. Өстәвенә «Еллар үткәч»-нең сюжет-композиция төзеклеге дә тиешенчә эшләнмәгән.

«Фәрхенур чокыры» колхозлашу еллары хакында. Авылдагы бөтен яңалыкның башында йөрүче кызның тормышын һәм үлемен сурәтләп, автор колхозларның нинди кыен шартларда оешуын күрсәтә.

Җыентыктагы новеллаларның күбесе әхлак-мораль мәсьәләләренә багышланган. Андыйлар — бишәү. һәм бишесе дә бер чамадарак эшләнгән. «Ана күңеле балада» һәм «Үги ана». Бу икесендә ни хакында сүз барганлыгын новеллаларның исемнәреннән үк чамаларга мөмкин. «Сары яфраклар коела» исемле өченче бер новеллада ире ташлап киткән хатынның газаплы кичерешләрен сурәтләүгә күп урын бирелә.

«Кайту» дигән хикәя Зөфәр исемле бер кешенең яңа елга каршы шәһәргә кайтып төшүе белән башланып китә. Казаннан ул моннан дүрт ел элек, яңадан әйләнеп кайтмам, дип чыгып киткән. Галия аңа көн саен диярлек хатлар язып торган, ләкин бу «җүләр аларны укып та карамый, кире җибәргән». Ни өчен киткән ул? Ни өчен кире кайткан? Алар ни өчен аерылышканнар? Әгәр гаеп Галиядә икән, нигә дип Зөфәр «үткәннәр өчен аңардан гафу үтенергә» җыена? Хикәядә шундый характердагы сорауларның берсе дә ачыкланмый калган.

«Әһли хат көтә» дигән новелла да сөергәк тәэсир калдыра.

Әһли Раушаниядән хат көтә... Зарыгып, сабырсызланып, дүрт күз белән хат көтә, ди автор. Рас шулай икән, сагынгандыр, әйтми калган сүзләре бардыр, дип уйлыйсың. Баксаң, «түбән җанлы, икейөзле, рухи гарип Раушаниягә ургып кайнаган бөтен ачуын, чиксез нәфрәтен түкми-чәчми язу» өчен хат көтә икән егет. Шундый җавап хат язу өчен ул «үзенә киләсе хатны бер ел да, ике ел да, биш ел да, хәтта ун ел да көтәргә риза». Бер дә изге теләк түгел. Әсәрдән күренгәнчә, кыз болай да үз ялгышын аңлаган бит инде...

Җыентыкның авторы — элекке моряк. Шуңа күрә китапта матрослар һәм моряклар тормышын чагылдырган новеллаларның булуы бер дә гаҗәп түгел. Ләкин бу темага караган әсәрләрнең «Комсомол билеты» исемлесе дә һәм «Заман башка» дигәне дә әллә ни уңышлы чыкмаган шикелле. «Карлыгачлар канат ярсын» исемле новелла турында да, кызганычка каршы, шул ук сүзләрне кабатларга туры килә.

Кыска хикәя — иң авыр жанрларның берсе. Бу жанрда эшләүче авторлар иҗатында төрлечә сөртенүләр дә булырга мөмкин. «Сары яфраклар коела» — шул кыен жанрда эшләүче авторның беренче җыентыгы. Ә беренче коймак төерле була, диләр. Киләчәктә без Гурий Тавлиннан яхшырак хикәяләр көтәбез.

**Ренат ГАЛӘВИН.**

# ХИКМӘТ ЭНҖЕЛӘРЕ

*XIV йөздә төрки телдә язган әдипләр арасында Сәйфи Сараи аерым бер урын биләп тора. Аның безгә килеп җиткән «Китабы Гөлстан бит-төрки» әсәреннән дә авторның зур акыл иясе, гуманист, кабатланмас нәфис сүз остасы булуын күрергә мөмкин (бу турыда «Казан утлары» журналының 1966 елгы 12 санын карагыз).*

*Соңгы елларда татар филологлары Сәйфи Сараи иҗатын җентекләп тикшерә башладылар. Мәсәлән, күренекле совет тюркологы, филология фәннәре докторы Әмир ага Нәҗип «Гөлстан бит-төрки»нең телен тикшерүгә багышланган зур хезмәтен Мәскәүнең «Наука» нәшриятына тапшырды. Казан университеты галимнәре тарафыннан әзерләнгән «Гөлстан бит-төрки» әсәре университет нәшриятында аерым китап булып басылып ята.*

*Журналыбызның бу санында без укучыларыбызга Сәйфи Сараи китабындагы хикмәтле сүзләр, канатлы шигъри юллардан үрнәкләр тәкъдим итәбез. Алар Әмир Нәҗип әзерләгән хезмәттәге «Хикмәтләр тезмәсе» исемле өстәмә бүлектән алынды.*

*Текстларда очраган архаик сүзләрнең аңлатмалары шушы конкрет очрактагы мәгънәләре буенча бирелә. Транскрипция хәзерге орфографиябезгә яраклаштырылды.*

*РЕДАКЦИЯ*

●

Бу рәгыяткә мәлик чубан ирүр,
Ул ничә кем күп вилаятне белүр.
Куй дәгел чубан өчүн, әй зөфнүн,
Бәлки чубан куйлара хезмәт өчүн.

*(Рәгыят — гади халык, хезмәт иясе кешеләре; чубан — чабан, көтүче; зөфнүн — акыл иясе, аңлы кеше).*

Дәгел ирлек агызга йомрук ормак,
Ир исәң кой агызга бал вә каймак.

*(Йомрук — йодрык).*

Дәүләтле ир ул кем йиде, дәгый йидерде.

*(Йимәк — ашау; дәгый — тагы).*

Йөк күтәргән ишәк яхшырак,—
Ул арысландан кем адамны ерткай.

*(Кешене талаган арысланнан йөк күтәргән ишәк яхшырак).*

Залимнәрне гафу итмәк фәкыйрьләргә
золым кылмак булыр.
Золым кыйлса мәлик рәгыяткә,
Ля җәрәм, мәмләкәт хәраб булур.

*(Ля җәрәм — шөбһәсез, шиксез).*

Кем золым илен озатса, солтан булырмы? —
Булмас;
Куйларга корт һәргиз чубан булырмы? —
Булмас.

*(Золым иле — золым кулы; корт — бүре; һәргиз — һичбервакыт).*

Ни кадәр кем бәкләр ашы татлы булса, әй кунак,
Ярлы-юксулга коры итмәке андан яхшырак.

*(Итмәк — ипи, икмәк).*

Рәгыят багының солтан алып йисә бер алмасын,
Йөз армудын йигәй бер кол берен элмәен тешкә;
Боерса бер йомыртканы алырга көч белән солтан,
Нүкәрләре тотып санчар егерме казны бер шешкә.

*(Йомыртка — йомырка; армуд — груша; нүкәр — патша хезмәткәре).*

Солтан рәгыят рәхәте өчен торыр.

Сәгадәт күрмәгән тапса вәзарәт,
Орып ир үлтерүр уйнар булса.

*(Дәрәҗә күрмәгән кеше властька ирешсә, уйныйм дип кеше үтерер).*

Ул кадәр каттылык итмәгел кем, синдән туйгайлар;
Ул кадәр йомшак булмагыл кем, аяк алтында куйгайлар.

*(Аяк алты — аяк асты).*

Фәкыйрь сабыры артыкдыр ганиләрнең гатасындан.

*(Гани — бай; гата — бүләк).*

Эчереп илгә кашык берлә шурба,
Чүмүч сабы берлә күзен чыгарма.

Өч нимә даим калмас:
Бере — тиҗарәтсез мал,
Икенчесе — бәхәссез гыйлем,
Өченчесе — сәясәтсез мәлик.

*(Нимә — нәрсә; тиҗарәт — сәүдә, оборот; сәясәтсез мәлик — максатсыз, идеологиясез патша).*

●

Белекле ир гаттар дөкане дорур,
Сүзләмәен илгә үзен белдерүр.

*(Гаттар дөкане — шәрык илләрендә хушбуйлар, чәчәк сулары, бәлзәмнәр сата торган кибет).*

Белексез кешегә сөкүтдән яхшырак юк;
Әгәр бу мәслихәтне белсә иде,—
Белексез булмагай иде.

*(Сөкүт — дәшми тору).*

Булмаса кырык йәшәрдә гакыл вә әдәп,
Дәгел инсан дисәң аны,— ни гаҗәп?!

*(Дәгел инсан — кеше түгел).*

Гамәлсез галим балсыз зәнбурга охшар.

*(Зәнбур — шөпшә).*

Гар күрмә белмәгәнне сормага,
Сормайынча гамәл үгрәнмәс кеше.

*(Гар күру — гарьлек дип исәпләү).*

Гариф билә ултурмак җаһилгә — ирүр зиндан,
Җаһил билә ултурмак гарифкә — җәһәннәм.

*(Гариф — укымышлы, акыл иясе; җаһил — надан, тинтәк).*

Ике кеше файдасыз рәнҗ чикте,
Дәгый тохымны шурә йиргә икте;
Бере ул кем мал йыгды — йимәде,
Икенчесе ул кем гыйлем укыды —
Дәгый гамәл кыйлмады.

*(Рәнҗ чигү —җәфалану; тохым — орлык; шурә йир — тозлы җир, шурлак; йыгу — җыю).*

Илгә дәйни тәркин үгрәткән фәкыйһ
Акчалар хасыйль кыйлып алтын йыгар,
Әйтүр үзгәгә, дәгый тотмас үзе,—
Ля җәрәм, оеган аңа юлдан азар.

*(Халыкны дөньядан биз дип өйрәткән шәригатьче, акчалар ясап, алтын җыя. Аңа ышанган кеше, һичшиксез, юлдан язар).*

Ирдәм — иясенең дәүләте торур.

*(Ирдәм — белем).*

Ирдәм бер чишмә дорур кем,
Дайим суы ташып килә дорур.

Ирдәмсезләр ирдәм иясен күрә белмәс;
Ничек, кем базар этләре ау этләрен телмәс;
Ерактын гауга кыйлур — якын килмәс.

*(Телү — биредә талау).*

Йимәс эт саркытын килеп арыслан,
Гар эчендә ачын үләр булса;
Гариф ир нәфсенә оеп китмәс,
Ни кадәр нәфсе аңа җафа кыйлса.

*(Саркыт — калган ризык; гар — мәгара).*

Мәзәлләт белән тере йөрегәнчә,
Гыйлләт белән үлсә яхшырак.

*(Мәзәлләт — хурлык, түбәнчелек; зилләт — авыру, чир).*

Озын буйлы ахмакдан кыска буйлы гакыйль
яхшырак дорур.

Өзмәс ике белекле бер кылны,
Сакламас ахмак адәми телне.

Сүзең будыр ки: «мән фәлән галим мән»,
Чөн юк гыйлмең йәнә һаман җаһилсән;
Моның мисле ушул ишәккә охшар —
Белмәс ни йөке — утынмыдыр йә дәфтәр.

*(Дәфтәр — биредә китап һәм гыйлем мәгънәсендә).*

Җәүһәр балчыкка төшсә, борынгы бикин нәфис торур,
Губар күккә чыкса, баягы бикин хәсис торур.

*(Борынгы бикин — элекке кебек; губар — тузан; хәсис — пычрак).*

●

Бу тереклек йимәк өчүн дәгүлдер ялгыз.

Ничә кем нәфсе юк мескин ишәкнең,
Күтәрмәк берлә йөкне кыйммәте бар.

Һәрбер ир эш өчүндер,
Һәрбер эш бер ир өчүн;
Мәслихәт ул:
Үз эшене эшләгәй һәр зөфнүн.

*(Зөфнүн — аңлы кеше).*

●

Дошман үгетен кабул кыйлмак хата дорур,
Вә ләкин ишетмәк — рәва.

*(Ишетмәк рәва — колак салырга ярый).*

Дустлар зиндан эчендә кирәк булыр,
Дәгый дошманлар сөфрәда дуст күренер.

*(Сөфрәда — табын янында).*

Елан башын дошман иле белән янчегел.

*(Әл, ил — кул).*

Сөхбәт итмә яман кеше берлән,
Никадәр пакь исәң,— нәҗес итәр.

*(Сөхбәт — әңгәмә, киңәш).*

Фетнә йөзле раст сүздән бул ерак,
Мәслихәтле ялган андан яхшырак.

*(Фетнә йөзле — фетнәгә, яман эшкә чакыручы).*

Ялган сүзләмәк ул зәхм бикин дорур,
Җәрәхәте бетсә нишаны калур.

*(Ялган сөйләү яра кебек, җәрәхәте бетсә дә, эзе кала).*

Әҗәлсез адәми үлмәс дип,
Сән йыланны койрукындан тотма, зинһар.

●

Күп малдан күрекле җамал яхшырак.

Күрексез ибченең ире күзсез кирәк,
Гәр күрәр булса йөзен — бирер талак.

*(Ибче — хатын).*

Ни кайгы сәүмәсә гөлне саескан?
Төмән былбыл кыйлур гыйшкында әфган.

Көнәш васлын теләмәс булса ватват,—
Көнәшнең нурына андан ниноксан?!

*(Төмгн — меңләгән; әфган — зар елау; көнәш — кояш; васл — кавышу; ватват — ярканат; ноксан — кимчелек).*

Чөн гыйшык вә мәгъшук бер йиргә килде,
Хуҗалык дәгый куллук уртадан китте.

*(Мәгънәсе: саф мәхәббәт тигезлек китерә).*

Бер кеше бакса ачып гүр эченә,
Белмәгәй: яткан мәликме я гәда.

*(Мәлик — патша; гәда — ярлы).*

Мөгаллим булмаса, һәйбәтле, әй яр,
Сакалындан тотуп угланлар уйнар.

*(һәйбәт — абруй, авторитет; углан — балалар).*

Йимеше күп агачка таш аталар.

Йосыфны сатып ни алгайлар?!

Йөзем ләззәтен баг иясе белмәс.

Күңүл бирмә күңүл бирмәс кешегә,—
Ашыккан ир белән юлдаш булма.

Ни эшләр кыйлгай иде адәмигә,
Карынчаның канаты бар булса?

*(Карынча — кырмыска).*

Ут сүндереп куз куймак,
Елан үлтерүп, баласын бәсләмәк —
Гакыйллар эше дәгүл.

*(Куз кую — утлы күмер калдыру; бәсләмәк — ашату, тәрбияләү).*

Яхшы кылыч булырмы һәргиз яман тимердән,
Юмак белән китәрме луты кара күмердән?

*(һәргиз — кайчан да булса; лут — корым).*

Әгәр язындагы барча комлар энҗе булса,
Теләнчеләрнең күзе туймагай.

*(Язы — чүл-сахра; теләнче — биредә соранчак).*

Әй, ничәләрне күрүптер бу җиһан,
Әй, ничәләрдән дәгый артып калур;
Сән алардан алмасаң гыйбрәт бу көн,—
Таң белән сәндән болар гыйбрәт алур.

Әя килгән җиһанга, игүлүк ит,
Яман эшне яманларга куеп кит!

Үлеләрдән килерме һәргиз аваз?

Үч алмакдан гафу хушрак.

**Фоат Вәлиев**


# МӘҺАБӘТ БИНАЛАР ҺӘМ АЛАРДАГЫ ЯМЬ

Халкыбызның гаҗәеп бай һәм күп гасырлык үсеш юлы үткән бизәү сәнгатенең чигү, туку кебек төрләре белән журнал укучылары инде таныш. Бу юлы без төзү материалы таш булган сәнгатьләр, атап әйткәндә, монументаль архитектурабызның кисеп-уеп бизәү алымнары, язулы һәм орнаментлы эпитафия ташларыбыз хакында сөйләмәкче булабыз.

Борынгы заманнардан бирле безнең җирдә киң таралган сәнгатьләрнең берсе бу. Болгар шәһәре үзенең төзеклеге һәм ямьлелеге белән заманында дан тоткан. Элекке традицион әдәби телебездә йорт салу, бина коруга бәйләнешле атамаларның актив кулланылуы, мигъмар (архитектор), мигъмарлык (архитектура), гыймарәт (корылма, сәрай, бина) кебек терминнарның 10 гасыр буе бабаларыбыз теленнән төшмәве үзе



Җәмигъ мәчетенең архитектура детальләрендәге уелма бизәк: ишек янындагы гөлбизәк.



а) Тәрәзә уемнарын әйләндереп алган уелма бизәкләр.
б) Портал такны кысалап алган уелма бизәкләр.

генә дә күп нәрсә сөйли. Болгар мигъмарларының осталыгы күрше илләрне дә җәлеп иткән. Мәсәлән, рус елъязмаларында әйтелгәнчә, болгар осталары Владимир-Суздаль князьлегендә төрле шәһәрләр төзү, чиркәүләр салуда катнашканнар[1]. Болгар архитектура мәктәбе традицияләрен без Уралдагы Тура-хан төрбәсе һәм Ока суы буена утырган Касыйм шәһәрендәге таш биналарда да ачык күрәбез[2].

Монгол явына кадәрге болгар архитектурасы хатирәләре бик аз сакланган. Сувар, Бүләр кебек шәһәрләрнең калдыкларын, элек дәүләтнең чиге булган җирдәге — хәзерге Алабуга шәһәре янындагы «Шайтан каласы» дип йөртелә торган цитадель янсә кәрвансарай бинасын шундыйлар исәбеннән күрсәтергә була. Дәүләтнең башкаласы булган шәһре Болгарда Алтын Урда чорында салынган берничә бина бүгенге көнгәчә сакланып килә. Болар безнең һәркайсыбызга билгеле. Болгар шәһәре хәрабәләре Кара Пулат, Кече Манара, Кече төрбә, Олы төрбә, Хан төрбәсе дип исемләнеп йөртелә торган бу биналар белән генә чикләнми, әлбәттә. Шушында ук XIV гасыр башында салынган мәһабәт Җәмигъ мәчетенең дә җимерекләрен күреп була. Бертуктаусыз алга барып торган заман әлеге биналарга да үзенең тамгасын сала килгән. Өле үткән гасырның беренче яртысында гына чагыштырмача төзек булган Ак Пулат һәм Кызыл Пулат кебек биналар да (тарихчылар боларны җәмәгать мунчасы булган дип исәплиләр) бүгенге көндә инде бөтенләй җимерелеп беткәннәр. Безнең тарихы-


---

[1] В. Н. Татищев. История Российская с самых древнейших времен. Мәскәү. 1774 ел. 79 бит.

[2] А. П. Смирнов. Волжские булгары. Мәскәү. 1951 ел. 78 бит; А. Берс. Прошлое Урала. Мәскәү. 1930 ел. 112 бит; Б. Калимуллин. Архитектурные памятники Башкирии. Уфа. 1956 ел.

быз өчен бик тә үкенечле югалту бу. Әлеге таш пулатлар эчтән дә, тыштан да бик матур итеп бизәлгән булган. Бүгенге көндә без менә шул уеп-сырлап эшләнгән бизәмнәрнең вак-төяк детальләрен генә табабыз.

Җәмигъ мәчете озынча дүрт почмаклы бина булып, диварларының почмакларыннан биек-биек манаралар торгызылган. Хәзерге көндә бина стенасының калдыклары гына җирдән беркадәр калкурак булып күренеп тора. Бу калдыклар буенча гына да төзек чакта бинаның тышкы һәм эчке күренеше ничек булганлыгын күз алдына китерергә мөмкин. Бинаның эчендә төньяктан көньякка таба дүрт рәт колонна уткән. Бу колонналарга йөкләнгән арка исә ук формасында эшләнгән булырга кирәк. Бинага керә торган порталның өслеге кисмә-уйма бизәкләр белән бизәлгән, ишек түбәләренә гөлбизәкләр белән үрелгән гарәпчә язу — коръән аятьләре язылган булган. Мәчетнең көнчыгыш һәм көнбатыш якларында запас ишекләр һәм тәрәзәләр булган. Бина эчендәге колонналар сигез кырлы, базалы һәм капительле. Капительнең формасы шактый катлаулы, бизәмгә хөрмә мотивлары кертелгән. База куб формасында, почмаклары конус итеп киселгән булган. Бинаның түбәсе ике кыеклы булып, үзәктә яктырткыч кәндил асылган булырга кирәк. Җәмигъ мәчетенең кисеп-уеп бизәлеше сәнгатебез тарихы өчен бик тә әһәмиятле. Монда бизәкләр гадәттә бинаның корылу элементларын, аларның үзара бәйләнешен тагын да калкытыбрак, ачыграк итеп күрсәтер өчен кертелә. Бизәкләр арасында үсемлек, гөлчәчәк мотивлары да, һәндәси (геометрик) бизәкләр дә кулланыла. Төрлечә бормалап-сырмалап язылган гарәп хәрефләре дә еш кына әлеге бизәкләр белән бергә үрелеп китә. Болгар осталарының ташны ую-сырлау техникасы бик камил: бизәк һәм язулар гаять пөхтә эшләнгән, кабарынкы булып, аермачак беленеп тора. Мисал өчен Җәмигъ мәчете порталының блокларындагы уелма бизәкләргә карагыз. Монда җиләк яфраклары һәм сабаклар бәйләме сурәтләнгән. Көнбатыш һәм көнчыгыш фасадларының тәрәзә уемнарына катлаулы-катлаулы гарәби бизәкләр (арабеска) ясалган.



Кече манараның көнбатыш нишасы. Эстамплар һәм гипстан ясалган калыплар буенча автор реконструкциясе.

Шәһре Болгардагы Җәмигъ мәчетен якын Көнчыгыш халыклары архитектурасының башка атаклы хатирәләре белән чагыштырып карарга һәм күп кенә уртак сыйфатлар табарга мөмкин булыр иде. Әйтик, Кырым, Әзербайҗан, Кече Азия, Мисырдагы биналар, эпитафияләрнең бизәлеше белән чагыштырсак, Болгардагы Җәмигъ мәчетендә без таш өслеген ыбыр-чыбыр бизәкләр басып китмәвен, һәр бизәкнең кирәк урында, үз урынында булуын күрербез. Бу Болгар архитектура мәктәбенең мөстәкыйль сыйфатларга ия булуы, үз яшә-

ешлеге, Болгар осталарының үзләренә генә хас зәвыкка ия булуы турында сөйли[1].

XIV гасыр башында салынган Кече Манараның да тышкы һәм эчке бизәлеше күңелне җәлеп итәрлек матур итеп эшләнгән. Бу бинага керә торган ишек төньякта, аның түбәсе ярым овал рәвешендә, ишекнең тирә-яклары «П» рәвешле уелма бизәкләр белән бизәлгән. Көнбатыш якта исә бик үк тирән булмаган нишалар — аларның түбәсе ук рәвешле очлаеп тора. Бу нишаның түбән ягында тирәнрәк икенче ниша бар. Ике ниша арасындагы яссылыкта уелма бизәкле, келәмне хәтерләтә торган панно булган. Кайчандыр бу паннодан өстәрәк гарәпчә язу булган. Манараның бизәлеше, мотивлары Җәмигъ мәчетенеке шикелле үк. Әмма бер үзенчәлеге дә бар: орнаменталь композицияләрдә эзлекле ритм юк. Мәсәлән, астагы тирән ниша өстендәге горизонталь кыса бордюрының нишаның вертикаль күчәренә карата симметриясе күренми. Кырыйдагы бордюрларда исә яфрак рәвешендә (тегендә булмаган) артык мотивлар бар. Тимпандагы гөлбизәкләрнең (розетларның) дә бизәлешендә азмы-күпме очраклылык сизелә, закончалык, эзлеклелек җитми. Төрле мотивлар сайлауда билгеле бер эклектизм, бизәкләрнең эшләнешендә шапшаклык бар. Кем белә: бу бина салынган чорда шәһре Болгарда заманалар, бәлки, бик үк тыныч булмагандыр да, шундый тынгысыз тормыш үзенең эзен бу бинага да азмы-күпме салмый калмагандыр...

XIII гасыр азагы, XIV гасыр башында салынган Кара Пулатның бүгенге көндә без хәтта нинди максат белән салынуын да анык белмибез. Берәүләр аны гадел хөкем (суд) йорты, икенчеләр — мәчет, өченчеләр — мавзолей булган диләр. Бу бинаның уелма һәм гипстан коелма бизәм формалары кызыклы. 1966—1967 елларда бу урында археологлар казыну эшләре алып барганнар иде. Шул вакытта Кара Пулат янында тагын артык зур булмаган инндидер биналарның нигезләре табылды. Монда, күрәсең, ил гизеп йөрүче дәрвишләргә сыеныр урын — хөҗрә булган булырга кирәк. Һичшиксез, Кара Пулат мавзолей булган. Көнчыгыш илләрендә заманында мондый культ биналары киң таралган нәрсә. Мәсәлән, Евпаториядәге дәрвишләр мәкъбәрәсе дә Болгардагыга бик охшаган. Бу өч катлы бина кирәч ташларның «туф» дип йөртелә торган төреннән салынган. Беренче һәм икенче катлар — дүрт кырлы, өченче кат — сигез кырлы. Түбә исә ярымтүгәрәк (сферик) гөмбәз белән очлана. Бу гөмбәзнең уртасы тишек булып, әлеге тәрәзә сыман тишектән якты төшеп торган. Мондыйлар Урта һәм Кече Азиядәге биналарда да очрый.




Кара пулатның эчке күренеше. Автор реконструкциясе.

Эчке яктан Кара Пулат ике генә катлы булып күренә (фасад ягының икенче һәм өченче катлары эчтән бергә кушылып, бер генә кат хасил итәләр). Бина эчтән ак балчык белән агартылган булган. Бинаның агач идәне астында баз бар. Кү-

---

[1] Бүгенге көндә Җәмигъ мәчете калдыкларын консервацияләү һәм реставрацияләү эше алып барыла. Әмма, безнеңчә, бу эшне башкарганда, тарих истәлегенең чын кыяфәтен, сәнгатьчә матурлыгын, ямен боза торган төгәлсезлекләр дә җибәрелә. Әйтик, бинаның манаралары кирәч таш һәм туф блоклардан салынган, аны реставрацияләгәндә дә шул ук материалдагы блоклар белән сипләү кирәк иде. Әмма аны цемент плиталар белән эшлиләр. Бу исә тарих истәлегенең кыяфәтен боза. Кыйбла һәм көнбатыш фасадларының тәрәзә уемнары хатирәнең үзендә уеп-сырлап ясалган искиткеч матур гарәби бизәкләр белән бизәлгән булган. Бүгенге реставраторлар исә бинаның менә дигән ямь бирә торган бу өлешен шома блоклардан гына салып куйганнар.




1870 елда Казан Кремлендә табылган архитектура детальләре. ТАССР дәүләт музеенда саклана.


рәсен, анда «әүлиялар» күмелгәндер. Икенче һәм өченче катлардагы нишалар өстендәге тимпаннарда телле-телле, алты һәм сигез кырлы гипс розетлар ясалган. Икенче ярусның өске өлешенең ян-якларында декоратив гипс колонналар бар. Һәр колоннаның капителе лалә чәчәге (тюльпан) рәвешле итеп ясалган. Бинаның тышкы кыяфәтенә тапкыр килә торган эчке декоратив эшләнеш табу, аның гадилеге һәм җыйнаклыгы, аерым кисәкләрнең гүзәл пропорциясе, катлар һәм алардагы такларның, архитектура детальләренең әвәләп ясалган кабартма бизәкләрнең динамикалы композициясе — менә болар бөтенесе Кара Пулатның интерьерына бер хәйран күренеш бирә. Колонналардагы капительләр дә бик үзенчәлекле. Һәм шунысы кызык, структурасы, стиль билгеләре белән болар якын һәм урта Көнчыгыш архитектурасында бөтенләй диярлек очрамыйлар, мондыйларны без бары тик Алтын Урта башкаласы Сарай-Бәркә шәһәре хәрабәләрендә һәм Казан шәһәрендәге һәркайсыбызга мәгълүм Сөембикә манарасының капителендә очратабыз. Менә бу уртаклык декорация алымнарындагы традицияләлек турында сөйли. Чыннан да, XV гасыр һәм XVI гасырның беренче яртысында Казан шәһәрендәге монументаль корылмаларда Болгар архитектурасының күп сыйфатлары дәвам иттерелә. Күп санлы сарайлар, мәчет һәм мәдрәсәләр, җәмәгать биналары, кәрвансарайлар, төрле оборона объектлары корыла. Архитектур стильдә мәһабәтлелек, тантана төсе бирү, эчке бизәлештә исә купшылык сизелә. Кызганычка каршы, Мәскәү патшасы Иван IV гаскәре Казанны яулап алган вакытта бу биналарның бөтенесе көлгә әйләнеп беткән. Бүгенге көндәге археологик казынулар вакытында да бу биналарның вак-төяк җимерекләреннән башка юньле әйбер табып булмый. Әмма табылган кадәресе дә безгә

Казандагы архитектура истәлекләренең эчке бизәлеше хакында азмы-күпме сөйлиләр. Мәсәлән, кисеп-уеп эшләнгән розет һәм гарәби бизәкле, гипс йөзләү детале Казан Кремле ихатасыннан табылганнар. Икенче бер гипс деталь ишек уемының бизәге булырга кирәк. Монда инде өслек вак-вак һәм катлаулы бизәкләр белән тутырылган — бу сыйфат белән алар Болгар чоры архитектура детальләреннән аерылып торалар, стилистик катлаулануны күрсәтәләр. Галимнәр еш кына бу чуар стильне «көнчыгыш бароккасы» дип тә йөртә.


Мәшһүр Сөембикә манарасы да, кайсы гасырда төзелгән булуына карамастан, татар архитектурасының төп сыйфатларын гәүдәләндерә һәм анык бер хатирәсе булып тора. Шушы ук фикерне күп кенә архитектура галимнәре дә әйткән. Шунысы кызык, болгар-татар архитектурасына хас сыйфатлар XVII—XVIII гасырларда Казан шәһәрендә руслар тарафыннан салынган төрле биналарда да чагылыш таба.

Таш биналарны бизәүдә уеп-сырлап эшләүнең башка төрләре, әйтик, төрле төстәге кирпечләрдән өю, буяп бизәкләү хакында да сөйләргә булыр иде. Әмма бу башка бер тема булганлыктан, монда аңа тукталмыйбыз. Без бары болгар-татарларның кече форма архитектура әсәрләре — таш эпитафияләрен бераз сыйфатлап китүне кирәк табабыз. Боларның XIII—XV гасырда эшләнгәннәрен, формалары һәм бизәменең характеры буенча, ике төргә бүләргә була. Беренче төр таш билгеләр зур-зур, калын, озын һәм киңчә таш кисәгеннән булып, аларның түбәләре түгәрәк итеп юынылган. Уелма бизәктә җирле халык сәнгате гәүдәләнә. Болар арасында кояш, йолдызга тартым бизәкләр, чәчәкләр, яфраклар, йөзем тәлгәшләре очратырга була. Кайбер очракларда ташларның арт ягында бик нык стильләшкән кош сурәтен күрергә мөмкин.

Икенче төр таш билгеләр төзек, тип-тигез туры почмак формасында. Аның уң (алгы) ягына түбәсе ук рәвешле очлаеп тора торган итеп сызыкча кыса уелган. Моның



XIV гасыр Болгар эпитафияләре. Рәсем ТАССР дәүләт музеенда саклана торган эстамп буенча ясалды.

XVI гасырның беренче яртысында эшләнгән эпитафия. Татарстанның Биектау районы Олы Сулабаш авылы зиратыннан.

башында сигез чатлы чәчәк сыман, йөзем тәлгәше сыман төрле бизәкләр төшерелә торган булган.

Таш билгеләрнең бу ике төре дә бер үк вакытта кулланылганнар. Әмма беренчесе сирәгрәк таралган. Беренче төрдәгеләрнең уемы-сыры тирән, тигез. Икенче төрдәгеләрендә кабартма-яссы сыр бик җиренә җиткереп, шома итеп, төгәл ритм белән эшләнгән. Шушы сыйфатлары белән ул Болгар архитектур гыймарәтләрен эчке бизәүдә кулланылган ую-сырлау техникасына якыная. Гомумән, таш архитектураның ике формасы — олы һәм кече формалары арасындагы якынлыкны, стиль берлеген без башка чор һәйкәлләрендә дә ачык күрәбез. Алда без XV—XVI гасыр Казан шәһәренең бинадар төзелеше-бизәлешендә катлаулы стиль урнашуы турында әйткән идек. Бу шул чорның эпитафия таш билгеләре бизәлешендә дә ачык чагыла. Болгар чорында чагыштырмача гади булган бизәм инде күпмедер бер гасыр эчендә катлауланып киткән. Композициягә Болгар чорыннан бирле еш кулланылып килгән традицион мотивлар — ләлә, хөрмә, бау бизәкләр дә керә. Кайбер таш билгеләрнең арт якларында гөл савытлары ясалган. Бу чор таш билгеләре масштаб, пропорцияләренең килешле булуы белән аерылып торалар һәм татарның ташны сәнгатьчә эшкәртү осталарының зур иҗади уңышларга ирешүен күрсәтәләр. Бу сәнгать бездә соңгы заманнарга кадәр дәвам итеп килде һәм патша заманында безнең халыкның таш эшкәртү белән бәйләнгән бердәнбер сәнгать өлкәсе булып калды.

Алда сөйләнгәннәрдән нәтиҗә шул: бик күп гүзәл хатирәләрнең юкка чыккан булуына карамастан, татар халкының таш, монументаль архитектура өлкәсендә, таш йортларның тышкы һәм эчке ягын кисеп-уеп бизәү өлкәсендә күп гасырлык бай мирасы бар. Хәзерге заман архитектурасы милли традицияләргә таянып үсәргә тиеш. Оста архитектор, бүгенге көндә бинадар салганда, аны тышкы-эчке бизәү эшләрендә әлеге хәзинәне иҗади төстә файдалана алыр иде.

## Заһирә Гомәрова

### Исем бирделәр

Узган елны язлыкта
Болындагы сазлыкка
Кереп бата яздык та,
Без шунда уйга килдек:
— Бу сазлык бетсен, дидек,
Корысын, кипсен, дидек.

Узган елны язлыкта
Шундый карар яздык та,
Без кирәкләр алдык та,
Киттек бер көн сазлыкка.

Сазлык суын агыздык,—
Эшли алмас явызлык.
Җәен безгә кешеләр
Аны эзләп килделәр:
— Сазлык кайда? — диделәр.

(Сазлыкларны күрсәтә
Картадагы билгеләр.)
Эшебезне сизделәр:
— Нигә безнең картаны
Бутадыгыз сез,— диләр.
Без корытасы сазлыкны
Ник алдан киптердегез?
Без аны киптерәбез,
Тиз табып китерегез!

Юри генә әйтәләр,
Күзләреннән беләбез.
Рәхәтләнеп көләләр,
Без дә бергә көләбез.

Мелиоратор сез,— диләр,
Шундый исем бирделәр.



### Куян артыннан

Әй, очабыз чаңгыда без,
Әй, карлар тузып кала.
Кара-кара, кыр куяны
Безне бит узып бара.



Вожатый апа күрде дә,
— Я, кайсыгыз җитез,— ди.
Без чаңгыда, куян безне
Чаңгысыз да җиткезми.

## Бер һәм биш

Бер әйтү белән тыңласам
Әнием кушкан эшне,
— Молодец,— дип мактый
әни,—
Куям,— ди,— бүген «бишле».

Биш әйтеп тә тыңламасам,
— Молодец, — дими әни.
Бер почмакка бастыра да
«Берле» куям менә,— ди.

## Битлек

*(Рәсем буенча)*

Ак сакаллы бабай мин,
Тик карт түгел, малай мин.
Тирә-юньне урарга,
Чыгып киттем урамга.

Салмак атлап барганда
Җитәкләде бер бала.
— Рәхмәт,— дидем,—
онытым.
Олылыйсың олыны!

Автобуска керүгә
Барып алгы ишектән:
— Әйдә, бабай, утыр әле,—
Дигәннәрен ишетәм.

Бер бәләкәй кыз гына
Сакалыма сузыла...
Бабайлык шунда бетте,—
Битлегем төште китте.

Оялып та кызарып,
Чабып кайттым өйгә мин.
Бит кызарткан битлекне
Элеп куйдым чөйгә мин.



Фәнис Яруллин

# ГЫЙЛЬМИНУР КАРЧЫК КУРОРТТА

хикәя



Гыйльминур карчык йокысыннан уянган чакта бик иртә иде әле.

— Хәзер авылда көтү китәдер инде,— дип уйлады ул.— Килен сыерны сава алдымы икән? Бер дә башка кеше тотынганын сөйми шул, мүкләккәем. Үзе мөгезсез генә булса да андый-мондый мөгезле сыерларыңа биргесез. Көтүдә дә, янарал кебек, иң алдан йөри. Иллә, тышаулап сауганны яратмый да инде. Аягында бау барын сизсә, котыра ук башлый. Андый чакта якын бармавың хәерле. Чиләген-ниен белән үзеңне тибеп очыруы бар.

Гыйльминур карчыкның фикерләр йомгагы шулай әкрен генә сүтелде дә сүтелде. Уйларында ул үзе эшли торган правлениегә дә, иң якын ахирәте Мөгелсем карчык янына да барып кайтты. Туган ягын калдырып гомерендә беренче тапкыр чит җирләргә килгәнгәме, үз авылындагы һәрбер урынны, һәр кешене күңелдән кичереп чыкты. Ахырдан ул яңадан оныкларына әйләнеп кайтты: «Өйдәгеләр ни хәлдә ята икән? Килен фермага балаларны ашатмыйча китмәсә ярар иде. Югыйсә көне буе ач йөрерләр. Фәрите бигрәк шук нәрсә, дөньясын онытып урамда йөри торгандыр әле. Аңа түлке уйнарга булсын, карыны ач икәнен уйламый да. Әниләре бәрәңге пешереп мендәр астына куеп киткән булса, уйнап арыгач бер кереп ашар инде.

Балаларның оекбашлары да тишелә башлаган иде, шуны ямап китәргә дә башка килмәгән. Их, бу карт хәтерне!»

Карчык шулай пошынып ята. Аның инде йокысы күптән ачылды. «Анда баргач бер туйганчы йокламмын»,— дип уйлаган иде. Баксаң, бу йокы дигәннәре чит җирдә бигрәк тә тиз туя икән. Кичтән дә иң соңгыларның берсе булып ул яткан иде, иртән дә беренче булып ул уянды. Палатадагы кешеләрнең берсе дә тормаган, һәммәсе изрәп йоклый әле. Гыйльминур карчык түзмәде, торып урыннарын җыештырып куйды. Аннан соң, үзенең идарә җыештырганда бәйли торган алъяпкычын бәйләп алды да, каяндыр себерке табып, идәнне себереп чыгарды. Алай да торыр вакытны җиткерә алмагач, тыштан бер чиләк

алып керде, итәкләрен алъяпкыч бавына кыстырып, идәннәрне юарга да тотынды. Ул бу эшне бик бирелеп эшләде. Һәр юылган сайгак, аңа рәхмәт укыгандай, ялтырап, елмаеп кала. Башка вакытта эшләгәндә ул авыз эченнән нинди дә булса берәр көй мыгырдый торган иде, бүген, кешеләрне уятудан куркып, карчык бу ләззәттән баш тартырга булды. Ул шулай бүлмәне ялт иттереп, вазадагы чәчәкләрнең суларын алыштырып, сулы чиләген түгәргә чыкканда, гөнаһ шомлыгына каршы, аңа дежур медсестра очрады. Башта ул Гыйльминур карчыкны үзләренең берәр санитаркасы дип уйлады булса кирәк, игътибар итми генә үтеп китмәкче иде, ләкин бераз ара киткәч, кире борылып килде. Үзенең шиге дөрескә чыккач, ул аптыравыннан ни дияргә белми торды. Аннары:

— Нишләп сез болай чиләкләр күтәреп йөрисез? — диде.

— Идәннәрне юып чыгарган идем, балам, бер дә йоклап булмый бит.

— Йоклап булмаса, дару сорарга иде, мин һәрвакыт шушында бит.

— И кызым, йокламаганга да дару эч, бүтәнгә дә дару эч, кая киткән эш ул. Авыл кешесе таң белән торырга өйрәнгән инде ул...

— Сез бит монда дәваланырга дип килгән кеше, дарусыз гына дәваланып буламыни? — диде сестра.— Монда инде идәннәр юуыгызны калдырып торырга туры килер. Врач билгеләгән режимны бозсагыз, сәламәтләнә алмассыз. Моннан соң андый эшегезне күрсәм, врачка әйтермен. Ә хәзер подъем булганчы урыныгызга барып ятыгыз.

Гыйльминур карчык, режимның да, подъемның да ни икәнен белмәсә дә, сестра кушкач, урынына кереп ятты. Бәхеткә каршы, аңа бик озак ятырга туры килмәде. Кешеләр йокыларыннан тора башладылар. Аннан бар да бергә чыгып физзарядка ясап керделәр. «Монда гел солдаттагыча икән,— дип уйлады ул.— Зарифулла мәрхүм, шулай ди торгание, солдатта бөтенең бергә сикереп торасың, бөтенең бергә чыгып йөгерәсең, бергә кайтып ашыйсың дия иде. Монда да шулай».

Менә иртәнге ашка барыр вакыт житте. Монда инде Гыйльминур карчык артык ашыкмады.— Башкалар ашап туйсын әле, безгә, карчык кешегә, калганы да ярар,— дип уйлады ул.— Әллә нинди нәчәнникләр белән бергә утырып ашау карт кешегә килешә торган эш тә түгел. Карыны ачты ачуын. Өйдә инде бу вакытта икенче самовар чәй куйган булыр иде. Монда өең түгел шул, аларның үз пурәткеләре бар.

Гыйльминур карчык ашханәгә килеп кергәндә, чынлап та, өстәлләр бушый башлаган иде инде. Ул бер ишек алдындагы өстәлнең кырыена гына килеп утырды. Өстәлдә чәйнек белән чәй һәм бер тәрилкә ипи тора. Гыйльминур карчык, миңа шушыдыр инде иртәнгелек дип, чәйне стаканга агызып ипи белән тәмләп кенә эчәргә керешге. Ул бер-ике кабарга да өлгермәде, аның янына официантка кыз йөгереп килеп житте.

— Бик соңга калдыгыз, әллә беренче көн булгач йокыдан уяна алмадыгызмы? — диде кыз.— Бүтән чакта кешеләр белән бергәрәк килергә тырышыгыз, юкса ашлар суына.

— Ярар, балам, шулай итәрмен,— диде карчык. Ә үзе кызның бик күп ризыклар күтәреп аның өстәле янына килүен күргәч, курка калды:

— Әллә, балам, монда берәр бүтән кеше урынымы? Нигә ул хәтле күп ризык ташыйсың?

— Юк, әби, бу өстәлдә сез генә калдыгыз инде. Башкалар бар да ашап чыктылар.

— Шулай булгач, бик күп тезмә, калып әрәм була бит. Миңа, карт кешегә, чәй дә ярар.

— Монда, әби, картына да, яшенә дә бертигез бирелә.

Кыз китеп баргач, карчык ашларның кайсына тотынырга белмирәк торды. Ләкин ачкан карын ризык сайлап тормады. Ашлар бар да бик

тәмле күренсә дә, ул барсына да кашык тыгып кабып карарга батырчылык итмәде. «Мин кашык тыкканны башка кеше ашамас, чиста көе калсын», дип, бер төрлесен, бары тик манный боткаларын гына ашады ул. Ашап туйгач, карчык догасын уч төбенә генә укып, мондый тәмле ашлар пешергән кешеләргә рәхмәт әйтеп урыныннан торды. Һәм ашаган тәлинкәсен дә, чәй эчкән чынаягын да алъяпкыч итәгенә салып, кухня ягына кереп китте.

— Кызым, монда савытларны кайда юалар?

Аш ташучы кыз итәгенә савытлар тутырып керүче карчыкны күргәч шаккатты. Аннары, бу кызыкны башкалар да күрсен әле дип, бүтәннәргә әйтергә йөгереп китте. Күп тә үтмәде, эчтән берничә хатын-кыз чыкты һәм алар пырхылдашып алдылар. Гыйльминур карчык, әллә берәр җиремә аш тамганмы дип, түшләрен сыпырып карады, ләкин алай көләргә сәбәп булырлык берни дә тапмады.

— Миңа савыт-саба юа торган җирне генә күрсәтегез инде...

— Апа, без монда савытларны үзебез юабыз,— диде өлкәнрәк кыз. — Китерегез үземә.

Гыйльминур карчык, ышанмыйча, кызларга карады. Миннән көләләр дип уйлап, бик каты кызып китәргә уйлаган иде дә, белмәгән урында ярамас дип кенә, бераз басыла төште.

— Ашаган савытларымны да кешедән юдырырга, әллә мине капрал хатыны дип белдегезме? — диде ул.— Тарткалашып тормагыз, кая юа торган урынны гына күрсәтегез дә... Һәм ул, барысын да каратып калдырып, зыр итеп эчкә кереп китте. Барысы да ах иттеләр. Ә Гыйльминур карчык, беркемгә дә карамыйча, кран төбендә үзенең савытларын юып, эшен бетереп чыгып китте.

Ашханәдән кайткач, карчык тәмам уйга калды.— Әллә соң болар мине берәр нәчәнник хатыны дип уйлыйлар микән? Алай дияргә кыяфәтем бер дә килмәгән. Нигә бу кадәр кадерлиләр соң? Иртән торгач үз бүлмәңне җыештырма, ашагач савытларыңны юма, ул ни була инде? Җитмәсә берсе: иртәгә нәрсә ашарсыз икән, ни язып дип тора. Кешегә яраган миңа да ярар әле. Мондагы кешеләрнең барсына да теләгән нәрсәләрен ашата башласаң, әндери казнаң да җитмәс. Мөгаен, болар минем җыештыручы булып эшләвемне белмиләрдер. Иртәгүк әйтергә кирәк булыр, әллә кая кеше өлеше ашатып яткырмагайлары. Болай кадер-хөрмәт булгач әйбәт әйбәтен дә, кешегә дигән әйбәтлеккә үрелмим тагы.

Шушы уйлар борчыды карчыкны. Тизрәк җаен туры китереп шуны әйтү нияте белән китте ул икенче көнне ашханәгә. Тик аш таратучы кыз бүтән булып чыкты. Карчык бу уен икенче көнгә калдырып торырга мәҗбүр иде. Ашаганда ул бүтәннәрне дә күзәткәли торды, аларны да шулай яхшы ашаталар икән. Ләкин бит алар урындагы кешеләрдер. Әнә бит берсе ашыгыз тәмсез дип ничек пыр туздырды үзләрен. Нәчәнник булмаган кеше шундый тәмле ашларны тәмсез дияр идеме?!

Менә карчыкка теге сүзен әйтергә җай чыкты. Беркөнне шефповарлары чыгып кешеләрдән: «Нинди зарларыгыз бар?» дип үзе сорап йөрде. Гыйльминур карчык, бу форсаттан файдаланып, поварны бер яккарак дәшеп алды:

— Кызым, сиңа сүзем барые,— диде ул.

— Әллә заказыгызны бирмиләрме? — диде повар, борчылып. Әгәр шулай икән, әйтегез, бер дә тартынып тормагыз. Мин аларның ничек эшләүләрен белергә тиеш.

— Юк, балам, барысы да бик әйбәтләр. Гел, ни язып, ни ашыйсың килә дип кенә торалар. Ул яктан зарланырлык түгел. Менә шул бик тә артык кайгыртуларына эчем поша минем. Әллә кая кеше өлешен ашатып яткырмыйлармы дим. Мине алар әллә кем дип белделәр бугай. Мин бит җыештыручы гына.

— Ничек, нәрсә жыештыручы? — диде повар, берни дә төшенмичә.

— Менә, менә. Мин үзем дә шулай булыр дип уйлаган идем аны. Хәзер синен дә исен китте. Мин идарә жыештыручысы. Ә алар мине нәчәнниктән дә ким сыйламыйлар.

Ниһаять, повар аңлады. Кычкырып көлде дә сөйләп китте:

— Монда, әби, бернинди дә начальниклар юк. Монда бар да дәваланырга килгән кешеләр генә. Жыештыручымы ул, бозау караучымы яки пешекчеме, безнең өчен барыбер. Без барыгызга да кулдан килгән хәтле кадер-хөрмәт күрсәтергә тырышабыз.

Гыйльминур карчык ышанырга белмичәрәк баш селкеп куйды. Ә үзе барыбер булса күрербез әле, иртәгә ничек ашатырсыз икән, дип уйлады.

Икенче көнне дә Гыйльминур карчыкны шундый ук ягымлы чырай белән каршы алдылар. Аш ташучы кызлар бу карчык керүгә, бик якын кешеләрен күргән кебек, бөтенесе дә килеп исәнләштеләр. Алар өстәлен караучы кыз:

— Әби, нәрсәләр китерим? Өегездә нинди ашларны яратып ашый идегез? — дип, карчык янында бөтерелеп йөри башлады.

— Кызым, мин бар нәрсәне дә яратып ашыйм,— диде Гыйльминур карчык.— Ипи белән бәрәнге дә ярый миңа.

— Юк инде, әбекәй, ипи белән бәрәңге ашап кына тазара алмассыз. Әллә яшь сарык итеннән пешергән өчпочмак китеримме?

— Ярар алайса, китер.

— Ә икенчегә нәрсә?

— Сөтле чәй.

— Чәйне китерербез, ансы аш санына керми аның.

— Чәй белән өчпочмак булгач, бүтән нәрсә кирәкми инде, кызым. Гыйльминур карчык бик әйбәтләп тамагын туйдырды. Башка көннәрдәгедән дә яхшырак мөнәсәбәт күргәч, карчык үзенең шиге юкка икәненә тәмам ышанды. Жаны тынычланды аның. «Кеше өлешен ашап ятамдыр»,— дигән уйлар күңелен тырнамый башлады.

Әмма күнеле тынычланса да, ул мондагы эшсезлеккә һич кенә дә күнә алмады. Беркөнне, башкаларга әйтми-нитми генә, якындагы авылга китте. Һәм алъяпкычына төйнәп бер төргәк йон алып кайтты. «Көндез барыбер йоклап булмый, ичмасам, оныкларыма оекбашлар бәйләп алып кайтырмын», дип, сестралар йөрмәгән вакытларда, йонны кровать башына әз-әзләп кенә бәйләп, эрләргә тотынды.

Өенә кайтканда аның чемоданында оныкларына гына түгел, улы белән килененә дә оекбашлар бар иде.

## Радик Исаев

# КҮРШЕ КИҢӘШЕ

хикәя



Тормышыбызга күрше-күләнгенә түгел, безне белгән барлык кеше соклана иде. «Менә, ичмасам, Хәбибулла яши карчыгы белән! Ярты гасыр тигез гомер иттеләр, берсеннән-берсе акыллы өч малай үстерделәр», дип сөйлиләр иде. Үзебез дә балаларыбызның эшләре, укулары, акыллы булулары белән горурлана идек. Беренче улыбыз Кәрим — нефтьче, икенче улыбыз Дәүли — укытучы. Төпчек улыбыз Айрат минем профессияне сайлады — техникум тәмамлап, бухгалтер булып эшли башлады. Ә без, карчыгым белән икебез дә, пенсиядә. Балаларыбызның кайтуына аш-су әзерләп торабыз, йорт-җирне карыйбыз. Тора-бара бу эш тә кулдан китте. Беренче улыбыз Кәрим килен алып кайтты. Килен ару гына күренә. Бик төчекәй: «әткәй-әнкәй» дип кенә тора. Без карт-корыга ягымлы тел булса, коелабыз да төшәбез инде. Киленгә «кызым» дип кенә дәшәбез.

Ике айлап вакытны бик күңелле үткәрдек. Аннан соң семьяда тынычлык югалды. Ягымлы телле, тыңлаучан киленебез үзсүзлегә әйләнеп китте. Безгә командалар биргәли башлады. Бераз түзәргә, чыдарга тырыштым. Әмма, чыдар хәлем калмагач, бер көнне киңәшфәләп сорарга күршем Гариф янына кереп киттем. Ул да безнең ырлы-мырлы яшәгәнне шәйләп алган икән.

— Килен белән яшәү кыенрак инде, син аларны башка гына чыгар,— диде бу.

Күршемнең киңәшен тотып, үзебез яшәгән дүрт бүлмәле квартирны икешәр бүлмәле ике квартирга алыштырдык та аерым тора башладык.

Яңа квартирда тормышны җайга гына салып килгәндә, Дәүли улыбыз да кыз ярәшеп кайтты. Йортыбызга икенче килен төшкәч, тормышыбыз тагы да ямьләнде. Монысы инде беренче киленгә бөтенләй охшамаган, безне өрмәгән җиргә дә утыртмый... Гүя карчыгым белән ялга чыктык. Кулдан эш китте. Көнгә әллә ничә тапкыр чәй куеп эчәбез. Бакчаларга чыгып йөрибез. Киноларга барабыз.

Тик, әлеге дә баягы, бу куанычыбыз да озакка бармады. Килен белән улым Дәүли башка чыгуны чамалый башладылар. Карчыгым:

— Киленнән игелек күрермен димә, беренче яуган карга ышанып чана җикмә,— дип сөйләнде. Бик аптырагач, тагын күршем Гариф белән киңәштем.

— Ике бүлмәле квартирың бар. Шулар белән олы башыңны тынгысызлап яшәмә, Хәбибулла. Белдерү бир дә берәр бүлмәле ике квартирга алыш,— дип киңәш итте ул.

Шундый акыллы киңәшне тыңламый булдыра алмадым. Төпчек улыбыз Айрат, карчыгым һәм үзем бер квартирга, Дәүли белән килен икенче квартирга күчеп яши башладык.

Балалар бер үсеп китсә үсә икән. Кече улыбыз Айратка да егерме биш тулды. Ул да күршебез Гарифның бердәнбер кызын алып кайтты. Кыз бик иркә, үзе яман телле. Килен булып төшкән көнне үк: «Квартирны бүлешеп бетергәннәр, безгә калмаган»,— дип ычкындырды.

Яшермим, без карчыгым белән байтак түздек. Тиздән төпчек киленебез бер малай да алып кайтты. Оныгыбыз булганга шатлансак та, йортта тынычлык калмавы җанга тиде. Ни эшләргә белмичә, элекке күршем — хәзерге кодам янына кереп киттем.

Гариф бу юлы ни өчен кергәнне дә сорап тормады:

— Тагын квартирдыр инде,— диде, сүз башлап.— Ни эшләмәк кирәк, кода, яшьләр бит, аларның да тормыш корасы килә. Сез инде аларга комачауламагыз. Шәһәрдә бетмәгәндер, үзем дә табарга булышырмын, берәрсенә квартирга күчегез. Сезгә дә тынычрак булыр, аларга да.

Менә шул. Башка сөйләп тормыйм. Бер җирдә квартирга кертәләр дип ишеткән идем. Киттем. Шуны карап кайтыйм әле.

# ЯНЧЫК ЮГАЛГАЧ

Безнең җимеш бакчасы бөтен район халкына билгеле.

Ата-бабамнан калган инде ул. Ә менә быел, мин өйләнгәч кенә, шул бакчабызның рәте китте. Куаклар суга сусадылар. Үч иткәндәй, бу елны явым-төшем дә аз булды. Бакчаны сугарырга үземнең вакыт юк. Колхоз шоферын беләсез инде, көне-төне дип әйтерлек машинада. Әнинең дә яше бакча тәрбияләүдән үткән. Хатыным Әлфия аннан башка да эше күплегенә зарлана. Үзе дә авыррак сөякле...

Авылны данлаган бакчабызны һәлак итәсем килми. Бер көнне эшкә киткәндә хатынга алмагачларга су сибәргә куштым. Кайтуыма бер чиләк су да сипмәгән. Ачу ярыйсы гына кабарган булса да, түздем. Һәм аны кызык итәргә булдым. Бакчаны әйләнеп чыккач, зур бәлагә тарыган кеше кыяфәтендә өйгә кердем.

— Ни булды? — диде хатыным Әлфия, сытылган йөземне күреп.

— Акчамны югалттым,— дидем, борын тартып.

— Кайда? Ничек? Әллә зарплатаңнымы?.. Тулы килешме? — Әлфиянең йөзендә төс юк иде. Ул һушын югалта язды.

— Бакчага бераз су сипкән идем. Шунда коега янчыгым төште бугай,— дидем. Шуннан соң гына ул аңына килде. Мин югалткан акчага: яхшы бер өстәл, алты урындык, тагын төрле вак-төяк әйберләр алырга мөмкин булуын чутлап чыгарды.

Бу хәбәр әнине дә борчыды булса кирәк. Ул да караватында тыныч кына ята алмады...

Иртән йокыдан торганда янымда Әлфиям юк иде. Тышка киенеп чыгам. Ихатада хуш исле дымлы һава. Алмагачлар күл эчендә утыра. Кое чылбыры чыңлый. Хатынымның алҗыган тавышы ишетелә: «Йөз дә егерме өч, йөз дә егерме дүрт...»

Исләрем китте. Әллә акчамны тапканнармы дип торам. Юк икән. Әлфиям коедан ничә чиләк су алганын саный. Әни ерганак ера. Ә күн янчыгым минем умарта оясына яшереп куйган килеш тора бирә.

## ҮЗЕШЧӘН СӘНГАТЬ КӨЧЛӘРЕНӘ СМОТР

КПССның Татарстан өлкә комитеты, республиканың Министрлар Советы һәм профсоюзларның Татарстан өлкә советы В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу һәм республиканың 50 еллык юбилее уңае белән үзешчән сәнгать көчләренә смотр үткәрергә карар бирде.

Смотр республика районнарында 1969 елның маена кадәр, зоналарда 1969 елның октябрендә үткәреләчәк. Йомгаклау Казанда 1970 елның июнь аенда булачак.

Үзешчән сәнгать көчләренең чыгышларын бәяләү өчен композитор Җ. Фәйзи (председатель), режиссер Ш. Сарымсаков (смотрның баш режиссеры), балетмейстер В. Феклин (смотрның баш балетмейстеры), художник Э. Нагаев (смотрның баш художнигы), А. Абдуллин, А. Гацуллина, М. Гумеров, Р. Ишморат, С. Казачков, З. Нури, М. Сәлимҗанов, Р. Сәләхетдинов, В. Саликов, Л. Сперанская, А. Тихонов, К. Хөсәенов, Р. Яруллина (членнар) составында жюри төзелде.

## ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ БРИГАДА

Берлинер Бремзенберк. Берлинда революцион традицияләргә бай булган бу заводның күп кенә бригадалары социалистик хезмәт коллективы исемен йөртә.

1967 елның сентябрендә бу заводка Казан туристлары кунакка килә. Алар социалистик хезмәт коллективларының берсендә — башлыча инженерлардан, экономист-плановиклардан торган бригада да булалар һәм коллектив членнарын татар халкының батыр улы, легендар шагыйрь Муса Җәлилнең тормышы, иҗаты һәм фашист топтыкынлыгындагы патриотик эшчәнлеге белән таныштыралар. Шуннан соң бригада членнары Германия — Совет дуслыгы җәмгыятенә, татар шагыйре һәм патриот Муса Җәлилнең исемен йөртергә рөхсәт сорап, мөрәҗәгать итәләр.

Безнең Германия Демократик Республикасындагы дустыбыз, әдип Леон Небенцальдән күптән түгел хат килде. Ул Муса Җәлил исемендәге бу бригада членнарының һәм 15 номерлы урта мәктәп укучыларының ГДР пионерлар оешмасының 20 еллыгына багышланган тантаналы утырышында Муса Җәлилнең хатыны Әминә Җәлиловага бергәләшеп хат язуларын хәбәр итә. Бригада членнары герой шагыйрь исеменә һәрвакыт лаек булырга сүз бирәннәр, ә укучылар, фамилияләрен язып, пионер галстугы җибәргәннәр.

## КОНВЕРТЛАРДА — АБДУЛЛА АЛИШ ҺӘМ ШАМИЛ УСМАНОВ

СССР Элемтә Министрлыгы татар язучылары Абдулла Алиш белән Шамил Усмановка багышлап нәфис конвертлар чыгарды. Атаклы балалар язучысы, Муса Җәлилнең көрәштәше Абдулла Алишка багышланган конвертны художник А. Зубов, ә танылган җәмәгать эшлеклесе һәм язучы Шамил Усмановның тууына 70 ел тулу уңае белән чыгарылганын художник П. Чурилин эшләгән.

## ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ХИКӘЯЛӘРЕ ЧУВАШ ТЕЛЕНДӘ

Чувашстан китап нәшрияты, татар язучыларының хикәяләрен туплап, китап бастырып чыгарды. А. Шамов, Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, Ә. Еники, З. Нури, Г. Минский, М. Әмир, Ф. Хөсни, Б. Камалов, С. Сабиров, Р. Төхфәтуллин, Х. Сарьян хикәяләрен чуваш теленә Ю. Мишши, В. Максимов, В. Игнатьев, В. Юдин, К. Петров, Ю. Скворцов һәм А. Еруслaнов тәрҗемә иткән.

Китапның күләме — 134 бит, бәясе — 19 тиен.

## Ф. ӘМИРХАН ӘСӘРЛӘРЕ РУС ТЕЛЕНДӘ

Галия Хантимирова — педагог һәм фән хезмәткәр буларак, М. Горький исемендәге әдәбият институтында яшь язучыларны тәрбияләү белән бергә, татар язучыларының әсәрләрен рус телендә популярлаштыручы әдипләрнең берсе. Күптән түгел Татарстан китап нәшрияты аның тәрҗемәсендә татар әдәбияты классигы Фатих Әмирханның повестьларын һәм хикәяләрен рус телендә йөз мең тираж белән бастырып чыгарды. «Хәят» дип исемләнгән бу китапка язучының «Минем тәрҗемәи халем», «Фәтхулла хәзрәт», «Хәят», «Танымаганлыктан таныштык», «Кадерле минутлар», «Бәхетле минутлар», «Татар кызы», «Хәзрәт үгетләргә килде», «Рәхәт көн», «Габделбасыйр гыйшкы», «Бәйрәмнәр», «Сәмигулла абзый», «Чәчәкләр ките-

регез миңа» әсәрләре кертелгән. Художник Т. Усманов әсәрләргә карата төсле буяулар белән иллюстрацияләр эшләгән. Күләме 286 бит, бәясе 85 тиен.

## МУСА ҖӘЛИЛ ҺӘМ ЛАТВИЯ ЯЗУЧЫЛАРЫ

Күптән түгел «Советская Татария» газетасы язганча, 1941 ел башында яңа гына Советлар Союзы составына кергән Латвия республикасы язучылары Татарстан язучылары союзы идарәсенә түбәндәге хатны җибәрәләр:

«Хөрмәтле иптәшләр!

Безнең республикада сезнең әдәбият, сезнең язучылар, гомумән сезнең культура тормышыгыз турында белешмәләр бик аз, чөнки капиталистик строй шартларында СССР халыклары белән бәйләнешкә керергә мөмкинлек булмады. Шуны әйтергә тиеш табам: безнең халыкта сезнең культура тормышыгыз белән кызыксыну зур. Шуңа күрә яңа чыккан китапларыгыз, язучыларыгыз турында белешмәләр, язучыларыгыз турында биографик очерклар һәм аларның рәсемнәрен, шигырь һәм проза белән язылган китапларын җибәрүегезне үтенәбез.

Үзебез дә әдәби тормышыбыздагы яңалыкларны белдереп торачакбыз.

Дусларча сәлам белән — Я. Якобсон».

Татарстан язучылары союзы идарәсе Латвия язучылары белән бәйләнешне ныгыту эшен Муса Җәлилгә тапшыра.

Һәр тапшырылган эшкә бик җаваплы караган һәм аны төгәл үтәргә яраткан Җәлил Латвиядәге каләмдәшләре өчен татар язучыларының шактый гына китапларын туплый, газеталарда, журналларда алар турында, республикабызның культура тормышы турында басылып чыккан материалларны җыя.

Архивтан күптән түгел генә табылган бу хат һәм аңа: «Латвия өчен материаллар оештыру М. Җәлилгә тапшырылды»,— дип язылган язу, бердән, татар һәм Латвия язучылары арасындагы бәйләнешне күрсәтсә, икенчедән, Җәлилнең каләмдәшләренә карата гаять игътибарлы булуы турында сөйли.

## ОЧРАШУЛАР, КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР

Шагыйрь М. Ногман Пермь өлкәсенең Барда районында булып кайтты. Ул анда, Сараш, Барда авылларында булып, укучыларга шушы районда туып үскән Советлар Союзы Герое Шәрифҗан Казанбаевка багышлап язган яңа поэмасын укыды, иҗат планнары, бүгенге татар әдәбияты турында сөйләде.

Шагыйрь партиянең Барда районы комитеты секретаре Зәбир Имайкин белән дә очрашып сөйләште.

«Безнең районда яши торган 42 мең кешенең 35 меңгә якыны татарлар,— диде иптәш Имайкин.— Мәктәпләрдә татарча укытыла. Райондагы 44 татар мәктәбендә 6800 татар укучысы укый. Барда, Үдик (Елпачиха), Сараш урта мәктәпләрен тәмамлаган бик күп яшьләр Мәскәү, Казан, Пермь, Свердловск, Чиләбе һәм башка шәһәрләрдәге югары уку йортларында укуларын дәвам иттерәләр.

Район хезмәт ияләре татар язучыларының әсәрләрен, татар матбугатын даими укып баралар. Бу кызыксыну районда Г. Әпсәләмов, Р. Ишморат, Н. Арсланов, М. Ногман, Ә. Маликов, Г. Латыйп, Г. Афзал, Р. Ишморатова һ. б. язучылар булып киткәннән соң тагы да артты.

Моны шул факт та ачык күрсәтә: 1968 елда районда «Казан утлары» журналын 470 кеше алдырган булса, быел исә аңа 617 кеше язылды.

Журналны тарату эшендә Төнгук элемтә бүлеге начальнигы Рәисә Сафина актив эшләде. Бу бүлек аша «Казан утлары» журналын 105 кеше алдыра.

Башлангыч партия оешмалары, элемтә бүлеге хезмәткәрләре, җәмәгать тәртибендә таратучылар татар телендә чыга торган бердәнбер әдәби журнал булган «Казан утлары»н тарату эшен киләчәктә тагын да киңрәк җәелдерәчәкләр.

Без колхозларда, совхозларда, предприятиеләрдә күп кенә хезмәт алдынгыларын «Казан утлары» журналына еллык подписка белән бүләклибез. 1970 елда районда «Казан утлары» журналын меңнән артык кеше алдырыр дип ышанабыз».

## УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Совет районының Дербышка культура сараенда А. Расихның «Ямашев» романы буенча укучылар конференциясе булды. Романга карата үзләренең фикерләрен әйтеп, пенсионер Бикташева, китапханә активистлары Шакирова, Низамова, Вәлиева, Гафиятуллин һ. б. лар чыгыш ясадылар.

Романның авторы А. Расих укучыларның күп санлы сорауларына җаваплар бирде, роман өстендә ничек эшләве, нинди чыганаклардан файдалануы, Х. Ямашев һәм аның замандашлары турында сөйләде.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Гамил Афзал һәм Рафаил Төхфәтуллин Әлмәттәге 34 нче тәзү-монтаж идарәсе эшчеләре белән очраштылар, бүгенге әдәбият, язучыларның иҗаты турында әңгәмә үткәрделәр, укучыларның күп санлы сорауларына җаваплар бирделәр.

Әлмәтнең көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинатында әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Кичәгә язучылар Гамил Афзал, Рафаил Төхфәтуллин һәм журналист Фазыл Мостафин катнашып, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. Әлмәт музыка училищесы директоры, композитор Мәсгут Имашев, училище укучылары Әлфия Гайфиева һәм Рәис Нәгыймов татар халык җырларын, композиторларыбыз әсәрләрен башкардылар.

М. Горький исемендәге клубта (Әлмәт шәһәре) шигырь һәм җыр кичәсе булып үтте. Кичәдә Гамил Афзал, Саҗидә Сөләйманова һәм Клара Булатова үзләренең шигырьләрен укыдылар. Композитор Мәсгут Имашев үзе иҗат иткән җырларны башкарды. Музыка училищесы укучылары Суфия Рәхмәтуллина һәм Әлфия Гайфиева җырларын тамашачылар яратып тыңладылар.

Соңыннан җыр һәм шигырь турында җитди сөйләшү булды.

Азнакай район культура йортында үткәрелгән «Зәңгәр ут» кичәсендә Гамил Афзал, Рафаил Төхфәтуллин һәм Мәхмүт Хәсәнов катнаштылар. Түгәрәк өстәл янында әдәбият турында сөйләшү булды. Язучылар үз әсәрләренең язылу тарихы, киләчәк иҗат планнары турында сөйләделәр, яңа әсәрләреннән өзекләр укыдылар, күп сорауларга җаваплар бирделәр.

## ТЫНЫЧЛЫК ФОНДЫНА

Татарстан язучылары союзы оештырган «Вьетнамга ярдәм» комиссиясе үзенең эшен уңышлы дәвам иттерә. 1967 елда Татарстан язучылары «Җиңелмәс Вьетнам» дигән китап чыгарганнар иде. Китапка Нәби Дәүли, Зәки Нури, Самат Шакир, Илдар Юзеев, Салисә Гәрәева, Гали Хуҗиев, Галимҗан Латыйп, Әхмәт Хәмәдишин, Фәнис Яруллин шигырьләре һәм Вьетнам язучылары әсәрләренең татар теленә тәрҗемәләре тупланган. Вьетнам язучыларының шигырьләрен һәм хикәяләрен Ә. Синегулов, Г. Хуҗиев, К. Фәсәхов, М. Садри, К. Миңлебаев, Н. Арсланов, З. Нури, М. Хөсәен, К. Тәхәү, Ә. Баянов тәрҗемә иткән. Китапны чыгарудан килгән гонорарны китапның авторлары тулысынча тынычлык фондына тапшырдылар.

Татар язучылары, «Казан утлары», «Азат хатын» редакцияләре, Язучылар союзы идарәсе хезмәткәрләре күптән түгел тынычлык фондына тагын 300 сумга якын акча җыйдылар.

## «КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР КЛУБЫ»

«Казан утлары» журналы редакциясе янындагы традицион «Кызыклы очрашулар клубы»ның чираттагы утырышы бу юлы республика прокуратурасының криминалистика залында үткәрелде.

ТАССРның баш прокуроры, III класс дәүләт советнигы И. Хәмидуллин очрашуга килгән язучыларга совет прокуратурасының тарихы, аның хокуклары, Татарстан прокуратура органнарының эшчәнлеге һәм алар алдында торган бурычлар турында сөйләде.

Аннары республиканың баш прокуроры урынбасары, өлкән юстиция советнигы А. Вәлиев сүз алды.

«Прокуратура хезмәткәрләре һәм әдәби иҗат кешеләре арасында хезмәттәшлек рус классикасында һәм дөнья әдәбиятында бик күптәннән бирле яшәп килә,— дип башлады ул үзенең чыгышын.— Мәсәлән, Л. Н. Толстой үзенең «Яңадан туу» романын прокуратура материалларына таянып язган».

Аннары А. Вәлиев татар язучыларын прокуратура органнары белән тыгыз бәйләнешкә керергә чакырды, үзләренең иҗади хезмәтләре белән халыкны коммунистик рухта тәрбияләүдә аларга уңышлар теләде һәм утырышка катнашучыларны җинаятьчелек белән көрәш практикасында очрый торган «гыйбрәтле эш»ләр белән таныштырды.

Прокуратура хезмәткәрләре язучыларның күп санлы сорауларына җавап бирделәр.

Соңыннан Х. Туфан, Г. Бакиров, М. Әмир, Ф. Хөсни, А. Расих һәм Г. Латыйп үзләренең чыгышларында, утырышка килгән барлык язучылар исеменнән, бу кызыклы очрашуга катнашулары, кызыклы әңгәмәләре, яхшы теләкләре өчен прокуратура хезмәткәрләренә рәхмәт әйттеләр.

## ҖИТМЕШЕНЧЕ ЕЛДА ЧЫГАЧАК КИТАПЛАР

Күптән түгел ТАССР Министрлар Советы янындагы матбугат идарәсе советының нәшрият җитәкчеләре һәм Татарстан язучылары союзы идарәсе катнашында үткәрелгән утырышында Татарстан китап нәшриятының 1970 елда китап чыгару планы проекты буенча фикер алышу үткәрелде.

1970 ел — өч зур юбилей елы. Ул елда В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу юбилее, республикабызның 50 еллыгы, Бөек Ватан сугышында совет халкының җиңүенә 25 ел тулу көне бәйрәм ителәчәк. Шуңа күрә бик табигый: Татарстан китап нәшриятының 1970 ел планында бу зур даталарга бәйле китаплар зур урын алып тора. 1970 елда нәшрият Лениниана буенча 5 нче җыентык — «Мәңге үлмәс» китабын бастырып чыгара. Анда В. И. Ленинга багышланган иң яхшы пьесалар, киносценарийлар тупланган. С. Хәкимнең «Күңелем Ленин белән сөйләшә» җыентыгы укучыларга матур бүләк булачак. З. Воскресенскаяның «Караңгылык аша үткәндә» китабында В. И. Ленинның һәм Н. К. Крупскаяның беренче рус революциясе елларындагы тормышы сурәтләнә. В. Байдерин «Иң кешелекле кеше» исемле китабында Володя Ульяновның Казандагы һәм Кокушкинодагы тормышы турында яза.

Республиканың 50 еллыгы уңае белән И. Газиның «Онытылмас еллар», Г. Ахуновның «Татарстанның данлы кешеләре», Ш. Рәкыйповның «Шахта көен уйнагыз», «Татар әдәбияты хроникасы», «Идел белән Урал арасында» һ. б. бик күп китаплар басылып чыгачак. М. Садриның «Солдат һәрвакыт юлда», Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз», Г. Бәшировның «Намус», Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» һәм «Җимерелгән бастион», С. Хәкимнең «Торыгыз, Мусалар», С. Таһировның «Урман гарнизоны», А. Әхмәтнең «Җыр белән очрашу» һ. б. китаплар Бөек Ватан сугышы елларында совет кешеләренең батырлыгын сурәтләүгә багышланганнар.

## МУЗЫКА ҺӘМ ЯКТЫЛЫК

Моннан ике ел элек, 1967 елда, музыка һәм яктылык синтезына карата Казанда семинар үткәрелгән иде. Бу өлкәдәге энтузиастлар башлыча Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Казан авиация институтында. Студентларнын «Прометей» конструкторлык бюросы музыканы ишетеп кенә түгел, «күреп» тә аңларлык итү өстендә актив эш алып бара. Бу мәсьәлә буенча «Прометей» СКБы бөтен илебездәге белгечләргә информацион белешмәләр җибәреп тора.

Февраль аенда Казан авиация институты, А. С. Попов исемендәге радиоэлектроника һәм элемтә фәнни-техника җәмгыятенең Татарстан идарәсе, Казан дәүләт консерваториясе, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты музыка һәм яктылык синтезы буенча конференция үткәрде. Конференциягә Мәскәү, Ленинград, Киев, Харьков, Вильнюс, Минск, Одесса, Свердловск, Кишинев, Муром белгечләре дә катнашты. Конференциягә катнашучылар музыканы кино кадрлары аша... карадылар.

Булат Галиев җитәкчелегендәге «Прометей» клубы членнары музыка һәм яктылык синтезын практик куллану коралларын да ясадылар. Мәсәлән, алар Казан циркын динамик яктырту ысулын эшләделәр. Куйбышев мәйданында салына торган үндүрт катлы гостиницага да музыка һәм яктылык җайланмасы куелачак.

## Хөрмәтле укучыбыз!

**1969 елдан «Казан утлары» журналы ике табакка артык чыга башлады. Шунлыктан аның бәясе дә бер санга 50 тиен булды.**

**Кайбер иптәшләр журналга узган елгы бәя белән язылып өлгергәннәр иде инде. Алар, өстәмә рәвештә язылмаган булсалар, октябрь, ноябрь, декабрь айларына журналсыз калачаклар. Без шул турыда исегезгә төшереп, журналга язылу тәртипләрен тагын бер кат язып чыгарга булдык:**

**«Казан утлары» журналына теләсә кайсы айдан башлап язылырга мөмкин.**

**Журналның бер айга язылу бәясе 50 тиен.**

**ярты елга 3 сум, бер елга 6 сум.**

**Журналга илебезнең теләсә кайсы почта бүлегендә язылырга мөмкин. Аның өчен 73 210 номерлы индексны әйтү дә җитә.**

# ЯЗЛАР, ЯЗЛАР...

**АРСЛАН БАТЫРШИН музыкасы** — **ЗӘКИ НУРИ сүзләре**

*Хатын-кызлар хоры*
*а капелла өчен*
*Разия Яруллина эшләнешендә*




Сез шундыйлар инде, язлар, язлар,
Сез шундыйлар безгә кирәкләр!
Кангылдашып килә киек казлар,
Давылланып тибә йөрәкләр.
Давылланып тибә йөрәкләр.

Бөтен якка җитез җырлар оча,
Шаулый-шаулый ташкын ашкына.
Мондый чакта җырлар җырламыйча
Түзсә түзәр бары таш кына.
Түзсә түзәр бары таш кына.

Теләгем бар, дуслар, аны кирәк
Йөрәкләргә уеп язарга:
Типсен инде җирдә барча йөрәк
Гашыйк булып җырлы язларга!
Гашыйк булып җырлы язларга!

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210